PISA (“уку грамоталылыгы”) халыкара тикшеренүләре нәтиҗәләре буенча, бүгенге балалар нәрсә укыганын аңламый. Материалны укыганнан соң, укучы нәтиҗәләр ясарга һәм мәгълүматны файдалана алырга тиеш. Моның өчен текстны аңларга, сүзнең ни хакта барганына төшенергә кирәк.Россия үсмерләренә исә текстны анализлау түгел, аңлау да авырдан бирелә. Балаларның 70 проценты укылган материалның бер өлешен булса да охшаш тормыш шартларында куллана алган. Шуларның бары тик 14 проценты гына дәреслек буенча үзлектән шөгыльләнә ала икән.

Гомуми белем бирү системасында функциональ грамоталылыкны формалаштыру өстенлекле максатларның берсе булып тора. Функциональ грамоталылык – тормыш бурычларын хәл итү өчен, кешенең гомер дәвамында алган белемнәрен эшчәнлекнең төрле даирәләрендә, аралашуда һәм социаль мөнәсәбәтләрдә куллана белү сәләте ул.

Белгәнебезчә, функциональ грамоталылык күпкырлы төшенчә. Ул уку грамоталылыгын, математик грамоталылыкны, табигый-фәнни грамоталылыкны, финанс грамоталылыгын, глобаль компетенцияләр, креатив фикерләүне үз эченә ала.

Шуларның берсенә – тел һәм әдәбият дәресләренең нигезен тәшкил иткән - уку грамоталылыгына тирәнрәк тукталасым килә.

Бүгенге цифрлаштыру гасырында укучыларда уку грамоталылыгын үстерү аеруча әһәмияткә ия дип уйлыйм. Белем бирүнең нинди генә предмет өлкәсен алсак та, беренче чиратта, аңлап уку, укылган тексттан кирәкле мәгълүматны аера белү сәләте кирәк. Укучы текстны аңлап укыган очракта гына,көтелгән нәтиҗәгә ирешеп була. Әдәби әсәр яки текст белән танышуны нәтиҗәле

(продуктив) уку технологиясе буенча алып барам. Бу технология нигезендә текст белән эшләүне 3 этапта оештырам.

**Беренчесе –** укучыларны әсәрне кабул итәргә әзерләү,укучыларда теләк, мотивация булдыру.

Әсәрне укыр алдыннан иң элек укучыларның игътибарынәсәрнең язылган елына,автор яшәгән чорга юнәлтәм, тарихи чор турында әңгәмә оештырам (матапредмет нәтиҗә).

- Тактага текстның асылын ачыклый торган әйтем/ цитата/ афоризм язып, текст нәрсә турында булыр икәнен чамалау алымын да кулланырга була.

– Әсәрнең исеменә игътибар итү, «Ни өчен әсәр шулай дип аталган?» соравына җавап эзләү, темасын билгеләү; туган ассоциацияләр турында сөйләшү;

Мәсәлән, 6 сыйныф укучылары белән Ә.Еникинең “Матурлык” хикәясен укырга әзерләнү. Әсәрнең исеменә игътибар юнәлтү. Ничек атала? Сез «матурлык» дигән төшенчәне ничек күзаллыйсыз? (*укучылар җаваплары:табигать матурлыгы, кешенең матурлыгы, кешенең күңел матурлыгы, тирә - юнь матурлыгы һ. б)*

Җавапларны тыңлаганнан соң, “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ннән “Матурлык” сүзенә бирелгән бирелгән аңлатманы укыйбыз:” Матурлык – гүзәл, күңелгә рәхәтлек бирә торган нәрсә, яки ягымлы, сөйкемле, үзенә җәлеп итә торган тышкы кыяфәт; кеше характерындагы, эшчәнлегендәге хуплана торган сыйфат”. Халык мәкальләреннән матурлыкның чын мәгънәсенә төшендерә торганмисаллар алабыз*:* Матурлык - күлмәк белән сәдәфтә түгел, оят белән әдәптә.

**Икенче этапта - текстны аңлап укуларына ирешүне тәэмин итү.**

Әсәрне уку вакытында автор белән, андагы геройлар белән бәхәскә, диалогка керергә мөмкин, сүзлек эше алып барырга яисә алда нәрсә көтеләчәген укучыларның үзләреннән сорарга,фаразлатырга мөмкин. Аңлашылмаган сүзләргә, фразеологик әйтелмәләргә аңлатма бирә барырга, таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен контексттан аңларга тырышырга, төрле таблицаларны тутыра барырга да мөмкин.

**Өченче этап ул** - текстны укып чыкканнан соң,укучыларның белемнәрен тикшерү,әсәрне ничек итеп аңлауларын тикшерү.Әсәр кем исеменнән сөйләнә? Ә.Еники үзенең бу әсәрендә «Матурлык» темасын ничек итеп ача? Автор матурлыкны нинди мәсьәләләр аша күтәрә? *(Әсәр матурлык турында. Кешенең эчке матурлыгы. Бәдретдиннең күңел матурлыгы. Ана белән бала мәхәббәтенең матурлыгы. Гаилә мөнәсәбәтләренең матурлыгы. Табигать матурлыгы турында).*

Төркемнәргә бүлеп, эш бирергә була:

1 төркем - Бәдретдиннең күңел матурлыгы( Бәрдертдин нинди герой? аның күңел матурлыгы нинди эш-гамәлләрдә күренә?);

2 төркем –Ана белән бала мәхәббәтенең матурлыгы; (Бәдретдиннең әнисенә мөнәсәбәте ничек? Ул иптәшләренә әнисен күрсәтергә ояламы? Ни өчен?);

3 төркем – табигать матурлыгы(тургай образына бәйләп, әйләнә- тирә, биология буенча белемнәрне искә төшерү –метапредмет нәтиҗә).

Хикәядә нинди вакыйгалар сурәтләнә? (*Берсе табигать күренеше, икенчесе Бәдретдин өендәге вакыйга)*

Хикәядә күренеп торган конфликт, ягъни каршылыкны таптыру (*Ямьсезлек - матурлык каршылыгы).*

-Шушы матурлыкка нәрсә каршы куела?*(Бәдретдиннең өе һәм өй эчендә герой-шәкерт күргәннәре. Ләкинберенчекүргәндәямьсез, чирканчыкбулыптоелганямьсезлек тора-бара матурлыккаәйләнә бара. Лирик герой-шәкертбаштааптырый, аннансоңгаҗәпләнә, буматурлыккасоклана).*

Хикәянең сюжетына игътибар иттерик. Вакыйгалар үстерелешен, кульминацион ноктасын, чишелешне билгеләү.

Әнисенең матурлыгы нидә соң? *(Бәдретдиндә. Улы тәртипле, инсафлы.Улы- аның горурлыгы, дәвамчысы.)*

Әсәрне йомгаклап, идеясен билгеләү, әсәрнең теле турында сөйләшү. Әсәрнеңәһәмиятен татар әдәбиятында тоткан урынын билгеләү, рус әдәбиятындагы әсәрләр белән чагыштыру.

Әлбәттә,тикшерүнең дә бик күп юллары бар.Мәсәлән, тест уздыру, бер – берәңә сорау бирү һ.б.

– төп сүзләрне аерып алу һәм язып кую;

– тексттан ачыктан-ачык бирелгән мәгълүматны яки фактларны таба белү, аларны тормыштан алынган мисаллар белән ныгыту;

– текстны кисәкләргә бүлү, планын төзү;

– тексттан төп вакыйгаларны аерып ала белү;

– тәкъдим ителгән рәсем һәм иллюстрацияләрнең текстның кайсы өлешен ачу өчен кулланылуын әйтү;

– текст нигезендә зур булмаган монологик яки диалогик сөйләм төзү;

- текстны төп герой исеменнән телдән /язмача сөйләтү;

-тексткаяңаисемуйлап табу.

– укылган текст эчтәлеге буенча дискуссияләр, дебатлар оештыру һ.б.

Критик фикерләү технологиясе элементларын куллану да укучыларда уку грамоталылыгын формалаштыруның өстенлекле бер алымы булып тора. Фикерләү күнекмәсе укучыларга уку дәверендә генә түгел, алдагы тормышларында кирәк булачак (килеп туган мәсьәләне дөрес чишү юлларын табу, күпсанлы мәгълүмат белән эшләү, анализлау).

Критик фикерләү технлогиясе кысаларында түбәндәге алымнарны кулланырга була:

– «Тукталышлар белән уку» алымы. Дәрес башында укучыларга текст исеменнән чыгып сорау куела, укучыларның фикерләре тыңланыла. Төп өлешендә текст фрагментларга бүленеп укыла, һәр өзектән соң укучылардан алга таба ни булачагы турында җаваплар тыңланыла;

– «Сораулык белән эш» алымы. Әлеге алымны дәреслек белән эш вакытында кулланырга була. Укытучы укучыларга сораулар тәкъдим итә.

Сораулар туры җавап бирерлек итеп тә, уйлану-фикерләүне таләп итәрлек итеп тә куела;

– «Беләм, белдем, белергә телим» алымы. Бу алымны яңа материалны аңлату һәм алынган материалны ныгыту этабында да кулланырга мөмкин. Өч графадан торган таблица бирелә, укучылар үз фикерләрен, җавапларын язалар;-

Фаразлау алымы. Ул булачак вакыйгага үз фаразларыңны белдерү. Бирелгән әсәр атамасын ачыклау максатыннан: «Бу әсәр нәрсә турында булыр?» — дигән сорау куела. Яки әсәрнең бер өлеше укылганнан соң, ”Укучылар, вакыйгалар ничек үстерелер? – дип сорап була. Кайбер әсәрләрдә, фильмнарда “ачык финал” алымы кулланыла. Монда да укучылар финалны төрлечә фаразларга мөмкин. Бу алым уйлау, күзаллау сәләтен арттырырга, үзеңнең фаразларыңны дәлилләргә өйрәнергә ярдәм итә.

– «Почмаклар» алымы. Әсәр геройларына характеристика биргәндә кулланырга ярый. Сыйныф ике төркемгә бүленә. Беренче төркемдәге укучылар, текст эчтәлегеннән һәм тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, геройның уңай сыйфатларына дәлилләр әзерлиләр. Икенче төркем исә, цитаталарга таянып, геройның тискәре сыйфатларын ачыклый;

– «Иҗади эш язу» алымы. Бу алымны өйрәнелгән теманы ныгыту этабында куллану уңай. Укучыларга яки әсәрне дәвам итәргә, яки үзгәртеп язарга, яисә үзләренә әкият, хикәя, шигырь язарга тәкъдим итәргә була. Әлбәттә, мондый эш биргәндә укучыларның сәләтен күз уңында тотарга кирәк.

Гомумән алганда, укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру максатында кулланыла торган алымнар бихисап.  Алардан уңышлы файдалану – һәр заман укытучысының изге бурычы.

**Әдәбият**

1.Вопросы формирования и оценивания функциональной грамотности средствами учебых предметов. : учеб.-метод. пособие / Е. С. Баранова [и др.]; под ред. И. Е. Барыкиной, Е. В. Иваньшиной. – Санкт Петербург: ГАОУ ДПО «ЛОИРО», 2021. – 230 с.

2.Читательская грамотность.5-9кл. Книга для учителя. Под редакцией Добротина. Российский учебник. Институт стратегии развития образования. https://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_2941962.pdf

# УКЫТУ ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНЫП РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАСЫ УКУЧЫЛАРЫН ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮ

***Гайнетдинова Г.И.***
***МБОУ«Гимназия №21» Приволжского района г.Казани***
***guzel_g_i@mail.ru***

***Аннотация.*** Обучение татарскому языку учащихся основной общеобразовательной организации на русском языке с использованием технологии развивающего обучения. Учебный процесс в системе образования

***Ключевые слова:*** учебный процесс, УМК, ФГОС

Бүгенге мәгариф системасында уку-укыту процессы яңа Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандартлары нигезендә оештырыла. Белем бирүнең төп эчтәлеген шәхес үсешен тәэмин итә торган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы, акыл эшчәнлегенең, дөньяга карашның җайлашкан системасы дип аңлатырга була.

Программалар, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре – УМКлар – телгә өйрәтүнең технологиясен үз эченә алган һәм уку-укыту барышын оештыру өчен кирәкле уңай шартлар булдыра торган фәнни-методик ярдәмлекләр.

Фәнне укыту өйрәтүнең эчтәлеге укыту программасы белән билгеләнә, ул исә Стандарт нигезендә һәм өйрәнелә торган фән буенча белем һәм күнекмәләргә таләпләр минимумына таянып төзелергә тиеш. Шулай итеп, татар телен чит тел буларак өйрәтүнең иң отышлы юлларын табу укыту предметы эчтәлегенең төп мәсьәләләреннән берсе булып тора [Харисов, 2015: 164].

Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандарты һәм аның нигезендә төзелгән программа – гомуми белем бирү оешмаларында уку-укыту процессын оештыру өчен төп документларның берсе. Дәреслек укытучы белән укучыларның тел өйрәнү юнәлешендәге барлык эш-гамәлләренең эчтәлеген билгели. Рус һәм милли телләрне укытуда Стандарт бертөрле булганлыктан, татар һәм рус телләре буенча программа һәм дәреслекләрнең үзара бәйләнештә булуы мөһим, чөнки белем бирү процессында бу телләрнең хас булган охшаш һәм аермалы якларга игътибар бирергә кирәк.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – системалы-эшчәнлекле (системно-деятельностный подход) юнәлеш, ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән татар теле укыту системасына да карый. Ягъни программалар, укыту-методик комплектлары, укыту процессы, белем дәрәҗәсенә контроль, идарә итү, белем күтәрү һ.б. – бар да бер максатка – нәтиҗәгә хезмәт итә.

Укытучылар эш программаларына белем бирү оешмасының эш үзенчәлеген, укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку

материалын өйрәнүгә сәгатьләр саны бүленешен һәм материалны өйрәнү эзлеклелеген билгеләүдә, эчтәлекне киңәйтүдә, шулай ук укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру юлларын ачыклауда үзгәрешләр кертә алалар. Бу үзгәрешләр эш программаларының аңлатма язуында чагылыш табарга тиеш.

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының V сыйныф укучыларына ана теленнән белем бирүнең төп максаты – Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә укучыларда аралашу, лингвистик һәм этнокультура өлкәләренә караган компетенцияләрне булдыру.

Ана теленә өйрәтүнең эчтәлеге шуңа яраклаштырылып төзелә, шул вакытта югарыда саналган компетенцияләр формалаша һәм үстерелә.

Программа Федераль Дәүләт стандартларының методологик нигезе булган системалы-эшчәнлекле юнәлешкә туры килә торган коммуникатив технологияне төп укыту ысулы буларак билгели.

Коммуникатив технология нигезендә укыту процессын оештыру өчен, бу технология билгеләгән максатларга һәм принципларга туры килгән программа эчтәлеген сайлау таләп ителә. Димәк, коммуникатив технология нигезендә укыту принципларнын ачыклау – программа эчтәлеген сайлау өчен төп критерийлар, норматив база булып тора.

Атаклы психологлар А.Н.Леонтьев, П.Я.Гальперин хезмәтләре күрсәтүенчә, белемнәрне үзләштерү аларны нинди дә булса эшчәнлектә куллану аша бара. Башта белемнәр суммасы булдырып, аннан соң аны практикада кулланырга мөмкин дип уйлау хәзерге дидактик таләпләргә җавап бирми. Сөйләмгә өйрәтү процессы башта аерым сүзләр, грамматик категорияләр өйрәнеп, аннан шулар нигезендә сөйләм оештыру аша барса, бу бик әйләнгеч, нәтиҗәсез юл булыр иде. Коммуникатив технология нигезендә эчтәлек сайлау стратегиясе һәм тактикасы түбәндәгедән гыйбарәт була: башта балаларның яшь үзенчәлегенә карап, аларның аралашу сфералары, аралашу ситуацияләре ачыклана, аннан соң ул сфераларда сөйләшүне оештыра алырлык лингвистик материал сайлана.

Сайлап алынган лингвистик материал филологик формада таныштыргач, аны төрле аралашу сфераларындагы социаль контактларда, аралашу ситуацияләрендә, текстлар эчтәлеген сөйләүдә куллану камилләштерелә. Өйрәнелгән грамматик материал максатчан рәвештә төрле жанрдагы текстлар эчтәлегендә кулланылып, укучыларның сөйләшә алулары камилләштерелә.

Югарыда әйтелгәннәрне искә алып сайланган материал мәктәптә телгә өйрәтү шартларын телне тормышта куллану шартларына якынлаштыру мөмкинлеген тудыра.

Россия Федерациясенең мәгарифне үстерү доктринасында күрсәтелгәнчә, хәзерге заман белем бирү системасы үсешенең төп юнәлеше – укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру.

Белем алу процессын укучыларның актив фикерләвенә нигезләп оештыру психология һәм педагогика фәннәренең алдынгы вәкилләре куйган төп

таләпләрнең берсе. Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнү өчен күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүр. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуы тәэмин ителә. Шуңа күрә программада һәр сыйныфта аралашу өчен коммуникатив максатлар, өлкән сыйныфларда аралашу проблемалары күрсәтелеп барды. Лингвистик материал һәм сөйләм үрнәкләре программада нәкъ менә коммуникатив максаттан, аралашу проблемаларыннан чыгып билгеләнде.

Коммуникатив методикага беренче нигез салучылардан булган Э.П. Шубин мәктәптә чит телне өйрәтү процессында грамматик материалны академик грамматика эзлеклелегендә һәм тирәнлегендә өйрәнүне мәҗбүр итеп куймый. Функциональ принцип нигезендә программага грамматик материал түбәндәге таләпләр буенча сайлана: грамматик материал коммуникатив максаттан, аралашу хаҗәтеннән һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнә; грамматик материалның өйрәнелү тәртибе академик бирелештә түгел, аралашу хаҗәтеннән һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнә; грамматик материалның күләме, теоретик авырлыгы укучыларның үзләштерү мөмкинлекләрен исәпкә ала; грамматика, тел берәмлеге буларак түгел, ә сөйләм берәмлеге буларак өйрәнелә; иң беренче чиратта, грамматик категориянең формасына түгел, ә аның функциясенә игътибар ителә: хәбәр итү, аңлату, сорау, тәкъдим итү, киңәш бирү, ышандыру һ.б.

Башлангыч этап өчен грамматик материал күрсәтелгән критерийларга таянып сайланды. Берникадәр грамматик материал теоретик формада бирелмичә, ә лексик-грамматик төзелмәләр формасында тәкъдим ителде. Аларны үзләштерү сөйләм ситуцияләре нигезендә оештырыла. Ә җиңелрәк дип саналган грамматик материал филологик формада, кагыйдәләр нигезендә өйрәнелә бара. Ләкин кагыйдәләрне ятлау мәҗбүр түгел, ә лексик-грамматик материалны күбрәк аралашуда имитацияләүгә игътибар ителә.

Икенче телне өйрәнү вакытында бала, ихтыярсыз рәвештә, лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу – телне үзләштерү процессын җиңеләйтә. Димәк, һәр сыйныфка программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур. Яңа грамматик кагыйдәләр бары тик ана телендә өйрәнелгәннән соң гына кертелә бара, ә дәреслекләрдә грамматик кагыйдәләрнең рус һәм татар телләрендә бирелүе укучыларның белем сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора.

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятkә карата ихтирам хисе

уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Урта белем бирү баскычында татар теле укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (танып белү, регулятив, коммуникатив) формалаштыруга хезмәт итә.

Татар теле укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (танып белү, регулятив, коммуникатив) формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни, төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә; укучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

Программаны нәтиҗәле итеп гамәлгә ашырырга ярдәм итә торган төп чара – дәреслек. Дәреслекнең төп максаты – укучыларга белем бирү, татар телен үзләштерүне җиңеләйтү, телне аралашу коралы буларак көндәлек тормышта кулланырга өйрәтү. Дәреслек – мәгълүмат алу чарасы гына түгел, аралашырга өйрәнү өчен кирәк булган сүзлек минимумы, үрнәк фразалар, җөмләләр, сөйләм үрнәкләре дә.

Федераль дәүләт белем бирү стандартының мәктәп алдына куйган иң мөһим бурычларының берсе мондый: мәктәпне тәмамлаганда, укучы «үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш». Бу яңа стандартта «эшлекле белем бирү» дип атала һәм ул стандартның нигезе булып тора. Димәк, традицион дәресләрдән аермалы буларак, укытучы, әзер материалны бирүче түгел, ә белем алуны оештыручы булырга, укучыны үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрергә тиеш. Укытучының төп максаты: укыту-тәрбия бирү процессында укучының белемгә сәләтен ачу, универсаль уку гамәлләре формалаштыру, рухи яктан камил, иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашырырга сәләтле, гомумкешелек кыйммәтләренә уңай карашлы шәхес тәрбияләү.

Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, Татарстанның территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча күренекле шәхесләр турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

Яңа программалар, укыту-методик әдәбият, рус телендә сөйләшүче укучылар өчен татар теленнән кулланмалар, рус телендә белем бирү оешмаларында татар телен укыту методикасын эшләү каралган. Хәзерге

шартларда рус-татар икетеллеге асылда башка нигезгә таяна, ул икетелле тирәлек тудыра. Анда татар теле үсеп һәм баеп кына калмый, бәлки рус халкының аны белүгә ихтыяҗы да арта.

Чит тел буларак татар телен үзләштерү процессында иң мөһиме булып, беренчедән, сөйләм булдыру закончанлыкларын саклау, ягъни өйрәнелә торган телдә сөйләмнең ике (телдән һәм язма) формасын да үзләштерүгә ярдәм итүче гомуми нигезләмәләргә таянып, эчке һәм тышкы сөйләм бәрәмлеге исәпкә алынган фикерләү белән әлеге эшчәнлек бәйләнеше; икенчедән, бәйләнешле сөйләмнең белем һәм күнекмәләрен формалаштыру закончалыкларын исәпкә алу (ул үзенә хәтернең ике - кыска вакытлы һәм озак вакытлы төрен, тел һәм сөйләм материалларын ирекле һәм ирексездән истә калдыруны, кызыксынуны, ихтыярны һәм игътибарны һ.б. ала) тора.

Укыту, белем бирү – катлаулы процесс. Укытучының максаты – белемле, тәрбияле, иҗади шәхес тәрбияләү. Укучының максаты биргән белемне үзләштерү. Бу үзенчәлекле процесс укытучы һәм укучының бердәм эшчәнлеге. Бердәм эшчәнлекнең актив булган чагына гына куелган максатларга ирешергә мөмкин.

## Әдәбият

1. Об образовании в Российской Федерации [Электронный ресурс]: федер. закон от 29 декабря 2012 г.№ 273-ФЗ: (в ред. от 31 декабря2014с изм. от 06.04.2015 г. «Об образовании в Российской Федерации» (с изм. и доп., вступ. в силу с 31.03.2015) //consultant.ru: КонсультантПлюс: справ. правовая система.URL: http://www.consultant.ru/document/cons_doc_LAW_173649 (дата обращения: 2.12.2023).

2. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы (татар балалары өчен). [Ф.Ф.Харисов һ.б.]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – С. 5-52.

3. Агапова Н.В. Перспективы развития новых технологий обучения. – М.: ТК Велби, 2005 – 247 с.

4. Ладыженская Т.М. Проблемы использования Интернет-технологий для формирования коммуникативной компетенции на уроках русского языка // Материалы второй Международной научно-практической конференции «Полатовские чтения – 2009: Дистанционное обучение в предметных областях». – Казань: ЮНИВЕРСУМ, 2011. - 432 с.

# ПЕРСОНАЛИЗАЦИЯ ОБУЧЕНИЯ В ФИЛЬМЕ «MUCIZE».

***Гайнутдинова А.С.***
***Казанский федеральный университет***
ASGajnutdinova@kpfu.ru

***Аннотация.*** В образование у всех бывают сложности в освоения материала, однако некоторые, несмотря на все сложности, преуспевают больше остальных. Примеры данной действительности настолько поражают людей, что их истории экранизируют, предоставляя остальным стимул в изучении.

***Ключевые слова:*** образование, персонализация, обучение, преподавание, учитель.

В 2015 году в Турции экранизировали история Азиза и его учителя. Школьного учителя Махира Йылмаза, который в 1960-х годах жил в приморском городе Турции, перевели в отдаленную деревню. Ему пришлось уехать вопреки желанию жены и двух дочерей. Ему пришлось совершить очень долгое путешествие на автобусе, который останавливается задолго до места назначения, которое находится в двух горах от деревни, поскольку правительство не проложило дорогу дальше. После прогулки по горам он добрался до деревни, которая, скорее всего, была поселением, чем деревней. Жители деревни подкрадываются к нему с оружием, и когда они узнают его личность, они дадут ему понять, что у них в деревне нет школы. Дети деревни навсегда обречены на неграмотность, поскольку учитель думает, что он не справляется с этой задачей. «Мы живем по воле Божьей в течение восьми месяцев (когда идет снег) и по милости правительства остальные четыре месяца.» [2] Эти слова деревенского старейшины подводят итог суровой реальности их общинной жизни. Но учитель берет на себя задачу привести к ним школу правительственным путем и терпит неудачу. Глава деревни, которого уже нравился учитель, грустит, видя, что он уходит, поскольку правительство не собирается открывать школу. По прошествии ночи учитель придумывает план строительства школы. Он звонит к себе домой и просит денег, говоря, что его похитили бандиты. После получения денег школа была построена с помощью жителей деревни и горных бандитов. Тем временем история начинает показывать нам жизнь деревни. Молодежь в общине женится один за другим на невесте, выбранной старейшинами. Ритуал выбора невесты довольно забавный. Старшие женщины деревни идут на отбор, выслушав пожелания и требования, подходящих женихов, и кого бы они ни выбрали, задав невесте вопросы о Коране, приготовлении пищи и проверке дыхания, жених должен взять в жены. Двое сыновей вождя женятся, но старший сын Азиз - инвалид, предположительно, страдающий какой-то умственной отсталостью. Деревенские жители и дети издеваются и насмехаются над ним. Учитель спасает его, принимая его в недавно открытую школу, где все дети деревни начали учиться в одной комнате, и фактически учит его писать. Никто не считал Азиза подходящим для брака, но внезапно Глава деревни спасает

жизнь человека за пределами суда в городе. Мужчина из чувства благодарности дает обещание отцу жениха выдать свою дочь Мизгин замуж за Азиза. После свадьбы жизнь становится трудной для Мизгин и Азиза, поскольку сообщество считает, что они неподходящая пара. После нескольких оскорбительных высказываний и поведения жителей деревни Азиз и Мизгин убегают, оставив прощальное письмо семье, написанное Азизом. Несколько дней спустя учитель также возвращается в свой город. 7 лет спустя учитель возвращается в деревню с Азизом, который больше не инвалид после лечения от мышечной дистрофии, Мизгином и их двумя детьми. [3]

В данной история Азиза четко выражена влияние авторитета учителя на его судьбоносную смену образа жизни. Первоочередной методикой в сфере образование был, контактный диалог, учитель позвал Азиза на занятия и в отличие от местных жителей он проявлял к нему особый интерес и уважение. Дальнейшей шагом в контакте было, то он сурово относя к детям, которые над ним насмехаясь, вели себе неподобающим образом. На данное поведение детей учитель мягко и в тоже время сурово выругал, а также предупредил о том, что если подобное продолжиться, то он не будет и с ними заниматься. Естественно последний факт был эффективным, так как дети очень стремились получить начальное образование. В дальнейшем не выявлялось подобное поведение со стороны учеников. Более того следующий шаг уже было сделано Азизом в сторону школы, где учитель занимался с ним как персонально, так и с другими учениками вместе. [1] Таким образом, Махир Йылмаз в своем преподавательской методике использовал в основном персонализированный подход в обучении. Кроме того эффективность данной методики заключалось еще и в том, что его видели через призму авторитета, которую он приобрел своими поступками и нравственными качествами.

**Литература**

1. Mehmet Açar. 'Mucize'nin sırrı öğretmende// URL: https://www.haberturk.com/yazarlar/mehmet-acar/1025633-mucizenin-sirri-ogretmende (дата обращения 10.01.2023)

2. ‘Mucize’ breaks best box-office opening record of the season // URL: https://translated.turbopages.org/proxy_u/en-ru.ru.a18919c0-63e690c9-cc216a51-74722d776562/https/www.dailysabah.com/cinema/2015/01/06/mucize-breaks-best-boxoffice-opening-record-of-the-season (дата обращения 10.01.2023)

3. Mashun kirmizigül filmindeki Aziz ile gerçek aziz’i biraraya getirdi ve sinemaya götürdü. // URL: https://www.magazinci.com/icerikler/sinema/mashun-kirmizigul-filmindeki-aziz-ile-gercek-azizii-biraraya-getirdi-ve-sinemaya-goturdu_47165.html (дата обращения 10.01.2023)

# ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ НИКАХ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ИР-АТ ҖЕНЕСЕНДӘГЕ ТУГАНЛЫК АТАМАЛАРЫ

***Гайсина Д.Р.***
***Казан федераль университеты***
***dilyrzamaletdinova@kpfu.ru***

***Аннотация.*** Родство определяет общественные отношения, определяет место человека в обществе и корректирует его поведение. Более того, термины родства и свойства отображают своеобразие языка, специфику национального пути, характеризуют национальный менталитет. Терминология родства является одним из древнейших лексических пластов и по сложности своей истории занимает особое положение в основном лексическом составе языка. Данная статья посвящена изучению турецкой терминологии родства по браку.

***Ключевые слова:*** родство, брак, турецкий язык.

Төрек теленең гасырлар дәвамында сакланып килгән үз лексикасы бар һәм ул, алынмалар белән чагыштырганда, күпчелекне тәшкил итә. Бу төр лексикага туганлык атамалары карый. Туганлык атамаларының мәгънә үзенчәлекләрен, алар белән бәйле гореф-гадәтләрне өйрәнү борынгы тормыш-көнкүрешне күзалларга, халык тарихында булып үткән төрле вакыйгаларны ачыкларга ярдәм итә.

Туганлык атамалары – төгәл системалардан торган, чынбарлыкны чагылдыручы төп чара. Туганлык атамалары ярдәмендә реаль кешегә бәйле берәмлекләр, мәгънә төрләре формалаша. Күренекле тюрколог Д.Б.Рамазанова туганлык атамаларын 2 төркемгә – кан кардәшлеге һәм никах кардәшлеге белән бәйле атамаларга бүлеп карый [1]. Әлеге мәкаләдә без төрек телендә никах кардәшлегенә бәйле ир-ат атамаларының үзенчәлекләренә тукталырбыз.

Төрек телендә никах кардәшлеге белән бәйле түбәндәге туганлык атамалары теркәлгән: *koca* (ир), *görümce* (каен сеңел), *damat* (кияү, кызның ире), *güvey* (кияү, кызның ире), *enişte* (кияү, апаның, сеңелнең ире), *yenge* (килен, эненең яки абыйның хатыны), *elti* (килен, ирнең энесенең хатыны), *dünür* (кода/кодагый), *bacanak* (баҗай), *baldız* (балдыз). Моннан тыш *kayınpeder* (каената) peder (ата), *kayınvalide* (каенана) valide (ана), *kayınbirader* (каенага, каенэне) birader (ага), *kaynata* (каената) ata (әти), *kaynana* (каенана) ana, anne (әни) сүзләреннән ясалган. Әлеге атамаларнаң барысында да “каен” лексемасы ярдәмендә туганлыкның кан-кардәшлек белән түгел, ә нәкъ никах белән бәйле булуы күрсәтелә [2]. Аларның еш очрый торган кайберләрен карап китик.

**Koca (ир).** Төрек телендә ир лексемасын *koca* сүзе аңлата. Зур төрек-рус сүзлегендә әлеге лексемага түбәндәге аңлатмалар бирелә: 1) ир, хатын ире: kocaya gitmek яки kocaya varmak – кияүгә чыгарга; koca ya vermek – кияүгә бирергә; 2) зур: koca memleket – зур ил; 3) карт, өлкән; 4) бөек, күркәм: koca şair – бөек шагыйрь; 5) баш: koca harfler – баш хәрефләр. Төрек телендәге *koca* атамасы *бөек, зур, олпат кеше, хатын ире* дигәнне аңлата. Бу исә халыкның ир кешегә зур хөрмәт белән, гаилә башлыгы итеп каравы турында сөйли.

**Damat (кияү).** Төрек телендә кияү атамасы *“damat”* буларак тәрҗемә ителә. Бу лексеманың этимологиясе Төркия тарихы белән бәйле. Төркиядә солтаннар заманында damat дип солтанның киявенә әйткәннәр. Әлеге титулны солтан үзе олылап киявенә тапшырган. Бу термин туганлык атамасыннан да бигрәк, титул буларак кабул ителгән. Солтан үзе дә шушы термин белән кызының иренә эндәшкән.

Төрек телендәге әлеге атаманың этимологиясенә килгәндә, ул гарәп теленнән кергән “damm – тулы көчендә” булырга мөмкин. Ягъни *dam+at* тулы көчендәге ир-ат. Солтан нәселе белән туганлашучы ир-егет солтан кызына тиң булырга, көчле, акыллы һәм зирәк булырга тиеш. Бары тик бөтен яктан да килгән шундый кешегә солтан кызын кияүгә биреп, аңа *damat* титулын тапшырган.

Төрек телендә бу атама ялгызлык исеме буларак та кулланыла. Төркиядә малайларга Дамат дип исем кушу бүгенге көндә дә популяр.

Моннан тыш *damat* сүзенең синонимы буларак *güvey* лексемасы кулланыла.

**Kaynata (каената).** Кайната – хатынга (иргә) карата ирнең (хатынның) әтисе. Бу атаманың семантик мәгънәсе бары шушы гына, ягъни чит кешеләргә карата бу лексема кулланылмый.

Әлеге атаманың шулай ук төрле фонетик вариантлары билгеле. Мәсәлән, kayınpeder, kayınbaba. Каен сүзе борынгы төрки телдәге “кан” (никахлашу нәтиҗәсендә барлыкка килгән туганлык) тамырына барып тоташа.

**Enişte (җизни).** Төрек телендәге бу атама татар телендәге кебек ике мәгънәгә ия: 1) ул бертуган апа тиешле кешенең иренә карата әйтелә; 2) башка туган булган өлкәнрәк хатын-кызларның ирләренә карата әйтелә. Атаманың этимологиясенә килгәндә, “enişte” сүзе фарсы телендә enguşt, ягъни бармак, йөзек дигәнне аңлата. Димәк, кыз туган белән өйләнешкән, бармакларына йөзек тагу ярдәмендә туганлашкан кешегә “enişte” дип әйтелә.

**Dönür (кода).** Төрек телендә коданы *dünür* дип атыйлар. Төрекләр бу атаманың мәгънәсен түбәндәгечә шәрехли: өйләнешүчеләрнең берсенең атасы һәм ир туганнарына икенче якның ата-анасы һәм туганнары тарафыннан эндәшә торган туганлык атамасы.

Әлеге сүзнең турыдан-туры тәрҗемәсе – әйләнүче, әйләнеп торучы. Төрек менталитетында туй вакытында кода – ул туйны алып баручы, табынны тотучы, мәҗлесне оештыручы буларак кабул ителгән, ягъни ул бар җиргә дә өлгерүче, “әйләнеп торучы” кеше булган.

**Bacanak (баҗай).** Төрек телендә бертуган кызларның ирләрен *bacanak* дип атыйлар. Төрек диалектларында “baca” сүзе апа яки сеңел дигәнне аңлата. “nak” – иркәләү-кечерәйтү кушымчасы. Ике ир-ат бертуган кызларга өйләнгәннән соң, бер-берсенә bacanak булалар. Шунысы кызык, бүгенге көндә төрекләр әлеге сүзне якын дусларга карата да кулланалар.

Шунысын әйтеп китик: төрек телендә туганлык атамалары лексиканың актив катламын тәшкил итәләр. Тюркологлар моны төрек лингвомәдәниятендә

*гаилә* төшенчәсенә иң якын туганнар гына түгел, ә аралашып, хәл-әхвәл белешеп яшәүче ерак туганнар да кертелү белән бәйлиләр.

**Әдәбият**

1. Рамазанова Д.Б. Атамаларда туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре: монография. – Казан.: Татар. кит.нәшр., 2014. – 287 б.

2. Napolnova Demiriz E. Rusça ve Türkçe: iki dil, iki kültür. – Istanbul: Multilingual, 2009. – 168 s.

3. Әхмәтьянов Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2001. – 272 б.

5. Aksözlük. Available at: http://aksozluk.org/

6. Nişanyan Sözlük. Available at: https://www.nisanyansozluk.com

# УКЫТУЧЫГА Р. ФӘХРЕДДИН САБАКЛАРЫ

***Гайсина Р.С.***
***Алабуга шәһәре, 6 нчы мәктәп***
***gaisina1972@inbox.ru***

***Аннотация.*** Статья описанию функций учителя в воспитании и обучении школьников по известному труду Р.Фахреддина. Даются достаточно подробные комментарии каждой функции, намеченных ученым и делается акцент на актуальность высказываний просветителя прошлого века для учителей современности.

***Ключевые слова:*** школа, образование, воспитание, учитель, учащиеся, функции учителя.

Үсеп килүче яшь буынга акыл-тәрбия бирүдә, аларны актив тормышка сәләтле шәхесләр итеп тәрбияләүдә, гаиләдән кала, икенче урында мәктәп тора. Укытучы, тирән гыйлемле булу өстенә, сабыр, күркәм холыклы, йомшак сүзле, шәфкатьле, таләпчән дә булырга тиеш. Укытучыга,чыннан да, әйтеп бетергесез олы вазыйфа йөкләнгән. Укучыда остазына карарта хөрмәт тәрбияләү, аның казанышларыннан хәбәрдар булуын тәэмин итү – монысы да, нигездә, мөгаллимнәр җаваплылыгында. Элек-электән халкыбыз укытучыны ихтирам иткән, аңа хөрмәт белән караган, аны остаз дип олылаган. Һәр кешенең – эшченең дә, язучының да, галимнең дә, укытучының да укытучысы, остазы булган. Әнә шуңа күрә бөек акыл ияләре дә, тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән каһарманнар да, ачышлары белән дөньяга танылган галимнәр, исемнәре халыклар тарихына алтын хәрефләр белән язылган әдәбият, мәдәният, сәнгать әһелләре дә ирешкән уңышлары турында сүз чыккач, иң беренче чиратта, үзләрен хәреф танырга өйрәткән, зур тормыш юлына чыгарган укытучыларын, остазларын олы хөрмәт һәм ихтирам хисләре белән искә алалар.

Укытучы һөнәрен сайлаган кешегә иң элек табигать биргән сәләт, тирән белем, сабырлык, күркәм холык, һәрвакыт үз-үзеңне башкаларга үрнәк итеп күрсәтә белү сыйфаты хас булырга тиеш.

Укытучы хезмәте элек-электән авыр, күп сабырлык сорый торган һөнәр санала. Риза Фәхреддинең “Әдәбе тәгълим” (“Уку кагыйдәләре”) китабы хезмәтләре саваплы, вазифалары авыр һәм мактаулы булган укытучыларга, белем-тәрбия, укыту мәсьәләләренә багышланган. Ул Казанда 1908 елда икенче басма итеп басылып чыга. Риза Фәхреддин укытучыларга үзләре укыткан һәм тәрбияләгән шәкертләре хакында җавап бирүе җиңел булмавын искәртә. Аның фикеренчә, алтын булачак бер шәкертне туфрак итеп җирдә калдырган укытучы да бар һәм туфрак булачак бер баланы алтын итә белгән укытучы да бар. Шуңа күрә, кешеләргә гыйлем өйрәтүче, дөнья йөзендә үз вазыйфасын намус белән җиренә җиткерүче укытучыдан да файдалы һәм кирәкле кеше юктыр. Укытучы нинди сыйфатларга ия булырга, дәресләрен ничек укытырга, аның вазыйфалары нәрсәләрдән гыйбәрәт булырга тиеш һ.б. шундый гаять әһәмиятле мәсьәләләр бу китапта бик җентекләп аңлатыла. Китап басылганга

гасырдан артык вакыт үтсә дә, күтәрелгән проблемалар бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган.

Р.Фәхреддин укытучыларга йөкләнә торган вазыйфаларны да тәфсилләп яза. Беренче вазыйфа – укытучының холкы-гамәленә бәйле. Ризаэддин Фәхреддин биредә төп канун буларак укытучы иң элек үзенең холкын яхшыртырга, үз холкы һәм гамәле белән шәкертләргә үрнәк булырга тиешлегенә басым ясый һәм шуннан соң гына, укытучы үзенең алдына тезелешеп утырган балаларга гүзәл әхлак турында дәрес бирергә мөмкин икәнен аңлата. Болай булмаганда, шәкертләргә бирелгән үгет-нәсыйхәтләр файдасыз, укытылган дәресләр дә нәтиҗәсез калачак. Чөнки, гадәттә, укучылар укытучының сөйләгән сүзенә түгел, ә гамәленә ияриләр һәм тора-бара бу күренеш укучының көндәлек табигый гадәтенә әйләнеп китә. Менә шуңа күрә дә инде, балалар укытучының "Шулай булыгыз! Болай булмагыз!" дип өйрәтүен түгел, ә үзенең гүзәл холкы һәм яхшы гамәле үрнәгендә тәрбияләвенә мохтаҗ.

Ризаэддин Фәхреддин укытучылар алдына бер бик мөһим һәм җитди таләп куя: әгәр дә син үзеңне укучыларыңннан хөрмәт иттерәсең килә икән, син әүвәл укучыларыңа – барысына да бертигез итеп хөрмәт күрсәт, йомшак итеп, үз итеп, шәфкатьле итеп эндәш, төрле кушаматлар тагудан сак бул! Әгәр син һәрбер укучыга олы шәхес итеп карасаң, аның нәтиҗәсе дә, әлбәттә инде, бик яхшы булачак... Һәр укытучы үз холкының һәм гамәленең тулы чагылышын укыткан шәкертендә күрә ала. Бу хакта Р.Фәхреддин: "Укытучы кулын сузса, шәкерт – аның күләгәседер, яки укытучы – бер китап язучы икән, шәкерте дә – аның язган китап нөсхәседер. Язылган китап нөсхәсен күреп, язучының гыйлем һәм гакылда булган дәрәҗәсен тәкъдир итү мөмкин булган кебек, шәкертен күреп, укытучысының кем икәнен белү дә авыр булмас", – дип, бик гыйбрәтле искәрмә ясый.

Укытучының икенче вазыйфасы итеп, Ризаэддин Фәхреддин гүзәл холыклы булудан тыш, укытучыга белергә тиеш булган белемнәрне белүен һәм укытучылык итәргә кулыннан килүен, булдыклылыгын күрсәтә. Болай булмаганда, укыту һәм тәрбия эшенә һичбер вакытта төзәтеп булмаслык зарар киләчәк.

Укытучының өченче вазыйфасы итеп, Ризаэддин Фәхреддин йомшаклык, ягымлылык, үз-үзен олы итеп тота белү сыйфатларын күрсәтә. Ул укытучыларның иң элек йомшак күңелле, түземле, шәфкатьле һәм мәрхәмәтле булырга тиешлеген, болай булмаганда, укытучылар үзләренең хезмәтләрен тиешенчә үти алмаячакларын аңлата. Укытучы өчен гыйлем белән булдыклылык өстенә, шәфкатьлелек белән мәрхәмәтлелек кебек изге төшенчәләрнең бергә тупланган чагында укыту һәм тәрбия эшенең уңай нәтиҗәләре күренеп тора. Әгәр укытучы күңелендә балаларга карата шәфкатьлелек һәм мәрхәмәтлелек хисләре булмаса, андый кешенең укыту һәм тәрбия эше белән шөгыльләнмәве үзе өчен дә, балалар өчен дә хәерлерәк.

Укытучының дүртенче вазыйфасы итеп, Ризаэддин Фәхреддин, ихласлык, дикъкатьлелек, тырышлык сыйфатларын күрсәтә. Аның фикеренчә,

укытучыларның барлык вазыйфалары аерым бер вакытта үтәлергә һәм укытыр өчен дә махсус вакытлар билгеләнергә тиеш. Дәресләрне үз вакытларыннан күчерү яки чигерү һичбер вакыт ярамый. Укытучының һәр эше үз вакытында башкаруы – дикъкатьле булу билгесе һәм шул нигездә тәрбияләнгән шәкерт тә надан калмаячак.

Ризаэддин Фәхреддин буенча укытучының тагын бер вазыйфасы укучыларны битәрләүдән тыелу һәм тырышлыкның бөеклегеннән гыйбарәт.

Галим фикеренчә, нәсыйхәт, яхшылыкка өндәү, тырышлык һәм теләктәшлек кебек сыйфатлар да укытучы вазыйфасына кирә. Укытучы булган кеше үзенең укучыларына карата аларның ата-аналарына караганда да шәфкатьлерәк һәм мәрхәмәтлерәк булып, аларны яхшылыкка өндәп үгет-нәсыйхәт бирергә тиеш. Нәсыйхәт ул сүз белән генә түгел, ә үзенең гамәлең һәм холкың белән балаларга үрнәк булып торуда да күренә. Шуңа күрә, укытучыларның үзләренең холык һәм гамәлләре үрнәгендә бирелгән шәфкатьле нәсыйхәтләре укучыларның зиһеннәре ачылу һәм холыкларын яхшырту турында китаплар белән дәрес бирүгә караганда файдалырак. Нәсыйхәтләре үтемле һәм күп булган укытучыларның укучылары күп вакытта күркәм холыклы, мөлаем сыйфатлы булган кебек, нәсыйхәт бирүгә игътибарсыз укытучыларның укучылары белемле булсалар да,тәрбиясез булалар. Шуңа күрә, шәкерт остазның күчермә нөсхәсе булганлыктан, укытучы булган кеше иң элек үзенең холкын яхшыртырга һәм аннан соң гына укыткан балаларына теле һәм гамәле белән тырышып нәсыйхәт бирергә тиеш.

Укытучы булган кеше матур һәм дөрес итеп сөйли белергә тиеш. Шул вакытта гына аның сөйләгән сүзләре укучыларга артыгы белән аңлашылыр. Димәк, укытучы даими рәвештә үзенең сөйләү осталыгын камилләштерергә тиеш, шул вакытта гына укучылар да аны зур игътибар һәм хөрмәт белән тыңлаячаклар. Укытучы дәрес вакытында оста сөйләп, укучыларга авыр нәрсәләрне дә җиңел аңлатса, бу дәрес укучыларның күңелләрендә калачак. Укучылар үзләренең укытучыларыннан үрнәк алып, аның кебек тырыш камил булырга, сөйләшкәндә, язганда, укыганда грамматик ялгышлардан сакланырга омтылачаклар.

Укытучының тагын бер вазыйфасы аның язу сәнгатенә оста булуы һәм үзлегеннән иҗат итеп яза белергә тиешлегенә бәйле, чөнки бу сыйфатларга ия булу гыйлем тарту һәм укыту эшендә гаять файдалы. Сүз сөйләү осталыгына һәм яза белүенә карап, укытучының белем дәрәҗәсен белеп була. Укытучы кеше сөйләргә ярамаган сүзне кәгазьгә язарга да тиеш түгел.

Укытучы кешенең һәрвакытта үзе белән хәтер дәфтәре тотып, шунда ишетелгән яки күңелгә килгән сүзләрне язып, беркетеп куеп, соңыннан, җае чыкканда, кирәк булганда аларны урынлы файдалана белүе дә мөһим. Очраганда, әдипләрдән, дин һәм каләм әһелләреннән, китаплардан, журналлардан һәм газеталардан үзе өчен кирәкле мәгълүматларны туплап барып, дәресләрендә уңышлы итеп куллануы укытучының камиллеген тагын да арттырачак.

Укытучы кешенең үз фәнен генә түгел, тарихны, географияне яхшы белүе мөһим, чөнки нинди генә фән укытучысы булса да, ул әлеге белемнәрнең әһәмияте, кайсы гасырда, кайсы илдә барлыкка килүе, бу фәннәрнең остазлары һәм бөек шәхесләре, алар хакында язылган башка китаплар турында үзенең укучыларына тулы мәгълүмат бирергә тиеш. Тарих, географияне тирән белгән укытучы акыллы, дөрес фикерле һәм алдан күрүчән була һәм ул укучыларын да үзе кебек үк тирән карашлы итеп тәрбияли ала.

Укытучының чираттагы вазыйфасы аның, укучы балаларга гыйлем бирүче һәм тәрбияләүче зат буларак, барлык кешеләргә караганда да гадел булырга тиешлегенә бәйле. Чөнки ул каршысына тезелеп утырган һәм нәрсә дөрес, нәрсә ялган икәнлеген аера белмәгән балаларга дөреслекне танырга, гаделлекне таба белергә һәм үзләренә дә гадел булырга өйрәтә.

Ризаэддин Фәхреддин фикеренчә, гыйлем бирү, укыту ысулының төп өлеше даими бер төрле булса, укыту ысулының тармаклары һәм бүлекләре заман, мәгърифәт һәм мәдәният таләп иткәнчә тулылана, камилләшә, үсә бара. Дәрес бирү ысулы һәм тәрбия кагыйдәләре мөселманнар арасында иң бөек, иң кадерле һәм иң мөһим бер фән булып, аны укытырга яраклы булган галимнәр дә иң бөек затлар булып торалар.

Укытучының соңгы, унөченче вазыйфасы итеп, Ризаэддин Фәхреддин мәктәпнең һәм укучыларның хәлен күзәтүне күрсәтә. Аның фикеренчә, укучыларның укуларына һәм тәртип-тәрбияләренә укытучылар җаваплы булган кебек, мәктәпнең эчке хәленә, тәртибенә тиешле дәрәҗәдә күзәтү алып баруга да җаваплы булырга тиеш.

Шул рәвешчә, бөек фикер иясе, галим, мәгърифәтче Р.Фәхреддиннең фикерләре бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый. Үз белемеңне, тәҗрибәңне укучыларыңа җиткерү, аларның ышынычын аклау, укытучы дигән изге сүзгә тап төшермичә хезмәт итүе җиңел түгел. Шуңа күрә балаларны яратып, үзенең бөтен җаны-тәне белән аларга белем һәм тәрбия бирүгә омтылган кешеләр генә чын укытучы була ала. Салкын, ваемсыз, каты күңелле, үз-үзен генә яратучы кешенең укытучы булырга хакы юк.

**Әдәбият**


1. Ибраһимов Н. Балаларга үгет – нәсыйхәт. – Казан: Дом печати, 2001. – 192 б.
2. Казыйханов В. Безгә Ризаэддин Фәхреддин ни өчен кирәк?// Мәйдан.– 2006.– Б. 128
3. Фәхреддин Р. Нәсыйхәт. Әхлак гыйлеменнән. – Казан: Мәгариф, 2005. – 159 б.

# *АКУСТИЧЕСКИЕ ХАРАКТЕРИСТИКИ ЗВУКА [Ə] НА ПРИМЕРЕ СЛОВА «ЧӘЧ» В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ*

***Гайфетдинова Р.М.***
***Казанский федеральный университет***
***g.r.m11@yandex.ru***

***Аннотация.*** В статье рассматриваются акустичские свойства звука [ə] на примере слова «чәч» в татарском языке, где с помощью спектрограммы определяются движение кривых интенсивности и частотности.

***Ключевые слова:*** звук [ə], спектрограмма, акустика, частота, интенсивность, звуковая волна.

Человеческая речь является многосложным процессом, где образуются различные звуки, вызывающие большой интерес изучающих фонетику. Особенно в ходе живой речи, где находят отражение не только свойства той или иной фонемы, а также и национальные характеристики народа. В связи с этим было проведено исследование спектрограмм с акустическими характеристиками татарского звука [ə] в живой речи на примере слова «чәч» с помощью специализированной программы Speech Analyzer [1,2]. Загрузив их в программу получили следующего рода изображения, которое отражено на рисунке №1.



Рис.1

На верхней части рисунка №1 мы можем наблюдать звуковую волну слова «чәч» в разных вариантах, где линиями определены границы звука [ə] [1]. Следующая графа дает информацию про интенсивность и последняя - про частоту произносимого звука. Линии изучаемой фонемы проделывают схожий путь, оставляя идентичные изгибы. В части интенсивности они образуют дугу,

самый пик которых направлен вверх. В первом и в третьем варианте дуга более растянута, в то время как во втором она более уже. Это связано тем что в последнем случае разрыв между начальным и пиком, конечным и пиком больше, чем в остальных двух.




Рис.2

В графе частотности линии не имеют ярко выраженные переходы, в первом и третьем случае она почти прямая, только во втором видны плавные изгибы. Рассматривая значения становится понятным кривые являются восходяще-нисходящими:




Рис.3

Несмотря на то, что рассматриваются спектрограммы одного и того же слова с одинаковым звуковым составом, кривые во всех трех аспектах отличаются друг от друга. На это могут влиять такие факторы как, индивидуальная речевая особенность диктора, ударность-неударность, местоположение слова в предложении и настроение, передаваемое в тексте. В данном случае, во втором варианте слово произноситься с большей силой и является ударным в предложении, а третий - произносится очень быстро, не давая большего значения слову, первый произносится со средним темпом и равномерным ударением.

Представленные выше результаты звука [ә] были получены после согласного [ч]. И исходя из этого можно сказать, что кривые в спектрограмме одного и того же слова «чәч» имеют идентичные очертания, а вот показатели частоты и интенсивности отличаются, что обусловлено экстралингвистическими факторами.

**Литература**


1. Татар әдәбияты үзәге. URL: https://tat.tatkniga.ru/about https://speech-analyzer.software.informer.com/3.0/ (дата обращения: 08.01.2023).

2. Speech Analyzer. URL: https://speech-analyzer.software.informer.com/3.0/ (дата обращения: 07.01.2023).

# ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

**Галимҗанова Р. Ф.**
**Башкортстан, Дүртөйле шәһәре беренче утра мәктәбе**
rufinagalimyanova@mail.ru

***Аннотация.*** В статье рассматриваются возможности применения инновационных технологий при изучении родного (татарского) языка и литературы.

***Ключевые слова:*** педагогическое образование, инновационные технологии.

Бүгенге көндә яңартылган ФДББС шартларында мәгарифне инновацион үстерү юнәлеше төп максат итеп куела. Инновацион белем бирүнең төп бурычлары исә яңа нәтиҗәләргә ирешү, социаль яктан җаваплы, конкурентлыкка сәләтле, инициативалы һәм компетентлы гражданнар тәрбияләүне күзаллый.

Педагогик тәрбия һәм тәҗрибә заманча таләпләр буенча укытуның эчтәлеге үзгәрешкә йөз тота. Әлбәттә, белем бирүнең традицион формалары гына түгел, ә яңа (инновацион) технологияләр дә уңышлы файдаланыла.

Киләчәктә һәрьяктан камил, рухи яктан үсешкән шәхес чынбарлык мохитенендә яшәргә сәләтле булу белән бергә актив эшләү күнекмәләренә дә ия булырга тиеш. Хәзерге шартларда «мәгариф» төшенчәсе киңрәк мәгънә ала бара. Моңа мәктәптә укыту процессында мәгълүмати технологияләрне куллану мөмкинлекләре артуы тәэсир итә. Технологик инновацияләр педагогик метод һәм алымнар эчтәлеген баета, педагогика үсешенә дә йогынты ясый.

Туган (татар) телен инновацион технологияләр белән укыту уку процессын яңача оештырырга ярдәм итә. Ул фәнгә кызыксыну уятырга, танып-белү активлыгын үстерергә, аралашу процессында үзара аңлашырга һәм ярдәмләшү мохите тудырырга, укучыларның иҗади сәләтләрен ачыкларга һәм үстерергә кирәклеген ачып бирә.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр кулланып эшләгәндә тәрбияле, белемле, көндәшлеккә сәләтле укучы тәрбияләү, заман белән бергә атлау, укучыларны кызыксындырырлык яңа технологияләр кулланып эшләү мөмкинлекләре арта.

Туган (татар) теле һәм әдәбиятын сыйфатлы, нәтиҗәле итеп укытканда телебезнең кулланылыш даирәсен киңәйтү, аны үзләштерүне тиешле дәрәҗәгә күтәрү өчен юл ачыла.

Компьютер тормышыбызның бөтен өлкәләренә дә үтеп керде. Шулай ук уку-укыту эшчәнлегендә компьютер технологияләреннән файдалану заман таләбе булып тора. Информацион технологияләр зур тизлек белән үсә. Шуңа күрә ул яшь буынның белемле, иҗади фикерләүче, сәләтле булуын таләп итә.

Белем бирүнең эчтәлеген, методларын, оештыру формаларын сыйфатлы итеп үзгәртү, укучыларның шәхси сәләтләрен, үзенчәлекләрен, танып белү

сәләтен үстерү өчен компьютер технологияләрен куллану бик отышлы.

Мәсәлән, дәрестә мультимедиа чараларын куллану аша дәресләрнең нәтиҗәлелеген күтәрергә була. Чөнки мультимедиа технологияләрен куллану үзе үк укучыда яңалыклар белән кызыксыну теләге уята. Уңай яклары: укучыларның белемнәре формалаштырылып кына калмый, ә сөйләм һәм мультимедиа чаралары белән эшләү күнекмәләре барлыкка килә, шомара бара.

Мультимедиа технологиясенең мөмкинлекләре чиксез күп. Беренчедән, слайд-иллюстрацияләр күрсәтергә, икенчедән, читтән торып онлайн-экскурсияләр үткәрергә, өченчедән, видео дәресләр үткәрергә һәм башка төрле мөмкинлекләр бирә. Татар телендә бирелгән информация укучыларга дәрестә компьютер куллануның күп төрле мөмкинлекләрен бирә. Мисал өчен түбәндәгеләрне әйтеп үтәргә була.

1. Интеренет татар теле грамматикасы һәм татарча әсәрләрнең, әдип һәм язучыларның әдәби басмалары белән таныштыра.
2. Компьютер куллану - тиз һәм нәтиҗәле итеп үткән материалны актуальләштерү дигән сүз.
3. Бу үз чиратында укучыларның белем һәм күнекмәләрен дөрес бәяләргә ярдәм итә.
информации, а также собственные теоретические поиски, можно утверждать, что большинство учащихся во время учебного процесса полагаются не только на одно чувство. Скорее всего, им нужно воспринимать информацию через несколько органов чувств для усвоения материала в полном объеме. Интерактивная тетрадь же, являясь полезным инструментом как для учителей, так и для обучающихся, включает в себя работу со многими органами чувств.

Все вышесказанное дает нам возможность сделать и следующие выводы: интерактивная тетрадь – это мощный конструктивистский инструмент обучения, используемый для повышения организованности обучения, поощрения использования письменной формы в рамках всей учебной программы, индивидуализации обучения учащихся и поощрения стратегий критического мышления и саморефлексии. Ее основная идея заключается в том, что учащиеся используют метапознание для развития собственного восприятия себя как учащихся и используют его для управления своими собственными учебными процессами, что в нынешнее время широко признана лучшей практикой в образовании [Евдокимов: 26].

Интерактивная тетрадь является полезным инструментом, помогающим ученикам лучше организовать свою учебную деятельность. Умение систематизировать информацию также является хорошим навыком для развития у учащихся, планирующих получить более высокий уровень образования, или даже у тех , кто планирует продолжить карьеру, где важна организация данных. Это также помогает обучающимся взять на себя ответственность за свое обучение, поскольку они должны обеспечивать обратную связь и создавать ту или иную форму продукта в результате своего взаимодействия с преподаваемым им материалом. Это также помогает учащимся стать более ответственными за свое обучение, вместо того чтобы просто быть пассивными получателями знаний. Наряду с этим необходимо отметить следующее: благодаря визуальному и непрерывному обновлению работ на интерактивной тетради, мотивация учащихся сохраняется на самом высоком уровне [Гальскова: 163].

Интерактивные тетради помогают учащимся установить реалистичные связи со своим окружением, связывая знания, полученные в результате обучения, со знаниями, которые они только что усвоили, анализируя свои чувства и мысли в этом контексте и приобретая эффективный инструмент обучения, который будет длиться всю их жизнь. Интерактивные тетради также нацелены на то, чтобы создавать людей, способных генерировать независимые и уникальные идеи и свободно их выражать.

Результаты проведенного нами анализа позволяют сделать вывод, что интерактивные тетради могут быть столь же разнообразны, сколь и способности ученика. Они не ограничиваются материалами, которые будут использоваться в течение определенного периода, и проектами, которые были определены и реализованы. Поскольку каждый студент обрабатывает информацию по-разному. Также важно отметить, что интерактивная тетрадь

предназначена для ее непрерывного совершенствования на протяжении всей жизни.

На основании всего вышесказанного мы можем констатировать, что ведение заметок и их рецензирование являются неотъемлемой частью успеха обучающихся. Можно утверждать, что конспектирование не только служит средством запоминания информации, представленной во время урока, но и, по-видимому, улучшает понимание материала учащимися. Таким образом, после создания и организации интерактивных тетрадей важно, чтобы учащиеся использовали содержащуюся в них информацию и взаимодействовали с ней, таким образом, контролируя свое обучение.

**Литература**


1. Воронкова, О.Б. Информационные технологии в образовании: интерактивные методы / О. Б. Воронкова. - Ростов-на-Дону : Феникс, 2010. – 314.
2. Гальскова, Н. Д. Современная методика обучения иностранным языкам: Пособие для учителя / Н.Д. Гальскова. – м. :аркти: глосса, 2000. – 165 с.
3. Гальскова, Н. Д. Теория обучения иностранным языкам. Лингводидактика и методика : учеб. пособие для студ. лингв, ун-тов и фак. ин. яз. высш. пед. учеб. заведений / Н .Д. Гальскова, Н. И. Гез. – 6-е изд., стер. – М .: Издательский центр «Академия», 2009. – 336 с.
4. Евдокимов, В. И. Наглядность и эффективность обучения : Учеб.пособие [для пед. ин-тов] / В. И. Евдокимов; Харьк. гос. пед. ин-т им. Г. С. Сковороды. – Харьков : ХГПИ, 1988. – 85 с.
5. Селевко, Г. К. Современные образовательные технологии: Учебное пособие. – М.: Народное. образование, 1998. – 256 с.
6. Щерба, Л.В. Преподавание иностранных языков в средней школе [Текст]: Общие вопросы методики / Проф. Л. В. Щерба ; Под ред. проф. И. В. Рахманова. - 2-е изд. - Москва : Высш. шк., 1974. - 112 с.

# КОММУНИКАТИВНАЯ СИТУАЦИЯ ПРИ ОБУЧЕНИИ ИНОСТРАННОМУ ЯЗЫКУ

***Гимадиева Э.Н.***
***Казанский федеральный университет***
***gellonsy@mail.ru***

***Аннотация.*** Данная статья посвящена исследованию понятия «коммуникативная ситуация». В рамках данной статьи были проанализированы понятия «общение», рассмотрена модель общения Р. Якобсона, выявлены её компоненты, а также представылены типы коммуникативных ситуаций, которые можно имплементировать в рамках занятий иностранного языка.

***Ключевые слова:*** коммуникативная ситуация, преподавание иностранного языка, ситуативное обучение

Коммуникация в любом своем проявлении является неотъемлемой частью жизни человека. Ежедневно мы сталкиваемся с различными коммуникативными ситуациями, в которых необходимо решить определенные задачи, получить необходимую информацию, выразить свои впечатления, при этом в процессе этого открывая для себя что-то новое. При изучении иностранного языка также является важным развивать коммуникативную компетенцию на таком уровне, чтобы вышеперечисленные функции могли быть успешно реализованы.

Для преподавателя иностранного языка необходимо знать, что есть коммуникация, коммуникативная ситуация, каковы ее функции и компоненты. С это целью мы изучили имеющуюся научно-методическую литературу и выявили основные точки зрения ученых-методистов на эту проблему.

И.А. Сокол полагает, что общение – это межличностное взаимодействие людей при обмене информацией познавательного или аффективно-оценочного характера [Сокол, 2007: 12].

Впервые модель общения была предложена Р. Якобсоном в 1965 году. По Якобсону выделяются следующие компоненты речевого общения: адресант, адресат, сообщение, контекст, код контакт. Следовательно, его речевая модель выглядит следующим образом: «адресант – сообщение – адресат – контекст – контакт – код» [Якобсон, 1975: 198].

Он считал, что данные компоненты соответствуют функциям языка: референтивная (коммуникативная) функция, эмотивная функция, конативная (аппелятивная) функция, фатическая функция, метаязыковая функция, поэтическая функция [Якобсон,1975: 202].

Предполагается, что основное общение происходит на уровне коммуникативной ситуации [Ипполитова, 2008: 139]. Под понятием «коммуникативная ситуация» понимается ограниченный в пространстве и времени целостный, социально осмысленный и принявший определенную форму процесс речевого взаимодействия коммуникантов, обобщенная модель условий и обстоятельств, обусловливающих речевое поведение личности.

Исследователи выделяют три основные составляющие коммуникативной

ситуации – это отправителя информации (адресант), получателя информации (адресат) и сообщение [Иссерс, 2009]; [Ипполитова, 2008]. Также кроме данных компонентов О.С. Иссерс акцентирует внимание на «коде, посредством которого осуществляется сообщение», и на «канале связи» [Иссерс, 2009: 46]. Н.А. Ипполитова кроме основных трёх компонентов, также выделяет такие значимые компоненты как: «цели каждого, сама информация (предмет речи), форма ее преподнесения и условия общения, благодаря которым появляется возможность взаимодействия коммуникантов» [Ипполитова, 2008: 140]. Исходя из этого можно сделать вывод, что феномен «коммуникативная коммуникация» состоит из множества компонентов, но самыми важными компонентами коммуникативной ситуации является отправитель информации (адресант) и получатель информации (адресат).

Вышеупомянутые компоненты являются ситуативными переменными. Изменение одного их них ведёт к изменению коммуникативной ситуации. В реальности количество коммуникативных ситуаций неисчислимо и каждая из данных ситуаций является уникальной.

Рассмотрим основными факторы, которые формируют специфику коммуникативной ситуации:

- цели коммуникантов, преследуемые в ходе коммуникации;
- характер отношений между коммуникантами;
- Например, официальный или неофициальный характер сообщения;
- условия осуществления деятельности (коммуникативное событие).

Коммуникативная ситуация играет значимую роль при обучении иностранным языкам, в особенности при реализации практических целей обучения иностранным языкам, которые состоят в формировании навыков и развитии умений устно-речевого иноязычного общения, прежде всего, создание условий для активного речевого взаимодействия обучающихся и для активизации речемыслительной деятельности. В учебных целях выделяют учебно-коммуникативные (речевые) ситуации.

Современные методисты выделяют несколько типов ситуаций, но на сегодняшний день не существует единой универсальной типологии. Рассмотрим классификацию В.Л. Скалкина. Он выделяет следующие типы учебно-коммуникативных (речевых) ситуаций [Скалкин, 1983]:

- дополняемые (данные ситуации представляют собой дополнение новой информации: завершение описания чего-либо, формулирование вывода, умозаключения);
- проблемные (данные ситуации имеют большую значимость при обучении спонтанной устной речи и способствуют появлению мотивации и потребности высказать свою мысль, выдвинуть гипотезу, предположить);
- воображаемые (воображение является ключевым инструментом в ситуациях данного типа, данный тип ситуаций предполагает дискуссию, отстаивание своей точки зрения);
- ролевые (делают акцент на социальных ролях участников ситуации и ставят перед обучающимися задачу «войти» в образ и определить тему

разговора самостоятельно).

Принимая во внимание вышеизложенное, мы можем сделать вывод, что коммуникативная ситуация – это процесс речевого взаимодействия коммуникантов, состоящий из нескольких компонентов, выполняющий различные функции, имеющий свои цели, условия и свою классификацию. Выше были рассмотрены учебно-коммуникативные ситуации, которые являются наиболее эффективными при обучении иностранным языкам. Имея свою классификацию, учебно-коммуникативные ситуации предлагают различные варианты создания ситуации, используя различные инструменты (воображение, социальные роли), преследуя разные цели (обучение неподготовленной устной речи, формулирование вывода).

## Литература


1. Ипполитова Н.А. Русский язык и культура речи / Учебное пособие/ Н.А. Ипполитова О.Ю. Князева, М.Р. Савова. – М.: ТК Велби, Изд-во Проспект, 2008. – 440 с.
2. Иссерс О.С. Речевое воздействие / Учебное пособие для студентов, обучающихся по специальности «Связи с общественностью»/ О.С. Иссерс. – М.: Флинта: Наука, 2009. – 224 с.
3. Скалкин В.Л. Коммуникативные упражнения на английском языке. / В.Л. Скалкин. – М.: Просвещение, 1983. – 128с.
4. Сокол И.А. Соотношение понятий коммуникации и общения / И.А. Сокол // VII Международная конференция «Личность-слово-социум». – Минск, 2007. – С. 61.
5. Якобсон Р. О. Лингвистика и поэтика / Р.О. Якобсон. Структуализм «за» и «против»: Сборник научных статей. – М.: Прогресс, 1975. – С. 193-230.

# ИНТЕРАКТИВНЫЕ МЕТОДЫ ОБУЧЕНИЯ ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ

***Гимаева Р.С.***
***МБОУ «СОШ №7 г.Лениногорска»***
**rozagimaeva1975@gmail.com**

***Аннотация.*** В статье рассматриваются вопросы применения инновационных педагогических технологий, способствующих развитию личности с активной гражданской позицией, способной осознавать себя и свое место в мире, умеющей ориентироваться в сложных жизненных ситуациях и позитивно решать свои проблемы.

***Ключевые слова:*** Интерактивное обучение, принципы инновационного обучения, критическое мышление

Интерактивное обучение — это практический подход к образованию, основанный на вовлечении учащихся в учебный процесс через социальное взаимодействие.

Одной из основных форм классического преподавания в обычной школе считается лекция, где учитель транслирует информацию, а ученик её получает. Независимые школьные учреждения и прогрессивные преподаватели задействуют интерактивные методы обучения, которые развивают у школьника критическое мышление.

Основа подхода - тщательно продуманная и структурированная деятельность в группах, в процессе которой создаётся увлекательная среда для учеников, где они разбирают новый материал и тренируют практические навыки. Школьники, предварительно ознакомившись с темами, приходят на занятия, заинтересованные предметом изучения. Затем они получают задание создать проект, смоделировать дискуссию в форме ролевой игры или другое активное упражнение, которое вовлекает в интерактивную учебную среду вместе с одноклассниками и преподавателем.

Интерактивное обучение увлекает учеников, развивает навыки критического мышления, которые являются основополагающими для развития аналитического мышления, а также в увлекательной форме учит детей сотрудничать и успешно взаимодействовать в группах.

Главная задача интерактивного обучения - помочь учащимся понять и раскрыть свои способности, а также в определённой степени контролировать процесс получения знаний. Школьники могут сами решать, каким способом они хотят разрабатывать и представлять свои проекты. Это помогает развивать сильные исследовательские навыки.

Интерактивное обучение помогает школьникам максимально вовлечься в работу по получению знаний. Ученик — это не только пассивный слушатель, но и активный участник процесса. Существуют разные методы вовлечения школьников в процесс обучения:

- взаимодействие между преподавателем и учеником;

- работа с аудио и видеоматериалами;
- взаимодействие между одноклассниками;
- практические занятия, исследовательская и проектная работа.

Поначалу ученики могут сопротивляться интерактивным методам обучения. Классические общеобразовательные учреждения имеют мало опыта применения таких методик. Ученики привыкли к традиционным урокам, а с новыми формами взаимодействия им приходится прикладывать больше усилий, что может вызвать противоречия и нежелание участвовать в процессах. Ученику кажется, что преподаватель отказывается от роли учителя. Эти точки соприкосновения с новыми методиками обучения могут стать причиной сопротивления в классе. Поэтому педагогам лучше разъяснить, почему применяется тот или иной метод интерактивного образования и чем он будет полезен.

К интерактивным средствам, используемых при обучении татарскому языку, относятся: творческие задания с учетом возрастных особенностей учащихся; обучающие игры, работа на занятиях с аудио- и видеоматериалами; метод анализа речевой ситуации (кейс-метод); метод мозгового штурма, метод карусели, метод синквейна, метод блиц-опроса, метод цепочки пожеланий, метод икебаны, метод рефлексивной беседы и т.п. Все эти виды работ наиболее эффективны, когда класс делится на подгруппы и работа ведется коллективно. Если при традиционной методике обучения татарскому языку сам учитель является источником знаний, то при интерактивном обучении акцент переносится на деятельность учащихся, которые в ходе коллективного обсуждения заданной ситуации или предложенной темы ищут ответы на поставленные вопросы, принимают совместные решения и готовят устное или письменное речевое высказывание. Только в этом случае мы можем утверждать, что татарский язык как учебный предмет помогает учащимся моделировать те речевые ситуации, в которых они могут оказаться в реальной жизни и будут способны практически использовать язык для коммуникации.

«Положительное, личностное, действенное отношение учащихся к совместной учебной деятельности связано с поиском средств и способов содержательного сотрудничества. Они ищут реальных путей делового взаимодействия друг с другом, оценивают свои и чужие действия с точки зрения их вклада в общий результат, ставят в зависимости от этого промежуточные цели», – подчеркивает Л.К.Гейхман [Гейхман 2003: 5]. Следовательно, современному учителю татарского языка, планируя свой урок, необходимо предусмотреть создание таких условий обучения, которые направлены на достижение конкретных предметных и метапредметных результатов, и учащиеся в дальнейшем смогут применять их в практической деятельности.

Под интерактивным методом обучения понимается такая организация учебных занятий, которая предполагает создание под руководством учителя проблемных ситуаций и активную самостоятельную деятельность учащихся по их разрешению, в результате чего и происходит творческое овладение профессиональными знаниями, навыками, умениями и развитие мыслительных

способностей. Здесь знания передаются им не в готовом виде, а в процессе самостоятельной познавательной деятельности в условиях проблемных ситуаций. Проблемные ситуации, используемые в целях обучения, должны иметь обучающий характер. Например, использование заданий проблемного характера при обучении монологической, диалогической речи в русскоязычных группах. Так при изучении темы «Татарстан», «Казань» или других тем каждый ученик получает карточку с заданием, например:

- Посмотрите на картину.
- Опишите свою республику или город.
- Употребите данные слова и выражения.

При обучении монологической речи возможны проблемные ситуации не только с опорой на картинку, но и на текст. Например, дается задание:

- Подобрать предложения, соответствующие содержанию картинки.
- Прочитать текст и составить рассказ по картинкам к тексту.
- Выбрать какой–либо персонаж, изображенный на картинке и рассказать о нем.
- Рассказать о своей будущей профессии на основе текста.

Можно дать учащимся и такие задания после прочтения текста:

- Разделите текст на смысловые части и озаглавьте их.
- Прочитайте абзац и найдите предложение, в котором описывается природа нашего края.
- Озаглавьте текст по-другому, полнее передав основной его смысл.

Критическое мышление - есть мышление самостоятельное. Когда занятие строится на принципах критического мышления, каждый формулирует свои идеи, оценки и убеждения независимо от остальных. Никто не может думать критически за нас, мы делаем это исключительно для самих себя. Следовательно, мышление может быть критическим только тогда, когда оно носит индивидуальный характер. Технология критического мышления дает ученику повышение эффективности восприятия информации, повышение интереса как к изучаемому материалу, так и к самому процессу обучения, умение критически мыслить, умение ответственно относиться к собственному образованию, умение работать в сотрудничестве с другими.

Уроки татарского языка способствуют развитию критического мышления благодаря разнообразному материалу и интерактивным подходам. Работа по развитию критического мышления в процессе обучения татарскому языку и литературе позволяет формировать у учащихся социально значимые, нравственно-ценностные мотивы поведения, повышать уровень социализации, развивать креативность и рефлексию, воспитывать инициативность, коммуникативность. Человек, обладающий критическим мышлением, отвечает всем требованиям современного общества. Он умеет видеть проблемы и перспективы, ставить четкие задачи, разрабатывать оптимальные пути. Стремясь к улучшению процесса обучения татарскому языку и литературе, провожу занятия с применением компьютерных технологий. Такие занятия пользуются большой популярностью у русскоязычных учащихся.

Разнообразные мультимедийные игры способствуют расширению словарного запаса, знакомят с грамматикой татарского языка, учат понимать речь на слух, правильно писать. Компьютерные программы сочетают в себе цветную графику, видеофильмы, музыку. Использование этих игр позволяет повысить мотивацию и интерес учащихся к предмету. Использую при изучении тем: «Числительные», «Цвета радуги», «Моя будущая профессия», «Глагол в татарском языке» и т.д. Дети с удовольствием работают над этими заданиями. Многие учащиеся делают презентации на различные темы, составляют мини-проекты «Сабантуй», «Театры города Казани», «Мой любимый писатель», «Герои-патриоты», «Казань-город родной» и т.д . Практически по каждой теме выполняются проекты с презентацией в Power Point по татарской литературе. Применение информационно-коммуникационных технологии позволяют эффективно организовать групповую и самостоятельную работу на уроке, способствуют совершенствованию практических умений и навыков учащихся, позволяют индивидуализировать процесс обучения, повышают интерес к урокам татарского языка и литературы, активизируют познавательную деятельность учащихся, развивают творческий потенциал учащихся, позволяют провести современный урок. Совместно с учащимися, были подготовлены презентации по татарской литературе по жизни и творчеству Г. Тукая, М. Джалиля, Ф. Карима, К. Тинчурина, Ф. Яруллина, С. Сайдашева, Г. Ибрагимова и т.д. Используя интернет-технологии, учащиеся сами подготавливают к урокам сообщения, рефераты по творчеству татарских писателей, по своей профессии.

Выполнение проектных заданий позволяет учащимся видеть практическую пользу изучения татарского языка и литературы следствием, что способствует повышению интереса и мотивации к изучению данного предмета. Значительно активизируется деятельность учащихся на уроке и во внеурочное время. Даже слабые учащиеся проявляют интерес к языку во время выполнения творческих заданий. Использование метода проектной деятельности, возможна при изучении отдельных тем курса, например: «Профессии», «Известные люди Татарстана», «Татарская кухня», «Достопримечательности Казани», «Народные праздники», «Деловые бумаги» и другие. Выполняя задания проекта, учащиеся сами находят необходимую информацию, содержащую лексический, грамматический материал, используя для этих целей не только материал учебника, но и другие источники информации.

На уроках татарского языка большое внимание в своей педагогической деятельности уделяю сохранению национальных традиций и духовно-нравственной культуры. И пусть каждый урок даёт детям лишь какую-то часть необходимой информации, постепенно складывается целостная картина. И если мы сохраним богатство традиций, культуры, то главным образом – мы сохраним наш язык.

Таким образом, использование интерактивных методов обучения позволяет не только повысить эффективность обучения, но и стимулировать учащихся к дальнейшему самостоятельному изучению татарского языка.

**Литература**

1. Гейхман Л. К. Интерактивное обучение общению./ Л. К. Гейхман. - Пермь: Изд-во Перм. ун-та, 2002. - 260 с.

2. Горбунова Н.В. Методика организации работы над проектом. Материал подготовлен на основе анализа педагогической литературы и зарубежного опыта, представленного в сети Интернет / Н.В. Горбунова, Л.В. Кочкина // Образование в современной школе. - 2000. - № 4. - С. 21-25.

3. Кашлев С.С. Современные технологии педагогического процесса / С.С.Кашлев. Мн.: Университетское, 2000. 95 с.

# ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЕ ТӘРБИЯ ДӘРЕСЕ БУЛЫРГА ТИЕШ

***Гобәйдуллина З.Р., Мөхәмәдова Ә. Ф.***
***Казан шәһәре Мәскәү районының 9 нчы гимназиясе***
***ZULFIAZULFIA72@ yandex. ru***

***Аннотация.*** Авторы обращают внимание на то, что главная задача образовательного процесса — это духовно-нравственное воспитание, воспитание личности. В статье представлен опыт работы учителей родного языка и литературы, показаны конкретные приемы работы, которые позволяют достичь необходимого результата.

***Ключевые слова:*** родной язык, обучение, воспитание, образовательный процесс.

“Игътибар белән тикшереп караганда, бу тәрбия дигәнебез уку-укыту өчен иң кирәкле һәм аңа иң лаек төрле фәннәрне үз эченә алучы бер фәндер. Укытучы кешенең тәрбия фәнендә барлык нечкәлекләрне аңлап, үзеннән яңа тәрбия юлларын тәҗрибә кылып чыгарырга көче булсын” [4:188]

Бөек энциклопедик галимебез Каюм Насыйриның әлеге сүзләрен искә алганнан соң, “Мәгариф” журналының РФА әгъза-корреспонденты, педагогика фәннәре докторы, Федераль Дәүләт белем бирү стандартларын төзүче төркем җитәкчесе Александр Кондаковның “Мәгариф” редакциясе хәбәрчесенә биргән интервьюсындагы фикере хәтергә килә. Галим әлеге әңгәмәдә “...были созданы новые матрицы — таблицы опросов населения. Мы неожиданно для себя выяснили, что общество и государство, семья не очень-то заинтересованы в том, знает ли ребенок бином Ньютона или не знает. Их гораздо больше волнует, является ли ребенок личностью, уважает ли старших и заботится ли о младших, умеет ли он коммуницировать в коллективе, умеет ли избегать конфликты, и т.д. И в результате, кстати говоря, с помощью коллег из Татарстана появилась Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина России, которая позволила нам впервые взглянуть на воспитание как на важнейшую составляющую процесса образования, заставила признать, что на самом деле главная задача образовательного процесса — это духовно-нравственное воспитание, воспитание личности”,- дип белдерә.[2:96] Бу сүзләр һәр татар кешесенең күңеленә хуш килгәндер, мөгаен. Ниһаять, безнең борынгы бабаларыбызның күп гасырлар буе чаң суккан фикере халык аңына килеп җитте, бүгенге заман галимнәребез колагына керде. Борынгы төрки шагыйребез Йосыф Баласагуни ун гасыр элек язылган “Котадгу белег” [1: 120] әсәрендә юкка гына:

“ Белем һәм акыл ул - антлы дустыңдыр,
Ул миһербанлы кардәшең булыр.
Тик акыл һәм белем булсын тиң-таман.
Акылың булмаса, белемең дошман” дип язмагандыр.

Дәүләтебез дә, бүгенге тынычлыкка омтылу, кеше хокукларын яхшы белү, толерантлык, хезмәттәшлек, әхлаклылык кебек сыйфатлар бик нык таләп ителгән шартларда, мәгариф системасы каршына белемле, милли һәм чит милләтләр мәдәниятен яхшы белүче, хөрмәт итүче, конкурентлыкка һәм хезмәттәшлеккә сәләтле шәхес тәрбияләүне куя. Әлеге максатка ирешүнең юллары нинди, киләчәк буыннарга дөрес тәрбия бирү өчен кемнәргә, нәрсәләргә таянырга?

Без, тел һәм әдәбият укытучылары буларак, әлбәттә , "шәхесләребезгә, милли-мәдәни кыйммәтләребезгә, күп гасырлык әдәбиятыбызга",- дип җавап бирәбез. Информацион технологияләр турында горурланып сөйләсәк тә, мәктәптә укучы һәм укытучы аралашуына нигезләнгән дәрес дип аталучы төшенчәнең кыйммәте кимегәне юк әле. Әлбәттә, дәрестә белем бирү беренче урынга куелырга, ләкин Каюм Насыйрича әйтсәк: "бу тәрбия дигәнебез уку-укыту өчен иң кирәкле һәм аңа иң лаек төрле фәннәрне үз эченә алучы бер фәндер". Бүгенге көндә туган тел дәресләре, XIX гасырда ук Насыйри тәкъдим иткәнчә, әдәбият фәне белән үрелеп бара. Тел дәресләрендә әдәби әсәр геройларын искә алып, әсәрнең өзекләрен тел чаралары ягыннан тикшерү бүгенге көн методикасы өчен гадәти күренеш. Шундый өзекләр белән беррәттән, балалар игътибарына гыйбрәтле хикәятләр дә тәкъдим итәргә мөмкин. Шундый дәресләрдән бер үрнәк:

Дәрес "Балыкчы белән студент" турындагы хикәят белән башлана.

Балыкчы белән студент көймәдә елга кичәләр. Студент бик сүзчән кеше булып чыга,балыкчыга сорау яудыра:

-Сез математиканы беләсезме?

-Юк, кая инде ул безгә уку!

-Алайса, сез гомерегезнең чиреген әрәм иткәнсез икән. Бәлки астрономияне беләсездер?

-Анысы нәрсә була инде?

-И, сез бигрәк мескен кеше икәнсез, гомерегезнең яртысын әрәм иткәнсез бит.

Шул чак давыл чыга, көймә чайкала башлый. Хәзер инде балыкчы сорый:

- Йөзә беләсеңме?

-Ю-у-у-к.

-Алайса, ныграк тотын, югыйсә бөтен гомереңне дә әрәм итәргә мөмкин.

(Бергәләп әлеге очракка анализ ясала. Нәтиҗә чыга: кешедән көләргә ярамый. Нәтиҗә "Халык әйтсә, хак әйтә" циклы астында мәкальләр белән ныгытып куела.

1)Кешедән көлгәннең борыны өшегән.

2)Иртән көлсәң кешедән,кич көләрләр үзеңнән.

3)Ахырда көлгән шәп көлә.

Шушы мәкальләргә синтаксик анализ ясап, дәрес дәвам ителә.

Мондый дәресләрдә бала фәнне дә үзләштерә, яхшы белем дә ала,тормыш дәресе дә алып китә.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен татар теле һәм әдәбияты дәресләре телне камилләштерү һәм әдәби әсәрләр белән танышу дәресе генә түгел, ә татарча яшәргә өйрәнү, тормышка әзерлек дәресләре дә. Әгәр дә бу дәресләрдә без халкыбызның бөек шәхесләренә хөрмәт, милли кыйммәтләренә игътибар тәрбияли, әдәбиятыбызның асыл каһарманнарына хас булган сыйфатларны укучыларыбыз күңеленә сала алмасак, бүгенге “туган йорттан – зур дөньяга” принцибына корылган укыту-тәрбия чылбырының иң төп буыны төшеп калырга мөмкин. Рус телле шәһәрдә яшәүче, туган телендә атнага шушы сәгатьләр күләмендә генә аралашучы әлеге балаларыбыз да аңларлык тел белән язылган бу хезмәтләрне дәресләрдә дә, дәрестән тыш чараларда да урынлы куллану-безнең төп максатыбыздыр.

**Әдәбият**

1. Әхмәтьянов Р.Г. Йосыф Баласагуниның “Котайткыч белек” әсәре //Чын мирас.- 2013.- №11.- 120 б.

2. Кондаков Александр. Сегодняшнее образование готовит молодежь к жизни в обществе, которого уже нет // Мәгариф.- 2014.- №11.- 96 б.

3.Насыйри Каюм. Китаб-әт- тәрбия. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992. – 144 б.

4. Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1т.- Казан: Тат.кит. нәшр., 2014. – 407 б.

# БЕЛЕМ БИРҮ ПРОЦЕССЫНДА ПРЕДМЕТАРА ЭЛЕМТӘЛӘР

***Гомәрова Г.А., Гарәпшина Л.А.***
***Казан шәһәре «171нче гомуми урта белем бирү һәм аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәбе»***
**galinagumarova@mail.ru**

***Аннотация.*** В статье рассматриваются вопросы организации работы с детьми при обучении родному языку и литературе, развития у них творческих, интеллектуальных, коммуникативных способностей и ключевых компетенций, а также методического мастерства учителей.

***Ключевые слова:*** родной язык и литература, творческая активность, интеллектуальные способности, мастерство учителя.

Бүгенге көндә туган тел һәм әдәбият укытучысы буларак, безнең бурыч, программада каралган әсәрләрнең идея-эчтәлеген ачу, укучыларны әйләнә-тирә мохиткә, вакыйларга дөрес бәя бирергә, матурлыкны күрә һәм тоя белергә өйрәтү белән берrәттән, дәресләрне тормыш белән бәйләп алып бару. Тормыш – ул халыкның үткәне. Халыкның үткәне – аның гореф-гадәте, йолалары, традицияләре. Халкыбызның язмышы, киләчәге бүгенге яшьләребезнең нинди шәхси сыйфатларга ия булуына бәйле. Укучыларыбыз халкыбызның рухи кыйммәтләрен барларга, сакларга, арттырырга сәләтле икән, димәк, киләчәк буынның да язмышы өметле.

Татар халкының милли мәгариф системасы “яхшы, мул тормышта яшәү өчен, кеше, иң беренче чиратта, белемле һәм тәрбияле булырга тиеш” дигән акыллы фикергә таянып эш итә. Бу фикер барлык мәгърифәтчеләр өйрәтмәләренә барып тоташа, белем бирү белән тәрбия бирүне бәйләп алып бару принцибын алга чыгара. Күп милли мәдәниятле Россия шартларында мәктәпләр һәм югары уку йортлары уку-укытуда шушы принципка нигезләнә.

Мәктәптә өйрәтелә торган фәннәр арасында туган тел – татар теле – халкыбызның әхлак кагыйдәләрен, рухи мирасын киләчәк буыннарга тапшыру чарасы булып тора. Туган телне өйрәтүче мөгаллим исә - балага шушы хакыйкатьне аңлатучы, төшендерүче, сүз аһәңен җиткерүче ул.

Туган телне өйрәнү, аны һәрвакыт камилләштереп торуның әһәмиятен атаклы галим-мәгърифәтчеләр тарафыннан ассызыкланып килгән. Бу юнәлештә күп эшләгән, аларны милләтпәрвәр шәхесләр итеп тәрбияләүгә, туган телебезне, аны укыту методикасын камилләштерүгә зур өлеш керткән зыялы галимнәр арасында Каюм Насыйри, Галимҗан Баруди, Риза Фәхретдин, Галимҗан Ибраһимов һәм башкалар бар.

Милли тәрбия бирүнең эчтәлеге, өч өлештән тора, дип әйтергә була. Беренчесе – балаларга гомумкешелек кыйммәтләренең асылын аңлату һәм аларның бу кыйммәтләрне тануына ирешү. Икенчесе – балаларда гомумкешелек сыйфатларын формалаштыру. Өченчесе – балаларның татар милләтенең төп сыйфатларына ия булуларына ирешү. Җир йөзендәге барлык халыклар өчен уртак гомумкешелек сыйфатлары кабул ителгән:

- намуслылык, вөжданлык;
- кешелеклелек, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек;
- кайгыртучанлылык;
- хезмәт ярату;
- милләтара дуслык;
- милләтпәрвәрлек.

Милли сыйфатлар формалаштыру – тәрбия бирүнең иң әһәмиятле өлеше. Милли сыйфатларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

1. Үзеңне милләт вәкиле итеп тану.

Бу тойгыны барлыкка китерү җиңелләрдән түгел. Аның формалашуы баланың үз милләтен, курыкмыйча, оялмыйча атавында күренә.

Укучылар үзләренең, эти-әниләренең, әби-бабайлары исемнәренең мәгънәсен, килеп чыгышы тарихын белмиләр. Менә шуңа күрә дә "Исемең матур, кемнәр куйган?", "Минем исемем – җырларда" дигән кичәләр, "Исемнәр бакчасында", "Исемнәрдә тарих кайтавазы" темаларына сыйныф сәгатьләре үткәрү зарури.

2. Милләт тойгысы һәм милли горурлык хисе –бу хис барлыкка килсен өчен, үз милләтеңнең тарихтагы урынын, аның башка милләтләрдән аермасын һәм үзенчәлекле якларын белү кирәк. Бу хиснең фомалашуында үз милләтеңнең күренекле шәхесләре турында белү аларны өйрәнү беренчел тора.

3. Туган телеңне камил белү, бу телдә аралашу, аны пропагандалау, мөмкин булганда, аны башкаларга өйрәтү. Әгәр дә бала туган көненнән башлап гомере буенча ана теле дөньясында булмаса, аның белән бергә яши алмаса, бу әһәмиятле милли сыйфатның көчле уңай йогынтысыннан мәхрүм булачак. Адәм баласын бу әһәмиятле , изге юлга бастыруны укытучылар хезмәтеннән башка күз алдына да китереп булмый.

4. Татар халкының гореф – гадәтләрен, йолаларын тану һәм үтәү. Татар халкының милли бәйрәмнәре Сөмбелә, Аулак өй, Нәүрүз, бөек шагыйрьләренең туган көннәрен билгеләп үтү. Күренекле шәхесләребез К.Тинчурин, Г.Бәширов, Г.Исхакый, Ф.Хөсни һәм башка язучыларыбыз иҗатында халкыбызның гореф-гадәт, йола һәм бәйрәмнәрененең бирелешен күрәбез.

5. Үз милләтеңнең тарихын белү, аны саклау һәм хөрмәт итү. Әдәби-музыкаль кичәләр, үз төбәгебездә яшәп иҗат итүче язучы-шагыйрьләр белән очрашулар укучыларда туган ягыбызга мәхәббәт тәрбияли, горурлык хисләре уята.

6. Үз милләтеңнең музыка, рәсем сәнгате, мәдәният казанышлары белән таныш булу. Халык авыз иҗатын – экиятләр, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, бишек җырларын белү; шигырьләр, җырлар өйрәнү; халыкка хас әдәп кагыйдәләрен, туган як табигатен, милли халык уеннарын белү дигән сүз.

Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре, йолалары була. Алар халыкта милли горурлык, гасырлар дәвамында халыкның күңеленә сеңгән йола һәм бәйрәмнәрнең рухын тәрбияләргә ярдәм итеп кенә калмыйлар, ә шул хисләрне кичергән кешеләрдә рухи канәгатьләнү дә тудыралар. Кешегә камил бәхет өчен нәкъ менә тулы рухи байлык һәм җан азыгы да кирәк.

Заман таләпләре үзгәрү, информацион технологияләрнең кулланылышка үтеп керүе кеше тормышындагы зур үзгәрешләргә китерде. Бигрәк тә яшь

кешеләрнең дөньяга карашы узгәрде. Шул сәбәпле, борынгыдан кигән йолаларыбыз, ни кызганыч, онытылып юкка чыгып бара.

Үзебезнең үткәнебезне, югалып баручы рухи байлыкларыбыз белән кызыксыну уяту, аларны кире кайтару өчен без нишлибез соң? Әлбәттә, туган тел, әдәбият дәресләрендә, дәресләрдән тыш чараларда халык авыз иҗатын кулланырга тырышабыз.

Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә без балаларны милли җанлы, үзенең тарихын, гореф-гадәтләрен белүче, киләчәген күзаллаучы, татар булуы белән горурлана торган шәхес итеп тәрбияләү максатын куябыз. Ана теле ярдәмендә туган төбәгеңнең тарихы, мәдәнияте, теле белән кызыксыну, халыкның гасырлар дәвамында буыннан буынга күчеп килгән гореф-гадәтләрен кире кайтару, үстерү һәм баету күпкә җиңелрәк. Шуңа күрә дә без, туган тел һәм әдәбият укытучылары, дәресләрдә һәм тәрбия чараларында халык авыз
иҗаты әсәрләрен бик теләп кулланабыз.

Менә мәкальләрне генә алыйк. Мәкальләрдән тормыш итү өчен күп киңәшләр, акыл алырга мөмкин. Чөнки алар – халык авыз иҗатының иң борынгы төре, шул ук вакытта иң кыска, иң җыйнак төре дә. Алар безнең халкыбызның никадәр зирәк, никадәр акыллы, уңган, булдыклы булуы турында сөйлиләр. Әгәр кеше үз сөйләмендә мәкальләргә күбрәк урын бирсә, аны тыңлыйсы килеп тора. Акыллы кеше күп сөйләми, ә хикмәтле сүзләре белән һәркемне үзенә карата. Мәкаль гел яхшылыкка, тырышлыкка өнди, тормышның авырлыгын җиңеләйтергә, тормышыбызны күңеллерәк итәргә өйрәтә. Шуңа күрә балалар мәкальләрне бик күп белергә тырышалар һәм бу тапкыр телле әсәрләрне бик яраталар.

Табышмакларны иң яратып әйтүчеләр шулай ук – балалар. Һәр баланың үзенең дәртенә, үз җитезлегенә карап, һәркайсында күпме дә булса табышмак хәзинәсе җыела.

Фольклор үрнәкләреннән файдалану әдәбият дәресләрендә генә түгел, туган тел дәресләрендә дә дәвам иттерелә. Табышмакларны, мәкальләрне, тизәйткечләрне, санамышларны ятлау, аларны дәфтәрләргә дөрес һәм матур итеп язып кую да балаларны татарча аңлаешлы, әдәби нормаларга туры килердәй итеп сөйләргә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булып тора.

Фольклорының тагын бер төре әкиятләр – халык иҗатының бик борынгы төре. Балалар әкиятләр сөйләргә, тыңларга яраталар, чөнки аларда кызыклы, гыйбрәтле хәлләр сурәтләнә. Әкиятләрнең һәрберсе үгет-нәсыйхәтне, нинди дә булса хакыйкатьне бәян итә. Аларда халык хезмәткә, тырышлыкка, күңел сафлыгына дан җырлый; гаделлек, зирәклек һәрвакыт җиңә; ялкау, комсыз, әдәпсез кешеләр көлкеле хәлләрдә кала. Мәсәлән, балалар “Үги кыз” әкиятен бик яратып укыйлар, аның эчтәлеген сөйлиләр, кызның гадел һәм тугрылыклы булуына сокланалар. Мин укучыларга шундый хакыйкатьне төшендерәм: халык үзеннән-үзе генә җиңми. Кыз тырыш булуы, эш сөюе, кешеләргә һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер торуы нәтиҗәсендә һәлакәттән котылып кала. Ә менә үги ананың үз кызы – ялкау, кире, үзсүзле; шуңа күрә ул һәлак

була. Бергәләп нәтиҗә ясала: гаделлек, эш сөю, сүзеңдә тора белү – уңай сыйфатлар; аларны һәркем үзендә булдыру өчен тырышырга
тиеш. Әкиятне укып чыккач, дәфтәрләргә мәкальләр дә яздырыла.

“Таңбатыр” әкиятендә хаклык, дуслык, иптәшлек, туры сүзлелек мәсьәләләре күтәрелә. Әсәрнең авторы – халык, шуңа күрә әлеге сыйфатлар әкияттә өстенлек итә.

Мәктәп баласы өчен әкият – гадәти тормыш кысаларын киңәйтеп, катлаулы күренешләр һәм кичерешләр белән очраштыручы, өлкәннәр дөньясына хас хисләр дөньясын бала аңлардай әкияти формада тәкъдим итүче үзенчәлекле чынбарлык.

Әкият образлары балага катлаулы хәлләрдән чыгу юлларын ирексезләмичә генә тәкъдим итә, үзенә һәм үз мөмкинлекләренә ышаныч уята. Күп очракта бала үзен уңай герой белән тиңләгәнгә күрә, ул изгелекне явызлыктан аерырга өйрәнә, чын рухи кыйммәтләрне үзләштерә.

Халык авыз иҗаты әсәрләренең бер төре булган мәзәкләрнең дә тәрбияви әһәмияте зур. Укучылар бигрәк тә белем алуга, мәктәп тормышына кагылышлы мәзәкләрне яраталар. Мәзәкләрдә күбрәк диалог өстенлек итә. Тапкырлык белән наданлык арасында фикерләр бәрелеше килеп чыга. Мәзәкне тыңлаучы балалар рәхәтләнеп көлә. Мондый мәзәкләрне рольләргә бүлеп тә укытырга була.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: туган тел һәм әдәбият дәресләрендә фольклорга мөрәҗәгать итү баланың фән белән кызыксынуын көчәйтә, ихтыяр көчен, акыл эшчәнлеген үстерә, укучыларны милли рухта тәрбияләргә һәм аларга әхлак тәрбиясе бирергә ярдәм итә. Халыкның рухи дөньясын, гореф-гадәтләрен, йолаларын белү безгә нәрсәгә кирәк соң? Бу сорауга Г.Бәшировның сүзләре белән җавап бирәсебез килә. “Без хәзер гаҗәп чуалчык заманда яшибез. Шуңа күрә, дөрес юлны табу өчен, безгә үзебезнең үткәнебезне, халыкның гүзәл йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә кирәк. Фәкать алар гына безгә дөрес юлны табарга, халкыбызга нахак бәла ягучыларга дөрес җавап бирергә ярдәм итәчәк”.

**Әдәбият**

1. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. –Казан: Мәгариф, 1997. - 175б.
2. Низамов Р.А., Нигъмәтов Җ.Г. Татар халык педагогикасы, - Казан: Мәгариф, 2002. – 111б.
3. Татар балалар фольклоры. (Төз. Р. Ягъфәров) Казан: Раннур, 1999. – 352 б.

# ТЕЛЛӘРГӘ ӨЙРӘТҮДӘ УНИВЕРСАЛЬ АЛЫМНАР ҺӘМ МЕТОДЛАР

***Горохова Й. Ә.***
***МБГББУ «К.Ф. Шакиров исемендәге Зур Сәрдек гимназиясе»***
***ildoz1999@mail.ru***

***Аннотация.*** В работе речь идет об универсальных методах и приемах при обучении языкам.

***Ключевые слова:*** ассоциативный метод, повтор хором, психологическая игра.

Дөньяда булган һәр тел серле, катлаулы, шул ук вакытта кызыклы әкият дөньясы. Без – укытучыларның – төп бурычы – укучыларга шушы серле дөньяны ачарга ярдәм итү, дөрес ачкычларны булдыру.

Бүгенге көндә кайсы телне генә өйрәтсәк тә, бары тик сүз ятлатып, яки теория аңлатып кына югары нәтиҗәләргә ирешеп булмый. Иң беренче чиратта, балаларны кызыксындыра белергә кирәк. Ә моның өчен телләргә өйрәткәндә төрле уеннар, эффектив методлар куллану – уңышлы булачак.

Ниндидер бер телгә өйрәтүне – өй салу белән чагыштырып карау уңышлы. Йорт салуда төп элементлар булып, төзелеш материаллары, архитектура-физика законнары, йорт дизайны торса, телгә өйрәтүдә бу элементларны лексика, грамматика һәм фонетика бүлекләре алыштыра. Лексиканы – төзелеш материалы, грамматиканы – архитектура-физика законнары, ә фонетиканы – йорт дизайны дип тәңгәл китерергә була. Тик болар арасында иң төп әйбер – төзелеш материаллары. Чөнки материалсыз бернинди архитекторлар да, дизайнерлар да әйбәт йорт сала алмаячаклар. Ә тел өйрәтүдә төп әйбер – лексика. Телнең лексикасын, ягъни сүзләрне белмичә, ятламыйча бер укучы да грамматик кагыйдәләрне дөрес итеп куллана алмаячак. Әмма, белгәнебезчә, телдәге сүзләр бик күп һәм бер бала да сүз ятларга яратмый. Шуның өчен башка тел сүзләрен җиңелрәк истә калдырырга ярдәм итә торган күнегүләр куллану телгә өйрәтүдә актив кулланылырга тиеш.

Лексиканы өйрәнгәндә, иң беренче эш итеп яңа сүзләр белән танышу мөһим. Гадәттә, укытучы китапта бирелгән сүзләрне тәкъдим итә, укучылар аны сүзлекчәләренә язып алалар, аннан соң укытучы тәрҗемәсен әйтә, ә балалар яңадан ишеткәнне генә язып куялар. Нәтиҗәдә, сүзләрне истә калдыру түбән була. Шуның өчен бу урында *ассоциатив метод* куллану уңышлы булачак дип әйтер идем. Чөнки бала баш миендә булган ниндидер бер образ аша сүзне истә калдырачак, шул ук вакытта ничек тәрҗемә ителешен дә аңлаячак. Ягъни, укытучы чит телдәге сүзне туган телдәге берәр сүзгә охшатып, яисә уйдырма образ табып өйрәтә. Бу метод – бигрәк тә кардәш телләргә өйрәткәндә әйбәт. Чөнки охшаш сүзләр аша образ тудыру җиңелрәк.

Сүзләр өйрәнүдә икенче этап – бергәләп тәрҗемә иткән сүзләрне дөрес итеп әйтә белү. Моның өчен сыйныф белән *бергәләп кабатлау алымын* куллану файдалы. Бергәләп кабатлаганда, беренчедән, укучыларның әйтү күнекмәләре формалаша, икенчедән, әзме-күпме, берничә сүз булса да исләрендә калачак. Әлеге алымның әһәмияте берничә тапкыр кабатлаганда гына бар. Бер тапкыр

гына кабатлау баланың игътибарын сүзләргә юнәлдереп бетерә алмый. Хор белән кабатлап бетергәннән соң парларда һәм индивидуаль кабатлау да ярдәм итәчәк. Галимнәр әйтүенчә, сүзне истә калдыру өчен, аны күп тапкырлар күрергә, ишетергә, укырга һәм кычкырып әйтергә кирәк.

Өйрәнгән яңа сүзләрне ныгыту өчен, алар белән эшне дәвам итү зарур. Бервакытта да сүзне өйрәнүгә үк грамматик теориягә күчүне киңәш итмәс идем. Әгәр, сүз артында ниндидер бер рәсем, образ торса, тизрәк истә кала дип исбатланган. Шуның өчен яңа сүзләрне өйрәткәндә, рәсемнәр белән эшләү дә мөһим этап булып тора. Мәсәлән, укучыларга сүзләр һәм рәсемнәр бирелә, шуларны тоташтырырга кирәк. Бер караганда, бирем бик гади кебек тоелырга мөмкин, ләкин күнегүләрне гадидән катлаулыга таба бирсәк, укучыга кабул итәргә җиңелрәк булачак. Әлеге төр күнегүләрне эшләгәндә, балаларның күз алдыннан лексиканы алып куймау да мөһим. Укучы парта кырыенда торган сүзлекчәгә күнегүләр эшләгәндә берничә тапкыр карап алачак. Шул рәвешле, тагын берничә сүз баш миенең киштәләренә кереп урнаша.

Гадәттә, без укучылар белән яңа сүзләр өйрәнгәннән соң текст укырга, шул укыганны тәрҗемә итәргә керешәбез. Әлбәттә, беренче партада утыручы, бик тырышып укучы бала текстка кереп китеп, һәр өтеренә кадәр аңларга тырышачак, әмма арткы партада, йокымсырап утырган бер малай китапка яки тәрәзәгә карап үз уйларыннан арынмаячак. Шуңа күрә укучыларны кечкенә-кечкенә төркемнәргә (максимум 3 кеше) бүлеп, *«Кискенлек аша камиллеккә» методын* кулланырга тәкъдим итәр идем. Әлеге метод укучыларның иҗади фикер йөртү сәләтен арттырырга һәм эшне вакытында тапшырырга өйрәтә. Бу методны кулланган вакытта укучыны кискен бер халәттә калдырабыз һәм ул аннан чыгу юлын үзе эзләп табарга тиеш. Мәсәлән, укытучы – ниндидер эшкә заказ бирүче, ә укучылар, вакытында шушы заказны дөрес итеп эшләп тапшыручылар формасында эшләү. Заказ бирүче укуыларга – өйнең эчке схемасына проект төзергә куша. Һәр бүлмәне яңа өйрәгән сүзләр белән билгеләп куярга да кирәк. Укучылар биремне эшлиләр, заказ бирүче яхшы эшләргә акча түли. Ә дәрес ахырында бу акчалар билгегә әйләнәчәк. Ә соңга калып тапшырган проектлар каралмый да, бәяләнми дә.

Биремне эшләгән арада тагы бер моментка игътибар итәргә кирәк, укучыларның һәрберсе алдында да дәрес башында өйрәнгән сүзләр ята. Алар капланмаган да, алып та куелмаган. Ягъни янәдән, янә карый-карый тагы 2-3 сүз үзеннән-үзен хәтердә сакланачак.

Бу методның әһәмияте шунда ки: орхидея чәчәкләре стресс кичергәндә генә күп итеп чәчәк ата ди галимнәр. Балалар да шулай, үзләренә ниндидер эш биреп, кискен каршылыкка куймасаң, алар яхшы нәтиҗә күрсәтмәячәкләр.

Югарыда тел өйрәтү өч төп элементтан тора дигән идек, азмы-күпме фонетика һәм лексика элементларын карап, берникадәр күнегүләр белән аларны ныгыттык. Ә грамматик теория – иң катлаулысы. Шуңа укытучы теоретик белемнәрне үзе аңлатырга тиеш, чөнки бала китапта бирелгән схемаларны карап кына аның асылына төшенә алмаячак. Ягъни монда элеккеге *тактага*

*язып аңлату методикасын* уңышлы дип әйтер идем. Ләкин күнегүләрне ныгытканда бераз креативлык һәм яңа методлар куллану комачау итмәс.

Гадәттә, укытучы нинди дер бер заман формасын, грамматик категорияне кертеп, җөмләләр төзетә. Укучылар әзер форманы куеп кына баралар. Шуңа биремне бераз башка яктан күрсәтә белергә кирәк. Мәсәлән, фигыльләрнең үткән заман формасы теориясен аңлатканнан соң укытуы шактый катлаулы гына текст өләшә. Укучылар исә, аннан үткән заман формасында килгән фигыльләрне табарга тиешләр. Болай эшләгән очракта бала шаблон буенча кушымчалар гына куеп утырмый, функциональ грамоталылык та арта, шул ук вакытта теоретик белемнәрне практикада кулланырга һәм эзләп табарга да өйрәнә.

Грамматиканы ныгытуның икенче нәтиҗәле алымы – *«Сорау-җавап»*. Ләкин бу форматны да бераз үзгәртергә киңәш итәм. Дәрес ахырында үткән тема буенча һәр укучыга берәр сорау уйларга кушыгыз. Безнең укучылар, гадәттә, укытучы биргән сорауга җавап бирергә иялэнгәннәр. Ә менә үзләре укытучыга сорау биргәндә, алар янәдән стресс ситуациясендә калалар, чөнки теманы аңламаган кеше сорау бирә алмый. Икенчедән, алар башка төрле фикерләргә дә өйрәнәчәкләр. Һәм инде теге арткы партада йокымсырап утырган малайның янәдән баш мие уянып китәчәк. Шулай ук, әлеге алым дәресне йомгаклап кую өчен дә бик яхшы.

Дәрес ахырын нинди дер әкияти герой белән тәмамлау – һәр баланың кәефен күтәрәчәк. Сезнең дәресегез аның күңелендә якты, күңелле булып калачак. Мәсәлән, безнең татар халкы электәннән йорт иясе – Бичурага ышанган. Ул татар өйләрен төрле бәла-казалардан саклый. Ә укучыларга ул дәрестә өйрәнгән сүзләрне баш миләрендә сакларга ярдәм итәчәк. Һәр укучы авыр булып тоелган сүзне кечкенә генә кәгазь кисәгенә язып, Бичураның сумкасына сала. Ул әкияти көче белән истә калдырырга ярдәм итәчәк. Төгәлрәк итеп әйткәндә, бу *психологик уен алымы*. Бала икенче дәрескә килеп, Бичураны күрүгә үк үзе язган сүзне искә төшерәчәк.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, дәреснең һәр этабында, теләсә нинди телгә өйрәткәндә дә универсаль алымнар кулланып үз фәнегезне мавыктыргыч итеп эшләргә була. Моның өчен – гадәткә кергән укыту алымнарын бер читкә куеп, биремнәргә башка яктан карарга, яңа технологияләр, методлар, алымнар кулланырга гына кирәк.

**Әдәбият**

1. Методика обучения иностранным языкам (учебное пособие для студентов Института математики и механики им. Н.И. Лобачевского по направлению «педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)»). – Казань, КФУ, 2016. – 189 с.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЭЛЕКТРОН СҮЗЛЕКЛӘРНЕ КУЛЛАНУ

***Госманова С.М., Алиева Ф.Н.***
***Казан шәһәре Мәскәү районы 94 нче гимназиясе,***
***Шәрәфетдинова Л.М.***
***Казан шәһәре Идел буе районы 139 нчы гимназия-Мәгариф үзәге***
***salihagusmanova@mail.ru, sharafutdinovaleila@mail.ru, alieva.faniya@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье: «Использование электронных словарей на уроках родного(татарского) языка» рассматривается значении электронных словарей, их роль в учебной деятельности. Только при последовательном использовании словарей можно добиться соответствующих результатов. Один из видов работы- это составление учащимися кроссвордов. Такой вид работы помогает ребенку запоминать написание большинства слов, развивает ассоциативное мышление, побуждает обращаться к электронным словарям. Также были рассмотрены положительные и отрицательные стороны бумажных и электронных словарей. Таким образом, автор делает вывод, что тщательно спланированная и хорошо организованная работа со словарями помогает развивать речь учащихся, способствует развитию культуры языка, формирует у ребенка внимание, уважение и любовь к родному языку. Статья будет интересна учителям родного (татарского)языка и литературы.

***Ключевые слова:*** электронный словарь, бумажный словарь, кроссворд, ассоциативное мышление, отрицательная сторона, положительная сторона.

Хәзерге дөньяда ике яки берничә телне белү зарур. « Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел. Икесе дә безнең өчен иң кирәкле затлы тел. » - дип яза татар шагыйре Шәйхи Маннур. Балалар ике теллелек мохитендә генә түгел, ә алар өчен туган булган ике культурада да тәрбияләнәләр. Беренчедән, алар зур сүзлек запасы туплыйлар, бу үз чиратында акылның сыгылмалылыгын үстерүгә ярдәм итә. Икенчедән, хәтерне ныгыталар һәм үстерәләр, бу, үз чиратында, абстракт фәннәрне тиз һәм сыйфатлы үзләштерүгә ярдәм итә. Өченчедән, акыл үсеше коэффициенты югарырак. Дүртенчедән, башка милләт кешеләренә карата толерант мөнәсәбәткә өйрәнәләр. Күп телләрне белүнең файдасына тагын бер дәлил: иртә балачактан ике телне тигез дәрәҗәдә белгән кешеләр өлкән яшьтә үзләренең акыл сәләтләрен акрынрак югалта. Икетелллелек буенча укыту процессы четерекле һәм катлаулы эш. Заманча технологияләрне кулланып укучыларны кызыксындыру өстендә эш алып баралар. Һәр укытучы заман белән бергә атларга тиеш.. Хәзерге уку-укыту процессында иң әһәмиятле урынны заманча технологияләрнең берсе булган мәгълүмати-коммуникацион технология алып тора. Әлеге технология эченә электрон сүзлекләр белән эшли белү дә керә. Укучыларга белем бирү, фәнни-тикшеренү эшләрен оештыру, тәрбияләү процессында электрон сүзлекләр белән эшчәнлек мәгълүматны кабул итү, игътибарны көчәйтү, хәтер һәм интеллектны үстерүдә югары

күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирә, уйлау сәләтен активлаштыра. Алда әйтелгәннәр теманың актуальлеген билгели.

**Эшенең төп максаты** – электрон сүзлекләрнең төрләре, татар һәм рус мәктәпләрендә уку эшчәнлегендә электрон сүзлекләрне куллануның әһәмиятен күрсәтү.

**Бурычлар:**

- электрон сүзлекләр ярдәмендә теоретик һәм практик белемнәр бирү;
- электрон сүзлекләр ярдәмендә укучыларның язма һәм телдән сөйләм күнекмәләрен үстерү;
- электрон сүзлекләр булган сайтлар белән танышу, эшләргә өйрәнү;
- электрон сүзлекләрне дәрестә куллану дәрәҗәсен үстерү.

Мәгълүмати-коммуникацион технология буларак электрон сүзлекләрне куллану.

Сүзлек белән эшләү укучының аралашу телен формалаштыра, аның дөньяга карашы, сөйләм культурасы өчен зур тәрбия-белем бирү әһәмиятенә ия. Бу эш укучыларның киләчәк практик эшчәнлеге өчен кирәкле күнекмәләр белән кораллану өчен кирәк.

Мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне без дәреснең барлык этапларында да кулланабыз: яңа материалны аңлатканда, беркеткәндә, шулай ук материалны кабатлаганда. Укучыларга билгесез сүзнең семантикасын һәм орфографиясен үзләштергәндә, этимологик белешмә кирәк, аны, кагыйдә буларак, укытучы бирә, бу сүзгә, телгә, аның тарихына карата кызыксыну формалаштырырга ярдәм итә. Хәзер бу этимологик белешмәне балалар, электрон сүзлекләрдән файдаланып, бер-берсенә мөстәкыйль төзи ала.

Без бу уку елында үз укучыларыма биш сүзлектән файдаланып, «сүз портреты» төзергә тәкъдим иттек. Бу-орфографик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, синонимнар һәм антонимнар сүзлеге (һәркем аерым), кирәк булганда, чит телләр сүзлеге, этимологик сүзлек һәм фразеологик сүзлек. Бу эш безгә укучылар моңарчы күрелмәгән текстларга да күчәргә мөмкинлек бирде. Әгәр элек өй шартларында мондый биремне үтәгәндә бер генә сүзлек яки мәктәп яки район китапханәсенә озак бару таләп ителсә, хәзер, бернинди чыгымсыз, һәр баланың өендә сүзлекләр бар, компьютерны кабызып Интернетны эшләтеп җибәрергә генә кирәк. Башкарылган эш безгә сүзлек запасы кысаларын киңәйтергә ярдәм итте, укучыларның сөйләме алар өчен моңарчы билгеле булмаган күп кенә сүзләргә баеды, бу аларның телдән җавап биргәндә дә, нинди дә булса язма эшләр, әйтик, хикәя һәм инша язганда да сөйләм сәләтен яхшыртты.

Сүзлекләрдән эзлекле рәвештә файдаланганда гына тиешле нәтиҗәләргә ирешеп була. Моның өчен: максат юнәлешен билгеләргә, укучыларның сүзлек запасын ачыкларга, аларның сөйләмендәге ялгышларын өйрәнергә, яңа сүзләр белән таныштырып торырга, тел һәм әдәбият дәресләрендә үткәрелә торган башка эшләр белән үреп, укучыларның танып белү эшчәнлекләрен, мөстәкыйльлекләрен үстерерлек итеп оештырырга һәм тормыш белән бәйләп алып барырга кирәк була.

Программа нигезендә V сыйныф укучылары лексика буенча түбәндәгеләрне белергә тиешләр: татар әдәби теленең сүз байлыгы турында төшенчә алырга; аның үзгәрүен, тагын да байый һәм камилләшә баруын, аның чыганакларын белергә; сүзләрнең күп мәгънәлелеге, туры һәм күчерелмә мәгънәле була алулары; омонимнар, синонимнар, антонимнар, тотрыклы сүзтезмәләр турында мәгълүмат һәм шуларны үзләренең сөйләмнәрендә куллана белү күнекмәләре алырга; сүзлекләр һәм аларның төрләре белән танышырга, алардан гамәли файдалана белү күнекмәләре булдырырга. V сыйныфта лексика буенча башланган эш башка сыйныфларда барлык уку елында да дәвам иттерелергә тиеш. Укучы мәктәптә уку дәверендә тел һәм әдәбият дәресләрендә һәм башка фәннәрне өйрәнгәндә дә аның сүзлекләрдән файдалануын системалы рәвештә алып барырга һәм төрле эш төрләренә бәйләп үткәрергә кирәк була.

Сүзлекләрдән файдаланганда бигрәк тә түбәндәге төп мәсьәләләр игътибар үзәгендә тора:

1. Сүзлекләр белән эшләүнең төп бурычы итеп укучының дөньяга карашын формалаштыруны, киләчәктә аның гамәли эшчәнлеге өчен кирәк булган күнекмәләр белән тәэмин итүне санау.

2. Сүзлекләр белән эшләүнең эчтәлеге булып, укучылар өчен яңа, аңлаешсыз сүзләрне төшендерү, укучыларга билгеле булган сүзләрнең мәгънәсен ачыклау һәм анализ ясау, укучыларны телебезнең сүз байлыгы белән таныштыру, аның төрле фикерләрен белдерә алу мөмкинлеген күрсәтү.

3. Сүзлекләрнең мәгънәсенә анализ ясау өчен, хәзерге телдә кулланыла торган сүзләрне алу, ә аерым очракларда тарихи аспектта да карау (этимологиясен төшендерү) һ. б.

4. Сүзлекләрдән аерым очракларда гына түгел, бәлки татар теле курсының барлык бүлекләрен (грамматика, орфография һ. б.) үткәндә дә системалы рәвештә, педагогик һәм методик яктан дөрес оештырган хәлдә файдалану.

Фән һәм техниканың үсеше белән бәйләнешле яңа сүзләрне укучыларның беләсе килү ихтыяҗы артканнан-арта, аларның кызыксынулары, алар өчен яңа күренеш һәм фактларны белдерүче сүзләрне белү теләкләре үсә. Бу аларга сүзлек запасын баетуга, сан һәм сыйфат ягыннан аны үстерүгә ярдәм итә. Шуңа күрә мәктәптә башка фәннәрне укыта торган укытучылар да укучылар белән системалы рәвештә сүзлекләрдән файдаланалар: фәнне өйрәткәндә очраган яңа сүзләргә аңлатма бирәләр, сүзлек дәфтәрләренә яздыралар һәм ул сүзләрне яки терминнарны аларның сөйләмнәрендә дөрес файдалана алуларына ирешергә тырышалар.

Әдәбият дәресләрендә сүзлекләр белән эшне төрлечә оештырырга була: беренче чиратта укучыларның актив сүзлегенә керергә тиешле сүзләр карала. Аерым персонажларга характеристика биргәндә яки язучының тел үзенчәлекләрен өйрәнгәндә исә диалектизмнар, архаизмнар яки гади сөйләмгә караган сүзләр тикшерелә; аларга анализлар ясала, әдәби телдәге сүзләр белән янәшә куеп чагыштырыла, андый сүзләрне укучылар үз сөйләмнәрендә кулланмаска кирәклек турында аңлатыла. Сүзләрнең формасы үзгәрүгә карап,

мәгънәнең дә үзгәрүен укучылар грамматика дәресләрендә төрле күнегүләр эшләү юлы белән төшенәләр. Укучы, сүзләрнең лексик һәм грамматик мәгънәләрен өйрәнгәндә, анализ ясаудан синтезлауга күчә белергә тиеш, шул вакытта гына ул сөйләү һәм язу теленә ия була ала. Сүзләрне төрле күзәтүләр ярдәмендә өйрәнү, сүз белән аның кисәкләрен чагыштыру, капма-каршы куеп карау, синонимнар таптыру, тамырдаш сүзләр төзү, сүзләрне куллана белү һәм бәйләнешле сөйләм телен үстерү – барысы да грамматика дәресләрендә дә, әдәбият дәресләрендә алып барыла. Мисал өчен, 8 нче сыйныфның Луиза Батыр-Болгарый биографиясенә багышланган текста “зәвык” сүзе кулланылган. Бу сүзне аңлар өчен иң беренче чиратта китаптагы сүзлекне карыйлар, анда “вкус” дип тәрҗемә ителгән. Укучылар аны тәм төю белән кабул итәләр. Бу очракта әлеге күзаллау туры килми һәм электрон сүзлекләрдән икенче мәгънәне эзлиләр.

Киләсе эш төре, ул – крассвордлар. Алар махсус сүзлекләр белән эшләсеннәр өчен эшләнелгән, чөнки анда синонимнар, антонимнар, омонимнарны табарга кирәк. Мондый эшләр өйгә бирелә, билгеле өйдә кәгазь сүзлекләр юк. Менә шул вакыт безгә электрон сүзлекләр ярдәмгә килә.

Шуны да онытмаска кирәк кәгазь һәм электрон сүзлекләрнең уңай яклары булган кебек тискәре яклары да бар. Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була, кәгазь сүзлекләр тулырак, әмма күләмле һәм эш тизлеге түбән, ә электрон сүзлекләр белән эш заманча, тиз ләкин күзләр сәламәтлегенә зарарлы һәм тулы түгел.

Үзебезнең эшчәнлегебездә без еш кына түбәндәге интернет ресурсларны кулланабыз. Алар: татзет тупланмасы, мобиль кушымталар, гугол һәм яндекс тәрҗемәчеләр, азатлык сайты.

Сүзлекләр белән җентекләп планлаштырылган һәм яхшы оештырылган эш - укучыларның сүзлек запасын баета, орфографик грамоталылыкны үстерә, укучыларның сөйләмен үстерергә ярдәм итә, ә гомумән, тел культурасын үстерергә, балада игътибар, туган телгә карата хөрмәт һәм мәхәббәт формалаштырырга ярдәм итә. Һәр эшнең уңай ягы булган кебек тискәре яклары да очрый. Электрон сүзлекләр белән эш барышында укучылар белән шуңа игътибар иттек, сүзлекләрнең кирәк дәрәҗәдә тулы булмавына, бер сүз өчен берничә сүзлек ачарга туры килә. Бу исә үз чиратында балаларда тискәре караш тудыра. Укытучыларның тырышып аларны бу эшкә этәргән көчләре юкка чыга. Киләчәктә электорн сүзлекләр тулыландырылыр дип ышанып калабыз. Әмма В.А. Сухомлинскийның әйткән сүзләрен искә төшерсәк: «Дәрес — укытучының гомуми һәм педагогик культурасының көзгесе, аның интеллектуаль байлыгы, аның күзаллаулары һәм эрудициясе күрсәткече ул». Әлбәттә, укытучылар да, укучылар да замана таләпләреннән читләшмиләр, яңа технологияләрне, шул исәптән электрон сүзлекләрне үз эшчәнлекләрендә һәрдаим кулланалар.

**Әдәбият**

1. Әсәдуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2012. – 151 б.

2. Желдаков М. И. Внедрения информационных технологий в учебный процесс. – Мн.: Новое знание, 2003. – 152 с

3. Ибрагимов И.М. “Информационные технологии и средства дистанционного обучения”. – М.: Изд-во «Академия», 2017. – 336 с.

4. Новые педагогические и информационные технологии в системе образования: Учеб. пособие для студ. пед. Кадров / Е.С. Полат, М.Ю.Бухаркина, М.В.Моисеева, А.Е.Петров; Под ред. Е.С.Полат. – М.; Издательский центр «Академия», 2012. - 272 с.

5. Нурова Л.А., Харисов Ф.Ф. Особенности использования информационных и коммуникационных технологий на уроках татарского языка в начальной школе // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тула, 2014. № 8- 2 (38). С. 110-112.

6. Шәйхин А. Татар теле укытучысына Интернет ничек булыша ала? // “Мәгариф. Татар теле” журналы / 2016, №4. – 40-43б

*Интернет ресурслар:*

*7.* belem.ru/resources-белем бирү ресурслары үзәге
*8.* www.edu.tatar.ru - электронное образование РТ
*9.* http://mon.tatar.ru/ - Министерство образования и науки РТ
*10.* http://kitaphane.tatar.ru – национальная библиотека РТ
*11.* http://shigriyat.ru– сайт для учителей татарского языка
*12.* http://www.tugan-tel.com/
*13.* http://tatartile.org/

# РЕПРЕЗЕНТАЦИЯ КОНЦЕПТА «БАХТ / СЧАСТЬЕ» В УЗЕКСКОМ ЯЗЫКЕ

***Гудзина В.А.***
***Бухарский государственный университет***
***gudzina.v.a.17@gmail.com***

***Аннотация.*** В статье освещается специфика отражения концепта «бахт / счастье» в узбекском языке. В центре внимания находится проблема отбора ключевых средств объективации рассматриваемого концепта в узбекском языковом сознании. Анализируется структура концепта *«бахт /счастье»*, состоящая из ядра и периферии.

***Ключевые слова:*** языковое средство, узбекский язык, базовый концепт, концептуализация.

Для современной научной парадигмы актуально лингвокультурное моделирование языка, которое опирается на изучение универсальных концептов культуры. Рассмотрение базовых концептов, функционирующих в узбекском языковом сознании, открывает новые перспективы исследований в русле современной анпропоцентрической парадигмы.

Язык является средством концептуализации окружающей человека действительности, средством усвоения культуры, получения, хранения и передачи культурно-значимой информации, неотъемлемой частью культуры. Культура – это форма сознания, отображающая мировоззрение человека. Человеческое сознание играет роль посредника между культурой и языком. В сознание поступает культурная информация, в нем она фильтруется, перерабатывается, систематизируется. Сознание же отвечает за выбор языковых средств, эксплицирующих эту информацию в конкретной коммуникативной ситуации для реализации определенных коммуникативных целей.

Будучи ключевым компонентом узбекской культуры, базовый концепт «бахт/счастье» отражает важнейшие категории и установки жизненной философии нации, являющиеся релевантными для понимания национального характера представителями других этносов.

Счастье – фундаментальная категория человеческого бытия. В связи с этим требует специальных исследований концепт «счастье», относящийся к числу базовых концептов культуры. Набор компонентов этого ментального образования, их иерархия зависят от этнических предпочтений носителей конкретной культуры, поэтому необходимо лингвокультурное исследование данного концепта на материале разных языков.

С.Г. Воркачев отмечает: «В эволюции концепта «счастье» последовательно прослеживается субъективизация и перемещение вовнутрь «локуса контроля»: изначально счастье – это судьба, рок, затем это случай, везенье – нечто сугубо внешнее и не зависящее от человека, и, наконец, это «деятельность души в полноте добродетели» (Аристотель), а быть или не

быть добродетельным зависит исключительно от воли человека, и в этом смысле – каждый кузнец своего счастья» [Воркачев: 264].

Под концептом *«бахт / счастье*» понимается такое чувства человека, которое выражает удовлетворение, отсюда можно предположить, чувство «бахт / счастье», связанное с эмоциями, близкими к радости, рассматривается всегда как чувство на фоне радости. Основная лексическая единица, представляющая данный концепт в русском языке, – *«счастье»*. Ключевое средство объективации концепта «счастье» в узбекском языке – это номинативная лексема *«бахт».* Базовость данных номинантов определяется: 1) включенностью их в состав ядерной лексики данных языков, 2) большим объемом лексико-семантического поля данных единиц, 3) их обширными сочетаемостными возможностями.

Согласно И.А. Стернину, когнитивная интерпретация лексических единиц предполагает «смысловое обобщение полученных результатов описания значений языковых единиц». Этап когнитивной интерпретации требуется для формулирования когнитивных признаков на основе полученных значений или семантических компонентов лексем номинативного поля. Языковое сознание материализуется и воплощается посредством языковых средств. Представители Московской психолингвистической школы А.А. Леонтьев и Е.Ф. Тарасова определяют языковое сознание как «образы сознания, овнешняемые языковыми знаками». Оно исследуется с помощью лексических единиц, которые являются предметом исследования когнитивной лингвистики. Семантическое описание лексических единиц позволяет смоделировать когнитивное сознание, что и происходит на этапе когнитивной интерпретации.

В русском языке счастье относят к сфере идеального, а в сознании русского человека оно закрепилось как что-то недостижимое. В концептосфере русского языка счастье можно найти где-то рядом с непостижимыми и фундаментальными категориями бытия и понятием «смысл жизни». И благодаря такому причислению к «высокому и духовному» русское счастье заключает в себе огромный эмоциональный заряд.

В узбекском толковом словаре выделяют 3 значения слова *«бахт /счастье»:* 1. Чувство и состояние высшего удовлетворения. 2. Созидание. 3. Удача, успех.

Н.А.Тухтаходжаева отмечает, что в узбекском языке лексико-семантическое поле «бахт» проявляется в следующих понятиях, как *«саодат»* (высшая степень счастья), *«омад»* (удача), *«шодлик»* (веселье), *«хурсандчилик»* (радость), *«такдир»* (судьба). Как в русском, так и в узбекском языках в составе лексико-семантических полей присутствует элемент выражения счастья как чувства [Тухтаходжаева: 30]. В обоих языках «бахт / счастье» образует факторы, вызывающие у субъекта положительную оценку существенных моментов.

Русское слово *«счастье»* объясняют из индоевропейских корней sъ- cestь. Бодуэн де Куртенэ считал, что приставка съ связана с санскритским su-,

означавшим «свое, родное» и «благо». Смысл второго корня – «часть» или *«доля».* Как видим, счастье в славянских языках первоначально означало *«благую долю»* или *«хороший удел»*. В результате утраты семантических и словообразовательных связей слова «часть» с лексемой «счастье» произошла модификация семантики рассматриваемого слова, что привело к переходу данной единицы из разряда конкретных предметов в разряд абстрактных имен. В узбекском этимологическом словаре данная лексема *«бахт»* имеет персидское происхождение. Анализ этимологии лексемы, репрезентирующей концепт *«бахт / счастье»,* сохранившейся в наивной картине мира, позволяет выявить семантические и национально-культурные особенности исследуемого концепта.

Концепт *«бахт /счастье»*, являясь базовой единицей концептосферы русского и узбекского языков, имеет сложную структуру, в которой выделяются ядро и периферия.

Синонимический ряд, репрезентирующий концепт *«бахт»* в узбекском языке выглядит следующим образом: *саодат, омад, шодлик, хурсандчилик, икбол, масъуд, толе, фарогат, мамнунлик.* Счастье в мировоззрении узбеков воспринимается как *везение, благополучие, состояние довольства, радости*. В синонимических рядах ядерных лексем *«бахт / счастье»* наблюдаются семантические коррелятивные пары: *мамунлик – радоваться, икбол – фортуна, толе – удача, фарогат – удовлетворение.* Синонимичные средства, использующиеся в русском и узбекском языках для обозначения данного ментального образования, в разных ситуациях имеющие коннотативную экспрессивную окраску, свидетельствуют об активном процессе осмысления концепта, его чрезвычайно высокой актуальности для носителей обоих языков.

Ю.Н. Караулов в сопоставительном ассоциативном словаре представляет ассоциативный ряд концепта «счастье». Согласно этому сопоставительному ряду, *счастье* характеризуется как нечто *собственное (мое), большое, мимолетное, семейное*, оно может ассоциироваться с деньгами, любовью, солнцем, удачей, дружбой, весельем, домом, свободой и т.д. [Караулов:78]. Но в то же время данный концепт представляется как нечто *недолговечное, непостижимое, редкое, шальное*, и очень часто ассоциируется со своим антонимом *«несчастье»*.

Как показал структурно-семантический анализ словарных единиц, в семантической структуре лексемы *«бахт / счастье»* выделяются такие семантические компоненты, как: *«шодлик /радость», «омад /удача», «оила/ семья»*. Именно они и составляют смысловое ядро концепта «бахт / счастье».
К ним можно добавить и дополнительные лексемы: *ривож - успех, обрў - авторитет.*

Когнитивные признаки концепта «бахт» проявляются в следующих категориях:

1. Счастье – дети: *фарзанд бахти – она тахти* (счастье ребенка – это счастье родителей);
2. Счастье – труд: *мехнат – бахт келтирар* (труд приносит счастье);

3. Счастье – Родина: *халқ кимни севса, бахт унга табассум қилади* (Кого народ полюбит, тому счастье улыбнется);
4. Счастье – сила: *бахтинга ишонма, бармогингга ишон* (не полагайся на счастье, а полагайся на свою силу в руках).

Таким образом, концепт счастье в узбекском языковом сознании на современном этапе понимается как состояние довольства и высшего удовлетворения. Пытаясь понять особенности концепта «бахт» в узбекском языке, неправомерно опираться, на наш взгляд, на мнения носителей языка, так как далеко не каждый из них может дать определение понятия «счастье». Вместе с тем каждый реципиент может сразу ответить на вопрос: «Счастлив он в настоящий момент или нет». В сознании носителя узбекского языка присутствует концепт «бахт /счастье», но вербализация его вызывает затруднение.

**[Литература**

1.Воркачев С.Г. Концепт счастья в английском языке: значимостная составляющая / С.Г. Воркачев, Е.А. Воркачева // Массовая культура на рубеже XX–XXI веков: Человек и его дискурс. – М.: Азбуковник, 2003. – С. 263–275.

2.Караулов Ю.Н. Русский сопоставительный ассоциативный словарь. URL: http://it-claim.ru/

3.Тухтаходжаева Н.А. Национально-культурная специфика концепта «счастье» в разносистемных языках // Филологические науки, Международный научно-исследовательский журнал, 2012, № 6. – С.30-33.

# ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЛЕКСИК МАТЕРИАЛНЫ ӨЙРӘТҮ

***Гыйләҗиева А.Н.***
***Казан шәһәре Идел буе районы 127нче мәктәбе***
***Batrus79@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье освещается способы обучения лексике татарского языка русскоязычных учащихся. Анализируется положительный опыт работы с учпщимися начаольных классов.

***Ключевые слова:*** язык, татарский язык, обучение, лексика, минимумы, текстоцентризм.

Тел – аралашу чарасы, ә сүз кулланыла торган берәмлекләр арасында төп урынны алып тора. Чит телне үзләштергәндә, аның сүзләрен белми торып, сөйләмгә чыгып булмый. Т. Б. Вепрева фикеренчә, күп еллар дәвамында телгә өйрәтеп тә, укучыларның бу телдә сөйләшә алмавы сәбәпләренең берсе – чит тел лексикасына өйрәтү методикасының дөрес юнәлештә эшләнмәве. Методист укыту вакытында сүзлек минимумы булдырылмау һәм лексиканы сайлап алу мәсьәләсе дөрес эшләнмәүне күрсәтә, дәреслекләрдә махсус лексик күнегүләр булмаганлыгын да хәбәр итә.

Совет методикасында лексикага өйрәтү мәсьәләләре 30 нчы еллар методистлары хезмәтләрендә, шул исәнтәп И. А. Грузин, А. А. Любарская кебек галимнәр эшчәнлегендә шактый урын алып тора. Бу вакытта зур игътибар лексиканы семантизацияләү мәсьәләләренә бирелә. Сүзләрне күрсәтмәлелек белән генә түгел, ә тәрҗемә юлы белән дә истә калдыруны кулай күрә башлыйлар. 30 нчы еллар ахырына шулай ук махсус лексик күнегүләр эшләнә башлый. [Вепрева 2015: 2 ] Алга таба күрсәтмәлелек сүзнең мәгънәсен ачуның бердәнбер ысулы булудан туктый һәм лексиканы үзләштерүнең өстәмә ысулына әверелә.

Лексикага өйрәтүнең төрле мәсьәләләренә зур игътибар бирелә башлый. И. В. Рахманов фикеренчә лексикага өйрәтүдә иң зур рольне күнегүләр башкара. Ул лексиканы өйрәнү, сөйләм эшчәнлегенең формалашуы икәнлеген искәртеп үтә. Төрледән – төрле лексик күнегүләр барлыкка килә башлый. Лексика беренче тапкыр грамматикага карата икенчел мөнәсәбәттә булудан туктый, аның тел материалын сайлаганда төп роле таныла башлый.

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар һәм инглиз телләрен аралашу максатыннан чыгып өйрәтү хәзерге вакытта да беренче планга куела. Моның өчен иң элек сүзләрне белү кирәк. Укучыларның дәресләрдә сүз байлыгын арттыру, лексик күнекмәләрен үстерүгә зур урын бирелә.

Лексикага өйрәтү эчтәлегенең өч компонентын аерып чыгаралар: лингвистик, методологик һәм психологик. [Сакаева, Баранова 2016: 59 ] Лексик берәмлек дигәндә аерым сүз, тотрыклы сүзтезмә яки идиома күздә тотыла. Аларның сөйләм мәсьәләләрен чишү өчен кирәкле җыелмасы лингвистик компонентын төзи. Методологик компонент лексикага уку эчтәлегенә кирәкле аңлатмаларны, белешмәлекләрне үз эченә ала. Ана сүзлекләрдән файдалану инструкцияләре, индивидуаль алып бару формасы яңа лексикалы сүзлекләр һәм

карточкалар, үзгәртеп кору ысуллары һәм өйрәнелгән лексиканы системалаштыру кирә. Психологик компоненты лексик белемнәр һәм күнекмәләр проблемасы белән бәйле карала.

Е. Н. Соловова лексик берәмлекләрне семантизацияләү өчен аеруча киң таралган алты ысулны аерып чыгара: 1 - күрсәтмәлелек куллану, 2 – синонимнар /антонимнар ярдәмендә семантизация, 3 - семантизация белән сүз ясалышының билгеле ысулларын куллану; 4 - туган телгә тәрҗемә ; 5 – укучының төрле сүзлекләрдән сүз эзләве; 6 - контекст буенча фараз кылу.

Укучылар яңа сүзләрне мәгънәләренә бәйле контекст аша истә калдыралар. Шуңа күрә укытучы дәрестә сүзләрне, аның әйтелеше һәм грамматик формалары белән истә калдыру һәм сүзләрнең текст эчендә кулланылышы, тотрыклы гыйбарәләр ярдәмендә сөйләмгә килеп керешен үзләштерүгә игътибар итә.

Инглиз теле дәресләрендә яңа лексиканы өйрәнү һәрвакыт сүзлекләрдән башлана. Хәзерге вакытта күбрәк электрон сүзлекләр кулланыла. Алар ярдәмендә укучылар үзләренең сүзлек дәфтәрләрен булдыралар. Бу дәфтәр дүрт баганадан тора: беренче баганада- инглиз телендәге сүз, икенчесендә- аның транскрипциясе, өченчесендә- рус теленә тәрҗемәсе һәм соңгысында- бу сүз белән сүзтезмәләр яки бер- ике җөмлә. Яңа лексиканың күләме акрынлап арта һәм яңа сүзләрне үзләштерү еш кына укучылар өчен күңелсез һәм шуңа күрә авыр дәрес булып тора. Соңгы елларда мондый уртак алымнар башка телләрне өйрәнгәндә дә еш файдаланыла.

Гадәттә, тел дәресләрендә яңа лексика белән эшләү үз эченә түбәндәгеләрне ала: яңа лексиканы өйрәнү; аны истә калдыру; практик күнегүләр үтәү; яңа лексиканы кабатлау һәм үз сөйләмеңдә файдалануны күрсәтү.

Гамәлдәге дәреслеклекләр һәм эш программаларын өйрәнгәннән соң, чит тел буларак инглиз телен һәм дәүләт теле буларак татар телен өйрәтү өчен тәкъдим ителгән норматив документлар һәм методик, уку-укыту әсбапларының охшашлыгы ачыкланды.

Мәсәлән, 1 нче сыйныф өчен татар һәм инглиз теле дәреслекләрендә "Әйдәгез танышабыз" дигән тема өйрәнелә. Бу дәрестә укучылар мин, син, бу, ул исем ( татар теле дәресендә), hello, goodbye, I'm a boy / girl, my name is… кебек сүзләрне өйрәнәләр. Безнең фикеребезчә, бу теманың ике тел дәреслегендә дә булу дөрес дип уйлыйбыз. Укучылар беренче дәрестән башлап чит телдә үзләре белән таныштыра алачаклар. Алга таба ике тел дәреслегендә дә "Безнең гаилә"- "My family" дигән тема бар. Ике телдә дә алар гаилә, әни, әби, әти, бабай, апам, энем, сеңлем, мин сүзләрен өйрәнәләр. Татар һәм инглиз теле дәреслекләренә "Мәктәптә"- "In school" дип аталган тема кертелгән. Укучылар карандаш, мәктәп, бетергеч, дәфтәр, китап, укытучы, такта кебек сүзләр өйрәнәләр. : "Йорт хайваннары"-, бу тема ярдәмендә укучылар авыл, сыер, ат, чеби, эт, каз, үрдәк кебек яңа сүзләр белән танышалар. Инглиз теле дәреслегендә бу тема "My pets".дип аталган. Укучылар cat- мәче, dog- эт, parrot – тутый кош, rabbit – куян, mouse- тычкан кебек яңа сүләр белән танышалар.

Темалар бер булуга карамастан ике телдә дә лексика төрле. Гомумән алганда күпчелек темалар ике тел дәреслекләрендә дә уртак. Бу яхшы күренеш дип уйлыйбыз, чөнки укучылар яңа лексиканы ике телдә дә чагыштырып өйрәнә алачаклар. Тикшерү барышында 1 сыйныфның татар теле дәреслекләрендә генә булган темаларны да искәртеп үтергә кирәк. "Бакчада"- кишер, кәбестә, бәрәңге, кабак, кыяр; "Кыш"- кар, тимераяк, чана, чаңгы, "Сәламәт бул"- баш, чәч, бит, бармак, аяк, кул, борын, "Татар халык ашлары"- гөбәдия, чәкчәк, кыстыбый, пәрәмәч, кош теле, бәлеш; "Кибеттә"- сөт, ипи, туңдырма, су;, "Шәһәрдә"- шәһәр, урам, автобус, машина кебек яңа лексиканы үзләштерә алалар. Инглиз телендә дә аерылып тора торган темалар бар. Мисал өчен, "My room", укучылар bed карават, table өстәл, chair- урындык, tv – телевизор,,room- бүлмә, house- йорт сүзләрен өйрәнәләр.

1нче сыйныф дәреслекләрендә 1 нче сыйныф темалары кабатланып киткәнен искәртеп үтергә кирәк. "Минем гаиләм"- "My family", "My love summer"- "Җәй". Ике телдә дә укучы әлеге тема ярдәмендә әни, әти, бабай, әби, җәй, кояш, ял, су коену, урман, кебек лексиканы кабатлый, ләкин аермалы яклар да бар, мисал өчен татар теле дәреслегендә "Минем гаиләм" темасында укучы онык, иртәнге аш, көндезге аш, кичке аш кебек яңа лексиканы да өйрәнә. Алга таба инглиз теле дәреслегендә "My love summer"- "Җәй" темасында укучылар sunny- кояшлы, hot- эссе, raining- яңгырлы, cold- салкын кебек яңа сүзләр белән танышып үтәләр. Тикшерү барышында 2 нче сыйныф өчен татар һәм инглиз теле дәреслекләрендә ике генә охшаш тема очраттык. Охшаш булмаганнар: татар теле дәреслегендә: " Көзге уңыш", "Мин чисталыкны яратам", "Яз"( татар теле дәреслегенә барлык ел фасылларына да кагылышлы темалар кертелгән), "Мин Татарстанда яшим", инглиз теле дәреслегендә: "I like food"- " Мин ашамлыклар яратам" , In my toy box"- " Минем уенчыклар тартмасы".

2нче сыйныф дәреслекләрендә шулай ук охшаш темалар очрады: "School days"- "Көндәлек режим" ( Яңа лексика- сәгать- clock, иртән- in the morning, иртәнге аш- breakfast, көндезге аш- dinner, кичке аш - dinner, дәрес- lesson, карандаш- pencil, китап- book, букча- school bag ) , " Family moments"- "Без әти-әниләргә булышабыз" ( Яңа лексика- әткәй- daddy, әнкәй- mommy, гаилә- family, әбекәй- granny, бабакай- grandpa) , "Furry friends"- " Кечкенә дусларыбыз" ( Яңа лексика- песи- cat, эт- dog, инглиз теле дәреслегендә боларга кушылып sheep- бәрән, mouse- тычкан, fish- балык, hourse-ат кебек яңа сүзләр дә өстәлә, татар телендә исә бу лексика 1 сыйныф дәреслегендә " Йорт хайваннары һәм кошлары" темасында үтелә һәм 4 нче сыйныфның "Хайваннар дөньясында" дигән темада кабатлана ).

Тикшерү барышында 4 сыйныф өчен татар һәм инглиз теле дәреслекләрендә бер генә охшаш тема табылды. "Минем дусларым"- "Family and friends" (Яңа лексика- дустым- friend. Әлеге тема ярдәмендә укучылар үзләренең дусларын тасвирларга өйрәнәләр. Мәсәлән кыяфәтен тасвирлау өчен лексика: озын- tall , кыска- short, чәч- hair, күз- eyes, , аның яраткан шөгылләре-

бию түгәрәге- dance club, тимер аягта шуу- skating, чаңгы шуу- skiing һәм башкалар.

Гомумән алганда, һәрбер сыйныф татар һәм инглиз теле дәреслекләрендә охшаш темалар бар һәм аларда бер төрле лексика өйрәнелә. Безнең фикеребезчә, бу уңай күренеш, укучылар ике телнең лексикасын чагыштырып истә калдыра алачаклар. Зур лексик запасны һәм лексик теорияне үзләштерү стихияле рәвештә уза алмый. Бу эшне башкарганда иң мөһим бурычларның берсе - лексик күренешләрне өйрәнү процессында башлангыч мәктәп укучыларының сүзлек запасын баету. Укучыларга яңа лексиканы өйрәнү кызыклы форматта үтергә тиеш. Шуңа ярашлы рәвештә, тикшеренү барышында яңа күнегүләр базасы да тәкъдим ителә ала.

Башлангыч мәктәп укучыларында лексик күнекмәләрне нәтиҗәле формалаштыру өчен, лексикага өйрәтүнең заманча алымнарын кулланып була. Аларның берсе булып уеннар тора. Бу ысул ярдәмендә укучыга яңа сүзләрне истә калдыру кызыклырак була. Кагыйдә буларак, лексик уеннарны яңа сүзләр белән танышу, аларны активлаштыру, хәтердә калдыру һәм кабатлау өчен кулланалар. Тикшеренүдә күренгәнчә укучыларны инглиз һәм татар телләренә өйрәткәндә, аудио, видеоматериалларны кулланырга тырышалар. Хәзерге дәреслекләрнең электрон формалары, аудиоязмалы вариантлары бар. Укутучы шулар ярдәмендә дәресне кызыклы һәм нәтиҗәле форматта алып бара ала.

**Әдәбият**


1. Вепрева Т. Б. Лексика в обучении иностранным языкам.- Санкт-Петербург: Поморский государственный ун- т , 2010. – 24 с.
2. Верещагина И. Н. Методика обучения английскому языку на начальном этапе в средней школе. – М.: Наука, 1988. – 224 с.
3. Гальскова, Н.Д. Современная методика обучения иностранным языкам. – М.: АРКТИ, 2000. – 176 с.
4. Сакаева Л. Р., Баранова А. Р. Методика обучения к иностранным языкам.- Казань: Казанский Федеральный Университет, 2016. – 35 – 36 с.
5. Фәттахова Р. Ф. Татар телендә кешегә уңай бәя бирә торган лексик һәм фразеологик берәмлекләр (лексик, структур, лингвокультрологик анализ) // Актуальные вопросы языкознания. Выпуск 6. – Казан, 2007. – 121 – 132 б.
6. Харисов Ф. Ф., Харисова Ч. М. Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар теле укыту. 1- 4 сыйныфлар: методик кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 175 б.

# ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ «БЛУМ КУБЫ» ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНУ

***Гыймадиева Д. Ш., Гыйзатуллина Л.М.,***
***МАОУ "Гимназия19"***
***dilaragimadieva@mail.ru., Liniza72@mail.ru***

***Аннотация.*** Актуальность доклада заключается в том, что «Кубик Блума» может быть использован во всех группах и по всем образовательным областям, в том числе и учителями на разных уроках .

Цель доклада: раскрыть особенности и научиться применять технологию «Кубик Блума»

Прием развития критического мышления «Кубик Блума» уникален тем, что позволяет формулировать вопросы самого разного характера.

Использование приема «Кубик Блума» только на первый взгляд кажется трудным. Но практика показывает, что прием очень нравится ученикам, они быстро осваивают технику его использования. А учителю этот прием помогает развивать навыки критического мышления и в активной и занимательной форме проверять знания и умения учащихся. Методика удобна тем, что не требует много времени на подготовку и проведение занятия и может быть использована на всех этапах урока, в качестве рефлексии.

***Ключевые слова:*** «Кубик Блума», критическое мышление, описание, урок, технология.

Әлеге технология, шәхес, метапредмет, предмет нәтиҗәләренә ирешүгә юнәлдерелгән, шуңа күрә ФГОС позициясеннән актуаль. Хәзерге белем бирүнең максатлары булып «фәнгә түгел, ә өйрәнергә өйрәтү» принцибы тора.

Укытучының бурычы - әзер белемнәрне һәм күнекмәләрне тапшыру түгел, ә баланың шәхесен үстерү өчен шартлар тудыру. Педагогның һөнәри компетентлыгы заманча белем бирү технологияләрен куллануны сорый. Аларның һәрберсе үзенчә кызыклы. Ләкин иң уңышлысы дип критик фикерләү технологиясе санала, чөнки ул укучыларның эшчәнлегенә туры килә.

Критик фикерләүне үстерү технологиясенең максаты - балаларга киләчәктә тормышта кирәк булган фикерләү күнекмәләрен үстерүдә (карарлар кабул итә белү, мәгълүмат белән эшләү, төп һәм икенчел фикерләрне аеру, күренешләрнең төрле якларын анализлау) чагыла.

Критик фикерләү сәләтен үстерү өчен дәресләрдә без махсус ысуллар кулланабыз. Мәсәлән: «Беләм – белергә телим – белдем», «Дөрес һәм дөрес булмаган раслаулар», «Авыр һәм җиңел сораулар» һ.б.

Критик фикерләү, беренче карашка, тәнкыйди фикер йөртү, тәнкыйть күзлегеннән карау дип кабул ителә. Ләкин белем бирү системасында бу төшенчә стандарт булмаган фикерләүне, укытуның иң югары дәрәҗәдә камиллеген ассызыклый. Ул – интелектуаль (гамәли) эшчәнлек төре: мәгълүматны кабул итү, төшенү, хәтердә калдыру, иҗади, интуитив фикерләү.

Бүген сезнең игътибарыгызга Америка галиме һәм психологы Бенджамин Блум тарафыннан эшләнгән критик фикерләү үсеше технологиясенең бер ысулын тәкъдим итәсебез килә, ул «Блум Кубы» дип атала.

Куб - зур фигура, аның һәр ягында сүзләр язылган (яисә схема-рәсемнәр ясалган, бу укучы балалар өчен иң кулай). Алар җавап өчен башлангыч нокта. Шулай итеп, җавап вакытында, бала үз тәҗрибәсеннән һәм танып белүдән чыгып проблемаларны чишү юлларын эзли.




Бу ысулның төп инструменты –куб. Билгеле булганча, куб алты яктан тора, һәр ягына бирем язылган. Шакмактагы биремнәр фикерләү эшчәнлегенең алты ягын чагылдыралар. Нәтиҗәдә укучылар укылган текстны яки проблеманы төрле яктан ачалар, төрле ракурстан карап эш итәләр.

- Тасвирла / Опиши (сурәтлә, текстның яки куелган проблеманың фактларын санап чык, сөйләп чык, атап чык);
- Ассоцияция китер / Проассоциируй (нәрсәгә охшаган икәнлеген ачыкла);
- Куллан / Примени (мисаллар китер: сүзтезмәләр, җөмләләр төзе);
-Чагыштыр /Сравни (аермалы якларын тап);
- Иҗат ит / Придумай (тема буенча диалог, кечкенә сочинение, синквейн, план төзе h.б. иҗади эшләр);
- Бәя бир / Оцени (өйрәнелгән материалның үзенә әһәмиятле якларын билгелә, аргументлар китер, исбатла, уңай һәм тискәре якларын әйтеп кит).

Куб белән уен кагыйдәләре бик гади:

1. Укучылар белән уртак эшчәнлек формалаштырыла. Дәрес темасы буенча җавап бирергә тиешле сораулар билгеләнә.
2. Укытучы яки бала кубны ыргыта.
3. Төшкән ягы нинди сорау бирергә кирәклеген күрсәтә.
4. Бирем кубтагы барлык сорауларга җавап бирелгәнче дәвам ителә.

Мәсәлән:

- “Әйт” биреме белемнәрнең гади репродукциясен үз эченә ала. Аны дәрестә ничек кулланырга?

- “Ни өчен” биреме процессларны, күренешләрне яки предметны җентекләп тасвирларга мөмкинлек бирә.

- “Уйлап тап” биреме сораулары фаразлау, уйлап чыгару элементларын үз эченә ала.

Бу ысул төрле характердагы сорауларны формалаштырырга мөмкинлек бирүче алым. «Блум Кубы» ярдәмендә педагог бөтен дәресне үткәрә ала, шулай ук аны дәрес этапларының берсе буларак та кулланырга мөмкин. Куб белән төркемнәрдә дә, аерым да эшләргә мөмкин.

Төркем белән эш.

Һәм хәзер без сезгә «Блум Кубы» нигезендә белем бирү эшчәнлеген модельләштереп карарга тәкъдим итәбез.

- Без сезнең белән Һ.Такташның «Мокамай» әсәре буенча «Блум кубы»на язылган биремнәрне үтәрбез. (Укучылар белән әлеге бирем Һ. Такташ иҗатын, «Мокамай» шигырен ничек үзләштерүләрен билгеләү максаты белән үтәлә)

***Әйт.***

*- Төп геройларның исемнәрен әйт.*

*- Һ.Такташ кайда туган?*

*- Шигырьдә кулланылган шәһәр исемен әйт.*

*- Мокамай нинди эшне бик яхшы башкарган?*

*- Мокамайның яхшы якларын әйт.*

*- Әсәр кем исеменнән сөйләнә?*

***Ни өчен?***

*- Ни өчен Мокамай начар адымга бара?*

*- Ни өчен авыл халкы Мокамайны гаепли?*

*- Ни өчен Мокамай әйберләр урлаган?*

***Аңлат.***

*-Такташ бәхетсез дусты турында шигырь язып дөрес эшләде дип уйлыйсыңмы?*

*- Дустын яхшы итеп күрсәтәсе килү теләген аңлат.*

*- Дусты Мокамай белән авторның нинди уртак сыйфатлары бар?*

*-“Мин тормышта һаман яктыга,*
*Югарыга табан юл алдым “ – юлларын ничек аңлыйсың?*

***Тәкъдим ит.***

*- Мокамайга “түбәнлектән” чыгу юлын тәкъдим ит.*

*- Шигырьгә башка исем тәкъдим ит.*

***Уйлап чыгар.***

*- Мокамайның тормышын үзгәртә алырлык вакыйга уйлап чыгар.*

*- Мокамай исән калса аның тормышы ничек булыр иде?*

***Уртаклаш.***

*- Бу шигырьдә сиңа кайсы юллар ошады яки ошамады?*

*- Начар кешене яратып буламы?*

*- Мокамай кебек балалар бүгенге көндә бармы?*

*- Шигырьдә сиңа нык тәэсир иткән момент белән уртаклаш.*

- *Тормышта төрле авырлыклар килеп чыгарга мөмкин, аларны җиңәргә кешедә зур ихтыяр көче булырга тиеш. Моңа ирешү өчен нишләргә кирәк соң?*

«Блум Куб»ын куллану беренче карашка гына авыр тоела. Укучыларга әлеге ысул белән эшләү бик ошый, алар аны куллану техникасын тиз үзләштерәләр. Ә укытучыга бу алым критик фикерләү күнекмәләрен үстерергә һәм балалар белән уртак эшчәнлек төзергә ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Беспалько В.П. Педагогика и прогрессивные технологии обучения.- М.: Издательство ИРПО МО РФ, 1995. - 336 с.

2. Выготский Л.С. Педагогическая психология. - М.: Педагогика Пресс, 1999. - 536 с.

3. Генеке. Е.А. Активные методы обучения: новый подход. - М.: Сентябрь, 2013. - 176 с.

4. Хасанова Ф.Ф. Татар әдәбияты.6 класс –Казан: Мәгариф- Вакыт, 2017.

# Ф. ӘМИРХАННЫҢ ТАТАР БАЛАЛАРҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ӘДӘБИЯТЫН ҮСТЕРҮДӘГЕ РОЛЕ

***Гыйниятова Ч. Ш.***
***МБОУ "Большекукморская средняя школа им. М.М. Мансурова»***
***latipchulpan@gmail.com***

***Аннотация.*** В этой научной статье рассматриваются произведения Фатиха Амирхана, которые написаны для детей. Ф. Амирхан – писатель, который оставил большой след в татарской детской литературе. В произведениях для детей он известен как писатель, понимающий психологию ребенка, как художник, описывающий эмоции различными средствами искусства, как писатель, глубоко понимающий роль литературы в воспитании детей. Роль Ф. Амирхана в татарской детской литературе особенная. Он оставил неизгладимый след в этой области и своим творчеством и журналистской деятельностью.

***Ключевые слова:*** Ф. Амирхан, детская татарская литература

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан мәдәни тарихыбызда лаеклы урын тоткан иң күренекле шәхесләрнең берсе. Фатих Әмирханның әдәби мирасы бай һәм затлы.

Фатих Әмирхан – укытучы-педагог. Мәгариф өлкәсен үстерүгә алдынгы карашлары белән дә сизелерлек өлеш кертте. Укучыларның эчке дөньясын яхшы белү Фатих Әмирханга, язучы буларак, балаларның күңелләренә үтеп керерлек, аларны табигый кызыксындырырлык әсәрләр иҗат итәргә мөмкинлек биргән.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай да Фатих Әмирхан әсәрләрен балаларның рухына тәэсир итү хасиятен бәяләгән, аларның мәктәп-мәдрәсәләрдә укытылуын хуплаган.

Әдип татар балалар әдәбиятын үстерүгә зур көч куя. Бу өлкәдәге эшчәнлеген ул Мәскәүдә чыгып килгән "Тәрбиятел-этфаль" журналыннан башлап җибәрә дисәк, мөгаен, хата булмас. Әдипнең журналны башыннан ахырына кадәр үзе эшләп чыгаруы турында да мәгълүматлар сакланган. "Тәрбиятел-әтфаль" – татар телендә балалар өчен махсус чыгарылган беренче матбугат. Ф.Әмирхан журналның тәүге санында ук, аның мәсләген билгеләп: "... Без ата-аналарга ярдәмче вә балаларга мөгаллим вә остаз гына түгел, бәлки аларның яхшы иптәшләре булырга телибез", - дип язып чыга.

Журналда ул фәнни һәм тәрбия мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләрен, әдәби тәрҗемәләрен һәм аерым әсәрләрен бастыра. Биредә дөнья күргән тәрҗемәләрнең иң матур үрнәкләре – Х.Андерсенның "Мәхәббәтсез үрдәк баласы", "Гөл агачы һәм әкәм-тәкәм" әкиятләре һ.б. булуы билгеле.

Журнал чыгудан туктагач, Г.Тукайның аңа багышлап язган "Тәрбиятел-әтфальгә" шигыре басылу да әлеге басманың үз вакытында тоткан урынын һәм әһәмиятен бәяләргә мөмкинлек бирә.

Казанга кайткач, 1907 нче елдан басыла башлаган “Әлислах” газетасында да Ф.Әмирхан эшчәнлеген халыкны, балаларны агарту юнәлешендә дәвам итә: “Тәрбия вә гыйлемханәләребезне тамырыннан яңартып корырга кирәк! Эшкә сәләтле, гайрәтле, зыялы татарлар чыга торган мәктәп вә мәдрәсә тәртибе, фәне, мөдәррисләре кебек”,- дип, белем, тәрбия мәсьәләләрендә үзенең борчылуын ул җәмәгатьчелеккә җиткерә.

Газета битләре аша ул әлеге надан муллалардан һәм хәлфәләрдән, байлардан көлә. “Казанның педагоглары”, “зур педагоглар” зур эш эшләп кайттылар”, “Мәктәп лаихәләре (проекты) өчен аяклар” һ.б. мәкаләләрендә аның сатирага осталыгы аеруча күзгә ташлана. Мондый хезмәтләрендә ул иске мәктәп-мәдрәсә тәртипләрен тәнкыйтьләп кенә калмый, уку-укыту эшләрен яхшырту юнәлешендә, мәктәпләр өчен дәреслекләр төзүдә аерым фикер һәм киңәшләрен дә бирә. 1918 нче елда, педагог Г. Рафиков белән берлектә, эш мәктәпләренең беренче һәм икенче сыйныфлары өчен “Ана теле” дәреслекләрен төзи.

30 нчы еллар урталарында хөр фикерле әдипнең аерым карашлары һәм әсәрләре тәнкыйтькә дучар ителә. Чөнки Ф.Әмирхан XX гасыр башындагы революцион борылышларны шатланып каршы алса да, соңрак, большевикларның гаделсезлеген күреп, хаталанганын аңлый, аларның аерым фикерләре һәм тоткан юллары белән килешми, карашларын үзенең әсәрләрендә дә яктырта. Болар исә әдип өстенә пычрак ату өчен сәбәп була. Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Ибраһимов, Х.Вәли, Г. Нигъмәти, Г.Гали, Г.Толымбай һ.б. аны “конрреволюционер, буржуазный язучы, буржуазия ялчысы” дип тамгалыйлар, әсәрләрен исә “ят һәм зарарлы” дип бәялиләр.

Балалар өчен язылган әсәрләрендә ул бала психологиясен аңлаучы әдип, хис-кичерешләрне төрле сәнгать чаралары белән сурәтләүче рәссам, әдәбиятның балаларны тәрбияләүдәге ролен тирәнтен аңлап иҗат итүче язучы буларак танылa. Аның “Нәҗип”, “Ул үксез бала шул”. “Корбан”, “Халык кызлары” һ.б. әсәрләрен бүген дә балалар яратып укыйлар.

“Нәҗип” хикәясе үзәгенә куелган төп фикер – һөнәрле кешенең кадерен, кирәклеген күрсәтү. Төп – герой Нәҗип. Ул әсәр башында абыйсы Гомәр белән капма-каршы куела. Каршылык нигезендә һөнәрле, курайда уйный белүче Гомәрнең Нәҗипкә караганда өстенрәк һәм башкаларга кирәклерәк булуын тасвирлау ята. Әмма әсәр дәвамында Нәҗип үсештә бирелә. Автор балаларга хас аерым сыйфатларның кешене көлкегә һәм уңайсыз хәлләрдә калдыруын мисаллар белән сурәтләп бирә. Нәҗипнең уңай якка үзгәрүен күрсәтү аша ул балаларда гаделлек, әдәплелек тәрбияләргә, һөнәрнең кеше язмышында тоткан урынын күрсәтергә омтыла. Әсәрнең эстетик кыйммәте дә нәкъ менә шунда: ул сабый күңелен, баланың рухи дөньясын үзенчәлекле әдәби чаралар ярдәмендә, үсештә күрсәтә, матурлыкны аңлый белергә өйрәтә. Сабый күңелен табигать күренешләре белән гармониядә карау, параллельләр үткәрү – шулай ук төп идеяне укучыга җиткерү ягыннан әһәмиятле. Хикәя азагында Нәҗип тә һөнәргә ия була. Дәвамлы рәвештә эзләнү, газаплану хисләре кичергән малайның матур

сәләте – үз кулы белән ясаган чәчәкләрендә нәфис зәвыгы, гүзәллекне аңлый һәм тудыра алу зирәклеге ачыла.

1913 нче елда беренче тапкыр балалар журналы “Ак юл”да басылган “Ул үксез бала шул” хикәясе дә, үзенең кыска гына күләмле булуына карамастан, зур проблеманы – ятимнәргә мөнәсәбәт мәсьәләсен үзенчәлекле хәл итүе белән игътибарны җәлеп итә. Биредә дә, алда телгә алынган хикәя герое кебек үк, геройлар үсештә бирелә. Үсеш, үзгәреш нәрсәдән гыйбарәт соң? Сюжет гади генә. Гает көнне көндәгечә малайлар ишек алдына җыелалар, ләкин алар гадәттәгедән башкарак – бәйрәмчә, яңарак һәм матуррак киемнәрен кигәннәр. Бары бер малай – “ата-анасы үлгәнлектән быел берәүдә хезмәт итеп торган асрау малай – Нури” гына һәрвакыттагыча, иске киеменнән. Чабышу-узышу вакытында малайлар арасында килеп чыккан каршылык нәтиҗәсендә балаларга хас булганча, үртәшү, Нурины кимсетү башлана. Бу исә, үз чиратында, Нуриның болай да яралы йөрәген тагын да телгәли, ул елап җибәрә. Әлеге хәл бөтен җыелган малайларны айнытып җибәргәндәй итә, һәм алар үз хаталарын аңлыйлар. Биредә автор гади тел белән кеше хисләре белән уйнарга ярамаганлыгын аңлата, дуслык кадерен белү, башкаларның хәленә керү кебек сыйфатлар тәрбияләргә омтыла. Нечкә психолог буларак, Ф.Әмирхан балалар теле белән аерым сыйфатларның начар гадәт булуына төшендерә. Вакыйгаларның беренче зат – “мин” исеменнән алып барылуы да хикәянең тәэсир итү көчен арттыра.

Авторның балалар өчен язылган “Корбан” хикәясенә килсәк, биредә күтәрелгән фикер беркадәр үзенчәлекле. Әсәрнең төп уңышы – персонажның күңел дөньясын, хис-кичерешләрен оста, тормышчан итеп сурәтләп бирүдә. Хикәяне уку дәвамында геройның шатлык һәм газаплары шулкадәр тәэсир итә ки, әйтерсең лә ул вакыйгалар эчендә үзең кайныйсың. Алдагы хикәяләрдән аермалы буларак, “Корбан”да герой үсеш-үзгәрештә бирелми. Автор аны аерым бер вакыйгаларда – сарык бәтие “Хөсәен”гә мәхәббәте планында гына ача, сабый баланың матурлыкка тартылуын, табигать белән гармониядә яшәргә омтылышын сурәтли. Әмма аның “Хөсәен”гә булган мәхәббәте фаҗигале төстә өзелә. Язучының төп идея-фикере дә нәкъ менә шушы вакыйгада яшерелгән. Ул – өлкәннәрнең бала күңелен аңлап бетермәве, сакчызлыгы һәм хәтта ваемсызлыгы. Әлеге фикер хикәянең үзендә үк хикәяләүче герой авызыннан әйтелә: “...Аналар кайсы вакытта бик гаҗәп булалар бит алар: әллә нинди күңелле, әллә нинди рәхәт булырлык нәрсәләрне санга такмыйлар”. Ягъни турыдан-туры балалар күңелен аңлап бетермиләр. Бу юнәлештән чыгып бәяләгәндә, хикәя өлкәннәр өчен дә гыйбрәт алырлык.

Язучының үткен сатирик тел белән иҗат ителгән әдәби әсәрләрендә, журналистика эшчәнлегендә милләт язмышы өчен борчылып яшәү, аны прогрессив аңлы итеп күрергә теләү сизелеп тора. Әдәби геройларның психологик дөньясын сурәтләү аша ул милли әхлакны, кеше рухын үстерүне алгы планга куя. Балалар өчен язган “Корбан”, “Ул үксез бала шул!” һ.б. әсәрләрендә Ф. Әмирхан әнә шулай үсеп килүче буынны тәрбияли, олы

хакыйкатьне ача: бу дөньяда кеше рәнҗетүдән дә яманрак эш юклыгын искәртә.

Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе – нугай мирзасы Йосыф кызы Сөембикә (Сөенбикә) турында инде татар әдәбиятында байтак әсәрләр язылды һәм языла. “Сөенбикә”дә Ф.Әмирхан беренчеләрдән булып татар әдәбиятына батыр ханбикә образын алып килә. Өченче хикәядә этисе тарафыннан картада оттырылган Зөлхәбирә язмышы бирелә. Өч хикәяне берләштереп торучы төп идея-фикер Ф.Әмирханның “Татар кызы” әсәре һәм, гомумән, иҗатында тоткан төп темаларның берсе белән аваздаш. “Халык кызлары”нда әдип заманында көн кадагында торган мәсьәләсен күтәрә. Татар хатын-кызларын искиткеч гүзәл һәм батыр йөрәкле итеп, хыялында йөрткәнчә тасвирлый.

**Әдәбият**

1. Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр.- Казан: татгосиздат, 1941. -381 б.
2. Даутов Р., Нуруллина Н. Совет Татарстаны язучылары:библиографик белешмә.- Казан: Татар. кит. нәшр,1986.- Б. 594-597
3. Климович Л. Фатих Әмирхан иҗаты// Казан утлары.- 1976. - №1. – Б. 105-110.
4. Ханбиков Я. Просветительская деятельность и педагогические идеи Фатиха Амирхана// Из истории педагогики Татарии.Сб. 2.-Казань, 1972. - С.19-33.

# ФОРМИРОВАНИЕ УНИВЕРСАЛЬНЫХ УЧЕБНЫХ ДЕЙСТВИЙ НА УРОКАХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

***Давлетгареев Д.Р.***
***Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы***
**dawletgareev1986@yandex.ru**

***Аннотация***. Реализуя стандарт, каждый учитель должен задумываться, прежде всего, о развитии личности ребёнка, необходимости формирования универсальных учебных умений, без которых ученик не сможет быть успешным ни на следующих ступенях образования, ни в профессиональной деятельности. Статья посвящена вопросу формирования универсальных учебных действий на уроках татарского языка.

***Ключевые слова***: универсальные учебные действия (УУД), личностные УУД, регулятивные УУД, познавательные УУД, коммуникативные УУД.

ФГОС ставит перед учителем новые цели. Задача учителя – научить ребёнка не только читать, писать и считать, но и привить две группы новых умений. Во-первых, это универсальные учебные действия, составляющие основу умения учиться. Во-вторых, формировать у детей мотивацию к обучению.

В современных условиях учителю начальных классов приходится решать целый комплекс профессиональных и около профессиональных проблем. С одной стороны добиться соответствия знаний, умений и навыков школьников требованиям учебных программ, с другой стороны создать комфортность пребывания школьника в классе и в школе и создавать оптимальные возможности для интеллектуального развития всех обучающихся в классе, т.е. учебная деятельность должна быть богатой по содержанию, требовать от школьников интеллектуального напряжения, и в то же время материал должен быть доступным детям. Важно, чтобы ученики поверили в свои силы, испытали успех в учёбе, что является сильнейшим мотивом, вызывающим желание учиться.

Главная цель работы с детьми – научить их мыслить. Именно поэтому обучающиеся стараются выражать свои мысли в устной и письменной форме, анализировать ответы сверстников, с удовольствием принимают участие в спорах по тем или иным вопросам как с учителем, так и с классом.

Формирование универсальных учебных действий на уроках татарского языка является одной из важнейших задач в рамках внедрения ФГОС. Т.е. ребенок должен научиться **учить себя**. Это означает, что школьник не равнодушен к той деятельности, которой занимается, осознает важность получения знаний, умеет ставить проблемные вопросы и находить пути для их решения, анализирует свою деятельность, оценивает успехи, определяет причины ошибок и неудач. И в решении этой задачи главное место занимает формирование системы универсальных учебных действий.

В составе основных видов УУД можно выделить 4 блока:

1. личностные;

2. регулятивные;
3. познавательные;
4. коммуникативные.

На уроках татарского языка и литературы личностные УУД – это формирование умения высказывать своё отношение к герою, выражать свои эмоции; умение оценивать свои поступки, согласно ситуации и соотносить поступки героев с собственной точкой зрения.

**Личностные УУД** – это умения самостоятельно делать свой выбор в мире чувств, ценностей и отвечать за свой выбор. На уроках татарского языка личностные результаты достигаются с помощью литературных произведений и текстов из учебников. На уроках под руководством учителя ученик учится:

- осознавать роль языка и речи в жизни людей;
- эмоционально «проживать» текст, выражать свои эмоции;
- понимать эмоции других людей, сочувствовать, сопереживать, предполагать и прогнозировать будущие события;
- высказывать своё отношение к героям прочитанных произведений, к их поступкам;
- придумывать окончания истории или неоконченного текста;
- самостоятельно определять и высказывать самые простые, общие для всех правила поведения.

Основная задача на уроках – развитие у детей таких социальных качеств, как уважение к старшим, доброта, честность, трудолюбие, бережливость, дисциплинированность, любознательность, стремление быть сильным и др. Эти важные общественно-значимые качества развиваются на каждом уроке через различные формы работы:

- интеллектуальные, ролевые игры;
- групповое чтение;
- обсуждение прочитанного;
- работа с пословицами;
- работа в группах;
- выполнение различных поручений и т.д.

**Регулятивные УУД** – это целеполагание, планирование, прогнозирование, контроль, коррекция, оценка своих действий. На уроках татарского языка ученик учится:

- высказать своё предположение на основе учебного текста;
| «Туган җирем» («Моя Родина») | «Туган җирем» бүлеге гражданлык тәңгәллеген аңлауны ныгытуга, патриотизмны, Ватанны яратуны үстерүгә юнәлтелгән.<br>Татар теленең грамматик категорияләренең үзенчәлеге (мәсәлән, исемнәрнең сан, килеш категориясе). Исемнәрнең аерым грамматик формаларын куллану нормаларын практикада үзләштерү [2: 7]. | Парларда эшләү, исемнәрне нинди сорауга җавап бирүләренә карап, ике төркемгә бүлү: «Нәрсә?» яисә «Кем?» Исемнәрнең лексик мәгънәсен күзәтү. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрен тану, исемнәрнең санын билгеләү, исемнәрнең санын үзгәртү, җанлы һәм җансыз исемнәрнең аермасын ачыклау [2: 32]. |

Тематик планлаштыру бүлегендә бирелгән «Укучыларның эшчәнлек төрләре» бүлекчәсе планлаштырылган нәтиҗәләрне тәңгәл китерергә, дәрес

эчтәлеген төзергә, дәрес эчтәлеген тәшкил иткән уку мәсьәләре һәм грамматик биремнәр системасын төзергә максатчан юнәлеш булып тора.

Мәсәлән, «Туган җирем» бүлеге, «Исем» темасында планлаштырылган предмет нәтиҗәләрен чагыштырып карауны таблицада түбәндәгечә күрсәтәбез.

| **Бүлек, тема исеме** | **Программаның эчтәлеге** | **Яңартылган ФДББС** | **Якынча эш программасы «Туган тел (татар теле)» укыту предметы башлангыч гомуми белемнең 1–4 сыйныфлары өчен туган телдә (татар телендә) белем алган белем бирү оешмалары өчен** |
|---|---|---|---|
| «Туган җирем» («Моя Родина») | «Туган җирем» бүлеге гражданлык тәңгәллеген аңлауны ныгытуга, патриотизмны, Ватанны яратуны үстерүгә юнәлтелгән. Татар теленең грамматик категорияләренең үзенчәлеге (мәсәлән, исемнәрнең сан, килеш категориясе). Исемнәрнең аерым грамматик формаларын куллану нормаларын практикада үзләштерү [2: 7]. | – өйрәнелә торган телнең фонетикасы, лексикасы, грамматикасы, орфографиясе һәм пунктуациясе турында башлангыч белемнәрнең формалашуы, шулай ук алынган белемнәрне сөйләм эшчәнлегендә куллана белү күнекмәләре: тел нормасы нигезендә өйрәнелә торган телнең авазларын һәм сүзләрен тану, аеру, фонетик хаталардан башка әйтү. | – сузык һәм тартык авазларга характеристика бирү;<br>– исемнәрне танып, аларның сөйләмдәге ролен билгеләү;<br>– исемнәрне күплек санда куллану;<br>– ялгызлык һәм уртаклык исемнәрен аеру. |
| | | – өйрәнелә торган коммуникатив-сөйләм материалы чикләрендә | – укыган текстны аңлау;<br>– таныш тел материалында төзелгән аудиотекстны ишетеп аңлау; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | үзләштерелгән сүзләрне сөйләмдә куллану; өйрәнелә торган телнең лексикасын тематик принцип буенча төркемләү. | – үзе турында, дуслары һ.б. турында сөйләү. |

Эш программалырының тематик планлаштыру бүлегендә бирелгән укучыларның эшчәнлек төрләре бирем эчтәлеген генә түгел, биремнәрнең эчтәлеген, укучылар эшчәнлеген оештыру формасын, дәрес төзелешендә һәм эчтәлегендә эшлекле якын килеп эшләү принциплары чагыла.

Бу үзгәрешләрнең барысы да укучыларны шәхес буларак үстерүне күздә тотып кертелгән, белем бирү процессының сыйфатын арттыруга юнәлтелгән.

## Әдәбият


1. Примерная рабочая программа учебного предмета «Родной (татарский) язык» для 1–4 классов начального общего образования для общеобразовательных организаций с обучением на родном (татарском) языке. – URL: https://fgosreestr.ru/ (дата обращения: 07.02.2023).

2. Федеральный государственный образовательный стандарт начального общего образования: утвержден Приказом Министерства просвещения Российской Федерации от 31.05.2021 № 286. – URL: https://fgos.ru/fgos/fgos-noo/ (дата обращения: 07.02.2023).

# УКУЧЫЛАРНЫҢ ИҖАДИ ФИКЕРЛӘВЕН ҮСТЕРҮДӘ КРИТИК ФИКЕРЛӘҮ ТЕХНОЛОГИЯСЕ АЛЫМНАРЫН КУЛЛАНУ

***Закирова Г.Ф.***
***Казан шәһәренең 125 нче гимназиясе***
***zakirova-100@yandex.ru***

***Аннотация.*** Для развития творческих способностей обучающихся на своих уроках я частенько обращаюсь к приемам технологии развития критического мышления. Эти приемы настолько интересны, что не оставляют равнодушными ни одного учителя и ученика. В своей статье я рассказываю о самом любимом приеме моих учеников – «Акростих». Думаю, другим учителям тоже будет интересно узнать об особенностях использования данного приема на уроках родного (татарского) языка.

***Ключевые слова:*** обучение, критическое мышление, технология.

Мәгърифәтче Риза Фәхретдин үз заманында: «Күп белдерүгә караганда, аз белдереп, эзләнү орлыгын салу, эзләгәнен үзе табарга өйрәтү, юлларын күрсәтү - мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр, оста эшедер», - дип язып калдыра. Шактый вакыт үтсә дә, бөек мәгърифәтченең бу фикере үзенең актуальлеген хәзер дә югалтмый.

Бүгенге көндә белем бирүнең төп максаты – укучыга белемнәр, күнекмәләр суммасын җиткерү генә түгел, ә аның үзен мөстәкыйль рәвештә белем алырга һәм бу белемнәрне тормышта иҗади кулланырга өйрәтү, ягъни үзгәреп торучы тормыш шартларында шәхеснең мөстәкыйль фикерләү мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итү. Әлеге максатка ирешү җәһәтеннән мин еш кына дәресләремдә критик фикерләү технологиясе алымнарына мөрәҗәгать итәм. Бу технологиянең яңалыгы - аның алымнарында, ягъни иҗади шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыруында.

Бу технологиянең актуальлеге түбәндәгеләрдән гыйбәрәт:

1) укытуда эшчәнлекле юнәлешне тормышка ашырырга мөмкинлек бирә;

2) укучының иҗади потенциалын, мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү өчен шартлар тудыра;

3) танып-белү эшчәнлеген үстерүгә юнәлтелгән универсаль уку гамәлләре формалаштыруда ярдәм итә.

Бурычлары:

1) укучы һәм укытучы арасында иҗади хезмәттәшлек булдыру; укучыны креатив эшчәнлеккә тарту;

2) белем бирү процессын оптимальләштерү, белем алуга уңай омтылыш (мотивация) булдыру.

Мәкаләмдә мин үз укучыларымның иң яраткан ысулы – «Акростих язу» алымы турында сөйләп китәргә телим.

Акростих - грек сүзе, юл кырые, рәт кырые дигәнне аңлата. Аны безнең эрага кадәр 6-5 гасырда яшәгән борынгы грек шагыйре һәм драматургы Эпихарм уйлап тапкан. Акростихның бик күп төрләре бар. Шулар арасында иң еш кулланыла торганнары түбәндәгеләр:

**Акростих–ачкыч.** Ачкыч сүз вертикаль буенча языла һәм шул сүз, төшенчә турында шигырь языла. Бу форма күбрәк табышмакны хәтерләтә.

**Акростих-багышлау.** Исемнәр буенча языла, беренче хәрефләрдән укыла торган сүз аның адресатын белдерә.

**Акростих–шифр.** Беренче хәрефләрдән укыла торган сүзнең шигырьнең эчтәлегенә катнашы булмаска мөмкин. Бу төр күбрәк хисләрне аңлату, яки цензураны урап узу өчен, хәтта шпионажда да кулланылган.

Акростихта рифма булырга мөмкин, булмаска да мөмкин. Ул тулы шигырь формасында булырга мөмкин, һәр юлда бер генә сүз булырга да мөмкин.

Дәрестә бу алымны кулланган вакытта түбәндәге эш этапларын үтәү мәҗбүри:

1. Иң элек темага бәйләнешле сүз, сүзтезмә, төшенчә сайлап алына.
2. Аннан соң сүзлекләр ярдәмендә сүзлек эше үткәрелә, ягъни теге яки бу хәрефкә башланган сүзләр язып алына. Бу эшне төркемнәрдә эшләү бик уңайлы. Әйтик, һәр төркемгә 1 яки берничә хәреф бирәбез дә, алар аерым битләргә шул хәрефкә башланган сүзләрне язып алалар. Соңыннан документ-камера аркылы аларны тактага чыгарабыз.
3. Сүзләр арасыннан акростих язылачак сүзгә мәгънәви яктан бәйләнгәннәрен ачыклыйбыз.
4. Шигъри юлларга салабыз.

Мәсәлән, КИТАП сүзен тәкъдим итәбез икән, шигырь менә болай килеп чыгарга мөмкин:

**К**өн саен күрәсең аны,

**И**ртән, көндез, кичен дә.

**Т**абыну гына аз аңа.

**А**кыл анда, белем анда.

**П**акьланыр күңелең дә.

Иҗади хыялга бөтен кеше дә ия. Аеруча балалар иҗатка тартыла һәм бу төрдәге эшләр укучыларга бик ошый, чөнки алар балаларга иҗади потенциалларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Әлбәттә, бу эшне һич кенә дә күңел ачуга гына кайтарып калдырырга ярамый, укытучыдан нык әзерләнү сорала.

Акростих алымы ярдәмендә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин:

1. Укучыларның сүзлек запасы байый.
2. Баланың сүзгә ихтирамы арта, сөйләм теле үсә.
3. Дәрескә кызыксыну туа. Бертөрлелектән качабыз. Ярыш элементлары кертеп җибәрә алабыз: Кем тизрәк яза? Кем матуррак яза?
4. Иҗади фикерләү сәләте үсә. Телчеләр, әдәбиятчылар буларак безнең төп бурычыбыз - балаларны иҗатка тарту, иҗади сәләтләрен уятып җибәрү, образлы фикерләүне үстерү.

Акростих алымын дәреснең кайсы этапларында кулланырга була? Әйтик, дәреснең темасын кызыклы итеп тәкъдим итү, уку мәсьәләсен кую этабында:

**С**ары

**Ы**спай
**Й**омры
**Ф**айдалы
**А**кыллы
**Т**ырыш

Шулай ук, белемнәрне кабатлау яки ныгыту этабында да әлеге алымны файдаланырга мөмкин. Әйтик, сыйфатларны үтәбез икән, сыйфатларны кулланып акростих язып алабыз. Гомумән, бу алымны дәреснең барлык этапларында да кулланырга була дигән нәтиҗәгә киләбез.

Белгәнебезчә, күңелгә якын эш кенә сәләтне үстерә. Әгәр дә дәрестә уйнап кына, уйлап кына иҗади эшләр белән шөгыльләнәбез икән, без балаларның уйлау, уйнау, иҗади фикерләү сәләтен үстерә алачакбыз.

**Чыганаклар**


1. Википедия (https://ru.wikipedia.org/wiki/Акростих)
2. Технология развития критического мышления https://www.ya-roditel.ru/professionals/pedagogika/tekhnologiya-razvitiya-kriticheskogo-myshleniya/)

# ДӘРЕСЛӘРДӘ ТАТАР КИНОСЫ

***Закирова Р.А, Муллагалиева Х.М.***
***Менделеев шәһәренең “1нче номерлы гимназиясе”***
***89872821800@mail.ru, www.halida1969@mail.ru***

***Аннотация.*** После противоречивых мыслей, мы решили снять детский фильм. Эту идею с удовольствием подхватили и ученики. Был составлен план снять два фильма для начальных классов. Первым делом мы внимательно просмотрели учебники учащихся 1 - 4 классов, выбрали понравившиеся сюжетные тексты, определили актеров для съемок, распределили по ролям слова, которые нужно было выучить, подготовили костюмы, необходимые атрибуты. Затем началась подготовка к съемкам по рассказу Резеды Валеевой “В день рождения”. Эта работа оказалась очень интересной не только для учителей, но и для самих учеников. И когда наша первая ласточка была готова и показана детям, мы поняли, что видеть их радостные лица – одно из доказательств эффективности нашей работы, и, вдохновившись, приступили ко второму проекту. На этот раз мы остановились на рассказе Идриса Туктара “Авыраяк”.

Также проводя внеурочные мероприятия, мы часто обращаемся к татарскому киноискусству. По просмотренным фильмам проводим викторины, квест-игры, КВН. Например, в прошлом учебном году среди школьников и людей старшего поколения была проведена игра “Звездный час” по фильму “Бибинур”. Такие мероприятия помогают сохранить связь поколений, пробуждают интерес к киноискусству.

***Ключевые слова:*** свободное время, кино, татарский фильм, фестивали мусульманского кино, детский фильм, дети – актёры.

“Сәнгатьнең кеше өчен иң мөһим төре – кино”
(Владимир Ильич Ленин)

“Буш вакытыңны ничек уздырасың?” - дип сорасалар, күпчелек: “ Кино карап”, - дип җавап бирер, мөгаен. Без совет фильмнарын карап үскән буын. Алары да, тәмле кәнфит кебек, сирәк була торган күренеш иде. Ә татар телендә төшерелгән киноларны карау түгел, алар турында хыяллана да алмадык.

Балачагында фильм карап туймаганнар хәзер, балалары, оныклары белән бергә утырып, бүгенге көндә чамасыз күп каналлардан күңеленә теләгәнен карап рәхәтләнә. Замана балалары татарчага тәрҗемә ителгән киноларны гына түгел, ә татарча төшерелгәннәрен карау, туган телендә сөйләшүче фильм геройлары тәэсирендә үсү бәхетенә дә ия.

Һәр нәрсәнең башлангычы булган кебек, кино сәнгатенең дә тарихы бар. Казанда бу эш, аерым сюжетлар рәвешендә генә булса да, кинофильмнар прокаты чыгу белән башлана. 1898 елда театр мәйданында төшерелгән кадрлар күрсәтелә.1926 елда оператор К.Ф. Мотков беренче тапкыр Сабантуй бәйрәмен төшерә. Татарлар тормышын кадрга төшереп калдыру эшчәнлеге белән 1932 елдан башлап Казан кинохроника студиясе шөгыльләнә башлый. Монда

кинематография хезмәткәрләренең профессионал кадрлары формалаша, нәфис фильмнар татар теленә һәм Идел буенда яшәүче башка халыклар телләренә тәржемә ителә башлый. Инде бүгенге көндә “Бибинур”, “Өч аяклы ат”, “Ак чәчәкләр”, “Күктау”, “Айсылу”, “Күк капусы ачылганда”, “Бичаракай”, “Бабай”, “Корыч”, “Югалту”, “Минем заманам” кебек фильмнар татар мөхитендә үскән кешеләрнең йөрәкләренә сары май булып ята.

Тик шулай да, бу киноларны караганнан соң, күңелдә бер китек кала: санап үтелгән барлык татар фильмнарында да аракы эчү, тәмәке тарту кебек ямьсез күренешләр бар. Хәтта, барлык тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителгән “Бибинур”ның да уңай герое булган карчык: “Мин бит тәмәке исен яратам”, - ди.  Ә инде иң соңгы төшерелгән “Мулла” фильмында шәрә кызларның мунча керүен, ә “Исәнмесез!” киносында, гомумән, көчләү элементын күрү – авыр тойгы калдыра. Без, татар теле укытучылары, балаларга белем генә түгел, тәрбия дә бирәбез: алар белән төрле темаларга әңгәмәләр уздырабыз, театр-спектакльләргә, музейларга йөрибез, яңа чыккан фильмнарга күзәтү ясыйбыз, татар халкының тарихы белән таныштырабыз, үткәне белән горурлану хисе тәрбияләргә тырышабыз, киләчәгенә өмет тудырабыз. Шулай итеп, бер яктан матурлыкны күрергә омтылдырабыз, икенче яктан, киноларда күрсәтелгән ямьсез күренешләрне дә кабул итәргә өйрәтәбез. Шулай итеп каршылыкка юлыгабыз.

Икенче мәсьәлә турында да әйтеп үтәсе килә. Ел саен “Алтын мөнбәр” конкурсы, халыкара мөселман киносы фестивальләре булып тора. Алар үткәннән соң, төрле чыганакларда кайсы фильмнарның җиңеп чыкканын күрсәтәләр, гәҗитләрдә мәкаләләр язалар. Ә аннары... оныталар. Бүген кайда соң ул фильмнар? Конкурслар үтү белән алар кая югала? Ник аларны гади кешеләргә күрсәтмиләр? Нигә аларны мәктәп укучылары карый алмый? Аларны конкурс өчен генә төшерәләрме соң әллә? Сораулар күп, кызганыч, җаваплар гына юк.

Менә шундый каршылыклы уйлардан соң, “Ә ник соң әле үзебезгә кино төшереп карамаска?” дигән фикергә килдек. Бу идеяны укучылар да бик теләп күтәреп алдылар. Утырып киңәшләшкәннән соң, узган уку елына башлангыч укучылары өчен ике фильм төшерергә план куелды. Иң беренче эш итеп, 1-4 сыйныф укучыларының дәреслекләрен игътибар белән карап чыктык, үзебезгә ошаган хикәя текстларын сайлап куйдык, төшереләчәк фильмга актерларны билгеләдек, ятланырга тиешле сүзләрне рольләргә бүлдек, киемнәрне, кирәкле атрибутларны әзерләп куйдык. Аннары  Резеда Вәлиеваның “Туган көндә” исемле хикәясе буенча кино төшерү эшләренә әзерлекне башладык. Бу эш укытучылар өчен генә түгел, укучыларның үзләре өчен дә бик мавыктыргыч шөгыль булып чыкты. Һәм беренче карлыгачыбыз әзер булып, балаларга күрсәткәч, аларның шатлыклы йөзләрен күрү – эшебезнең нәтиҗәле булуына бер дәлил икәнен аңладык һәм илһамланып икенче проектка тотындык. Бу юлы – Идрис Туктарның “Авыраяк” хикәясенә тукталдык. Төп геройларның икәү генә булуына карамастан, калган укучылар да аларга булышып, көч биреп тордылар. Шуның нәтиҗәсендә, икенче фильмыбыз да дөнья күрү бәхетенә

иреште. Инде бүгенге көндә җиң сызганып өченче проектыбыз өстендә эшлибез. Ул нинди форматта һәм ничек килеп чыгар – ансын инде вакыт күрсәтер.

Дәрестән тыш чаралар үткәргәндә дә, татар кино сәнгатенә еш мөрәҗәгать итәбез. Каралган фильмнар буенча викториналар, квест-уеннар, КВНнар үткәрәбез. Мәсәлән, узган уку елында укучылар һәм өлкән буын кешеләре арасында “Бибинур” фильмы буенча “Йолдызлы сәгать” уены уздырылды. Мондый чаралар буыннар чылбыры бәйләнешен сакларга ярдәм итә, кино сәнгатенә кызыксыну уята.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар киносының бай тарихы, бүгенгесе һәм киләчәге дә бар. Алдагы көннәрдә дә режиссерларыбыз шушы яссылыкта үз эшләрен дәвам итсеннәр, телебезне, гореф-гадәтләребезне саклауда киноның әһәмиятен күтәрсеннәр иде дигән теләктә калабыз. Ә без үз чиратыбызда, алардан калышмаска, үзебезнең тырышлык белән яңа проектлар әзерләргә, яңа үрләр яуларга, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә бар көчебезне куячакбыз!

# ЯШЬ БУЫНДА МИЛЛӘТАРА ДУСЛЫК ТӘРБИЯЛӘҮ, ТУГАН ТЕЛНЕ УКЫТУДА ТУГАН АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАР БУЕНЧА ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШУ

*Закирова С.И.*
*МБОУ "Камскоустьинская СОШ"*
*zakirovasania@yandex.ru*

***Аннотация.*** Среди предметов, изучаемых в школе, родной язык – татарский язык – средство передачи нравственных норм, духовного наследия нашего народа будущим поколениям.

Задача учителя родного языка-направить все свои знания на понимание тонкостей родного языка, углубленное изучение его, используя различные способы положительного воздействия на ребенка, привить желание к постоянному использованию родного языка, воспитать интерес к изучению процесса развития и совершенствования родного языка.

Часто повторяется мнение, что при усердном изучении языка в семье, в начальных классах, он навсегда закрепляется в памяти. Можно ли его сохранить и развивать, обучаясь в семье, в детском саду, в начальной школе? Если ребенок учится в первом-четвертом классах чисто татарского языка, он не потеряет свою национальность. Это научно обосновано. По словам ученых, основа усвоения языка у ребенка закладывается до 9 лет.

Работа учителя родного языка в школе ответственная и достаточно сложная, особенно в русской школе. Воспитать любовь к родному языку очень сложно. Основным средством овладения речевым языком, родным языком является внеклассная работа. Во время этих мероприятий ученики ведут себя более свободно, учитель и ученик общаются ближе.

***Ключевые слова:*** воспитание, опыт работы, молодежь

Тел - халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телеңне кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы,матурлыгы өчен көрәшү һәр кешенең изге бурычы.

Татар теле гаять бай мираска ия булган тел. ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган ундүрт телнең берсе – татар теле. Бу күрсәткеч безнең телебезнең бай булуын һәм буыннан-буынга күчеп, сакланып калуын раслый. Туган телне саклау – хәзерге вакытта иң актуаль һәм җитди проблема булып тора. Татар әдәбиятында да бу проблема зур урын били. Г. Тукай, К. Насыйри, Н. Исәнбәт кебек абруйлы татар әдипләре дә милләтне һәм аның телен саклап калу өчен зур хезмәт юлы үткәннәр. Туган телне саклауда беренче адымнар нидән гыйбарәт соң? Әлбәттә, беренче чиратта үз туган телеңне камил белү һәм иркен аралашу. Татар телен саклап үстерү, аны

кулланучыларның санын арттыру өчен әһәмиятле шартларның тагын берсе- татар телен өйрәнү, мәктәпләрдә уку системасын камилләштерү һәм яхшырту. Татар әдәбияты дәресләре санын арттырып, татар телендә кичәләр үткәрү, дәресләрдә укучылар арасында әңгәмәләр оештыру да туган телебезне саклау һәм камилләштерү өчен, укучы күңелендә теленә карата мәхәббәт хисләрен тагын да арттырып, аның бай мираслы телен киләчәк буынга тапшыру ихтыяҗын булдырыр иде.

Халкыбызның язмышы, киләчәге бүгенге яшьләребезнең нинди шәхси сыйфатларга ия булуына бәйле. Укучыларыбыз халкыбызның рухи кыйммәтләрен барларга, сакларга, арттырырга сәләтле икән, димәк, киләчәк буынның да язмышы өметле.

Бүгенге көндә мәктәп бу сыйфатларны формалаштыруның үзәге, сүнмәс учагы булып тора. “Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге булмас”, – ди татар халык мәкале.

Бүгенге мәктәп дөньяны аңларга, алда торган проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтә, максатка ныклы, ышанычлы адымнар белән бара белү сыйфатлары тәрбияли. Тәрбия бирүнең тагын бер мөһим бурычы – белем алу аша дөньяны танып белүгә, камиллеккә омтылуга ихтыяҗ формалаштыру.

Кешелекнең иң зур байлыгын милләтләр тәшкил итә һәр милләт үз теле, мәдәнияте белән яшәешне бизи, баета һәм үзе дә башка халыклар белән аралашып үсә, алга китә.

Мәктәптә һәм югары уку йортларында укытыла торган татар теле татарларның барысы өчен дә уртак, ул бер генә, һәркемгә газиз һәм кадерле. Үзен татар дип санаган һәр кеше аны камил белергә, даими камилләштерергә тиеш.

Туган тел укытучысының бурычы – үзенең барлык белемен, балага уңай тәэсир итүнең төрле юлларын файдаланып, аны туган телнең нечкәлекләрен аңлауга, тирәнтен өйрәнүгә юнәлдерү, туган телне даими кулланылышка кертүгә теләк уяту, туган телебезнең үсү-камилләшү процессын барлауга кызыксыну тәрбияләү.

Бүгенге көндә иң актуаль проблемаларның берсе булып торган милли мәгариф системасын без киләчәк буынны гаилә ,балалар бакчасыннан алып, югары мәктәпкәчә ана телендә тәрбияләү һәм укыту буларак күз алдында тотабыз. Алдагы тормышында ни генә булмасын,баланың характер үзенчәлекләре, туган телгә карашы , аң-белемгә омтылышының күп өлеше буыннар аша аңа нәселдән күчә. Шуңа күрә гаилә мөнәсәбәтләре булачак шәхеснең формалашуына хәлиткеч йогынты ясый. Бөек мәгърифәтчебез Р.Фәхреддин: "Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас ",- дип әйтсә, атаклы совет педагогы А.С.Макаренко:"...Сез

баланы аның белән сөйләшкәндә генә, аңа акыл өйрәткәндә яки аңа боерык биргәндә  генә тәрбиялим дип уйламагыз.Сез аны тормышыгызның һәр моментында, хәтта бөтенләй өйдә булмаган чагыгызда да тәрбиялисез”,-дип язып калдырган. Димәк, баланың дөньяга карашы, үз-үзен тотышы, дусларына, туган теленә мөнәсәбәте гаиләдә формалаша башласа , мәктәптә дәвам итә.

Безнең Республикада ике дәүләт теле: рус Һәм татар телләре. Дәүләт хезмәткәрләре дә дәүләт телен яхшы белергә тиеш.

Бездә татар теленә ихтыяҗ җитми. Татар телен белүнең кирәклеге һәркайда чагылырга тиеш. Белдерүләр, эш кәгазьләре урыс телендә, тармакларда хезмәт күрсәтүче белгечләрнең күбесе урыс телендә аралаша. Шуңа да кешеләр, бигрәк тә яшьләр, татар булса да, урысча сөйләшүне хуп күрә. Шуның аркасында туган тел алар өчен әҺәмиятен әкренләп җуя бара, ул аны кирәксенми. Авыл җиреннән шәһәргә килгән татар балаларының ана телен санга сукмавы, хәтта онытулары гадәти хәлгә әверелеп бара.

Мәктәптә татар теле укытучысының эше җаваплы Һәм шактый ук катлаулы, бигрәк тә рус мәктәбендә укыту. Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү бик авыр. Сер түгел: хәзер балалар әдәби китапны аз укыйлар. Күпләр телевизор карауны, кич белән урамда йөрүне, компьютер каршында утыруны хуп күрәләр. Ә әдәби китапларны күбрәк укыган саен кеше тормышны күбрәк танып белә, әдәби образларга охшарга тырышып яши, әдәп - әхлак кагыйдәләрен яхшырак үзләштерә.Сөйләм телен, туган телне үзләштерүнең төп чарасы – сыйныфтан тыш эшләр. Бу чаралар вакытында укучылар үзләрен иркенрәк тота, укытучы белән укучы якыннан аралаша. Туган телгә, халык җырларына, фольклорга багышланган бәйрәмнәр, җырлы-биюле уеннар балалар Һәм ата-аналар күңелендә онытылмас эз калдыра. Мәктәптәге әлеге чаралар да әнә шул максаттан чыгып оештырыла.

Тел– диңгез,шуңа карамастан, бөек татар телен саклап калу үзебезнең кулда. Туган телне өйрәтү, саклау, әлбәттә, беренче чиратта, гаилә бурычы ул.

Милләтем исән, рухы сау булсын өчен мин бүген, хәзер ни-нәрсә эшли алам, дигән сорау һәркемне борчый торган заманда яшибез. Тел, әдәбият, гореф-гадәтләр, йолаларыбыз сагында торучылар, без телебезнең ямен, үзенчәлекләрен саклап, матур гадәтләребезне киләчәк буыннарга җиткерү – бу безнең уртак бурычыбыз.

Татар теленең яшәеше өчен кирәкле шартлар

1. Татар теленең кулланылышын дәүләт тарафыннан тәэмин итү.
2. Тулы татар милли мәгариф системасын кору: татар балалар бакчалары-татар мәктәпләре, милли техникум, университетлар булдыру.
3. Тулы рәвештә һәм бөтен яклы татар мохитен булдыру.

4. 100% татар телевидениесен булдыру һәм аны эшләтү (Татарстанда гына түгел, Федераль дәрәҗәдә дә, чит илләргә чыгарлык итеп тә).
5. Милли үзаңны үстерү вә ныгыту өчен татар телен һәм мәдәниятенә зур реклама компаниясе башлау.

ХӘЗЕР БЕЗДӘ НӘРСӘ БАР?

1. Татарстан Республикасында татар теле рус теле белән бертигез дәрәҗәдә дәүләт теле санала. Әмма аның дәүләт теле булуы күбрәк кәгазьдә генә.
2. Татар мәктәпләре бик толерант һәм, йомшак итеп әйткәндә, республикабызга җитми. Республикабызның күп район үзәкләрендә татар мәктәпләре гомумән юк, ә авылларда булганнарының шактыен ябып бетерделәр.
3. Татар мохите Татарстанда минималь: театрлар, концертлар, татар телендә берничә дистә элмә такта (урыны белән), ТНВ, татар радиолары, милли түгәрәкләр һәм бу бөтен булганы.

Татар теленә каршы фикерләр.

Милләтебезнең бүгенге хәле, авыр язмышы турында кемнәр генә язмады, сөйләмәде: янәсе татар яшьләре үз туган телендә сөйләшми, имеш, татар телен начар укыталар һ.б. Күпчелек очракта татар теленең авыр хәле турындагы зарланышулар үз-үзеңнән гаеп эзләүгә барып терәлә: имеш, татарларда бердәмлек хисе юк, гаиләдә «дөрес» тәрбия бирелми, янәсе, татар телен укыту программалары «начар» һ. б.

Соңгы арада интернет челтәрләрендә күп кенә кешеләрнең язмаларын укырга туры килде. Имеш мәктәпләрдә татар теле дәресләре артык булып чыккан икән. Кемгә комачаулаган соң ул? Кемнең кинәт кенә татар телен укыйсы килми башлаган? Татарстанда яшәп тә, дәүләтебезнең икенче теле саналган татар телен укыту шуның белән бетәрме? Нигә мәктәпләрдә физкультура дәресен атнага 3 тапкыр кертәләр дә, ә татар теленә күп дигәндә 2 сәгать кенә бүлеп бирәләр? Башыма мондый сораулар бик күп килде. Тик бу сорауларның барысына да җавапны каян алырга гына белмәдем.

Бер уйласаң, нигә гаҗәпләнергә соң? Гаепне үзебездән эзләргә кирәк. Нәкъ менә татар кешесе туган телебезне шундый аяныч хәлгә куя да инде. Моңа мисаллар бик күп бит. Татар гаиләсеннән булган сабыйны рус балалар бакчасына йөрткән, рус гимназияләренә укырга биргән, матур яңгырый дип, рус яки бөтенләй чит илдән кергән исем кушкан заманда, бу бер дә гаҗәеп түгел.

Милләтне аның теле саклый. Шулай булгач туган телне саклау һәр кеше өчен дә мөһим булырга тиеш. Тел – бөтен халык казанышы, меңнәрчә, миллионнарча кешеләрнең күп гасырлык иҗат җимеше. Шуңа күрә дә телгә карата башбаштаклык кылырга, аның белән саксыз эш итәргә, аны үзенә ошаганча бозарга беркемнең дә хакы юк.

Гаиләдәге тәрбия белән татар телен саклап калуга зур өлеш кертеп була. Замана баласы булып үсү өчен телләрне белү кирәк.

Безнең татар телебез бүген үк инде матбугат, әдәбият, сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау, ял итү һәм башка бик күп өлкәләрдә кулланылышка кереп китәргә тиеш.

Туган телебезгә игътибарлы булыйк, аны үстерүгә көчебездән килгәнчә тырышыйк, киләчәк буынга тапшырып калдыру өчен дә хезмәт итик, яклыйк һәм сөеп үстерик. Ана телендә аралашу мөмкинлегеннән иркен файдаланыйк, интернет челтәрендәге уеннарны, сайтларны татар телендә булдырып, эшләгән вакытыбызны да татар телен үстерү өчен кулланыйк. "Туган телен кадерләгән халык кына кадерле булыр", – дигәннәр борынгы әби-бабаларыбыз.

**Әдәбият**

1. Вәлиева З. Теле барның – иле бар // Мәгариф. – №2. – 2003.
2. Гыйләҗев И. Татар теле язмышы турында кайбер уйланулар // Безнең мирас, 2012. – №71. – Б.7. 3. Фәйзрахманова К. Телләр турындагы программаның үтәлешен Мәгариф һәм фән министрлыгы контрольдә тотачак // Мәгариф, 2014. – № 3. – Б.5
3. Татар теле әдәбияты һәм тарих: үткәне, бүгенгесе, киләчәге: укучыларның һәм студентларның VII Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Алабуга, 18 ноябрь, 2016 нчы ел). – Алабуга: КФУның Алабуга институты нәшрияты, 2016. – 260 б.

# ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ВИРТУАЛЬНЫХ ЭКСКУРСИЙ НА УРОКАХ ЛИТЕРАТУРЫ

***Заляева Р.К.,Хакимова Р.А,***
***МБОУ «Арская СОШ №1 им.В.Ф.Ежкова с УИОП»***
***arskrk@mail.ru, chakim73@mail.ru***

***Аннотация.*** Виртуальные туры по домам-музеям, музеям-усадьбам, музеям-заповедникам, мемориальным музеям – это уникальная для обучающихся возможность посетить литературные места, связанные с жизнью и творчеством великих русских писателей и поэтов, прямо на уроке, не выходя из-за своих парт. Ученики начинают незабываемое путешествие, открывая для себя интереснейшие подробности из жизни и быта великих художников слова.

***Ключевые слова:*** виртуальные экскурсии по музеям, урок литературы, дома-музеи.

Где, как не в школе, может человек получить начала эстетического воспитания, на всю жизнь приобрести чувство прекрасного, умение понимать и ценить произведения искусства, приобщаться к художественному слову? Обращаясь на уроках литературы к творчеству самых разных мастеров, учитель стремится привить эстетическую культуру - одно из проявлений духовного богатства всесторонне развитой личности.

Известно, что визуальное (зрительное) восприятие является одним из важнейших условий успешной жизнедеятельности человека. Психологами установлено, что посредством зрения человек получает свыше 90% информации, на основе которой он строит оптимальную стратегию взаимодействия с окружающим миром. Поэтому при изучении биографий писателей на уроках литературы в средней школе важно максимально использовать возможности виртуальных музеев. Оказавшись на литературной экскурсии, ученик становится настоящим исследователем, занимающим активную поисковую позицию. А в процессе поиска ответов на интересующие вопросы возникает потребность в общении, приводящая к обмену рациональной и эмоциональной информацией, опытом, выработке взаимодействия, восприятия и понимания другого человека.

Виртуальной экскурсии, как и обычной, присущи определенные признаки, при отсутствии которых ее нельзя считать таковой. Выделяют шесть обязательных признаков экскурсии: четко определенная тема, являющаяся «стержнем» осмотра, диктующая его направление; протяженность по времени, обычно от академического часа до нескольких часов; наличие экскурсионной группы (15 – 30 человек); наличие квалифицированного специалиста-экскурсовода; осмотр экскурсионных объектов, первичность зрительных впечатлений. Но главным признаком экскурсии является обязательное использование при ее проведении экскурсионного метода, то есть единства показа и рассказа, при первичной и определяющей роли показа.

Огромную роль в активизации деятельности учащихся во время виртуальных экскурсий играет поисковый метод. Ученики не просто

знакомятся с материалами экспозиций, но и занимаются активным поиском информации. Это достигается путём постановки проблемных вопросов перед экскурсией либо получением определённых творческих заданий. Во время проведения экскурсии учащиеся могут записывать тезисы в тетрадь, копировать материалы с сайта в свои папки, делать пометки.

Заканчивается экскурсия итоговой беседой, в ходе которой учитель совместно с учащимися обобщает, систематизирует увиденное и услышанное, выделяет самое существенное, выявляет впечатления и предварительные оценки учащихся; намечает творческие задания для них: написать сочинение, подготовить доклады, составить альбомы.

Кроме фронтальной виртуальной экскурсии на уроках литературы можно организовать индивидуальную и групповую работу учащихся по подготовке и проведению виртуальных экскурсий. В этом случае учащиеся, создавая проекты виртуальных экскурсий по тем или иным темам, углубляют знания, полученные на уроках литературы, осваивают приемы и методы исследовательской деятельности. Подготовка виртуальной экскурсии включает в себя несколько этапов: диагностический, подготовительный, исполнительский, заключительный, аналитический.

Особое внимание следует обратить на организацию диагностического этапа, на котором выявляются интересы учащихся, мотивы, которыми они руководствуются, приступая к работе, степень их самостоятельности и ответственности за свои действия. На основе проведенной диагностики для учащихся (групп учащихся) разрабатывается «индивидуальный маршрут» деятельности: объединяются в рабочие группы, члены которых могут выполнять разные функции («исследователи», «художники», «фотографы», «аниматоры», «редакторы», «экскурсоводы»).

В настоящее время многие сайты музеев русских писателей позволяют совершить виртуальный тур и рассмотреть усадьбы, мельчайшие детали внешнего и внутреннего убранства домов-музеев. Вот некоторые из них:

1. http://biblio-ast.ru/ – Библиотека-музей В.П. Астафьева,
2. http://www.voronezh-foto.ru/virtual-tours/bunin – Дом-музей Ивана Бунина,
3. http://www.domgogolya.ru/ – Дом Гоголя. Мемориальный музей и научная библиотека,
4. http://grinworld.org/index.htm – Романтический мир Гринландии. Феодосийский литературно-мемориальный музей А.С. Грина,
5. http://www.museum-esenin.ru/aboutmuseum/virtualnyj-muzej – Государственный музей-заповедник С.А. Есенина,
6. http://culture.ru/atlas/object/519 – Государственный Лермонтовский музей-заповедник «Тарханы»,
7. http://www.музей-тургенева.рф/leskov_p_1.html – Дом-музей Н.С. Лескова,
8. http://vmkor.ru/ – Виртуальный музей В.Г. Короленко,

9. http://karabiha-museum.ru/ – Государственный литературно-мемориальный музей-заповедник Н.А. Некрасова «Карабиха»,

10. http://www.prishvin.ru/o_prishvine/hunt.htm – Музей-усадьба М.М. Пришвина,

11. http://www.pushkinmuseum.ru/ – Государственный музей А.С. Пушкина,

12. http://pushkin.ellink.ru/vtour/titlem.asp – Виртуальные прогулки по Пушкинскому Заповеднику (Михайловское, Тригорское, Петровское, Святогорский монастырь),

13. http://culture.ru/atlas/object/219 – Музей-усадьба «Ясная Поляна»,

14. http://www.turgenev.org.ru/museum/spasskoe.htm – Музей-заповедник “Спасское-Лутовиново”

Важно учесть, что сегодня большинство наших соотечественников работают над своим развитием: много путешествуют. Ребята имеют возможность вместе со своими родителями посетить настоящие музеи, а затем, благодаря полученным знаниям, фото- и видеоматериалам создать свой виртуальный музей и провести по нему экскурсию.

Основным каналом передачи информации на уроке литературы, конечно же, является слово, но виртуальные экскурсии позволяют расширить диапазон восприятия учебного материала через виртуальный, зрительный ряд, способствуя повышению эффективности усвоения учебного материала.

Таким образом, использование виртуальных экскурсий на уроках литературы позволяет преподавателю приблизиться к выполнению «золотого правила» дидактики, сформулированного Яном Амосом Коменским: «…всё должно быть представлено внешним чувствам, насколько это возможно, именно: видимое – зрению, слышимое – слуху, обоняемое – обонянию, вкушаемое – вкусу, осязаемое – осязанию, если же что-нибудь может быть одновременно воспринято несколькими чувствами, то и представлять этот предмет одновременно нескольким чувствам».

## Литература


1. Бордовской Н.В.: Современные образовательные технологии. - М.: КНОРУС, (2010, 322 с.)

2. Давкаева Ф.М. Современные образовательные технологии на уроках русского языка и литературы. https://www.metod-kopilka.ru/muzeynaya_pedagogika_na_urokah_russkogo_yazyka_i_literatury-37697.htm (Дата обращения: 16.10.2022)

3. Панфилова А.П. Инновационные педагогические технологии. Активное обучение. - М.: Издательский центр «Академия» (2009, 192с.)

4. Токарева А.Н. Применение виртуальных экскурсий на уроках литературы. http://psychology.snauka.ru/2016/02/6445 (Дата обращения: 16.10.2022)

5. Виртуальны музеи. https://www.sites.google.com/site/oljsamarova/kommerceskoe-predlozenie/virtualnye-muzei-pisatelej (Дата обращения: 15.10.2022)

# ПОЛИЛИНГВАЛЬНЫЙ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫЙ КОМПЛЕКС КАК МОДЕЛЬ СОВРЕМЕННОЙ ШКОЛЫ

***Замалетдинов Р. Р., Фатхуллова К. С.***
***Казанский федеральный университет***
***sovet.rus16@gmail.com, kadria.kgu@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье рассматриваются вопросы внедрения полилингвальности в систему общего образования, что вызвано бурным развитием интеграционных процессов в многонациональном российском социуме. Проблема полилингвизма в условиях глобализации и тесной межкультурной коммуникации обретает особую значимость, поэтому роль полилингвального образования в сохранении национально-культурных традиций народов, проживающих в РФ, весьма актуальна. В статье также представлен опыт создания полилингвальных комплексов в РТ и подготовки для них педагогических кадров, показаны особенности организации образовательного процесса и разработки средств обучения родному языку.

***Ключевые слова:*** многонациональный социум, полилингвальность, полилингвальный образовательный комплекс, полилингвальная среда, поликультурная компетенция.

В современных условиях внедрение полилингвальности в систему отечественного общего образования продиктовано активным развитием интеграционных процессов в культурной, социальной, экономической и политической областях мирового сообщества, а также в многонациональном российском социуме. Проблема полилингвизма в условиях глобализации и тесной межкультурной коммуникации обретает особую значимость, поэтому роль полилингвального образования в сохранении национально-культурных традиций народов, проживающих в РФ, весьма актуальна. С учетом этих приоритетных задач в последние годы в некоторых субъектах РФ были разработаны и утверждены Концепции полилингвального образования и открыты пилотные полилингвальные комплексы [4]. В качестве положительного примера можно привести опыт Республики Татарстан, где с 2020 года реализуется уникальный проект по созданию полилингвальных образовательных комплексов «Адымнар – путь к знаниям и согласию», обеспечивающих конкурентоспособное образование на русском, татарском и английском языках в соответствии с ФГОС [1]. В настоящее время такие комплексы функционируют в таких крупных городах РТ как Казань, Елабуга, Набережные Челны, Нижнекамск, Альметьевск, а также в Актанышском муниципальном районе.

Как известно, изучение нескольких языков в полилингвальных образовательных комплексах способствует развитию у учащихся интеллектуальных и творческих способностей, а также приобщает их к культурным и национальным традициям контактирующих народов. В процессе усвоения школьных предметов на разных языках у учащиеся формируется умение адекватно воспринимать свою и другие культуры, вырабатывается своя линия поведения в различных ситуациях межкультурной коммуникации. В таких современных образовательных учреждениях для достижения результатов обучения используется высокотехнологичная инфраструктура (комфортные помещения для учебных, развивающих, оздоровительных мероприятий); лаборатории с применением цифровых технологий; видеоконференционные системы; цифровые проекционные экраны, слайд-проекторы; интерактивные дисплеи, документ-камеры, маркерные доски, экранно-звуковые средства обучения и многое другое, что способствует обогащению технологического инструментария педагогов и автоматизации процессов администрирования. Изучение опыта работы образовательных учреждений нового типа показывает, что полилингвальные комплексы – это особая модель в системе отечественного общего образования, которая требует внесения изменений в организацию учебно-воспитательной деятельности школьников. Система полилингвального образования в РТ функционирует с учетом этнокультурных потребностей народов, населяющих республику, на основе федеральной и республиканской законодательной базы.

Как подчеркивается в методической литературе, полилингвизм – это полноценное владение несколькими языками на уровне родного, естественное употребление одним человеком нескольких языков в повседневной жизни, каждый из которых выбирается в соответствии с конкретной коммуникативной ситуацией. Следовательно, полилингвизм включает в себя речевую и языковую компетенции, которые позволяют использовать в общении несколько языковых систем.

В сфере общего образования полилингвальное образование представляет собой единство взаимосвязанных процессов изучения в школе не менее трех языков и организации целенаправленного процесса обучения и воспитания, личностного развития и социализации школьников, приобщения их к мировой культуре средствами нескольких языков, которые выступают в качестве средства постижения специальных знаний, усвоения культурно-исторического опыта различных народов. Основным принципом полилингвального образования является функциональное многоязычие, то есть преподавание на одном и том же образовательном этапе одной части предметов на родном (нерусском) языке, второй – на русском языке, третьей – на иностранном. На

долю родного (нерусского) языка должен приходиться больший объем на начальной стадии обучения. На старшей ступени школы в качестве языка обучения наряду с русским и родным (нерусским) языками может быть использован иностранный язык. Организация учебного процесса таким образом приводит к развитию личности, которая обладает многоязычной и поликультурной компетенцией. Формирование полилингвальной личности – основное направление развития поликультурного образования в нашей стране. Основным критерием успешной социализации личности школьника в поликультурной среде является уровень его готовности к межэтническому взаимодействию и взаимопониманию. Ключевая компетенция полилингвальной личности заключается в совокупности знаний и умений, которые способствуют усвоению знаний о нескольких языковых системах; приобретению умений переключения с одного языка на другой и применения языков в разных социокультурных контекстах. В полилингвальных образовательных комплексах изучение предметов на разных языках готовит личность обучающегося к адекватному восприятию своей и других культур, способствует выработке собственной линии поведения в ситуациях межкультурных контактов. Формирование культуры полилингвальной личности в школе способствует принятию других существующих культур через осознание своей культуры и места своей культуры в окружающем мире. По мнению педагогов, полилингвальная образовательная модель отличается от традиционной системы общего образования тем, что она дает возможность анализировать и сопоставлять предметное содержание в разных учебных культурах; способствует развитию культуры речи, как на родном, так и на других языках, преодолению разобщенности мышления на родном и других языках; обогащает общеобразовательный кругозор учащихся, развивает у них интеллектуальные и творческие способности; приобщает учащихся к культуре и национальным традициям различных народов.

Таким образом, основные цели развития полилингвального образования в нашей стране неотделимы от общей стратегии модернизации российского образования, которая опирается на принципы социальной адресности и сбалансированности этнокультурных и национальных интересов граждан. Достижение основных целей обеспечивается следующими приоритетами образовательной политики РФ: сохранение целостности культурного и образовательного пространства России; гуманистический, светский и поликультурный характер образования; ответственность государства за получение детьми полноценного образования; научная основа содержания образования и принципов воспитания; сохранение этнокультурной самобытности народов России, приобщение учащихся к духовному наследию своего народа, традиционной и профессиональной национальной культуре; вариативность выбора родителями

образовательного пути ребенка; воспитание трудовых навыков, необходимых для активной профессиональной деятельности.

Одной из важных проблем в становлении полилингвальных школ в РТ является подготовка педагогических кадров. С 2018 года на базе Высшей школы национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая Института филодогии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета реализуются уникальные проекты по подготовке билингвальных педагогических кадров для общеобразовательных организаций РТ. С этой целью разработаны и внедрены новые образовательные программы: начальное образование и иностранный (английский) язык (в полилингвальной образовательной среде); история и иностранный (английский) язык; русский язык и иностранный (английский) язык; математика и физика; музыка и дополнительное образование (в билингвальной образовательной среде). С 2020 г. осуществляется подготовка учителей-предметников для полилингвальной образовательной среды, способных преподавать учебные предметы на русском, татарском и английском языках.

С 2016 г. на базе Высшей школы русской и зарубежной филологии им. Льва Толстого КФУ реализуется магистерская программа по направлению подготовки: Педагогическое образование. Мультилингвальные технологии раннего развития детей [2]. Данная программа актуальна**,** так как **с**овременные родители хотят, чтобы их ребенок умел говорить на нескольких языках с самого раннего детства. Вместе с тем, не всегда педагоги владеют специальными знаниями. Для того чтобы обучать ребенка дошкольного возраста языкам в мультилингвальной среде, необходимо не только знать языки, но и обладать знаниями в области педагогики, методики преподавания, возрастной психологии. Данная программа разработана с учетом этих требований. Форма обучения – заочная. Срок обучения – 2,5 года. Также на базе Елабужского института КФУ реализуется магистерская программа «Полилингвальное образование», которая готовит квалифицированных специалистов и педагогов, владеющих умениями и навыками научно-педагогической, методической и воспитательной работы в контексте полилингвальной среды обучения [3]. Форма обучения – заочная. Срок обучения – 2,6 года.

Для успешной организации учебного процесса по родному (татарскому) языку для полилингывльных школ разработаны новые учебно-методические комплексы «Адымнар», которые нацелены на развитие у учащихся речевой, языковой и этнокультурной компетенций [5, 6, 7, 8]. Данный УМК включает в себя рабочую программу, учебное пособие, книгу для учителя, рабочую тетрадь, электронный учебник и контрольно-измерительные материалы.

Обучение татарскому языку на основе нового УМК направлено на овладение умениями свободно разговаривать на родном языке, осмысление данного языка как основного средства общения, освоение морально-этических норм, осознание эстетической ценности татарского языка и знаний об устройстве языковой системы, а также закономерностях ее функционирования. Авторы УМК нового поколения активно сотрудничают с учителями родного (татарского) языка полилингвальных школ, посещают уроки, решают методические вопросы, возникающие при их апробации.

Таким образом, в дальнейшем предстоит решение стратегических задач, связанных с совершенствованием образовательного процесса в полилингвальных школах, значимость которых заключается в педагогических основаниях: стремлении к обмену ценностями и идеями, диалогу культур, интеграции в единое культурно-образовательное пространство.

## Литература


1. Государственное автономное общеобразовательное учреждение "Полилингвальный комплекс "Адымнар - путь к знаниям и согласию" г. Казани // https://edu.tatar.ru/nsav/page2317.htm (дата обращения 15.01.2023).
2. Программа магистратуры по профилю «Мультилингвальные технологии раннего развития детей https://kpfu.ru/multilingvalnye-tehnologii-rannego-razvitiya-detej_242167.html (дата обращения 15.01.2023).
3. Программа магистратуры по профилю «Полилингвальное образование» https://kpfu.ru/elabuga/abitur/n/440401plo (дата обращения 15.01.2023).
4. Ялалов Ф.Г. Концепция полилингвального образования в Республике Татарстан // Научный Татарстан, 2019. - № 3. – С. 80-96.
5. Адымнар. Татар теле. 1 нче сыйныф: гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә./ Р. Р. Җамалетдинов, Э. Н. Денмөхәммәтова, Р. К. Сәгъдиева, Г. Р. Галиуллина, К. С. Фәтхуллова, А. Х. Әшрәпова. — Казан: Татар. кит. нәшр. 2021. — 152 б.
6. Адымнар. Татар теле. 2 нче сыйныф: гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә./ Р. Р. Җамалетдинов, Э. Н. Денмөхәммәтова, Р. К. Сәгъдиева, Г. Р. Галиуллина, К. С. Фәтхуллова. — Казан: Татар. кит. нәшр. 2022. — 103 б.
7. Адымнар. Татар теле. 3 нче сыйныф: гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә./ Р. Р. Җамалетдинов, Э. Н. Денмөхәммәтова, Р. К. Сәгъдиева, Г. Р. Галиуллина, К. С. Фәтхуллова, А. Х. Әшрәпова. — Казан: Татар. кит. нәшр. 2022. — 106 б.
8. Адымнар. Татар теле. 4 нче сыйныф: гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә./ Р. Р. Җамалетдинов, Э. Н. Денмөхәммәтова, Р. К. Сәгъдиева, Г. Р. Галиуллина, К. С. Фәтхуллова, А. Х. Әшрәпова. — Казан: Татар. кит. нәшр. 2022. — 112 б.

# ДӘРЕСТӘҺӘМ ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЧАРАЛАРДА УКУЧЫЛАРНЫҢ СӨЙЛӘМЕН ҮСТЕРҮДӘ ТӘНКЫЙДИ ФИКЕРЛӘҮ ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНУ

***Зиатдинова Л. Һ.***
***Казан шәһәренең 4 нче гимназия-интернаты***
*Leisan025@yandex.ru*

***Аннотация.*** Современный ученик каждый день сталкивается с большим количеством нового. Из этой информации он должен выбирать то, что ему нужно, самостоятельно рассуждать, четко излагать свои мысли. Считаю, что успешному обучению и отбору нужной информации помогает использование на уроках технологии критического мышления.

***Ключевые слова:*** критическое мышление, технология, урок, таксономия Блума.

Хәзерге заман укучысы һәркөн бик күп яңалык белән очраша. Ул шушы мәгълүмат арасыннан тәнкыйди күзлектән карап, чагыштырып, анализлап, үзенә кирәклесен генә сайлап алырга , мөстәкыйль фикер йөртергә, үз уйларын ачык итеп әйтеп белергә тиеш. Балага шул мәгълүматтан кирәклесен сайлап алырга, уңышлы укырга дәресләрдә тәнкыйди фикерләү технологиясен куллану ярдәм итә дип саныйм.

Тәнкыйди фикерләү технологиясе ул - үз позициянне яклый һәм җиткерә алу, әңгәмәдәшеңне тыңлый белү, аргументларга нигезләнеп, логик фикер йөртү сәләте.Тәнкыйди фикерләү технологиясен өйрәнүчеләр Америка Кушма Штатларында: Чарльз Темпл, Джон Дьюи, Джинни Стилл. Россиядә: С.И.Заир-Бек, И.О.Загашев ,И.В.Муштавинская.

Тәнкыйди фикерләү технологиясенә нигезләнгән дәрес 3 этаптан тора:

1.Чакыру, кызыксындыру этабы (булган белемнәр актуальләштерелә, проблемалы, кызыксыну уята торган сорау туа)

2.Аңлау, төшенү этабы (бу этапта материал төрле яктан карала, анализлана, чагыштырыла)

3.Рефлексия (өйрәнелгән материалны иҗади анализлау, бәяләү, йомгак ясау)

Тәнкыйди фикерләү технологиясең ысуллары бик күп төрле. Мин аларны әкренләп өйрәнәм, үз дәресләремә яраклаштырам. Иң яратып кулланганнары һәм нәтиҗә биргәннәре: ”Тәлгәш” (кластер), Блум таксономиясе, Венн диаграммасы, паузалар ясап уку, ирекле эссе, Блум шакмагы, РАФТ ысулы.

Мәсәлән, “Тәлгәш”(кластер) ысулын татар теле дәресләрендә ничек кулланып була? Җөмлә темасы бик күләмле, әгәр укучы схеманы бер-бер артлы үзе төзеп, үзе китереп чыгарса, ул аны яхшырак аңлаячак һәм хәтерендә дә калачак.

Гади һәм катлаулы сораулар ысулын өч төрле итеп кулланып була:

Укытучы-укучы, укучы-укучы, укучы-укытучы

Гади сорауларга бер-ике сүз белән генә җавап биреп була.

Катлаулы сораулар, киресенчә, иҗади фикерләүне, үз фикереңне дәлилләүне таләп итәләр.

РАФТ ысулы билгеле бер тематикага корылган иҗади эш төрләренең берсе.

Р(оль) – бу эш кем исеменнән (хәзерге чор баласы исеменнән, әдәби герой исеменнән, язучының үз исеменнән һ.б.)

А(удитория) – бу эш кемгә адресланган(хәзерге чор кешесенә, әдәби геройга, авторга)

Ф(орма) – хат, интервью, эссе, шигырь.

Т(ема) – текст нәрсә турында .

Мәсәлән, Ф.Хөснинең “Йөзек кашы” әсәрен укып, анализлап чыкканнан соң куллануы бик уңышлы булырга мөмкин (хәзерге егерме беренче гасыр укучысы Айдарга хат язып, хата эшләмәскә, андый дуамал булмаска, Вәсиләне ташлап китмәскә киңәшләр бирә ала), шулай ук К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар ” драмасы буенча уздырылган дәрестә дә шушы ысулны кулландым. Укучыларга бу алым бик кызыклы булды, алар үз фикерләрен ачык җиткерә алдылар.

Әлбәттә, һәр әсәрнең тәрбия юнәлеше бер яклы гына түгел, бер әсәрдә патриотизмның тәрбия элементлары, туган телгә сак караш, толерантлык, гаилә, ата-анага игелекле мөнәсәбәт, игелек һәм явызлык һ. б. очратырга мөмкин. Программа буенча барлык әсәрләрне анализлап, аларны төркемнәр буенча классификацияләргә була. Укучылар әсәрнең асылына төшенеп, тема буенча дискуссияләр һәм әңгәмәләр корып, фикер алышып, материалны җиңелрәк үзләштерәләр.

Әдәби әсәрләр туган телгә һәм халык иҗатына, халык мирасына, милли мәдәнияткә мәхәббәт тәрбиялиләр, үз халкының гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә, табигатьнең матурлыгын күрергә өйрәтәләр. Башка милләт балаларына карата дустанә хисләр, толерантлык тәрбиялиләр, кече Ватанга мәхәббәтләрен һәм төрле милләт кешеләренең дуслыгын һәм үзара ярдәмен аңларга ярдәм итүче халыклар тормышын да ачалар. Кешеләрнең игелеклелеген, намуслылыгын, күңел юмартлыгын тәрбиялиләр, якыннарыбызга, әти-әниләребезгә һәм дусларга яхшы мөнәсәбәттә булырга өйрәтәләр. Әдәби әсәрләр шатлык һәм бәхет белән бүлешергә кирәк, үз тойгыларыңнан оялмаска, ихласлыкка өйрәтәләр.

Игелек һәм яманлык проблемасы турында да әсәр геройлары аша күп мәртәбәләр очрашырга туры килә. Шулай ук эш сөючәнлеккә, үзара аңлашуга, дустанә мөнәсәбәт, ярдәмчелек, миһербанлыкка өндәүче әсәрләр дә мәктәп программасында бихисап.

Мәктәптә патриотик тәрбия бирү мәсьәләсенә кагылсак, татар теле һәм әдәбияты дәресләре бу өлкәдә зур роль уйный. Укучылар Советлар Союзы Герое Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Габдрахман Әпсәләмов һәм күп кенә татар шагыйрьләре һәм язучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар батырлыклары турында иҗат ителгән әсәрләр белән үсәргә тиеш. Шушы иҗат җимешләре аша туган ягына, үз ватанына мәхәббәт хисе балалар күңеленә сеңә.

Мәктәптә туган тел һәм әдәбият укытучысының роле бик үзенчәлекле. Ул укучыларга белем биреп кенә калмый, ә киләчәктә үзләренә эш сайлый алырлык, тормышларын төзеп, бәхетле, шәфкатьле, кешелекле, илебезнең чын патриотлары булып яши алырлык югары әхлакый кешеләрне тәрбияли. Тел һәм әдәбият дәресләре – чын мәгънәсендә әхлак дәресләре ул, дип әйтергә була. Моның өчен мул материалны һәр тема, һәрбер дәрес өчен табарга мөмкин, аны оста кулланырга гына кирәк. Укыту программасына кергән һәр әсәр дә әхлак, кешелеклелек, миһербанлык, патриотизм тәрбияләү дәресләре буларак кабул ителергә мөмкин.

Югарыда әйтелгәнчә, әдәби әсәрләр балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып сайланган. Милли геройларның мисалларында, балалар үзләренә якынрак булган әтиләре һәм бабайлары башкарган батырлык гамәлләре турында әңгәмәләр корырга яраталар. Шулай үрелеп барганда, патриотик тәрбиягә ирешү җиңелрәк. Балалар теләп төрле иҗади бәйгеләрдә катнашырга телиләр, фәнни-гамәли конференцияләргә дә кызыксыну туа. Башлангыч сыйныф укучыларының дәреслекләрендә күбрәк милли каһарманнар турында әкиятләр булса, ә урта звено программасына Ибраһим Газиның «Йолдызлы малай» хикәясе, Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» повесте, Шамил Ракыйповның «Чәчәкләр сөйли белә» повесте, соңрак Габдрахман Әпсәләмовның «Миңа унтугыз яшь иде» повесте, Ләбибә Ихсанованың «Лачын кыз» хикәясе, Әмирхан Еникинең «Кем җырлады?» һ.б. Шушы әсәрләр белән бергә сугыш вакытында яшь буын батырлыгы турында дан җырланган күпсанлы поэзия әсәрләрен дә атарга була.

Татар теле - дөньяның камил һәм бай телләренең берсе. Татар теле дәресләрендә дә әхлакый төсмерле тел материалы кулланыла. Шуны һәрдаим исәптә тотып, игелек, кешелеклелек, мәрхәмәтлек, вөждан, Ватанга мәхәббәт турында сүз алып барырга тырышабыз. Эш өчен текстлар сайлаганда да һәрвакыт шушы мәсьәләне күздә тотарга кирәк. Рухи-әхлакый тәрбиядә иҗат эшләре дә зур роль уйный (иншалар, изложениеләр, диктантлар, проект эшләре һ.б.). Дәресләрдә патриотизм, туган җиргә мәхәббәт, намус, вөждан темаларына кагылышлы текстлар сайлап кулланыла. Укучылар Ватанны ярату нәрсә аңлатканын, гражданлык бурыч турында тугры дөрес фикер йөртәләр. Шулай итеп, сәнгати каләм сүзе балаларның хисләренә дә, эшләренә дә тәэсир итә.

Чыннан да, әдәби сүз баланы канатландыра, югары тәрбияле булырга, яхшы гамәлләр башкарырга теләк уятырга сәләтле. Шулай ук кеше мөнәсәбәтләрен дөрес аңларга, тәртип нормалары белән танышырга ярдәм итә. Гомумән, әдәбият, нинди телдә генә булмасын — ул тәрбиянең нигезе, һәрвакыт тугры юл сайларга ярдәм итүче илаһи күренеш.

Шуңа күрә балаларны матур әдәбият китаплары укырга өндәргә кирәк. Әдәбият дәресе тормыш итәргә өйрәтә, тәҗрибә формалаштыра, геройларның кылган ялгышлыклары аша дөрес юлны сайларга булыша. Өстәвенә, китап кешене рухи яктан баета, аның эстетик яссылыгын тәрбияли. Текстны күзәтү, аны игътибар белән уку баланың критик фикер йөртә алу сәләтен үстерә. Бала укый, анализлый, бәя бирә, автор ни әйтергә теләгәнен ачыклый. Гражданлык тәрбиясендә әдәби дискуссияләр бик зур роль уйный. Алар критик фикер йөртүне үстерәләр, укучыларны реаль тормышка әзерлиләр.

Әхлакый тәрбия проблемасы хәзерге вакытта бик актуаль. Совет мәктәбендә патриотик тәрбия октябрь, пионерлар, комсомол оешмалары, күпсанлы патриотик конкурслар, хәрби-патриотик слетлар, Тимур хәрәкәте ярдәмендә башкарылса, хәзер, кызганычка каршы, болар барысы да онытылган. Мондый гадәтләрне заманга яраклаштырып, торгызырга кирәк. Рухи кыйммәтләрне формалаштыру процессы — озак вакытны ала, монда тиз нәтиҗә була алмый, ләкин татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укытучылар тарафыннан үткәрелә торган эш укучыларның күңеленә кыйммәтле азык, зиннәт, рухи байлык салырга ярдәм итәчәк.

**Литература**


1. Махмудов А.Г.,Гараева Н.Г. Татарская литература. Учебник хрестоматия для студентов средних специальных учебных заведений / Казань «Магариф», 2010.
2. Морозова А.Р. Этнокультурное образование в Российской Федерации. Татарский компонент/А.Р. Морозова, Р.Р. Корчагина. – Казань: РИЦ «Школа»,2006. – 140с.
3. Хасанова Ф.Ф., Примерная рабочая программа учебного предмета «Татарская литература» для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык как родной). 1 – 11 классы /Казань. Татарское книжное издательство, 2017.

# ТАТАР ТЕЛЕН ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ БУЛАРАК ӨЙРӘТҮ ПРОЦЕССЫНДА ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

***Кадыйрова Л. З.***
***Казан шәһәренең 99нчы мәктәбе***
***e-mail:ltisan-leika21@inbox.ru***

***Аннотация.*** В данной статье рассматриваются современные технологии обучения татарскому языку как государственному. На сегодняшний день в Республике Татарстан существует два подхода в обучении татарскому языку: для учащихся, изучающих татарский язык как родной и для учащихся, изучающих язык как государственный. Последние изучают татарский язык на уровне иностранного. Для того, чтобы повысить у детей их коммуникативную компетенцию на татарском языке важно уметь правильно выбирать технологии преподавания. Наряду с традиционными технологиями преподавания на сегодняшний день особую значимость приобретают и современные технологии обучения языку.

***Ключевые слова:*** современные технологии преподавания, татарский язык, государственный язык, методика преподавания татарского языка, обучение в сотрудничестве.

Күпчелек тикшерүчеләр уку технологияләрен сыйныфта укуга шәхси-эшлекле карашны тормышка ашыруның бер ысулы дип саныйлар. Мондый караш кыссаларында укучылар белем бирү эшчәнлегенең актив иҗади субектлары булып торалар [2: 12].

Татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче мәктәпләрдә татар телен укыту методикасында заманча укыту технологияләренә гадәттә түбәндәге технологияләр кертеп карала: хезмәттәшлектә уку, проект методы (проект технологияләре), укучыларга юнәлтелгән укыту, дистанцион укыту, тел портфолиосы, компьютер һәм аудиовизуаль технологияләр куллану.

Әлеге технологияләрне аерым карап узыйк:

*Хезмәттәшлектә укыту технологиясе.* Бу технология сыйныфтагы укучылар арасындагы үзара бәйләнеш һәм үзара өйрәнү идеяләренә нигезләнгән, анда укучылар уку проблемаларын чишү өчен бер-берсен генә түгел, коллектив җаваплылыкны да үзләштерәләр, бер-берсенә булышалар һәм һәр укучының уңышлары өчен коллектив җаваплылыкны үз өстенә алалар. Фронталь һәм индивидуаль укудан аермалы буларак, укучы индивидуаль белем бирү субъекты булып тора, ул “үзе өчен”, уңышлары һәм уңышсызлыклары өчен җаваплы, һәм укытучы белән мөнәсәбәтләр хезмәттәшлектә алып барыла, үзара бәйләнеш өчен шартлар тудырылган. “Укучы – укытучы – сыйныф” системасында хезмәттәшлек һәм мәгариф эшчәнлегенең коллектив предметын актуальләштерү эше башкарыла. Бергәләп бирем чишелә, һәм көчле укучылар “йомшаграк”ларга белем алу бурычларын тормышка ашыруда булышалар. Бу уртак укуның гомуми идеясы уку биремен чишүдә көчле дә, йомшаграк

укучылар да катнашуын тәэмин итә. Тәмамланган биремне бәяләү булып барлык сыйныфка бер билге куелудан гыйбарәт.

*Компьютерлар технологиясе.* Бу компьютер белән эшләү өчен эшләнгән укыту планнарын кулланып телне укыту технологиясе. Әлеге технология программалаштырылган уку идеяларын барлыкка китерде һәм бүгенге көндә урта белем бирү оешмаларының массакүләм компьютерлаштыру, укыту предметлары өчен компьютер программалары булдыру, шул исәптән телләрне өйрәнүчеләр өчен укыту процессының барлык аспектларына да, шул исәптән укучыларның мөстәкыйль эшендә Интернетны куллануга да зур йогынты ясады.

Компьютер лингводидактикасы – дисциплинар белем өлкәсе һәм информацион технологияләр, гамәли һәм математик лингвистика үсеше, ясалма интеллект өлкәсендәге үсеш, компьютер дизайны, кеше-компьютер үзара бәйләнешен тикшерү, гомумән компьютерларның өйрәнү теориясе һәм практикасы белән тыгыз бәйләнештә тора. Бу дисциплина XX гасырның 80-нче еллар ахырыннан телләрне укытуда мөстәкыйль юнәлеш буларак формалашты һәм анда өч тикшеренү өлкәсе эшләнде:

1) тел укытуда компьютерларны кулануның теоретик аспектларын үстерү (компьютер лингводидактикасының методик проблемалары, компьютер укыту материалларының типологиясе, компьютер укыту әсбапларының эффективлыгын бәяләү һ.б.);

2) компьютер материалларын тел укыту процессының төрле максатлары, этаплары һәм эксперименталь эш төрләре;

3) компьютер өйрәнүен тел өйрәнүнең гомуми процессына интеграцияләү ысуллары.

Интернет барлыкка килү һәм үсеше белән компьютерларны тел укытуда куллану мөмкинлекләре бик киңәйде. Глобаль челтәрдә укучыларның өч төп эшчәнлеге карала:

1) Мәгълүматны текст, электрон газета, китап, аудио һәм видео тапшырулар рәвешендә кабул итүгә юнәлтелгән чаралар. Кабул итүнең эффективлыгын тикшерү бу очракта традицион рәвештә, шулай ук гади басма текст, аудио һәм видео язмалар белән эшләгәндә үткәрелә.

2) Актив эшчәнлек – укучы мәгълүматны кабул итү белән беррәттән, онлайн формалар тутыруда катнашканда, тестлар үткәндә, нәтиҗәләре шунда ук бәяләнә һәм экранда күрсәтелә, укучы электрон почта аша открыткалар җибәрә, үз веб-страницаларын булдыра, уртак онлайн проектларда катнаша, онлайн уеннар уйный ала һ.б.

3) Интерактив эшчәнлек – бу очракта укучы мәгълүмат җибәрүче дә, алучы да. Бу төрле чатлар, мәсәлән реаль вакыттагы сөйләшүләр, аудио һәм видео конференцияләр, дистанцион уку сессияләре ярдәмендә уку.

*Укучыларга юнәлтелгән укыту.* Бу төр белем заманча уку технологияләренең вариантларының берсе буларак чит ил урта һәм югары уку йортларында киң таралды. Мондый укытуның асылы дәресләр процессында инициативаны максималь рәвештә укучының үзенә бирүдән тора. Дидактик

күзлектән караганда, бу уку технологиясе дәреснең махсус оештырылуы, укытучы һәм укучылар арасында хезмәттәшлек мөнәсәбәте булдыру нәтиҗәсендә укучының шәхси потенциалын тулысынча ачуны үз эченә ала. Бу алым традицион укыту технологиясеннән аерылып тора: укытучы укучыга белем бирә, осталык һәм сәләтләрен формалаштыра һәм белемнәрне үзләштерүне контрольдә тота. Коммуникатив өйрәнү идеясенең алга таба үсеше дип саналырга мөмкин булган бу укыту технологиясе белән, өйрәнелә торган телдә аралашу укытучы һәм укучылар арасында хезмәттәшлек мөнәсәбәте урнаштыру һәм шәхесне ачу өчен шартлар тудыру мөмкинлеге бирә. Бу технология кысаларында укытуның максаты – укучыларның укудагы автономиясе булганлыктан, укучы үзе өчен уңайлы булган белем алу юлын сайларга тиеш. Бу максаттан ул телне үзләштерү стратегиясен сайлый һәм аларны уку процессында кулланырга тырыша. Менә бу стратегияләрнең кайберләре: 1) индивидуальлегеңне күрсәт; 2) белем алу процессын оештыр; 3) иҗади бул; 3) билгесезлек белән көрәшергә өйрән; 5) хаталарыңны кабаттан тикшереп, аларны бетер; 6) контекстны кулан.

*Дистанцион уку.* Мәгариф процессын оештыруның бу формасы компьютер телекоммуникация челтәрләрен кулланып дистанцион өйрәнүне тәэмин итә. Укучылар үзләренә тәкъдим ителгән биремнәрне мөстәкыйль башкара, алар укытучы тарафыннан укучылар белән шәхси очрашуда тикшерелә яки электрон почта ярдәмендә укучыларның эше контрольдә тотыла. Дистанцион укытуның төп үзенчәлеге – укытучы һәм укучы арасындагы телекоммуникация элемтәсенең арадаш характеры. Дистанцион уку курслары укучының эшчәнлеген җентекләп планлаштыру, кирәкле уку материалларын китерү, югары эффектив җавап алу, укучы һәм укытучы арасында максималь интерактивлык өчен эшләнгән. Хәзерге вакытта телләрне дистанцион өйрәнүне оештыру өчен төрле вариантлар эшләнде, һәм мондый өйрәнүнең эффективлыгы исбатланды. [1] Мондый укыту укучыларга глобаль интернет челтәрләрендә тупланган дөньяның мәдәни һәм мәгариф кыйммәтләрен киң кулланырга, тәҗрибәле укытучылар җитәкчелегендә өйрәнергә, осталыкларын арттырырга һәм белемнәрен тирәнәйтергә мөмкинлек бирә. Илдәге мәгариф учреждениеләрен планлаштырылган тулы компьютерлаштыру белән бәйле рәвештә, дистанцион уку заманча технологияләр системасында мәгарифнең иң перспектив формаларының берсе булып каралырга мөмкин.

*Интерактив укыту методлары.* Бу хәзерге социаль психологиядә иң популяр төшенчәләрнең берсе булган интерактивизмга нигезләнгән заманча методлар төркеме. Бу концепция кысаларында кешеләрнең иҗтимагый үзара бәйләнешен шәхесара аралашу дип аңлау тәкъдим ителә, аның иң мөһим үзенчәлеге – кешенең “бүтән ролен кабул итү” сәләте, элемтә партнеры аны ничек кабул итүен күз алдына китерү һәм, шуңа күрә, ситуацияне аңлатып, үз максатына ирешү. Күпчелек ил укытучылары белән берлектә тормышка ашырылган тәнкыйди фикерләү өчен уку һәм язу (Reading and Writing for Critical Thinking – RWCT) проекты кысаларында интерактив укыту методикасы эшләнә. Проектның төп максаты – педагогикага төрле яшьтәге укучыларның

тәнкыйди фикер йөртүен үстерүче мондый универсаль ысуллар кертү. Бу ысуллар традицион мәгариф формаларында эффектив кулланылырга мөмкин. Интерактив методларның үзәк идеясы – конструктив интеллектуаль эшчәнлек буларак тәнкыйди фикерләү үсеше, мәгълүматны мәгънәле кабул итү һәм аннан соң үзләштерү. Тәнкыйди фикерләү – катлаулы акыл процессы, ул яңа мәгълүматны өйрәнүдән башлана һәм карар кабул итү белән тәмамлана. Интерактив методлар кысаларында, өйрәнү этабы, аңлау һәм рефлексия этабыннан торган өйрәнүнең нигезләре эшләнде. Авыр этапта бу метод яңа темага кызыксыну уята, укучылар элеккеге белемнәргә һәм тел тәҗрибәсенә нигезләнеп, яңа мәгълүматның эчтәлеге турында фаразлыйлар. Аңлау этабында эш текст белән алып барыла, яңа материал өйрәнелә, укучылар яңа мәгълүматны аңлау өчен текстка кертелгән идеяларны үз идеялары белән берләштерәләр. Уйлану (рефлексия) этабында, укучылар алынган мәгълүмат турында уйланалар, шулай итеп яңа материалны берләштерәләр.

*Уку технологиясе буларак тел портфолиосы.* Тел портфолиосы – аның хуҗасы максатчан телне үзләштерүдәге казанышларын һәм тәҗрибәсен, алган квалификацияләрен, шулай ук телне өйрәнү барышында башкарылган кайбер эш төрләрен туплаучы документлар пакеты.

Тел портфолиосын материалларын кулланып, укучы үзенең тел белү дәрәҗәсен сыйныфта башка укучылар дәрәҗәсе белән, шулай ук уку стандартлары белән чагыштырырга һәм билгеләргә (мөстәкыйль рәвештә дә, укытучы ярдәмендә дә) мөмкинлек бирә. Шуңа күрә тел портфолиосы укучыларның максатчан телне үзләштерү буенча мөстәкыйль эшләрен иң рациональ оештыру өчен эшләнгән уку ысулы.

Европа тел портфолио (ELP) дип аталган тел портфолиосы Европа Советы проекты кысаларында эшләнде. 1997-2000-нче елларда 15 Европа илендә, шул исәптән Рәсәйдә дә, төрле белем дәрәҗәләрендә сынадылар: урта һәм югары мәктәпләрдә, тел курсларында, һәм проект катнашучылары әйтүенчә, бу стандарт телләрне өйрәнүгә зур йогынты ясады.

Европа тел портфолиоы нигезендә телләрне өйрәнүдә милли мәдәни һәм мәгариф традицияләрен исәпкә алып, тел портфолиосының милли версияләре эшләнде. Татар тел портфолиосы стандартын булдыру – киләчәк эше, ул якын киләчәктә булдырылыр дип ышанабыз.

Шулай итеп, татар телен дәүләт теле буларак укыту өчен кулланырга мөмкин булган заманча технологияләрне өйрәнеп, без түбәндәге нәтиҗәләр ясый алабыз: хәзерге вакытта уку процессын көчәйтүнең ике төп ысулы бар: берсе – техник чараларны максималь куллану аша, икенчесе – һәр укучының шәхес резервларын активлаштыру аша. Укыту системасына техник чараларның органик кертелүен тәэмин итүче интенсив методлар булдыру, киләчәктә укыту процессын көчәйтү юнәлешендә методиканы камилләштерү өчен иң перспектив юнәлеш булачак дип фаразлыйбыз.

Һичшиксез, киләсе еллар өчен иң перспективалы булып компьютерлар технологиясе һәм укыту процессында төрле дистанцион уку формаларын үз эченә алган технологияләрне өйрәнү булачак.

**Әдәбият**

1. Азимов Э.Г., Самуйлова Н.И., Шамши Л.Б. ТСО на современном этапе развития методики преподавания русского языка как иностранного // Русский язык за рубежом. – 1998. – № 2.

2. Щукин А.Н. Обучение иностранным языкам: теория и практика. 3-е изд. М., 2007. – 186 с.

# *ҚАРА* ТҮС ҰҒЫМЫМЕН ҚАЛЫПТАСҚАН АТАЛЫМДАРДЫҢ ТАНЫМДЫҚ-СЕМАНТИКАЛЫҚ МӘНІ

**(*Түркі тілдері негізінде*)**

**Қасым Б., Бақбергенова Р.**
**Абай атындағы Қазақ ұлттық педагогикалық университеті**
**bkasym_gosyaz@mail.ru, roza7713@mail.ru**

***Аннотация.*** В статье когнитивная система тюркского слова «кара» рассматривается с лингвокогнитивной точки зрения. Изучение слова «кара» в тюркологии было дифференцировано языковыми данными. Было разработано семантическое поле слова «қара» и показаны эффективные способы их анализа.

***Ключевые слова:*** Семантическое поле, семантический анализ, тюркские языки, когнитивная парадигма, культурно-духовный мир.

**Кіріспе.** Тілдің тұтас сөзжасам жүйесінде ***күрделі аталымдардың*** (*сложные номинаций*) алатын орны ерекше. Олардың белгілі бір тілдік заңдылықтар жолымен дамып, мағыналық-семантикалық өрбуі, функционалды қызметі негізінде туындаған аталымдар атау, ***таңбалық-символдар*** ретінде ұлттың танымы, болмысы, әдет-ғұрпы, наным-сенімі, салт-дәстүрі, рухани-мәдени өмірімен тығыз байланысты. Соның нәтижесінде когнитивтік, семантикалық-функционалды қызметте жұмсалып, белгілі кеңістікте коммуникативті-прагматикалық қызмет атқарады. Осындай аталымдар *ұғым, мағына* жағынан *символдық мәнге* ие болған атаулар, яғни тілдік бірліктер белгілі бір дәрежеде халық танымындағы *дүниенің тілдік бейнесін* танытады. А.М. Плотникова: «Одно из ведущих направлений современной лингвистики – *когнитивная семантика* исследует значения языковых единиц как результат *познавательной деятельности человека* и способ репрезентации знания. Когнитивная парадигма, возникшая на рубеже XX–XXI вв., является новым этапом осмысления проблем языка и мышления, языка и действительности» дейді [4: 4] (*курсив*-Б.Қасым). Демек, қазіргі лингвистиканың соңғы дамулық кезеңінде ғалымдар тіл табиғатын адам болмысымен, оның ұлттық дүниетанымымен, қимыл-әрекетімен ұштастыра қарастыра отырып, тіл мен таным, оның мән-мазмұн ұғымдарына назар аударуда. Соның нәтижесінде қазіргі уақытта *антропоцентристік бағыт* басымдыққа ие болуда.

**Зерттеу мақсаты.**

- ***қара*** сөзінің ұғымдық мазмұнында (*түрк тілдері негізінде*) қамтылған танымдық жүйесін лингвокогнитивтік, семантика саласында ғылыми түрде зерттеліп мойындалған тұжырымдар негізінде түркі тілдеріндегі деректермен салыстырып, зерделеу, талдау;
- ***қара*** сөзінің сөздіктердегі мағыналық ерекшеліктері мен танымдық мазмұны туралы ақпаратты зерделеу;
- ***қара*** сөзінің семантикалық өрісін құрып, оларды талдаудың тиімді жолдары мен әдіс-тәсілдерін ұсыну.

**Зерттеу әдісі.** Сипаттау, салыстыру, талдау, жинақтау.

• ***қара*** сөзінің түркологияда зерттелуі тілдік деректермен сараланады**;**

• ***қара*** тірек сөзінің семантикалық мазмұндық құрылымын анықтауда семантикалық талдау әдісі (пәндік, бағалауыштық, сезімдік компоненттер) қолданылады; тілдік деректердің берілуіне талдау жасалады;

**Талқылау.** Қазақ халқының мәдени-рухани әлемінде *ақтың* антонимі ретінде *қара* түс қолданылып, *ақ – қара* қарама-қарсы концепті жүйесін құрайды. Сонымен бірге *ақ – күннің, қара – түннің* символдық белгісі. Қазақ тілінде *қара* сөзінің ең негізгі түстік номинативтік мағынасы көптеген ауыс, символдық мағыналарының пайда болуына ұйытқы болған. Түстік, сындық мағына беретін *қара* сөзінің неліктен түс атауына қатыссыз мағынаға ие болғанын қазіргі синхрондық тілдік тұрғыдан әрине қиындық тудыратын тұстары бар. Сөздің жаңа мағынаға ие болуы, оның белгілі бір жағдаятта немесе мәтінде жаңа қолданысқа түсуі, функционалды-прагматикалық қызмет атқаруы, тіл иесінің жұмсалым мақсатмен тығыз байланысты. Б.Қасымның: «Заттың, құбылыстың атауы жасалғанда сол нақтылы сөздің (атаудың мағынасы ескеріледі, нақтырақ айтқанда, негізгі номинативтік мағына – сигнификат, затты бейнелеудегі маңызды белгісі немесе талданған сөздің нақтылы тура мағынасы қатысады. Яғни заттың тура аталым қасиеттері заттың күрделі атауларының белгілерін көрсетеді [1: 135]. Демек мұндағы ***қара*** – қасиетті деген ұғымды да береді. Қазіргі лингвисткада семантикалық бағыт тілдік бірліктердің концептуалдық мазмұн ерекшелігін қарастырады: (А.Н. Бабушкин, И.А. Стернин, З.Д. Попова және т.б.). Осы орайда кейбір *қара* түсіне байланысты сөздер көне ескерткіштер тілінен бастап, бүгінгі тілдік қолданыста да лексема ретінде өз мән-мағынасын жоймағанын көрсетеді. Мысалы, «қара» сөзінің архисемасына талдау жасалады: көне түркі тілінің өзінде бірнеше мағынасы болған: **ҚАРА** I. 1. *қара* (түс); 2. *түнек* (жарық емес); 3. ауыс. *бақытсыздық, қайғылы*; 4 ауыс. *жамандық, қара көңіл;* 5 ауыс. күнделікті жай; 6. лас; 7. сия; *qara jer* – ауыс. *табыт*; *qara juz* – қызметші (слуга); *qara orun* – ауыс. *мола* (могила); *qara jağ* – нефть (МК III 222), *qara jol* – жол, *qara jel* – қатты жел (сильный ветер); шторм; *Қара терім* йүгүрті (Тон, 52*), Қара терімді* ағыздым. II. Тобыр*,* ***көпшілік*** (масса, толпа): *qara bodun – бұқара*; *qara baş* – құл (раб, слуга), [ДТС., 108, 169, 423с.], *qara jüz* – слуга [ДТС, 423 с.]. Бұл сияқты сөздер басқа сөздердің тууына өз үлестерін қосары сөзсіз. Жоғарыдағы сөздердің үлгісімен қазіргі тілде қаншама *туынды сөздер* (күрделі атаулар) жасалғаны белгілі. Соған орай ***жер*** стихиясы да, қараның бірнеше мағынасына архетип, негіз болған. ***Қара*** – *жер, тас, күш* т.б. Судың түбі, тереңдігі, сыры мәлімсіздігі, апат әкелетіні, сонымен қатар, нәр, қуат, күш беретіне қатысты – *қаражер****,*** *қарасуық; қаражел; қаракүз; қарасуық; қараборан, қарадауыл****,*** *қарасу* (*терең су*), *қара(а)ғаш* (*мықты, күй талғымайтын*), *қаранан* т.б. Мысалы, *қарахалық, қарашаңырақ, қараөлең, қарасөз, қарамал,* т.б.

***Қара*** сөзінің түркі тілдеріндегі ауыс семантикалық мағыналары бұдан да көп болуы мүмкін, себебі коммуникативті-прагматикалық мақсатқа

байланысты контекстік жұмсалымда да кездеседі. Қазақ тілінде отыздан аса семантикасын тілдік деректермен дәйектеп көрсетіп отырмыз [3:126]

***Алтай*** тілінде ***КАРА*** (түс). **семантикалық өрісі:** «Прилагательное *кара* в алтайском имеет широкую семантическую наполненность, начиная от обозначения пигмента, краски, красителя (*кап-кара чачту уй кижи* – брюнетка, *кап-кара чачту/кара чырайлу кижи* – брюнет, *кара чачту* – черноволосый, *кара башту* – черноголовый, *кара терелу* – чернокожий, *кара ат* – вороная лошадь, *кара-куреҥ* – чернобурый) до значений *отрицательный, плохой, злостный, коварный, преступный* (*кара санаалу кижи* – злодей, *кара сагыш* – злой умысел). А.Н.Кононов: «Кроме того, *кара* может выступать как составная часть некоторых ботонических и зоологических названий (*кара агаш јиилек* – ежевика, *кара торбос* – черника, *кара тытвяз, кара-куреҥ мешке* – березовый гриб, *кара бака* – жаба, *кара чилен* – цапля)» [2: 54].

***ҚАРАҢУЙ.*** «Прилагательное отмечено в небольшом количестве алтайских топонимов, что в др.-тюрк. *qaranqu* означало 1) темный, лишенный света; черный, 2) темнота, тьма, мрак, 3) *перен.* темный, неблагадивный, подозрительный; *qaranqu qarargy* – тьма, мрак; *qaranqu tunarig* темный, лишенный света; мрачный; *karanku tuni* – темная ночь, *karankuda erdim* – я был во тьме. Алтай тілінде *қара* түсінің мағынасын топонимикалық атауларында жиі кездесетіні жайлы тілші О.Т.Молчанова: «В алтайском *караҥуй* встречается в следующих сочетаниях: *караҥуй комната* – темная комната; *караҥуй тун* – мрачная ночь; *эш неме корунбес караҥуй* – непроглядная тьма, но угрюмый мрачный лес – *буруҥкуй агаш*; *караҥуйлаган* – стемнело, *караҥуй тун* – темная ночь. В кирг. *караҥгы бөлмө* – темная комната; якутск. *хараҥа түүн* – темная ночь; *далай хараҥа* – темный как водная глубь; *ыас хараҥа* – темный как смоль и др.; хак. *харасхы хараа* – темная ночь; тув. *караҥгы дүн* – темная ночь; *караҥгы арга* – дремучий лес. В монгоьских языках данное прилагательное образует ряд сочетаний: монг. *харанхуй ой* – дремучий лес; *харанхуй тасалгаа* – темная комната; *харанхуй шөнө* – темная ночь; *харанхуйлан бүрхсэн тэнгэр* – мрачное небо; По-видимому, в монгольских языках анализирумое прилагательное более продуктивно, образует большее, чем в тюркских языках, количество словосочетаний. *Караҥуй* не зафиксировано ни в алтайских этнонимах, ни в личных именах. Употребление слова в топонимии Киргизии тоже ограничено: *Караҥгы-Токой;* в доступных нам материалах по казахской, тувинской, хакасской, шорской топонимии указанное прилагательное не зафиксировано. На средневековых монгольских картах встречается всего два топонима с анализируемым компонентом: Qarangqui bulay, Qarangqui yool (обо водные обьекты) [7].

***Монғол*** тіліндегі *Хар* сөзі *қара* түсін білдірумен қатар, ауыс мағыналарда қазақ тіліндегі күрделі сөздермен сәйкес келеді.

***Башқұрт*** тіліндегі ***Қара*** сөзі де осы мағынада келеді. ***Кара*** I 1) *черный*; 2) *карий*; 3) *смуглый*; 4) *чумазый, грязный*; а) *чернить, марать, кого-что*; б) перен. *пятнать, запятнать, чернить, очернить кого-что*; 5) дремучий (о

лесе); 6) *курной, қара мунса - черная баня*; 7) *необразованный, темный* (о человеке); <> *күş караһы* – зрачок; *кара йөрәк* – жестокосердный.

*Қара һауыты* – чернильница; *қарабалык* – линь (рыба); *қарабойşай* – гречиха; *қарағат* – смородина; *қарағош* – стервятник; *қаразирә* бот. – дурман т.б.

***Тыва*** тілінде ***Кара*** 1. 1) черный; темный; кара карак – темные глаза; кара довурак – черноземный; 2) *перен.* простой, рядовой. кара кижи простой человек; 2. мишень; цель; *кара угаан* природный ум; *кара сагыштыг* коварный, злой, злоумышленный; *кара суг* ключ, ручеек; *кара таакпы* опиум; *карабаарзык* скворец; *кара-бажың* тюрьма; *карабөскек* курапатка; *карабыт* блоха; *каракат* черника; *каракундус* выдра; *каракуш* глухарь; *каратараа* просо т.б.

«*Қазақ тілінің түсіндірме сөздігінде*» ***қара*** сөзіне қатысты берілген мағыналары:

***Түстік мағынасы.*** **Қара** сын есім. Күйенің, көмірдің түсіндей (түс, бояу).

**2. Қара түсімен келген заттық-таңбалық мағынадағы *күрделі аталымдар:***

Аталмыш жайт таңбаланушы денотаттың символдану үдерісін көрсетеді.

**а) аң-құс атаулары:**

*Қарабай*[1] зат. зоол. *Басы, мойны, арқасы қоңыр, жылтыр қара болып келетін, сулы жерлерде болатын құс. Қарабай қоңыр түсті, сулы жерде болатын құс.*

*Қарабауыр* зат. зоол. *Аяқтары қысқа, денесі тығыз, кептер шамалас, бұлдырықтар отрядына жататын құс. Қарабауырдың* сүйіп қоныстанатын жері – сазды шөлдер (Ш.Әлиев, Сирек хайуан).

*Қарабауыр* зат. зоол. *Аяқтары қысқа, денесі тығыз, кептер шамалас, бұлдырықтар отрядына жататын құс. Қарабауырдың* сүйіп қоныстанатын жері – сазды шөлдер (Ш.Әлиев, Сирек хайуан).

*Қарабалық* зат. *Балықтың бір түрі.* Маринов, Су сіңген көлдерінде сазан, шортан, *қарабалық,* мөңке, алабұға өседі (К.Күленов, Қазақстан. балық.).

*Қарабай (құс), қарабас: қарабас шағала (құс), қаракөз (балық), қаракүзен (зоол.), қаракүйе (зоол.), қарақарға (зоол.), қарақас (зоол.), қарақас тышқан, қарақол, қарақоңыз (зоол.), қарақұйрық (зоол.), қарақұлақ (зоол.), қарақұрт (зоол.), қарақұс (құс), қаратұрпан (құс), қаратүлкі (зоол.), қарабауыр (зоол.), қаратырна, қарашыбын, қарабалық,* т.б.

**ә) өсімдік атаулары:**

*Қараағаш (өс.), қараалма (өс.), қараандыз (өс.), қарабарақ (өс.), қарабас шалғын (өс.), қаработа (өс.), қаражеміс (өс.), қаражидек (өс.), қаражидегі, қаражусан (өс.), қаражырық (өс.), қаражырығы, қаразерек (өс.), қаразерегі, қаракенен (өс.), қарамеңдуана (өс.), қараот (өс.), қарарша (өс.), қарасасыр (өс.), қарасора (өс.), қараөлең (өс.), қарасұлы (өс.), қаратал (өс.), қаратамыр (өс.), қаратаяқ (өс.), қаратұяқ (өс.), қарашора (өс.), қарашулан, қарашығын (өс.), қараырғай (өс.), қаратұяқ (өс.)* т.б. *Қарабарақ* зат. бот. *Сексеуіл тәрізді*

*алабота тұқымдасына жататын бұта.* Ошақ басына боялыш пен *қарабарақты үйіп тастайды (Н.Сералиев, Ыстық күлше). Қарабарқын* зат. бот. *Сор, ащы жерге өсетін,* биіктігі жарты метрдей қатты бұта. *Қарабарқын* отынға жарайды, жапырағын түйе сүйіп жейді (Диал. сөздік). *Қарабас* зат. бот. *Астық тұқымдас өсімдік, арам шөп.* Жатаған бидайық, шырмауық, *қарабас,* қара сұлы, арам сояу, сұңғыла арам шөптерін дихандар егістіктің өрті деп атайды (Т. Таубаев, Жасыл әлем.).

*Қарабидай* зат. 1. *Сабағы тік, ...жапырағы таспа тәрізді, сырты түкті, шашақ тамырлы астық тұқымдас дақыл.* Ең ірі, клетчаткасы көп, соған орай сіңімділігі де, жұғымдылығы да төмен сабан – *қарабидай* мен күздік бидайдың сабаны (Қ. Құсайынов, Сабан.). 2 *Осы дақылдың дәні; астық. Қаработа* зат. бот. *Ала бота тұқымдасының бір түрі.* ***Қарабура***[1] зат. кәсіб. *Ағаш, шырпы, қамыс сияқтылардан су жолына қойылатын тосқауыл, бөгет.* Міне, 20-30 жігіт әрқайсысының ұзындығы 10 метрдей келетін қомақты-қомақты *қарабураларды* өзеннің екі жағынан кере қағылған ағаштардың аралығына жіп арқанмен өзен түбіне түсіре бастады (Лен. жас).

***Қарабура***[2] зат. *қамыс, құрай сияқтылардан жасалған қоршау, шарбақ, қора. Қарабураны* жақсылап істесе, үй маңайына қар түспейді (Диал. сөздік.).

*Қарабүлдірген* зат. бот. *Ұсақ, шырынды, қара немесе қызыл қара түсті жемісі бар, бұталары тікенекті, раушан гүлділер тұқымдасының бір түрі.*

*Қаражидек* зат. бот. *Ірі сабақты, жасыл бұтақты, қара домалақ жемісті көп жылдық өсімдік. Қаражусан зат. бот. Жусан тұқымдасының бір түрі. Бұл – қаражусан, оны қазақша майқара деп те атайды (Б. Мұханов.., Қазақст. өсімдік.), қарақұмық, қарақұмығы, қаraшірік(ауылшар)* т.б.

**3. Қара түспен келген аталымдардың ауыспалы мағыналары:** *қарабауыр (қатыгез), қарабет, қарабет болу, қарабие (ойын), қарағұс (шүйде сүйек), қарадәу (фольк.), қаражарыс, қаражарысқа түсу, қарақағаз, қарақағаз келу, қарақағаз төсеу, қарақазан (ауқатты), қарақұлақ (ойын), қарақұлағы, қарапайым сөз, қарасөз, қарасу (геогр.), қаратізім, қарашаш (фольк.), қарашекпен (көне), қарашешек, қараниет.* ***Қарабай***[2] зат. *Сараң, қайырымсыз, дүниеқор. Сартабан өмірі малмен өткен адам көрінеді.*

**Аузынан қара қан ағызды.**

а) *Таяққа жықты, өлтіре соқты.* Кеше мұз ығардың алдында осы Еламанды ұрып, аузынан *қара қанын* ағызып жібергені есіне түсті (Ә. Нүрпейсов, Қан мен тер). ә) *Былапыт сөздер айтты, балағаттады.* Ашулы адамның сөзі аз болса, ыза қуаты артында болғаны. Егерде аузынан *қара қан* ағызса, мақтаншақ, я қорқақ (Абай, Тол. жин.). *Аузына қарақан толғыр [аузынан қара қан келгір]. Ертеден қара кешке – Күні бойы, таң атқаннан күн батқанға дейін, ұзақты күн.* т.б.

*Ақсақал-қарасақал. қара бақай, қара бала, қара бақыр, қарабет, қара борбай, қара жаңбыр, қаражаяу, қаражел, қаражер, қаражол, қаражұмыс, қаражұрт, қара жүз, қара жүрек, қарадауыл, қара домалақ, қарает, қаражарыс, қаражол, қара жон, қаражұрт, қаракесек, қаракөже, қарасөз, қаракөлеңке, қаракөңіл, қаракүз, қаракүш, қарақазан, қара құлақ, қара орман,*

*қара нәсіл, қаранөсер, қара нөпір, қараорын, қараот, қараөлең (әдеб.), қара қорым, қарасан, қарасирақ, қарасуық, қаратабан, қаратер, қаратобыр, қара топырақ, қаратұяқ, қаратүнек, қара тіл, қара үй, қара халық, қарашай, қарашаңырақ, қара шаруа, қарақұс, қаражат, қарақағаз, қарашығын.*

а) **Қара түсімен келетін ауру атаулары:**

*Қарабез* зат. *Түйеде болатын жұқпалы ауру (омырау, шап бездері ісіп, қараяды).* Бұл індет жылқыда *жамандат*, түйеде *қарабез, ақшелек*, ірі қарада *қараталақ*, ошақ, қойда *топалаң, ылаң, алаң*, ешкіде *шекшек* деп аталатын (Х.Арғынбаев, Қаз. этногр.). *Қараөкпе (мал ауруы), қарасан (мал ауруы), қарабез (ауру), қаратүйнек (мал ауруы). Артынан [соңынан, ізіне] қара ермеген. Тұл, баласыз, бауырсыз. Аузына [аузынан] ақ ит кіріп, қара [көк] ит шықты. Аузына келгенін айтты, бет алды сөйледі.*

Бұл – қазіргі қазақ тілінде *қара* сөзінің ең негізгі түстік номинативтік мағынасының негізінде туындаған ауыспалы мағыналары. Көптеген ауыс, символдық мағыналардың пайда болуына ұйытқы болған. Сонымен *қара* түсіне байланысты берілген мысалдар арқылы ***түстік, зұлымдық, белгісіздік, қайғы-уайымдық, киелілік, қасиеттілік, қарапайымлық,*** мағынасын тануға болады және осы мағыналар сөздің ұғымдық нышандық, яғни таңбалық белгісін де білдіріп жатады.

*Қара* сөзінің бірінші мағынасы – «*ақтың қарама-қарсы түрі*». Бұл оның негізгі мағынасы. Бірақ бұл номинативтік мағына одан кейін пайда болған коннотативтік мағынаның қалыптасуының барлығына бірдей ұйытқы бола алмайды. Мысалы, түркі топонимикалық жүйесінде жиі кездесетін *ɡara su* тіркесінің мағынасы сумен емес, жермен байланысты. Ал барлық орта ғасырлық түркі ескерткіштерінде кездесетін *ɡara budun* термині халықтың түсіне байланысты емес, оның қоғамдық-әлеуметтік орнымен байланысты, яғни қарапайым төменгі сатыдағы халық. *Қара* сөзінің ауыспалы коннотативтік мағынасы оның номинативтік мағынасына қарағанда әлдеқайда көп. *Қара* сөзі де көптеген зат, құбылыс және іс-әрекет атаулымен тіркесе келе, әр алуан символизмдердің жасалуына ұйытқы бола алады. Олар: *қара ту, қаралы көш, қарақазан, қарашаңырақ, қарашымылдық, қаражаулық, қараниет, қаражүрек* т.б.

*Қара* түске қатысты символдық мәні бар тіркестерді тілдік қолданыста жиі кездестіруге болады. Бұл тілдік бірліктер жай ұғым-түсінік ретінде қабылданады да символдық мағынасы көмескіленіп тұрады. Оны тек өмірдің нақтылы көрінісінен, не көркем шығарма мәтінінен айқын көруге болады. Жалпы қайғы қасіреттің белгісі еуропалықтарда – қара түс, ал австралиялықтарда – ақ түс болған десе, қазақ халқы үшін – *қара түс*. Оған тілдегі *қарақағаз, қара ту, қара ат* т.б. сөз оралымдары дәлел бола алады.

Ш.Уәлиханов, Ы.Алтынсарин, этнограф Ө.Жәнібековтың көрсетуінше, қазақ халқынның дәстүрінде ел жақсысы қаза тапқанда шаңырақтан *қара ала шашақты қара жалау* көтеріп, жақындары *қара жамылып* аза тұтатын, оның мінген атын бір жылға дейін тұлдап, ер-тұрманына *қара жабу* жауып, көші-қон

кезінде жетелеп ертіп жүрген [Жәнібеков, 6]. Қазақ халқы адам өлгенде найзаға *қаралы ту* тағып, шаңырақтан шығарып қоятын болған, адам жерленгеннен кейін найзаны сындыру ырымы жасалған. Мысалы, М.Әуезовтің «Абай жолы» романында мынадай көрініс суреттеледі: «Байдалы өлік үстіне тіккен ақ үйдің оң жақ белдеуіне өз қолымен әкеп *қара тікті.* Бұл жұмыс өліктің артын күтудің үлкен бір серті еді (М.Әуезов). *Қара* дегені – ұзын найзаның басына тігілген қара түсті ту». Бұл салт туралы Құрбанғали Халид «Тауарих хамса» атты кітабында қазақтар өлікті қойып болған соң *«қара»* тұрғызады. *«Қара»* дегені – найза ұшына белгі байлау, мәйіт жас болса – *қызыл,* ересекке – *ақ*, орта жасар болса – *бір жағы қара, бір жағы қызыл* не ақ матадан құрап тігеді. Бұл *қара* қазақтың белгісі. Төрелер тірісінде қай ту ұстаған болса, өлігіне сол ту байланады, төрелерде жас пен кәрісі бірдей. Өлікке тігілген белгі қай түрлі болсын *«қара»* деп аталады. *«Қаралы күн тудының»* белгісі» деп жазады [6: 221]. Өлім-қазаға байланысты аза тұту дәстүрінің бұл бір ғана көрінісі. Ол салт-дәстүр ондаған символдық мәні бар жеке көріністерден, яғни рәсімдерден тұратыны белгілі. Өлген адамның атын тұлдау рәсімі бойынша аттың жал-құйрығын күзеп, ел көшкенде оны ерттеп, тоқымын қайыра тартып, үстін қара жабумен жабулап жетекке бос алып жүруді талап еткен «тұлданған ат» марқұмның жылдық асында міндетті түрде құрбандыққа шалынатын болған. Мұны «*қараны жығу»* деп атайды. Осы тәрізді атрибуттар мен іс-әрекеттердің бәрі де ритуалдық-символдық сипат алып, дала салтында орындалып келген. Ал сол үйде бір жыл бойы белдеуде тігулі тұрған *қара туды* ырымын жасап болғаннан кейін, табанға салып сындыру рәсімін *«қараны сындыру»* деп аталады. *Қара ту, қара жабу* әрекеті қазақтың жерлеу ғұрпымен байланысты «найза сындыру» салтында да көрініс табады. Ал «*қара жамылу*» орта жастағы адам қайтыс болып, әйелі мен балалары жетім қалуына байланысты айтылған себебі қазақтар қаралы киімді әдейі тікпеген. Қазақ салты бойынша күйеуі өлген әйел қара киінеді, қызы үстіне ақ киім, басына қызыл бөрік киеді. Күйеуі өлген әйел басына қара жаулық салса, ұлын жоқтаған ана басына ақ орамал тартқан. Ара-тұра осы тәріздес синкретті қолданыстар орын алса да, қазақтар үшін қайғы белгісі *қара түсін* қолдану кең етек алған деуге болады. Мысалы, қайғы белгісі *қара* түсімен қатар, *ақ, көк* сияқты түстердің де қазаға байланысты қолданылуын «Қорқыт ата кітабында кездесетін Бамса-Бұйрықты жоқтаудан да көруге болады. Мысалы: Ақ үйдің ішінен зарлаған дауыс шықты,

*Сұқсырдай* бой жеткен жас қыз
Ақ киімін шешіп *қара жамылды.*
Бамсының ақ боз атының құйрығын кесті
Қырық беске келгендер,
Тегіс *қара киім* киісті.
Бастарына *көк сәлде* салысты
Қазанбектің алдына келіп,
Сәлделерімен жерді ұрып,
«Бұйрық қайда?» деп жыласты (Қорқыт ата кітабы)

Мұндай символдық мәнге ие ырымдар қолданыста болған, тілдік жұмсалымда олардың атаулары сақталса да, мағынасы бүгінде ұмыт бола бастаған сөздер де кездеседі. Мәселен, өлім-жітім рәсіміне байланысты *«қара»* символынан туындаған *«қарашы»* деген сөзді көпшілік ел біле бермейді. «*Қарашы*» – өлген адамды аза тұтып, артын күтіп, оған құрмет көрсетуші тілеулес адам [8]. Бұл сөз «Манас» эпосында да бар екен. Мысалы: Менің көзім өткен соң, Жұртым, *қарашы* болып тұра гөр (Манас).

*Қара жамылу, ниеті қара* сияқты тіркестердегі *қара* сөзінің ***қайғы, қаза, жамандық*** мағыналарында жұмсалып символдық мәнге ие болуы лингвомәдени коннотация болып табылады.

**Қорытынды.** ***Қара*** түсті білдіретін атаудың «*ақ*» түсті білдіретін атау сияқты көп мағынаға ие болуы, біріншіден, оның табиғаттағы ең негізгі, көрнекті және басқа да көп түстердің құрамында кездесетін табиғаты күрделі түс болуына байланысты болса, екіншіден, қоғамдық өмірдегі көптеген құбылыстармен түр-түсіне байланысты сәйкестігі, ұқсастығы, мәндес-мағыналастығы негіз болған деп карауға болады. Мәселен, қарайып көрінген зат бейнесі де, адамға тек зиянын тигізетін жын-шайтанның белгісіз болмысы да, қайғы-қасіреттің ауыр азабы мен қаралы сәті де, сән-салтанатта тым қарапайым көрінетін жұрт, қара қазақтың болмысы да, қаражер бетінде ағып жатқан судың да, қара ісімен айыпталған адамның бейнесі де – бәрі «*қара*» түспен сипатталуы логикалық жүйеге сай құбылыс.

***Қара*** сөзінің түркі тілдеріндегі ауыс мағыналары бұдан да көп деп көрсетіледі де, ал қазақ тілінде, ғалымдардың беруінше, отыз шақты болып келеді. Сонымен қазақ тіліндегі ***қара сөзінің*** ауыспалы мағынасы белгілі бір сөздермен тіркесте қолданылғанда ғана көрінеді, айқындалады, молая түседі.

### Әдебиет


1. Жәнібеков Ө. Уақыт керуен. – Алматы: жазушы, 1992. – 192 б.
2. Кононов А.Н. «Семантика цветообозначений в тюркских языках. // Тюркологический сборник. 1975, – Москва, 1975.
3. Қасым Б. Когнитивті семантика. – Алматы, 2021. – 256 б.
4. Қасым Б. Метафоралы аталымдар: когнитивті-семантикалық сөзжасам. – Алматы: ЖК Волкова Е.В. 2015. – 300 б.
5. Қасым Б. Сөз семантикасындағы бағалауыштық және эмотивті мән. //ПМУ Хабаршысы, Филологиялық серия, СПЕЦВЫПУСК. – Павлодар, 2017. – 267-275 б.
6. Құрбанғали Х. Тауарих хамса. – Алматы, 1992.
7. Молчанова О.Т. Топонимический словарь Горного Алтая. – Горно Алтайск, 1979; Прилагательные *ак* и *кара* в алтайском ономастиконе. // Вопросы изучения алтайского языка (сборник научных трудов), – Горно-Алтайск, 1981.
8. Плотникова А.М. Когнитивные аспекты изучения семантики (на материале русских глаголов): Учеб. пособие. – Екатеринбург: Изд-во Урал. ун-та., 2005. – 140 с.

## ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮДӘ ИНТЕНСИВ, ҮСТЕРЕЛЕШЛЕ ҺӘМ КОНЦЕНТРИК БЕЛЕМ БИРҮ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ

***Кириллова З.Н.***
***Казан федераль университеты***
***zkirillova@yandex.ru***

***Аннотация.*** Данная работа посвящена исследованию некоторых технологий обучения языкам, в частности, технологии интенсивного, развивающего и концентрированного обучения.

***Ключевые слова:*** преподавание языка, технологии обучения языкам.

Хәзер мәктәп, укыту һәм тәрбия системасы бала шәхесендәге эшчәнлеккә кирәкле сыйфатлар булдыру мәсьәләсе белән тирәнтен шөгыльләнә. Укытучының педагогик осталыгының торган саен әһәмияте арта баруы шуның белән аңлатыла да инде. Моны хәл итү өчен, укытучыдан актив педагогик эзләнү, аның эш тәҗрибәсендә үстерелешле укыту технологиясе принцибына нигезләнгән билгеле бер методик система булдыру таләп ителә. Бу системаның төп максаты – шәхес тәрбияләү, бәләкәйдән үк баланы шәхес итеп күрү, аның сәләтен күрә белү, аны үстерүгә ярдәм итү, иҗади баскычка күтәрү.

Яңача эшләргә омтылу өчен, иң элек теге яки бу «яңа» системаның концепциясен һәм теориясен өйрәнү таләп ителә. Укытучы әлеге система турында махсус мәкаләләр, хезмәтләр белән танышырга, шул системада эшләүче укытучылар белән фикерләшергә, аларның эш тәҗрибәсен өйрәнергә тиеш.

Соңгы елларда җәмгыятебездә барган үзгәрешләр белем бирү системасына да йогынты ясады. Ул дөньякүләм белем бирү киңлеге үсеше тенденцияләрен исәпкә алып үзгәрергә мәҗбүр. Димәк, педагогик тәрбия һәм практика заманча таләпләргә җавап бирергә тиеш. Моның өчен укучыга карата уңай мөнәсәбәт белән бергә укытуның эчтәлеге дә үзгәрергә бурычлы. Бу исә эксперименталь һәм хосусый мәктәпләр, лицейлар, гимназияләр ачылуга этәргеч ясады. Аларда, белем бирүнең традицион формалары белән беррәттән, укытуның сыйфатын сизелерлек күтәрердәй заманча технологияләр дә уңышлы файдаланыла. Укытуның эчтәлеге дә үзгәреп тора: мәсәлән, XX гасырның беренче яртысында алга киткән илләрдә – башлангыч белем бирү, 1950 нче елларда урта белем бирү массакүләм төс ала. Безнең чорда исә югары белемле булу җәмгыятьнең үсеш дәрәҗәсенә бәйле, шулай ук кешенең тормыш дәрәҗәсе үсү аның яшәешендә белемнең әһәмиятле фактор булуын да раслап тора.

Мәктәп алдына заман куйган бурычлардан чыгып, татар телен укытуга да таләпләр куелды. Дәресләр укучыга ныклы белем бирергә, алган белемнәрен тормышта куллана, логик фикер йөртеп, фикерен дәлилләп аңлата белергә, телдән оста файдаланырга, һәм төрле тәрбия бирергә тиеш. Академик М.И. Мәхмүтов язганча: «…хәзерге дәреснең төп үзенчәлеге: ул – балаларның акыл сәләтен үстерү» [4: 11].

Интенсив белем бирү технологиясе (латинча – көчәнеш, көчәю) буенча эшләгәндә, чит тел кыска вакыт эчендә һәм тиз үзләштерелә, укучыларның танып белү эшчәнлеге активлаша. Белем бирүнең интенсив технологиясенә болгар табибы, психотерапевт Георгий Лозанов нигез сала. Ул чит телгә кешенең эчке мөмкинлекләрен активлаштыру (суггестия) юлы белән өйрәтә. Гадәттә, мондый дәресләр укучы белән укытучыда бер үк дәрәҗәдә кызыксыну тудыра.

Россиядә бу методның киң кулланыла башлавы Г. Лозановта тәҗрибә үткән Г.А. Китайгородская исеме белән бәйле. Чит телне интенсив юл белән өйрәтүнең төп мәгънәсе өйрәнүчеләрнең үзара бәйләнештә булуыннан гыйбарәт. Телне төркем белән бергәләп өйрәнү иң нәтиҗәле юл булып санала. Бу очракта, беренчедән, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә күләмле материалны үзләштереп була. Икенчедән, табигый һәм гадәти шартларда аралашу чит тел өйрәнүдә югары нәтиҗә бирә [2: 33].

Г.А. Китайгородская фикеренчә, аерым укучының эшчәнлеген активлаштыру аша төркемнең мөмкинлеге үсә; белем бирү интенсив оештырылган, дип санала ала. Интенсив белем бирү технологиясе гадәти технологиядән түбәндәге яклары белән аерыла: аны файдаланганда, чит телдә аралашу барышында психологик киртәләр юкка чыга, өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уяна, тиешле социаль-психологик мохит формалаштырыла һ.б. [2: 33].

XIX йөзнең беренче яртысында чит ил педагоглары И.Г. Песталоцци, А. Дистервег, рус галим-педагоглары Л.С. Выготский, К.Д. Ушинский һ.б. тарафыннан үстерелешле белем бирү технологиясенә нигез салына. XX гасырның 60 нчы елларыннан бу теория көчле үсеш ала. Аның нигезен укучыларның танып белү мөмкинлеген активлаштыру һәм үстерү тәшкил итә.

Үстерешле белем бирү теориясе Л.В. Занков, Д.Б. Эльконин, В.В. Давыдов һ.б. педагогларның хезмәтләрендә камилләштерелә.

Проблемалы-үстерешле белем бирү методларын гамәлдә куллануга академик М.И. Мәхмүтов та үзеннән зур өлеш кертте. Ул үз хезмәтләрендә күпсанлы мисаллар белән укучыларның интеллектуаль мөмкинлекләре үсешендә, аларның танып-белү мөстәкыйльлеген формалаштыруда һәм укуга карата кызыксынуын арттыруда бу методның нәтиҗәле булуын исбатлады [4: 31].

Л.В. Занковның үстерешле белем бирү технологиясе түбәндәге дидактик принциплар нигезендә төзелгән: эчтәлекнең системалылыгы һәм бөтенлеге, материал катлаулылыгын югары дәрәҗәгә җиткереп укыту, теоретик белемнәрнең әйдәп баруда әһәмияте, материалны кызу темплар белән өйрәнү, барлык укучыларның белемнәрен үстерү, аларга шәхси якын килү һ.б. Укытканда дидактик уеннар, дискуссия формаларын куллану тәкъдим ителә. Уку эшчәнлегенең төп шарты – балада танып-белүгә кызыксыну уяту [1: 64].

Д.Б. Эльконин – В.В. Давыдовның үстерешле белем бирү технологиясе баланың логик һәм теоретик фикерләвен үстерүгә юнәлтелгән. Әлеге авторлар системасының үзенчәлеге – укыту эчтәлеген теоретик белемнәр нигезендә төзү.

Алар рус телен укытканда төп принцип дип фонематик принципны саныйлар [5: 87].

Концентрик белем бирү технологиясе исә – уку вакытын бүлү, предметны, күләмле темаларны (мәсәлән, белем бирү процессын ситуатив-тематик оештыру) берьюлы өйрәнү. Аның төп максаты – укытуның сыйфатын күтәрү һәм материалны ныклап үзләштерү. Моның өчен укытучы берничә дәрестән торган уку-укыту блоклары төзи.

Концентрик белем бирү түбәндәге принциплар нигезендә оештырыла: уку вакытын, өйрәнелә торган материалны концентрацияләү, проблемалылык, дәвамчанлык, системалылык һәм комплекслылык, вариативлык һ.б. Г.И. Ибраһимов концентрик белем бирүнең өч моделен аерып күрсәтә. Беренчесе бер предметны билгеле бер вакыт эчендә өйрәнүне күздә тота; икенчесе бары тик бер оештыру-дидактик берәмлекне – уку көнен эреләндерүне күзаллый, биредә өйрәнелә торган фәннәр ике-өчтән артмый; өченче модель «үзенчәлекле модуль барлыкка китерә торган өч-дүрт дисциплинаны бер үк вакытта һәм параллель өйрәнүне» күздә тота [2: 25].

Белем бирүнең заманча технологияләре исемлеген Е.А.Ямбург, Б.А.Бройде, А.Н.Тубельский һ.б. авторлык мәктәпләре технологияләре белән дә тулыландырырга мөмкин булыр иде.

Алда язылганнардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарур. Иң мөһиме шул: заманча технологияләрне куллану алынган мәгълүматның – 85% ка якынын, ә традицион технологияләр 40% белемне хәтердә озак сакларга ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Занков Л.В. Избранные педагогические труды. – 3-е изд., доп. – М.: Дом педагогики, 1999. – 608 с.

2. Ибраһимов Г. Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910-1930). 8 том. – Казан: Татар. китап нәшр., 1987. – 431 б.

3. Китайгородская Г.А. Методика интенсивного обучения иностранным языкам. М.: Высшая школа, 1986. – 104 с.

4. Мәхмүтов М.И. Сайланма хезмәтләр. 6 том: Милләт, мәгариф һәм дин. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2016. – 303 б.

5. Эльконин Д.Б. Избранные психологические труды. – М.: Педагогика, 1989. – 554 с.

# БАЗОВЫЕ КОНЦЕПТЫ В КАРТИНЕ МИРА УЗБЕКСКОГО ЯЗЫКА

***Кодиров А.А.***
***Бухарский государственный университет***
***abbos.qodirov.ruslit@gmail.com***

***Аннотация.*** В статье освещается состав словаря культурно-языковой картины мира. В центре внимания находятся концепты узбекской культуры, в которых отражены представления носителей данной лингвокультуры об окружающем мире.

***Ключевые слова:*** концепт, узбекский язык, этнокультурная информация.

В каждой языковой картине мира существует совокупность семантически нагруженных слов (культурные концепты, ключевые слова), называющих узловые точки в картине мира. Культурная модель, порождающая соответствующие тексты, языковые стереотипы и новые значения, формирует состав словаря культурно-языковой картины мира.

Большое количество публикаций, так или иначе затрагивающих проблему «язык и культура», свидетельствует об актуальности изучения явлений языка в их соотнесенности с его кумулятивной функцией.

Основные концепты узбекской культуры становятся объектом не только культурологического, но и филологического исследования. Особый интерес представляет изучение концептов на пословичном материале, так как речь в данном случае идет о национальном видении мира и способах его языковой репрезентации.

Как справедливо отмечает узбекский исследователь Б.М. Жураева, «в последние годы в узбекском языкознании, то есть в период возрождения национальных ценностей, от говорящего требуется глубокое усвоение языка, в частности узбекского языка, имеющего статус государственного; лаконичное, обоснованное, образное и эффектное выражение мысли. Поэты, писатели и ораторы независимо от возраста, если хотят обосновать или укрепить мысль, то обязательно обращаются к пословицам» [Жураева: 19].

В когнитивной лингвистике термин «концепт» является базовым. Этот термин заимствован когнитивной лингвистикой из логики. Проблема определения концепта в целом не является новой для лингвистики [Воробьев: 94].

«Хат ташучы» “к» хәрефле башлык кигән бала янына килә. Исәнләшәләр. «Хат ташучы» кайсы шәһәрдән кучтәнәч җибәрелгәнен һәм нәрсәләр икәнен әйтә.

Уен дәвам итә.

«Тиз әйт» уенын исә предмет һәм аның билгесен әйтүдән тыш, башкачарак та үзгәртергә мөмкин. Бу уен антоним сүзләр, сүзләрне күплек санда әйтүне һәм башка грамматик категорияләрне кабатлаганда да отышлы була.

«Рәсемне өйрән» уенын аеруча яратып кулланабыз. Әлеге уен 2 команда арасында сорау-җавап рәвешендә дә үткәрелә ала.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: башлангыч сыйныф укучыларын диалогик сөйләмгә өйрәтү һәм ныгыту өчен, күптөрле уеннар уйлап табарга мөмкин. Алар сыйныфтагы бөтен укучыларның активлыгын үстерә, әңгәмәгә кушылырга этәрә. Иң мөһиме, уеннар укучылар өчен аңлаешлы, кызыклы булырга, теманы аңлауга һәм ныгытуга, диалогик сөйләмне камилләштерүгә юнәлдерелергә тиеш.

## Әдәбият


1. Вафин Ф. Тел өйрәтүдә коммуникатив уеннар. – Керү режимы: http://vafin.ucoz.ru.
2. Камаева Р. Татар теленә өйрәтүдә заманча педагогик технологияләр / Р. Камаева // Мәгариф. – 2014. - №12. – Б.12.
3. Халимова Р. Р. Балалар бакчасында дидактик уеннар. – Керү режимы: http://nsportal.ru/detskiy-sad/raznoe/2013/09/29/balalar-bakchasynda-didaktik-uennar

# ПОДГОТОВИТЕЛЬНЫЕ УПРАЖНЕНИЯ ДЛЯ РАЗВИТИЯ НАВЫКОВ АУДИРОВАНИЯ

***Макаров И.М.***
***Казанский федеральный университет***
***indir.makarov@yandex.ru***

***Аннотация.*** В статье рассматривается система подготовительных упражнений для развития навыков аудирования, приводятся примеры упражнений на татарском и английском языках.

***Ключевые слова:*** аудирование, подготовительные упражнения.

Эффективная коммуникация в большей степени зависит от сформированности навыков понимания иноязычной речи на слух, однако изучению процесса аудирования не уделялось должного внимания, потому что считалось, что навыки аудирования формируются сами собой и не нуждаются в целенаправленном обучении, поэтому аудирование считается одним из наименее разработанных разделов методики обучения иностранным языкам.

«Аудирование – слушание звучащих текстов с учебной целью для тренировки восприятия и понимания их содержания на слух» [Кромлев Н. Г., 2006]. Оно является сложным видом речевой деятельности, поэтому необходима специальная система упражнений для обучения учащихся аудированию.

Система упражнений для обучения аудированию по В. А. Артемову должна обеспечить:

а) соответствие упражнений психологическим и лингвистическим сложностям воспринимаемых на слух сообщений;

б) возможность взаимодействия аудирования с другими видами речевой деятельности, и в первую очередь аудирования и говорения как двух форм устного общения;

в) управление процессом формирования умений и навыков аудирования;

г) успешную реализацию конечной практической цели и промежуточных задач обучения;

д) постепенное увеличение трудностей, что позволит гарантировать посильность выполнения упражнений на разных этапах обучения. [Артемов В. А., 1969: 179]

Под системой упражнений понимается организация взаимосвязанных действий, расположенных в порядке нарастания языковых и операционных трудностей, с учетом последовательности становления речевых умений и навыков в различных видах речевой деятельности.

Составными компонентами системы упражнений являются, как известно, группы (упражнения для снятия лингвистических трудностей аудирования, упражнения для устранения психологических сложностей аудирования), типы, виды упражнений и их расположение, соответствующее последовательности формирования навыков и умений, количество упражнений, форма и место их

выполнения. Из этих компонентов постоянной остается лишь аргументированная последовательность расположения упражнений, прочие составляющие будут изменяться в зависимости от характера аудиотекстов, языковой подготовки учащихся, сложности коммуникативных задач и других факторов.

В методике упражнения для преодоления трудностей восприятия речи на слух и осмысления поступающей по слуховому каналу информации на занятиях по аудированию делят на две подсистемы: *подготовительные (языковые) и тренировочные (речевые) упражнения*. [Гальскова Н. Д., Гез Н. И., 2009: 179]

**Подготовительные упражнения** направлены на овладение навыками аудирования. Они выполняются с использованием единиц языка в виде отдельных слов, словосочетаний, фраз и формируют способности вычленять из речевого потока отдельные языковые явления, развивают психологические механизмы аудирования.

Подготовительные упражнения способствуют развитию прогностических умений; объема кратковременной и словесно-логической памяти; механизма эквивалентных замен; речевого слуха; умений свертывать (редуцировать) внутреннюю речь и др:

*Упражнения на преодоление лингвистических трудностей аудирования:*

Фонетические упражнения направлены на формирование навыков узнавать отдельные звуки в аудиотексте, дифференцировать их от сходных определять интонационный тип фразы. Работа сначала организуется на знакомых учащимся словах, затем в упражнения включается новая лексика. При выборе упражнений учитываются трудности фонетической системы изучаемого языка и трудности, возникающие в результате интерференции родного языка.

В качестве примера студентам могут быть предложены следующие виды заданий:

- Для английского языка можно предложить следующий вариант задания, например, listen to the pronunciation of the given words and complete the table (прослушайте произношение следующих слов, затем заполните таблицу):

| [i:] | [e] | [ʌ] | [ɔ] |
|---|---|---|---|

He, run, ten, dog, jump, see, ugly, green, frog, pet, clock, tennis.

Для татарского языка можно предложить подобное задание для проверки усвоения глассных звуков [о], [ө], [ә] или согласных [к], [қ], [г], [ғ] и т. д.

- Прослушайте слова и поднимите руку (карточку), когда услышите определенный звук, например, для английского языка звуки [е] и [әе], для татарского – [о] и [ө].

Отличительной чертой татарского языка является то, что звуки подчиняется законом сингармонизма, поэтому можно предложить следующий вариант заданий:

• Тыңлагыз һәм сингармонизм законнарына (ирен һәм рәт гармонияләре) буйсынган сүзләрне язып алыгыз (прослушайте слова и выпишите те, которые поддаются сингармонизму): унбиш, карга, төтен, иртәнге, тоташ.

Лексические упражнения направлены на формирование навыков узнавания значения слова во фразе. Такие упражнения выполняются на знакомом лексико-грамматическом материале. Допускается включение в текст 3% незнакомых слов с целью формирования механизма догадки о значении слова из контекста.

Примеры заданий:

• Для обоих языков можно предложить следующий вариант заданий, например, прослушайте аудиотекст и догадайтесь о чём идёт речь:

It's a fruit. It's round. It's tasty. (Orange or tangerine)

It's a pet. It's small. It lives in the house. It likes mice. (Cat)

Ул җимеш. Ул кызыл. Ул урманда үсә. (Җиләк)

Ул зур. Ул җылы. Анда кешеләр яши. (Өй)

• Для обоих языков можно предложить следующий вариант задания, например, прослушайте предложения и определите лексические несоответствия, допущенные в процессе их перевода (данное задание позволяет обратить внимание на слова, которые являются «ложными друзьями переводчика» и пр.):

Дождь идёт. – Яңгыр *бара* (ява).

You are brilliant. – Ты *бриллиант (*очень умный*)*

Грамматические упражнения предназначаются для формирования навыка узнавания пройденного грамматического материала на знакомой учащимся лексике.

Например:

• Для английского языка можно предложить следующий вариант задания, например, fill in the blanks using the right word. Listen and check (заполните пропуски, используя слова, данные в скобках. Затем прослушайте и проверьте правильность выполнения задания):

1. You … come in time to school in the morning. (have to/ should)
2. You look very tired. You … have a short holiday. (have to/should)
3. You … take these pills twice a day after meals. (must/ should)

• Такой же вариант задания можно использовать и в татарском языке, например, бушлыкларны *кирәк* яки *тиеш* сүзләре белән тулыландырыгыз, аннары тыңлагыз һәм тикшерегез (заполните пропуски соответствующим глаголом тиеш или кирәк. Прослушайте и проверьте):

1. Ул мәктәпкә барырга __________. (тиеш)
2. Айрат өй эшен эшләргә __________. (тиеш)
3. Аңа каләм __________ иде. (кирәк)
4. Сәламәт булу өчен, дөрес тукланырга __________. (кирәк)

*Упражнения на преодоление психологических трудностей аудирования:*

Для *развития* механизма оперативной памяти применяются упражнения, способствующие увеличению объема оперативной памяти. Развитию

оперативной памяти способствуют упражнения: повторяйте за диктором, выделение новой информации при сравнении двух вариантов сообщения и заучивание наизусть.

Можно применить следующие виды заданий:

- Для английского языка можно предложить следующий вариант задания, например, listen to the short messages and compare (прослушайте короткие сообщения и выделите новую информацию, сравнив услышанное):

1. Daffyd's laptop is on table. – Daffyd's black laptop is on his table.
2. His guitar is in the corner next to the bookcase. – His new guitar is in the corner next to the small bookcase.
3. Karen's bedside lamp is on her bedside table. – Karen's balloon shaped bedside lamp is on her bedside table.

- Для татарского языка можно предложить следующий вариант задания, например, 2-3 кыска фразаларны тыңлагызтһәм алардан бер җөмлә ясагыз (прослушайте две-три короткие фразы, соедините их в одно предложение):

1. Ул яңа карандаш алды. Ул искесен югалтты. – Ул яңа карандаш алды, чөнки искесен югалтты.
2. Кояш чыкты. Көн җылынмады. – Кояш чыкты, ләкин көн җылынмады.
3. Ул мәктәптән кайтты. Ул өй эшләрен карарга утырды. – Ул мәктәптән кайткач, өй эшләрен карарга утырды.

<u>Упражнения на развитие механизма идентификации понятий</u> подразумевает прослушивание аудиоматериала и определение значений определенного слова в фразе или соотнесении слова с его значением.

<u>Упражнения на развитие механизма осмысливания</u> включают задания на прослушивание диалога и передачи его главной информации, либо прослушивания двух и более диалогов, с последующим выявлением добавленной или опущенной информации.

<u>Упражнения на развитие механизма вероятностного прогнозирования</u> содержит задания на вставку в текст пропущенных слов, завершения фраз и предвосхищение содержания текста.

<u>Упражнения на развитие механизма эквивалентных замен</u> обеспечивает возможность заменить развернутое высказывание свернутым. Попытка дословно воспроизвести услышанное свидетельствует о недостаточном развитии механизмов эквивалентных замен.

Развитие механизма эквивалентных замен требует особого внимания, поэтому оно требует определенных аудитивных навыков, для совершенствования которых следует употреблять задания подобного типа:

*Упражнения на преодоление трудностей, вызванных с условиями предъявления материала,* формируют навыки и умения понимать информацию, поступающую по зрительному, слуховому или зрительно-слуховому каналу, от разных лиц, в разном темпе, т. е. для успешного овладения навыками аудирования необходимо учитывать не только внутренние особенности аудиотекста, но и внешние факторы и условия процесса.

Эти трудности прежде всего связаны с темпом, размером речевого сообщения и количеством его предъявления. Эти факторы в большинстве случаев оказывают отрицательное влияние на результативность процесса аудирования, поэтому следует целенаправленно обучать студентов/ обучающихся тому, как преодолевать эти трудности.

По мнению многих учёных, одним из главных условий преодоления данного вида трудностей является не многократное прослушивание одного и того же текста, а прослушивание или просмотр различных сообщений, предъявляемыми разными людьми и в разной обстановке, например: интервью с кинозвездой, выпуск программы новостей, радиопередача, беседа доктора с пациентом, в ресторане и т. д.

Таким образом, в настоящее время методика преподавания аудированию включает в себя его целенаправленное обучение, разработку и систематизацию упражнений.

## Литература


1. Артемов, В. А. Психология обучения иностранному языку – М.: Наука, 1969. – С. 179-181.
2. Гальскова, Н. Д., Гез, Н. И Теория обучения иностранным языкам: лингводидиактика и методика/ учебное пособие для студентов лингвистичеких университетов и факультетов иностранных языков высших педедагогических учебных заведений. – М.: Академия, 2009. – С. 179.
3. Кромлев, Н. Г. Словарь иностранных слов. – М: Наука, 2006.- 380 с.

# ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ПУБЛИКАЦИЙ ПО ИСТОРИИ ТАТАР НА УРОКАХ АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКА

***Миргалеева Д.Р.***
***МБОУ «Лицей №149 с татарским языком обучения» г. Казани***
***diliara.mirgali@mail.ru***

***Аннотация.*** В представленной статье автор делится опытом использования сведений о истории и культуре татарского народа на уроках английского языка. Использование культурных традиций, истории родного края и народа в качестве примера и сравнение с аналогичными примерами из мировой истории при изучении английского языка очень помогает освоить живой язык и использовать метод запоминания через понятные аналогии и представления об окружающей действительности. Для этого автор использует исторические книги на английском языке. Проблема заключается в том, что мало популярных работ об истории татар и работ о культуре и быте татарского народа на английском языке.

***Ключевые слова:*** История татар, Татарстан, английский язык, межпредметные связи, урок, школа

Изучение иностранных языков является показателем образованности современных людей. Иностранные языки являются обязательными в школьных программах, по ним разработаны федеральные стандарты, линейка учебников и методической литературы. Также и учителя стараются собрать как можно больше дополнительного аутентичного материала, который помогает углубить изучение иностранного языка и закрепить полученную на уроке информацию.

По предмету английского языка разработаны не только учебники, но имеется и огромная база всевозможных полезных ресурсов и литературы. Одним из важных методов, позволяющих лучше усвоить материал и изучить язык, является запоминание лексики через известные примеры, характерные для культурного окружения ребенка.

В данной работе я бы хотела остановиться на проблемах по использованию исторических сведений при изучении английского языка. Материалы по татарской истории, о Татарстане и городе Казани в англоязычной литературе, благо, все же имеются, хотя и не в том количестве и не на том уровне. А конкретных работ по истории Казани, татарского народа и Татарстана на английском языке и написанных популярным и доступным языком, к сожалению, практически нет.

Тем не менее, есть фундаментальные труды по истории татар, подготовленные Институтом истории имени Ш. Марджани, прежде всего это «История татар с древнейших времен», в семи томах [2]. Все тома доступны на русском и английском языках на сайте одноименного института. Для использования средневековой истории великолепным изданием является коллективная монография «Золотая Орда в мировой истории» [1]. Данная монография является исследованием истории Золотой Орды и представляет ее

роль в мировой истории. Монография содержит ключевые современные научные исследования ведущих ученых российских и иностранных научных центров.

Хотя эти работы и написаны сложным научным языком, в них имеется обширный фактологический материал, который можно использовать в качестве примера, а демонстрация этих работ вызывает у учеников интерес к своей истории. Так, используя метод аналогии, можно изучать свою историю и на уроках английского языка.

Также сегодня на уроке иностранного языка можно использовать материал из периодической печати, такие журналы, как «Безнең Мирас» («Наше наследие») для детей, журналы «Эхо веков – Гасырлар авазы», «Золотоордынское обозрение» и др.

Сегодня в эпоху цифровых технологий, когда люди привыкли находить необходимые материалы быстро и на электронных носителях, важны специализированные интернет-ресурсы, где в свободном доступе выставляются и электронные версии книг и журналов.

Из всего многообразия интернет-ресурсов, которыми могут пользоваться учителя, можно выделить и такие региональные сайты, как:

http://kitap.tatar.ru/ru/
https://vk.com/tatelkit
https://kitaphane.tatarstan.ru/e-library.htm
http://xn--80aagie6cnnb.xn--p1ai/libraries
http://goldhorde.ru/RU/
https://tatkniga.ru/

Примеры из татарской истории, истории Казани, повседневной жизни нашего народа, близко знакомого ученикам помогают не только расширить лексический запас, но и составлять минирассказы на английском языке и тем самым не только увеличить свой кругозор, но и и переходить на описательный уровень составления рассказа. Примеры из истории хотя и являются достаточно сложными в языковом отношении, из-за большого потока информации даже у тех, кто мало знает историю, но все же обладает определенным уровнем знаний истории, культуры, повседневной жизни, питания, отдыха и т.д. может составить на много интересный рассказ, нежели по незнакомой тематике. Использование аналогий из английской и татарской кухни, краткой истории города, народа мотивирует обучающихся к желанию изучать новую тематическую лексику, расширить словарный запас и формулировать свои высказывания. Обучающийся пытается использовать как можно больше слов и тем самым раскрывать тему и описывать ее как можно емко и информативно.

Такой подход подталкивает к тому, что у ученика не ослабевает интерес к изучаемому языку и появляется мотивация раскрыть себя и стараться донести свои знания на другом языке. Это важный метод и мотивационный подход. Однако, для ее использования нужны хорошие и, главное, специализированные ресурсы, с которыми, к сожалению, у нас есть большие трудности.

В этой небольшой работе мы затронули аспект истории в широком смысле. Но хотелось бы озвучить и несколько проблем, с которыми можно столкнуться при использовании материалов по татарской истории на уроках английского языка.

Прежде всего, это практически отсутствие популярных работ по истории, культуре, повседневной жизни татарского народа на английском языке. Работать только с русскоязычной литературой достаточно сложно, так как для изучаемого языка важно иметь базовые материалы прежде всего на изучаемом языке.

Еще одна проблема заключается в том, что имеющаяся литература достаточно объемна и сложна в языковом отношении, перенасыщена специальной терминологией, в ней мало конкретики и больше обобщения. Особенно большой проблемой является нехватка материалов о повседневной жизни, как в прошлом, так и в настоящем, описаний культуры отдыха и питания, развлечений, традиций. Интересных сведений и кратких рассказов о локальных историях, связанных, например, только с местом проживания, учреждений, культурных событий и т.п.

Бесспорно, богатейшая татарская история, история Татарстана и России, города Казани были бы интересны и полезны для более успешного изучения иностранных языков.

## Литература

1. The Golden Horde in World History. A Multi-Authored Monograph. – Kazan: Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences, 2017.

2. The History of the Tatars since Ancient Times. In Seven Volumes. Volume 1-7. - Kazan: Sh. Marjani Institute of History, 2002- 2017.

# РУС ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТЕЛЕВИЗИОН ТАПШЫРУЛАРНЫ ФАЙДАЛАНУ

***Мөбәрәкшина А. Р.***
***МБОУ "Многопрофильный лицей №186 – "Перспектива"***
***Приволжского района г.Казани***
***Aliya-891163@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье освещаются особенности использования телевизионных передач детского телеканала "ШаянТВ" на уроках татарского языка. Описываются методы и принципы, необходимые для освоения новой лексики, правильной постановки интонации, формирования навыков правильной речи. Также подчеркиваются, что одним из успешных приемов информирования детей о татарском фольклоре, культуре, литературе является применение телевизионных проектов.

***Ключевые слова:*** «ШаянТВ», мультфильм, сказка, диктор, дикция, интонация, лингвокультурология, приемы перевода, сознательно-практический метод обучения, диалогическая речь, имитативный метод.

Мәгариф һәм белем бирү системасында хәзерге заманның төп максатларыннан укучының үзүсеше һәм җәмгыятькә файдалы өлеш кертүе өчен мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә эзләп табуга, аны анализлау, структурага салу һәм гамәлдә куллануга ирешүен булдыру тора. Бу функциональ грамотлылык таләпләре буенча, һәр дәрестә календарь-тематик планда күрсәтелгән теманы өйрәнү нигезендә, укучыда патриотик-гражданлык хисләрен үстерү, рухи-әхлакый, эстетик-мәдәни тәрбияне ныгытуга төрелеп бирелергә тиеш [1; с.7-8]. Альфа буын балаларын дөрес яза, дөрес укый, дөрес сөйли һәм фикерли белсен өчен мәктәп системасында цифрлы ресурсларны актив куллануга ихтыяҗ туды. Соңгы елларда бик күп татар әкиятләренең мульфильмнары барлыкка килү, балалар өчен эшләнгән газета-журналларның QR-кодлар, 3-D форматындагы рәсемнәре белән чыга башлавы һәм "Шаян ТВ" татарча балалар телеканалы барлыкка килү ана телебезнең популярлашуына, аны өйрәнүгә кызыксыну уянуга китерде. Беренче һәм бердәнбер татарча балалар телеканалы «Шаян ТВ»да танып-белүне, белем бирүне һәм фикерләүне үстерергә ярдәм итүче оригиналь программалар эфирга чыга, иң яхшы мультфильмнар, халыкара дәрәҗәдәге фәнни-популяр, документаль һәм әдәби жанрдагы тапшырулар татар теленә тәрҗемә ителеп, ТВ караучыга тәкъдим ителә (https://shayantv.ru/ ). Заманча технология буларак, «Шаян ТВ» проектларын татар теле дәресләрендә куллану уку-укыту процессын яңача оештырырга һәм татар телен өйрәнүгә теләк уятуда; танып белү активлыгын арттыруда; телне өйрәнүдә уңай шартлар булдыруда; укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачуда максатларга ирешергә ярдәм итә .

Күрсәтмәлелек ягыннан "Шаян ТВ" проектлары дәрестә психологик уңай халәт тудыруда зур этәргеч бирә. Мультимедианың кызыклы хәрәкәт, тавыш, төсләр, үзенчәлекле персонажлар белән тәэмин ителүе татар телен өйрәнүнең

мотивлаштыруына китерә. “Шаянн”ның мәктәп яшендәге балалар өчен эшләнгән тапшыру, мультфильм, уеннары укучыларның акыл сәләтен үстерерлек һәм аларга төрле яклы тәрбия бирерлек, балаларның дәрескә битараф булмыйча, эшкә тойгылары һәм эмоцияләре җигелгән; дөньяга караш, тормышта үзенең урынын таба белү кебек сыйфатлар тәрбияли торган чыганаклар булып хезмәт итә.

Башлангыч сыйныфларда рус телле балаларга татар телен укытуда, аеруча, “Шаян әлифба” проекты материалын куллану дәрескә куелган максатларга җиңел ирешергә ярдәм итә. Монда татарча әлифбаның һәр хәрефенә багышланган 1 минутлык җырга төсле хәрәкәтләнүче рәсемнәр, сүзләр белән баетылып эшләнгән күңелле видеоматериал тәкъдим ителә. Аны балалар яратып тыңлый, кушылып җырлый, видеочыганакны бирелеп карый һәм үзенә таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен экранга чыккан рәсемнәр аша үзе эзләп таба. Бу очракта еш кулланыла торган тәрҗемә методы читләштерелә һәм аңлы-гамәли методка йөз тотыла. “Шаян әлифба” җырлары, бигрәк тә, икенче сыйныфта фонетик күнегү эшләгәндә дә, лексиканы кабатлау, баетуда да уңай кабул ителә. Мисалга, “*ң*” хәрефенә тукталыйк. Җырдагы сүзләр: *“ң” яңгырда бар, “ң” бәрәңгедә бар”*. “*Яңгыр*” диюгә экранда яңгыр тамчылары бии башлый, ә “*бәрәңге*” диюгә балаларның яраткан популяр ризыгы “фри” сикереп чыга. Җырны тыңлаганнан соң бала укытучы белән әңгәмәгә керә, “бәрәңге”нең тәрҗемәсен фаразлап әйтә һәм укытучының бу җавапны раславын сорый *(“Бәрәңге – картофель-фри була, дөрес әйтәмме?”)* һәм бала үзе дә сизмичә, эвристик метод ысулын куллана. Танып-белү өчен файдалы күрсәтмә материал белән баетып бирелгән әлифба җырлары дәрестә ассоциатив күзаллау һәм кабул итү методын кулланырга мөмкинлек бирә. Балалар шушы җырлар аша сүзлек запасын – лексиканы баету белән бергә, татар теленең фонетик үзенчәлекләрен дә үзләштерүгә ирешәләр. Иҗади яктан көчле сыйныфларда укучылар җырны үз сүзләре белән дәвам итәргә омтыла. Мәсәлән, “*ж*” һәм “*җ*” хәрефләренең яңгырашы төрле, әлеге авазларны әйткәндә бутамау бурычын күздә тотып проекторга чыгарылган “*Җ*” хәрефе” җырында “*җиләк, җимеш, җырчы, җир*” сүзләре бирелә. Көчле һәм иҗади балалар бу сүзләр белән генә канәгать булып калмыйча, үзләре “*җил, җәй, җыр, җим*” һ.б. дип тезеп китә. Билгеле, мондый уен технологиясен куллану һәр баланың да актив катнашуына китерми: өстәмә сүзләрне татарча яхшы белүче бала гына әйтә ала. Ә сүзлек запасы белән мактана алмаган укучыны башкалардан ишеткән өстәмә сүзләрне язар өчен тактага чыгарганда, ул “*җ*” / “*ж*” хәрефләрен бутап язмаячак, чөнки әле генә кайсы хәрефкә багышланган җырны ул яхшы белә. Күп очракта укучы чагыштыру аша “җ”/ “ж” хәрефләренең аермасын тоюга ирешә һәм җырга өстәп әйтелгән сүзләрне язганда язу күнекмәсен ныгыта. “Шаян әлифба”ны шулай ук 3, 4, 5 нче сыйныфларда да ышанычлы рәвештә кулланырга мөмкин. 3 нче сыйныфта язма күнегүләр башкарганда “*ә*” белән “*е*”, “*ч*” белән “*щ*”, “*ү*” белән “*у*” һ.б. хәрефләрен бутау очраклары булганда (ул һичшиксез була), шунда ук дәреснең 1 минутын “Шаян әлифба” җырына багышлау уңай нәтиҗәләргә китерә. Бала таныш материалны кабатлый, ныгыта. Ул мондый төр

хаталар өстендә эш башкарганда һәм алга таба орфографик ялгышларны булдырмас өчен бик отышлы. Укучыны хатасыз язарга өйрәтүдә автоматизм һәм орфографик-фонетик хосусый методик принциплары белән эш итүгә, һәм шул ук вакытта балаларда фонетик, лексик һәм иҗади фикерләү күнекмәләрен ныгытырга әлеге проектлар ярдәм итә.

Татар теленә камил тәрҗемә ителгән, образларның, татар милли мәдәниятенә яраклаштырып, ышандырырлык һәм кызыклы персонаж телен тудыра алулары, яшь үзенчәлеген истә тотып сайланган геройларның сөйләм теле аша "ШаянТВ" мультфильмнары балалар тарафыннан яратып кабул ителә һәм татарча сөйләм телен үстерүдә көндәлек ярдәмлек булып хезмәт итә. Дәрескә куелган бурычларда тыңлау, аңлау, сөйләү генә түгел, язу күнекмәсен булдыру, грамматик күнегүләр эшләү дә алгы планда тора. Гадәттә, башлангыч сыйныфларда диалогик сөйләмгә көчле басым ясала. Морфология, синтаксисны кечкенә сыйныфларда бирү телне өйрәтү методикасын катлауландыра дигән фикерләр өстенлек итә. Ләкин җанлы сөйләм нигезендә грамматик кагыйдәләрнең комплексллы җыелмасы ята. Сөйләмне фонетик һәм лексик яссылыкта гына аңлатып бирү мөмкин түгел. Фонетика, лексикология, морфология, синтаксис телнеңербөтен системасын тәшкил итә. Кечкенә яшьтәге балаларга катлаулы кебек тоелган кагыйдәләрне уен технологиясе, шулай ук мультфильмнар аша бирү уңай нәтиҗәгә генә китерә [2; Б.4]. Мәсәлән, *-ты/-те, -ды/-де* аффиксларының кулланылышын, ягъни үткән заман хикәя фигыль формаларын аңлатканда 2-3 минутлык мультфильм тәкъдим итәргә була. Мисалга, "ШаянТВ"ның бик күңелле "Зигби" дип аталган чит ил мультфильмын алыйк. Әлеге күрсәтмә материал белән танышканнан соң, үткән заман хикәя фигыль формасында яңгыраган сорауларга укучыдан җавап алуга ирешергә мөмкин.

Шуны да истә тотарга кирәк: дәрескә әзерләнгәндә укытучының теге яисә бу материалны чыганак итеп алуы зур әзерлек һәм җаваплылык таләп итә. Әлеге каналда күрсәтелгән күпкенә чит ил мультфильмнарындагы татарларга хас булмаган этномәдәни үзенчәлекләрне аерып укучыларга күрсәтү, татар һәм башка мәдәниятләрне чагыштырма планда өйрәтү баланың күзаллау дәрәҗәсен киңәйтә, дөньяны танып белү күнекмәсен ныгыта. Тәрбияви яссылыктан карасак, мисалга, корея мультфильмы "Зузу"да кечкенә тычкан баласы Зузу үзе теләгәнне эшли, кайвакыт әнисе әйткәннәрне оныта, көнозын уйный, хаталана, ялгыша, авыр хәлгә калганнан соң гына әнисенең сүзен искә төшереп үкенә һәм үз хатасын үзе төзәтә. Әнисе Зузуны бервакытта да шелтәләми, һәрвакыт терәк булып, үсендереп, мактап тора. Татарларда тәрбия чарасына борынгыдан килгән традицион алымнарга корылган. Ул, гадәттә, кисәтү, куркыту белән бәйле ырымнар, әйтемнәрдә (Өлешеңне ашап бетермәсәң, бәхетең кала. Аягыңны селкетеп утырма – шайтан чакырысың. Тупсага утырма – кечкенә калырсың һ.б.); фольклор әсәрләрендә еш очраган үгет-нәсыйхәттә (әкиятләрдә) ачык чагыла. Әби-бабайлардан килгән зур тәҗрибәгә, өлкәннәрнең өйрәтүләренә нигезләнеп, бала тәрбияләү алымнары, гореф-гадәткә әйләнеп, буыннан буынга тапшырылып килә. Татар әкиятләрендә еш кына үгет-нәсихәт

белән бергә баш кахарман юлыккан маҗаралы вакыйгалар бергә үрелеп бирелә. Тик безнең фольклорда кылган ялгышны төзәтү еш кына мөмкин булмый, әкият геройлары үкенсә дә, соң була. Моны укучылар “Өч кыз”дагы кызларның гөберле бакага һәм үрмәкүчкә әверелүеннән дә аңлый ала. Тиен аларны кабат кыз рәвешенә кайтармый. Фольклорда еш очраган елан начар кызларны чагып үтерә, убырлы карчык авыр сынаулар белән сыный. Шул рәвешле, тәрҗемә мультфильмнардагы милли-мәдәни үзенчәлекләрне татар җирлегенә куеп аңлату, чагыштырма принцип белән эш итү балада милли үзаң формалашуга этәрә. Төрле мәдәниятләрнең үзенчәлеген яктырткан чыганаклар белән эш иткәндә, укытучы бик сизгер булырга һәм чит/үз оппозициясенең бик нечкә сызыгын да күрә белү сәләтенә ия булырга тиеш.

“ШаянТВ” платформасында татар фольклорына да зур урын бирелә. “Кичке әкиятләр” тапшырулары, исеменнән күренгәнчә, укучыларны әкиятләр белән таныштыра. Татар теленең фонетик үзенчәлекләрен үзләштерүдә дикторларны тыңлату һәм алар артыннан кабатлау кебек эш төрләре отышлы [4; Б.9]. Бу тапшыруда халык әкиятләрен балаларның үзләре кебек үк кечкенә, шул ук вакытта бик матур һәм камил татарча сөйләшүче Ләйлә Таишева алып бара [5; Б.1]. Ләйләнең сөйләмен, аның артистлык хәрәкәтләрен, жест-мимиканы балалар бирелеп тыңлый, карый. Еш кына рус телле бала Ләйлә әйткән җөмләнең тәрҗемәсен белмәсә дә, аның усал карашыннан, усал интонациясеннән ачуланганны, әкияттә нindидер каһарманның ярамаган эш эшләгәнен аңлап ала. Шунда ук алып баручының арткы фонында әкият сюжетын комда ясап күрсәтеп барган рәсемнәр рус телле балага ярдәмгә килә. Укучы тыңлый, карый, үзе күзәтеп, аңлы-гамәли метод ярдәмендә татарча җөмләләрнең асылына төшенә. Ул Ләйләнең сөйләү интонациясе, комда ясалган рәсем аша, “Әһәәә, тиен олы кызга ачуланып, аны бакага әйләндерә икән!” (“Өч кыз” әкиятеннән) дип нәтиҗә чыгара. Шулай итеп, бала башта күрү, ишетү һәм фаразлау, уйлау-фикерләү күнекмәләре аша эчтәлекнең асылына төшенә. Аннан соң гына текст белән эшләгәндә инде аңлаган материал тәрҗемә методы белән ныгытыла. Шул ук вакытта Ләйләнең камил, төзек һәм аһәңле сөйләмен тыңлау аша рус телле укучыда дөрес сөйләү һәм сәнгатьле уку күнекмәсе булдырыла. Ул дикторның эмоциналь интонациясен отып кала һәм аны кабатларга тырыша. Бу төрдәге имитатив метод сөйләм осталыгын, күнекмәләрен формалаштырганда мөһим фактор булып тора. Баланың диктор, алып баручы, укытучының сөйләмен кабатлау татар теленә өйрәткәндә нәтиҗәле юлларның берсе. Алга таба дәрес барышында әкияттә очраган яңа сүзләрне тактага язу, аларны темага туры китереп, тиешле конструкциягә кую һәм шулар нигезендә телдән һәм язма күнегүләр башкару баланың дәрес башында таныш булмаган сүзне актив лексикага кертеп җибәрергә ярдәм итә, бәйләнешле сөйлә телен үстерергә ярдәм итә [6; Б.63]. Диалогик сөйләм телен үстерү, ишетеп аңлау, сөйләм күнегүләрен, трансформацияләү күнегүләрен башкаруда әкият тапшырулары чыганак-ачкыч функциясен үти.

Нәтиҗәдә, башлангыч сыйныфта рус телле балаларга татар телен укытканда укучының сүз запасын баетуда, ныклы орфографик һәм фонетик

күнекмәләр булдыруда, сәнгатьле итеп сөйләргә, укырга өйрәтүдә, татар халкының гореф-гадәтләренә, тарихына, мәдәниятенә ихтирам хисләре уятуда, һәм шулай ук чит мәдәниятләргә карата толерантлык хисе тәрбияләүдә “ШаянТВ” проектлары дәресләрдә уңышлы чыганаклар булып хезмәт итә. Лингвокультурологик аспект яктан караганда да, “Шаян” тапшырулары укучыда татар сөйләм этикетын булдыруда зур ярдәм күрсәтә, мәкаль, әйтем, афоризмнар кебек тел кодлары аша милли дөнья картинасын күзаллауны булдыра.

**Әдәбият**


1. Аналитическая деятельность управленческой команды (методическое пособие по анализу урока в контексте обновленных ФГОС). – Казан, 2022. 124 с.
2. Гиниятуллина Л.М., Шакурова М.М. Современные проблемы методики преподавания родного (татарского) языка. – Казань, 2018. 119 с.
3. Ландыш Нигъмәтҗанова шатлыклы яңалык белән уртаклашты // Шәһри Казан. 2022. 13 октябрь.
4. Шәкүрова М.М. Татар мәктәпләрендә татар телен укыту методикасы. – Казан, 2014. 61 б.
5. Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М. Дидактик уеннар. – Казан, 2019. 60 б.
6. https://shayantv.ru/ (03.11.2022)

# ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ АКТИВ АЛЫМНАР ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНУ

***Мөбаракшина Г.И., Карманова А.Р.***
***Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 77 нче урта мәктәбе***
***aminova.guzalia@yandex.ru***

***Аннотация.*** Активные методы обучения – это система методов, обеспечивающих активность и разнообразие мыслительной и практической деятельности учащихся в процессе освоения учебного материала. В данной статье представлены активные методы обучения для каждого этапа уроков родного (татарского) языка и литературы.

***Ключевые слова:*** метод, лексика, практика, обучение.

Эшебезне Галимҗан Ибраһимовның сүзләре белән башлап китәсебез килә: *"Күп белдерүгә караганда, аз белдереп, эзләнү орлыгы салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү- мөгаллим бирә торган хезмәтләрнең иң кадерлесе , иң зурысыдыр".* Бу сүзләр бүгенге көндә бик актуаль.Чөнки ФДББС таләпләре буенча белем бирүнең төп максаты- укучыларга белемнәр, күнекмәләр бирү генә түгел, ә аның үзен мөстәкыйль рәвештә белем алырга һәм бу белемнәрне тормышта иҗади кулланырга өйрәтү. Бу максатны үз эченә алган инновацион технологияләрнең берсе- "актив алымнар" технологиясе. Бүген укучылар үзаллы фикер йөртергә, күп төрле мәгълүмати чыганаклар белән эш итә белергә тиеш, бу – заман таләбе.

**Эшебезнең максаты:** танып-белү эшчәнлеген үстерүгә юнәлтелгән күнекмәләр булдыру һәм продуктив иҗат югарылыгына күтәрелергә ярдәм итү.

**Нәрсә соң ул укытуның актив алымнары?**

Актив алымнар белем бирү системасында стандарт булмаган фикерләүне, укытуның иң югары дәрәҗәдә камиллеген ассызыклый.

Алар-интелектуаль (гамәли) эшчәнлек төре: мәгълүматны кабул итү, төшенү, хәтердә калдыру, иҗади, интуитив фикерләү.

Бу технологиясенә корылган дәрес өч этаптан тора: *өйрәнелә торган темага кызыксыну уяту → төшенү (аңлау) → рефлексия.*

1. Кызыксыну уяту һәр дәрестә була. Бу өйрәнелә торган тема яки проблема буенча укучының элекке белемнәрен актуальләштерү һәм гомумиләштерү һәм актив эшчәнлеккә (уку эшчәнлегенә) ныклы кызыксыну уяту өчен кирәк.

2. Төшенү (аңлау) этабында укучы өйрәнелә торган материал буенча яңа мәгълүмат ала, төшенчәләрне, фактларны аңлап, элегрәк алган белемнәрен яңалары белән бәйли, тулыландыра.

3. Рефлексия этабында укучы өйрәнгәннәрне done бербөтен итеп күзаллый, аңлап гомумиләштерә, яңа мәгълүматны тулысынча үзләштерә, иҗади фикер йөртә һәм өйрәнелә торган материалга карата аның шәхси мөнәсәбәте формалаша.

***Туган (татар) тел һәм әдәбият дәресләрендә актив алымнар***

***технологиясе ысуллары:***

***1.Оештыру этабында:***

-“Поздоровайся глазами” (“Күзләр ярдәмендә исәнләш”)

- “Добро в ладошках” (“Акыллы гамәлләр безнең учларыбызда”)

- “Самолётик  пожеланий” (“Теләкләр самолеты”)

***2.Дәрескә максат һәм бурычлар кую, укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру этабында:***

- “Солнышко и туча” (“Кояш һәм болыт”)

- “Дерево ожиданий” (“Фаразлар агачы”)

***3.Белемнәрне беренчел ныгыту этабында:***

- “Шаг за шагом” (“Адым саен”)

- “Кластер” (“Тәлгәш”)

***4.Белемнәрне яңа ситуациядә иҗади куллану һәм эзләп табу этабында:***

- “Диалогические бусы” (“Диалогик сәйләннәр”)

- “Ромашка”

- “Парный выход” (“Парлап чыгу”)

- “Пазл”

- “Доскажи словечко” (“Сүзне әйтеп бетер”)

- “Один лишний” (“Берәү артык”)

- “Синквейн”

***5.Рефлексия этабында:***

- “Мудрый совет” (“Акыллы киңәш”)

- “Комплименты” (“Комплиментлар”)

- “Ресторан”

Хәзер берничәсенә тукталып үтәрбез.

***1.“Кластер” (“Тәлгәш” алымы)***

***Кластер*** дәрес материалын график калыпка салуны күздә тота.Төп мәгънәне белдергән сүз уртага языла, аңардан төрле якка киткән уклар бу сүзне ачыклаучы башка сүз, сүзтезмәләр белән бәйли. Шулай итеп, бер сүзне, төшенчәне ачыклаучы бик күп мәгълүмат җыела.

***2.”Синквейн” алымы.***

*Синквейнны язу тәртибе:*

Беренче юл - бер исем

Икенче юл - ике сыйфат

Өченче юл - өч фигыль

Дүртенче юл - бер җөмлә-метафора

Бишенче юл - бер сүз (беренче сүзнең синонимы, нәтиҗә).

Практик бирем: “*җыр*”сүзенә синквейн төзеп карыйк эле:

*Җыр*
*Моңлы, моңсу.*
*Шатландыра, биетә, күңелгә рәхәтлек бирә.*
*Җырламый күңел ачылмый!*

*Көй.*

***3.”Блум ромашкасы” алымы:***

Таныш булмаган текст алына, алдан тукталышлар билгеләнә. Вакыйгалар үстерелеше, сюжет, көтелмәгән финал туктап уку алымын мәгънәле итә. Укытучы алдан ук сораулар әзерләп куя. Сораулар түбәндәгечә төзелә:
**Гади сорау** - материал буенча булган белемнәрне камилләштерә
**Сорау –төпчену** – «мин ничек аңладым?….», «мин сезне дөрес аңладыммы?…»
**Сорау –интерпретация** (аңлатучы) **– теге яки бу күренешләрнең асылына төшендерү** (ни өчен?)
**Сорау –чагыштыру –** укучыларның үзара әңгәмәсендәге каршылыклар
**Иҗади сорау (**прогноз) – «Алга таба нәрсә булачак, сез ничек уйлыйсыз…?»
**Практик сорау –** «Без нәрсә эшли алабыз…?» «Сез ничек эшләр идегез…?».
*Сан сүз төркеменә Блум ромашкасы төзеп карыйк:*

1.Сан нәрсәне белдерә?

2.Сан нинди сорауларга җавап бирә?

3.*Сигез укучы укый* җөмләсеннән саналмышны табыгыз.

4.Саннар сүз белән языла аламы?

5.Сан нинди цифрлар ярдәмендә языла?

6.Саннарсыз аралаша алабызмы?

***4.“Дирижер”****(дәрестә ял минуты)*

Басабыз, үзебезне иркен хис итәбез! Хәзер без сезнең белән бик матур музыка тынлыйбыз. Һәм һәрберегез үзен зур оркестр белән идарә итүче дирижер итеп хис итсен! Күңелегез музыкадан килә торган энергия һәм гармония белән тула! Әгәр дә теләсәгез, күзләрегезне йомып тыңлый аласыз! Ә хәзер музыкага кулларыгызны хәрәкәтләндерегез, әйтерсең лә сез дирижер. Сез үзегезнең оркестр белән горурланасыз! Музыка туктады, ә хәзер әйдәгез шушы концертны көчле алкышлар белән тәмамлыйбыз!

Алда саналып киткән алымнарны дәреснең төрле этапларында куллана алабыз. Шулай итеп, актив алымнар технологиясе шәхеснең ирекле үсеше өчен шартлар тудырып кына калмый, баланы мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә. Укучы дәрестә өйрәнелә торган материалның асылына төшенеп, тулысынча анализлый, нәтиҗәләр чыгара. Бу технологиянең нигезендә стандарт булмаган фикерләү, ирекле күзаллау, катлаулы проблемаларның яңа чишелешен табу һәм иҗади эшләү ята. Бу акыл эшчәнлегенең гадидән катлаулыга таба үсешен тәэмин итәргә ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Гин А.А. Приемы педагогической техники [Текст ]: пособие для учителя. Изд.5 / Под общ. ред. А.В. Хмелева.– М.: Вита – пресс, 2004.
2. Загашев И.О., Заир-Бек С.И. Критическое мышление: технология развития. – Санкт-Петербург, 2003.

3. Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М. Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту.- Яр Чаллы, 2015.

# ТӘЭСИР ИТҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК БАШИСЕМНӘРНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Мөгътәсимова Г.Р.***
***Казан федераль университеты***
***gulnaz-72@mail.ru***

***Аннотация.*** В данной статье рассматриваются особенности заголовка в современных средствах массовой информации. Воздействие рассматривается на примере газет на татарском языке. Актуальность изучения обусловлена тем, что в наши дни традиционные СМИ оказывают колоссальное влияние на аудиторию, что, в свою очередь, формирует мировоззрение аудитории.

***Ключевые слова:*** средства массовой информации, татарский язык, заголовок, воздействие.

Телнең кешегә, аның фикер йөртү рәвешенә һәм үз-үзен тотышына тәэсир итүе турыдан туры массакүләм мәгълүмат чаралары белән бәйле. Чыннан да, массакүләм мәгълүмат чараларына караган төп функцияләрнең берсе хәбәр итү булса, икенчесе – тәэсир итү. Дөнья вакыйгалары белән таныштырып һәм кешенең ял сәгатьләрен алып, массакүләм мәгълүмат чаралары анын фикер йөртүенә, дөньяны кабул итү стиленә, бүгенге көн мәдәнияте төренә тәэсир итәләр. Ә ышандыру һәм нәрсәгә дә булса теләк тудыру дөньяга бәя бирү аша башкарыла. Гомумтел категориясе буларак, бәя бирү телнең барлык өлкәләрендә, аеруча лексикада чагылыш таба.

Тел берәмлегенең бәя бирә алу үзлеге анын төп мәгънәсе түгел, еш кына коннотатив мәгънәсе белән бәйле. Сүзнең лексик мәгънәсенә турыдан туры карамаса да, коннотация тасвирлана торган предметның бәя бирелгән образын укучыга тәкъдим итә. Шулай итеп, махсус бәя бирүче сүзләрне, гыйбарәләрне кулланмыйча, нәтиҗәле бәяләүгә булыша, димәк, укучылар аудиториясенә тәэсир итә.

Хәбәр итү функциясе публицистик стильгә караган түбәндәге үзенчәлекләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, дөреслек, рәсми бәян итү, объективлык, тотнаклылык. Тәэсир итү функциясе ачык, иҗтимагый бәяләнү һәм бәхәсләшүчәнлек, гадилек һәм аңлаешлы аңлату белән билгеләнә. Мәгълүмати жанрларга хәбәр итү функциясе хас булса, аналитик жанрларга тәэсир итү функциясе хас.

Алга таба татар газета-журналларында тәэсир итү функциясен белдерүче вербаль чараларны барларбыз. Эшебездә без аеруча игътибарга лаеклы булган һәм киң таралган күренешләргә тукталачакбыз.

Укучыларны җәлеп итүдә язмаларның атамалары яки башисем зур роль уйный. Укучыларның 80 % ы башисемне уку белән генә чикләнүе билгеле. Материалны тулысынча укып чыгу-чыкмау шуның белән хәл ителә. Тәэсирле башисем моны уңай хәл итергә мөмкин. Бик коры һәм кычкырып тормаган башисем мәкаләне игътибарсыз да калдыра ала. Башисем ул – текстның гади генә исеме түгел, ә автор белән укучы арасында тоташтырып торучы үзенә күрә бер күпер дә. Язманың нәкъ менә шул өлеше үзенә күп игътибар җәлеп итә.

Татар вакытлы матбугатында башисем булып мәкаль-әйтемнәр, җырлардан алынган өзекләр, кинофильмнарның исемнәре һәм башкалар булырга мөмкин. Алга таба шуларны карап үтәрбез.

А) Әлбәттә, башисемнәр арасында мәкаль-әйтемнәр беренчелекне бирми. Мәсәлән:

*Сыныкка сылтау эзләмиләр* (“Ватаным Татарстан”, №:46, 01.04.2017);

*Кунакның урыны түрдән* (“Ватаным Татарстан”, 25.04.2017);

*Акча санаганны ярата* (“Ватаным Татарстан”, 12.04.2017);

*Туй узгач – думбра* (“Ватаным Татарстан”, 4.04.2017);

*Тарткан атка йөк... җиңел?* (“Ватаным Татарстан”, 17.03.2017);

*Гаеп – атта да, тәртәдә дә* (“Ватаным Татарстан”, 21.03.2017);

*Һәр эшнең дә җае бар* (“Ватаным Татарстан”, 21.03.2017);

*Күршең үзеңнән яхшырак булса?!* (“Ватаным Татарстан”, 15.03.2017);

*Бер таякның ике башы* (“Ватаным Татарстан”, 7.03.2017);

*Яхшылык эшлә дә суга сал, ди безнең халык.* (“Ватаным Татарстан”, 23.04.2019).

Шулай итеп, татар вакытлы матбугатында мәкаль һәм әйтемнәр актив кулланыла. Н.О. Григорьева әйткәнчә, “мәкаль һәм әйтемнәр ярдәмендә әйтелгән фикер, җиңел кабул ителә, яңара, тәмамлана...”.

Ә) Хәзерге татар вакытлы матбугатында төрле елларда популяр булган җырлардан алынган цитаталар үзгәртеп ясалган башисемнәр киң кулланыла. Җырлардан алынган цитаталар, укучыга тәэсир итеп, аның белән бәйләнеш урнаштыралар. Бу очракта цитата үзе әлләни мөһим дә түгел. Аны танып алулары әһәмиятле: укучылар башисемне таныш бер язма итеп кабул итәләр. Мисалларга игътибар итик:

*“Тал бишектә үстем мин дә...”* (“Ватаным Татарстан”, 18.04.2017);

*Шушы туфрактан без...* (“Ватаным Татарстан”, 22.03.2017);

*Үз ягыма кайтсам...* (“Ватаным Татарстан”, 11.03.2017);

*Ал кирәк, гөл кирәк, акыллы хатын кирәк* (“Ватаным Татарстан”, 08.02.2017);

*Дус-иш кирәк дөнья көтәргә.* (“Ватаным Татарстан”, 23.04.2019);

Б) Халык арасында киң таралган, яратып каралган фильмнарның исемнәре дә башисем була ала. Мәсәлән:

*“Ы” операциясе* (“Ватаным Татарстан”, 21.03.2017);

В) Татар газета-журналларында төрле авторларның шигырьләреннән, чәчмә әсәрләреннән алынган юллар да башисем ролен үтәгәне ачыкланды:

*Дәрсе гыйбрәттер театр...* (“Ватаным Татарстан”, 01.04.2017)

*“Монда хикмәт, мәгърифәт...”* (“Ватаным Татарстан”, 21.03.2017)

***Былтыр кысканга, кычкыралармени быел**, яки Гали абый 50 елдан соң гаделлекне табармы?* (“Шәһри Казан”, 14.06.2016);

***Үзебез сайлаган язмыш**, яки бала төшерүчене каторгага?* (“Шәһри Казан”, 10.09.2015);

*Яши хәзер миндә ике “мин”...* (“Безнең гәҗит”, 05.02.2014).

Мисаллардан күренгәнчә, башисем ролендә килгәндә, мәкаль-әйтемнәр, җырлар, шигырьләр һәм башка материаллар төрле трансформацияләргә дучар булалар. Мәсәлән, журналистлар аерым компонентларын кыскарталар:

*Кызым, сиңа әйтәм...* (“Ватаным Татарстан”, 11.03.2017);

*Үз ягыма кайтсам...* (“Ватаным Татарстан”, 11.03.2017);

*Тау Мөхәммәткә бармаса...* (“Ватаным Татарстан”, 15.03.2017);

*Күпер салуның ние бар?* (“Ватаным Татарстан”, 10.02.2017);

*Җиде кат уйла...* (“Ватаным Татарстан”, 21.09.2010);

Журналистлар компонентларын башка сүзләр белән алыштырып та куеп, төрле экспрессив мәгънәләр тудыруга ирешә:

*Язмаса язын, көенербез көзен.* (“Ватаным Татарстан”, 23.04.2019);

Язмаларның авторлары мәкаль-әйтемнәр һәм башка материалның бер генә, ләкин эмотив семантика тудыручы өлеше белән генә эшләргә мөмкин:

***Пычак кем кулында,** яки каз чалырга кайткан Марат Кәбиров чак кына дөнья белән хушлашмый калган* (“Шәһри Казан”, 15.12.2015);

*Татарлар декабрьдә **“куерачак”*** (“Татарстан яшьләре”, 29.11.2007).

***Асрамага** әти-әни бирәм* (“Шәһри Казан”, 14.10.2013).

Газета-журналларда кайвакыт экспрессия барлыкка китерү өчен, мәкаль-әйтемнәрне әзер типик эмоциональ берәмлекләргә үзгәртеп куялар:

*Үлгәннәрнең каберен генә түгел, кадерен дә белергә кирәк...* (“Шәһри Казан”, 20.10.2015);

*Бала күңеле нигә далада?* (Ватаным Татарстан, 21.09. 2010);

*Бала күңеле кайларда?* (“Ватаным Татарстан”, 24.03.2017);

Шулай итеп, массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәр тарату максатын күздә тотып кына барлыкка килсәләр дә, бүгенге көндә мәгълүматны хәбәр дә итәләр, анализлыйлар да, дөнья сурәтен дә барлыкка китерәләр, күңел ачарга ярдәм итәләр. Өстәвенә, массакүләм мәгълүмат чараларының теләсә кайсы функциясе тәэсир итү белән бәйле булырга мөмкин. Теге яки бу вакыйга турында хәбәр итеп кенә калмыйча, җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру да аларның бурычы булып санала. Димәк, вакытлы матбугат – халык аңына тәэсир итүче мөһим бер чара.

**Әдәбият**

1. Гарифуллин В. З. Газета текстының төзелеше. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 104 б.

4. Гарифуллин В.З. Вакытлы матбугатта жанрлар. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2007. – 124 б.

5. Гарифуллин В.З. Журналист эшчәнлегенең нигезләре: уку ярдәмлеге. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. – 120 б.

6. Зәйни Р.Л. Татар матбугаты системасында яңа тип басмалар // Белем һәм тәрбия чарасы буларак татар журналистикасы: "Мәгариф" журналының 100 еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары (26-27 февраль, 2014 ел) / төзүче-редакторлары В.З.Гарифуллин, Р.Л.Зәйни. – Казан: Идел-Пресс, 2014. – Б. 90-93.

7. Зәйни Р.Л. Яңа технологияләрнең журналистика материалларын кабул итүгә ясаган тәэсире // Укыту-тәрбия процессында балалар һәм яшьләр матбугатын куллану. Югары, һөнәри, гомумбелем бирү уку йортлары укытучылары һәм укучылары өчен фәнни-гамәли республика конференциясе материаллары (2019 елның 7 феврале, Казан) / ред. Зәйни Р.Л., төз. Антонова Л.М. – Казан, 2019. – Б. 26-29.

# ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ИНТЕРАКТИВ УКЫТУ ЫСУЛЛАРЫ

***Мөхәммәтҗанова Э. Р.***
***Дүртөйле районы Мәскәү авылы мәктәбе укытучысы***
***amineva1960@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье актуализируется проблема реализации интерактивных методов обучения в школе, также рассматриваются различные интерактивные формы и методы обучения на уроках родного языка.

***Ключевые слова:*** интерактивные методы, диалог.

Интерактив укыту ысуллары – ул танып-белү эшчәнлеген оештыруда махсус эш формасы, аның төп максаты - диалог коруның уңайлы шартларын булдыру. Уку процессының шарты булып, укытучының һәм укучыларның диалогка нигезләнгән үзара бәйләнешкә керүе тора. Дәрес барышында һәркем аралашырга, шәхесара төрле мөнәсәбәтләргә керергә, эшчәнлек башкарырга тиеш. Дәрес никадәр җанлы һәм кызыклы – укучыда фәнгә карата уңай мотивация шулкадәр югары. Моны булдыручы – остаз, һәр баланы эшчәнлеккә җәлеп итүче. Диалогта катнашу – ул тыңлау, ишетү, сөйләшү генә түгел, ә аңлау да таләп итә. Димәк, кызыклы, конструктив диалог төзергә өйрәнергә һәм өйрәтергә кирәк.

Интерактив ысуллар уку мотивациясен арттыруга, белемне тирәнәйтүгә, иҗади сәләтне, аралашучанлыкны үстерүгә ярдәм итә һәм үз позицияңне белдерергә мөмкинлек бирә. Балаларның үз-үзләренә хөрмәте, ышанычлары арта. Тирә-яктагы кешеләрнең фикерләренә һәм эшләренә карата ихтирам, түземлелек тәрбияләү бик мөһим. Җәмгыятьтә кешеләр белән аралаша белү, килешүләр төзү, командада эшләү кебек сыйфатлар югары бәяләнә. Интерактив ысуллар җаваплылыкны бүлергә, максатлар куярга, дөрес методлар сайларга, ситуацияне анализларга ярдәм итә, шулай ук иҗади фикер йөртүне үстерә, эшләнгән эштән канәгатьлек хисе бирә.

Интерактив методларга уен (эшлекле уен, рольләргә бүлешеп уйнау, психологик тренинг), парлы һәм төркем эшләре, «карар агачы», «баш мие штурмы» (брейнсторминг), «гомуми дискуссия», «түгәрәк өстәл», дебатлар, диспутлар, форумнар, проектлар, кейслар, семинарлар, ассоциацияләр, «Аквариум», «Блум ромашкасы», «Кар бөртеге» технологияләре керә. Укучыларның танып-белү эшчәнлеген активлаштыру һәм укучыларда уңай мотивация булдыру дәреснең һәр этабында тормышка ашырылырга тиеш. Укучыларны кызыксындыруны тәэмин итә торган кайбер нәтиҗәле алымнарга күзәтү ясап китик.

Дәрес башында «фаразлау агачы»н кулланырга мөмкин, анда дәреснең темасы – «агач кәүсәсе», «яфраклар» - дәрескә фаразлар, «ботаклар» - аргументлар. Мәсәлән, «Алмашлыклар» темасын өйрәнгәндә лингвистик әкият сөйләнә, анда укучылар агач моделен төзиләр. «Лексика» бүлеген өйрәнгәндә, дәресне «Сүз болыты» алымы белән башлау урынлы, анда ачкыч сүзләр яшерелә. Шулай ук дәресне өч фазалы структура: чакыру, фикерләү, рефлексия нигезендә төзү дә уңай нәтиҗә бирә. «Чакыру» этабында табышмаклар,

башваткычлар, лингвистик биремнәр бирергә була. «Фикерләү» ситуациясендә сингапур укыту методы элементларын кулланырга мөмкин, анда укучылар элемтәгә кереп, хезмәттәшлек итәләр һәм команда булып өлгерәләр. Икешәр һәм дүртәр төркемнәрдә укучылар буталчык логик чылбырлар, интеллект карталары, график кластерлар, таблицалар, дәрес темасы буенча дөрес һәм дөрес булмаган раслаулар булдыра алалар.

Парларда эш - хезмәттәшлек һәм үзара ярдәм күрсәтү өчен иң яхшы форма. Монда укучылар бер-берсен тикшерә, яңа материалны ныгыта, үткәннәрне кабатлый ала. Төркемдә укучылар «Ишикава диаграммасы» буенча эшли алалар, «Фишбоун», «Күрше өчен сүзлек диктанты» модельләрен төзи алалар.

Рефлексия этабында укучылар «Кластер» ысулын эффектив кулланып төп сүзне табалар, дәрес моделен эшлиләр.

ПАМН-формула (П-позиция ( «Мин уйлыйм,... »); А – аңлатма (яки нигезләү); М - мисал («мин моны ... мисалында исбатлый алам»); Н – нәтиҗә («моннан чыгып, мин нәрсә турында нәтиҗә ясыйм») – катлаулы мәсьәләләр турында фикер алышканда кулланыла.

Һәр укучы үз эшчәнлеген график формада «Бәяләү тәрәзәсе» методы буенча башкара ала, ул «Шунда ук куллана алам», «Бөтенләй аңлашылмый», «Яхшы аңлашыла», «Беркайчан да куллана алмыйм» дигән бүлекләрдән тора. Шул рәвешле, туган тел дәресләрендә яңа материалны һәм кагыйдәләр үзләштерүне җайга салырга мөмкин.

Укучыларның уңышлы сөйләм активлыгының нигезе булып традицион булмаган дәрес формалары тора, алар барышында укучылар белемнәрен киңәйтәләр, бу исә укучыларга фикер алышуда актив катнашырга мөмкинлек бирә.

Интерактив укыту технологиясе нигезендә туган тел буенча биремнәрне үтәгәндә, проблемалы ситуацияне үзенчә күрү, аннан чыгу мөмкинлеген формалаштыру өчен шартлар тудырыла; үз позицияләреңне, тормыш кыйммәтләреңне нигезләү; башка карашны тыңлау сәләте, хезмәттәшлек итү сәләте, үз оппонентларына карата толерантлык күрсәтеп, парың белән аралашу кебек үзенчәлекләр үсә, үзара аңлашу, хакыйкать эзләү юлларын бергәләп табу процессында катнашу мөһим роль уйный.

Шулай ук туган тел дәресләрендә интерактив технологияләр кулланганда метапредмет һәм предмет бәйләнешләр генә түгел, шәхси компетенцияләр формалаштыру да бара, бу исә үсетерелешле укыту технологияләрен тулысынча гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

1.Вислобоков Н. Ю. Технологии организации интерактивного процесса обучения // Информатика и образование. - 2011. - N 6. - С. 111-114.

2. Воронкова О. Б. Информационные технологии в образовании: интерактивные методы / О. Б. Воронкова. – Ростов н/Д: Феникс, 2010. - 315 с.

3.Ермолаева М.Г. Интерактивные методики в современном образовательном процессе. - М.: Просвещение, 2014. - 42 с.

4.Кажигалиева Г.А., Васенкова М.В. О принципах и методах технологии интерактивного обучения русскому языку в средней школе // Педагогика. – 2005. - №2.

# ЧИТ ТЕЛГӘ ӨЙРӘТКӘНДӘ ТУГАН ТЕЛНЕҢ РОЛЕ

***Мөхәммәтшина А.Ф., Нурмөхәммәтова Р.С.***
***Казан федераль университеты***
***alisafaizovna99@mail.ru, rsagadat@yandex.ru***

***Аннотация.*** В работе рассматривается принцип опоры на родной язык как один из ключевых принципов в практике обучения иностранному языку. Процесс обучения иноязычной речи неразрывно связан с проблемой взаимодействия двух языковых систем в сознании говорящего. Все мыслительные процессы учащихся, их психическая деятельность тесно связаны с родным языком, его фонетическим, грамматическим и лексическим строем.

***Ключевые слова:*** родной язык, иностранный язык, обучение, принцип опоры на родной язык.

Бүген укучылар мәктәптә чит телләрне башлангыч сыйныфлардан ук өйрәнә башлыйлар. Чит телләр арасында кытай теленең роле көннән-көн арта бара. Әмма әлегә методик киңәшләр, татар һәм кытай телләре үзенчәлекләрен фәнни нигезләгән чагыштыру булмау, укытучыларның милли тел нигезләрен тиешенчә белмәве чит тел үзләштерүдә күп кыенлыклар тудыра. Нәкъ менә бу хәл укытучыларны чит телне укыту процессында барлыкка килә торган икетелле интерференция белән бәйле кайбер проблемаларны күрү мөмкинлегеннән мәхрүм итә.

Кытай телендә уку, язу һәм сөйләм кебек күнекмәләргә өйрәткәндә дә укучыларның грамматика һәм фонетика өлкәсендә белем дәрәҗәсенә аерым игътибар бирергә кирәк. Методологик тикшеренүләр чит телләрне укыту методикасын камилләштерүдә иң мөһим аспект булып тора. С.Ф. Шатилов, М.В. Ляховицкий, Г.В. Рогова, Н.Н. Гез, А.А. Миролюбов кебек методистлар методик, специфик һ.б. принципларны аерып чыгалар. Әлеге принциплар арасында чит тел дәресләрендә туган телне исәпкә алу принцибы аерым игътибарга лаек.

Туган телне системалы рәвештә кулланган очракта, ул чит телне өйрәнү баскычларының теләсә кайсысында ярдәм итәргә мөмкин. Шул ук вакытта ул теоретик яктан гына түгел, ә гамәли яктан да бик нәтиҗәле. Әлеге карашны Р.К. Миньяр-Белоручев, Э.Г. Вольтер, Д. Аткинсон, С. Крашен, Л. Продромоу һәм башка күп кенә галимнәр яклап чыга.

Балалар өчен берникадәр тел тәҗрибәсе булу хас, чөнки укучылар, кагыйдә буларак, туган тел күнекмәләрен чит тел күренешләре кысаларында куллана. Бер яктан, инде булган тел тәҗрибәсе икенче телне өйрәнү өчен яхшы нигез булып тора, чөнки бу – укучыларның шәхси тәҗрибәсен баета торган өстәмә вакытлы элемтәләр комплексы. Әлеге тел тәҗрибәсе чит телне өйрәнү өчен яхшы шартлар тудыра. Әмма булган тел тәҗрибәсен дөрес кулланырга һәм уңай якка борып җибәрергә кирәк, югыйсә ул укуда да, әйтелештә дә чагылыш табарга мөмкин булган тискәре йогынты ясарга мөмкин. Шуңа күрә татар теле үзенчәлеген исәпкә алу чит телгә өйрәтүдә мөһим әһәмияткә ия. Мәсәлән, кытай телен өйрәнгәндә интерференция күренеше барлыкка килә, ягъни күнекмәләр

туган телдән өйрәнелә торган телгә күчерелә. Болар без сайлаган теманың актуальлеген ассызыклый.

Хәзерге вакытта үсеп килүче буынны тынычлык һәм мәдәни татулык рухында тәрбияләү – мәгариф системасының иң мөһим бурычларыннан берсе. Ул заманча мәдәни мохиттә, үзенең мәдәни үзенчәлеген аңлый ала торган, әмма шул ук вакытта башка мәдәният кешеләре белән тату яши белгән ирекле шәхес формалаштыруга ярдәм итә. Педагогикада милли һәм гомумкешелекнең үзара бәйләнеше турында П.Ф. Каптерев идеяләре тәрбия бирүнең ролен аңлау өчен зур кызыксыну уята. Милли кыйммәтләргә бәйле педагогик процессның үзенчәлекләре буларак, ул телне, динне һәм көнкүрешне аерып чыгара. Туган телне үзләштерүне ул милли, рухи хәзинәләргә һәм әйләнә-тирә дөньяга фәнни карашлар формалаштыручы гомумкешелек белемнәренә җәлеп итү буларак карый. П.В. Каптерев буенча, педагогик эшчәнлек башта милли идеал нигезендә башкарыла, ә аннары гомумкешелек идеалына ирешү эшчәнлегенә әверелә. «Тәрбиядә бер халыкка түгел, ә күпләргә, аларның идеалларын һәм кыйммәтле чит үзенчәлекләрен карарга, үз милли идеалларының җитешсезлекләрен тулыландырырга кирәк; халыкны үз һәм чит, халыкара күренешләр белән бергә катнаштырырга кирәк», – дип ассызыклый ул [Каптерев: 67].

Мәктәп мәгарифен модернизацияләү, барыннан да элек, аның эчтәлеген сыйфатлы яңарту һәм аны үстерүче мәдәният барлыкка китерү белән бәйле. Шуңа бәйле рәвештә укучыларның иҗади, шәхси потенциалын үстерү өчен шартлар тудыруга һәм заманча тирәнтен белем бирү мөмкинлекләрен киңәйтүгә аерым игътибар бирелә. Өйрәнелгән тел белеме кысаларында мондый шартлар полилингваль нигездә укыту процессында барлыкка килә. Шул ук вакытта соңгы елларда икетелле укыту проблемасы буенча фикер алышулар еш була, әлеге технологиянең актуальлеге һәм прогрессивлыгы раслана. Билингвизм шартларында укыту күп кенә галимнәр тарафыннан мәктәптә чит телне укытуны нәтиҗәле формалаштыру мөмкинлегенең берсе дип таныла һәм шуңа күрә хәзерге вакытта тикшеренүчеләрнең игътибар үзәгендә тора. XXI гасыр башында ике- һәм күптелле укыту аеруча перспективалы юнәлеш буларак карала. Күп кенә галимнәр чит телгә икетеллелек өйрәтүне кертүне яклый һәм, полилингваль мәктәпләр һәм сыйныфлар санын арттырганда, эшнең уңышы булачагына шикләнми.

«Полилингвизм» сүзенең латин теленнән «poli» – «күп» һәм «lingua» – «тел» тамырларыннан барлыкка килгән. Полилингвизм – ике яки аннан күбрәк телдән куллана белү сәләте буларак билгеләнә. Полилингвист кеше – ким дигәндә өч телдә аралаша белә торган кеше. Полингваль укыту башка халык мәдәниятенә тирән үтеп керергә ярдәм итә, чит телне актив куллану мөмкинлекләрен киңәйтә, бу исә чыгарылыш укучыларын гомумевропа базары шартларына уңышлы җайлаштыруның алшарты булып тора. Тирәнтен тел белеменең база компоненты буларак полилингваль нигездә укытуның актуальлеге, барыннан да элек, икътисади, мәдәни һәм сәяси өлкәләрдә интеграциягә гомумдөнья тенденциясе белән билгеләнә.

Әлеге тенденцияләрне исәпкә алып, полингваль нигездә укыту

укучыларга, шәхси ихтыяҗларга туры китереп, төрле фән өлкәләрендә мәгълүмат алу мөмкинлеген, яңа мәгълүмат һәм өзлексез белем алуны тәэмин итә, бу исә, үз чиратында, гомумевропа һәм дөнья базарында белгечләр өчен өстәмә мөмкинлекләр тудыра. Шуның белән бергә, полилингваль нигездә укыту гомуми тел әзерлеген һәм махсус фәнни максатларда чит телләрне белүне камилләштерергә, предметларны тирәнәйтергә һәм мәдәниятара укыту өлкәсен киңәйтергә, шулай ук чит телне өйрәнүдә мотивацияне арттырырга ярдәм итә.

Чит телне өйрәнү туган телне өйрәнүдән аермалар булу белән дә характерлана. Аерым алганда, туган телне өйрәнгәндә әзер схемалар юк, тел күренешләрен тел системасы белән туры китерү мөмкинлеге кыен. Ләкин балалар билгеле бер шаблон буенча эшләргә ияләнгән. Шул ук чит телне өйрәнгәндә, сөйләшүчегә аның туган тел системасы һәм нормасы турында булган күзаллауларын «өзәргә» туры килә. Нәкъ менә шуңа күрә башка телгә күчкәндә, кеше инерция буенча, үз теленә хас булган синтаксик структураларны һәм лексик-семантик категория алымнарын куллана, моннан тыш аның теле туган телгә хас артикуляция хәрәкәтләреннән азат булмый.

Белем бирү, бер яктан, кешенең үз тамырларын аңларга һәм аның дөньядагы урынын билгеләргә ярдәм итә, икенче яктан, башка мәдәниятләргә карата хөрмәт тәрбияли. Башка халыклар мәдәниятен өйрәнү тигезлек хисләрен формалаштыра, төрле милләт вәкилләренең мәдәни диалогын булдыруга мөмкинлек бирә. Этник мәдәниятне торгызу шартларында заманча белем бирү буыннарның дәвамчанлыгын, туган телне һәм яшь буынны әхлакый тәрбияләүдә этнокультура традицияләрен яңадан торгызу, саклап калу һәм үстерүне тәэмин итәргә тиеш.

Балаларны туган этномәдәниятркә кертүнең иң нәтиҗәле юлы – телне һәм әдәбиятны өйрәнү. Тел аралашу һәм фикер белдерү чарасы гына түгел, ә мәдәният кыйммәтләрен туплау чарасы да. Телдә халык тәҗрибәсе, аның тарихы, матди һәм рухи мәдәнияте чагыла. Филолог И.И. Срезневский да: «Телдә халык үзен башка нәрсәләргә караганда тулырак һәм күпкырлырак итеп күрсәтә, үзенең соңгы хәлендә генә түгел, тарихи хәлендә дә. Аның көнкүрешендә һәм төшенчәләрендә булган бар нәрсә һәм халыкның хәтерендә сакларга теләгән бөтен нәрсә тел белән әйтелә һәм саклана. Үзенең бөек тормышы һәм мөһим тарихи кулланылышында тел – мәгърифәтлелекнең барлык ихтыяҗларын канәгатьләндерүче корал һәм ярдәмче», – дип язып калдырган.

Билгеле булганча, тел тормышта әйләнә-тирә дөньяны танып белүнең мөһим чарасы. Тел ярдәмендә кешеләр үзара аралашалар, аларның бер-берсенә йогынтысы барлыкка килә. Нәкъ менә аралашу процессында бала шәхесе үсеше, аның акыл, сөйләм һәм әхлак үсеше барлыкка килә. Шулай итеп, телнең җәмгыятьтәге урыны укучыларны туган һәм чит телгә телгә өйрәтүнең төп максатын билгели. Һәм бу ике телне өйрәнүдә беренче аерма булып тора. Туган телгә өйрәтүнең максаты – сөйләмне үстерү. Чит телгә өйрәтүнең максаты – аралашу компетенциясе булдыру.

Телне өйрәнү процессларында һәм механизмнарында аерма бар. Балалар,

мәктәптә татар телен өйрәнә башлаганда, туган телдә сөйләшә beләләр инде. «Балалар сөйләмен тикшерүләр күрсәткәнчә, бала инде мәктәп чорында ук сөйләм үсешенең шактый югары дәрәҗәсенә ирешә ала, өстәвенә ул телнең сөйләм стиленә дә ия була. Киресенчә, китап стиленең грамматик элементлары алар тарафыннан үзләштерелми кала...». «Мәктәпкә килгәндә балаларның сөйләү һәм тыңлау күнекмәләре була, әмма аннан тыш укучылар уку һәм язуны үзләштерүгә керешәләр, аларны һәм барлык башка уку предметларын өйрәнгәндә, китаплар һәм уку әсбаплары белән танышканда аңлы рәвештә файдалана башлыйлар» [Львов: 90].

Ә чит телне бала «нуль»дән өйрәнә башлый. Туган һәм чит телләрне үзләштерү процесслары һәм механизмнары бик катлаулы, алар әлегә җитәрлек өйрәнелмәгән. Л.С. Выготский «бала туган телен аңсыз рәвештә, ә чит телне аңлы һәм ниятле итеп үзләштерә. Шуңа күрә, туган телнең үсеше астан-өскә бара дип әйтергә мөмкин, шул ук вакытта чит телнең үсеше өстән-өстән аска таба юнәлгән» [Львов: 94]. Шуңа күрә туган тел һәм чит телгә өйрәтү методикалары да төрле. Туган тел аңсыз рәвештә өйрәнелә, ә аннары аңлау һәм камилләштерү бара, ә чит тел башта яңа сөйләм күренешләрен аңлау, ә аннары сөйләм практикасында тормышка ашыру тәртибендә үзләштерелә.

Әмма башлангыч мәктәптә балалар туган һәм чит телләрне параллель өйрәнәләр. Бу – тел компетенциясе ике тел тәэсирендә формалаша дигән сүз. Бала чит тел сүзләрен туган телдәгеләр белән бәйли. Шулай итеп, мәктәптә чит телне туган телгә таянмыйча өйрәнү мөмкин түгел. Балалар туган телдә уйлый. Укучы өчен туган тел өйрәнү предметы гына түгел, башка предметны укыту чарасы да булып тора.

Туган телне өйрәнү алфавитн, сузык һәм тартыкларның хәрефләре белән танышудан һәм матур язу дәфтәрендә (прописьта) эшләүдән башлана, ягъни балалар телдән һәм язма сөйләм белән танышалар. Грамотага өйрәтүнең төп бурычлары – уку һәм язуга өйрәтүдән тыш, сөйләшү һәм тыңлау күнекмәләрен булдыру. Эчке сөйләм – мөстәкыйль күренеш түгел, ә тышкы сөйләмнән килеп чыккан күренеш. Аны үзләштерү өчен, башка кешеләр сөйләмен кабул итү һәм сөйләмнең барлык төрләрен һәм формаларын актив белү кирәк. Чит тел дәресләрендә укытучы укучыларны сөйләшергә һәм чит ил сөйләмен ишетеп аңларга өйрәтергә тиеш. Башлангыч мәктәптә балалар ишеткәнне җиңел кабул итә. Алар телдән аерым сүзләрне генә түгел, бәлки тулы бер сөйләм чылбырларын да үзләштерәләр, шул ук вакытта уку алар өчен кыенлык тудыра. Җанлы сөйләмнән башлау гына тизрәк хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирә, ә бу, үз чиратында, чит телне өйрәнүгә тагын да зуррак кызыксыну тудыра.

Чит телгә өйрәтү билгеле бер коммуникатив структураларны кертүдән башлана. Андыйлар, мәсәлән: «你好» (Сәлам!), «我是... » (Мин ...), «你是谁? » (Син кем?), «你最近怎么样?» (Хәлләрең ничек?) һ.б. Структура белән танышу бөтеннән өлешкә таба гамәлгә ашырыла. Әлеге структураларны туплау һәм эшкәртү, балаларның кызыксынуын һәм материалны ныгыту өчен, укытуның, уеннарның билгеле бер алымнары ярдәмендә алып барыла. Чит ил алфавитын

өйрәнү коммуникатив структураларны өйрәнү белән параллель бара. Укучылар кытай ачкычларын, сузык һәм тартыкларны белергә, аларны «пьинин»дә укырга һәм алар белдерә торган авазларны әйтергә тиеш. Тыңлаудан соң телдән аралашу башлана. Тыңлап аңлау (аудирование) эчке сөйләмдәге сүзләргә җавап реакциясен әзерләүне дә, телнең аваз составын һәм интонацияне үзләштерүне дә, лексиканы һәм грамматиканы үзләштерүне дә күздә тота. Тыңлау һәм сөйләшү үзара бәйләнгән. Сөйләшү һәм төрле типтагы күнегүләр ярдәмендә ирешелергә тиешле лексик күнекмә формалаша.

Уңышлы нәтиҗә берничә шартка бәйле. Е. Пассов фикеренчә, бу, барыннан да элек, «сөйләү һәм фикерләү бурычы булу, сөйләм гамәленең шәхси мотивациясе булу, гомуми эш контекстында ситуациянең булуы, ситуацияләрнең вариативлыгы, продуцентның һәм реципиентның мөстәкыйльлеге. Бу аралашу була да инде». Чит телдәге когнитив һәм коммуникатив функцияне үзләштерү өчен «чит телне мәдәниятара аралашу чарасы буларак үзләштерүнең аерым-мөһим мотивларын мотивацияләү» таләп итеlә [Рамзаева: 67]. Алдагы аерма И.А. Зимняя тарафыннан «чит телдә аралашуның аз вакыт алып тору»ы буларак билгеләп үтелә. Нәкъ менә шуңа күрә коммуникатив метод – чит телгә өйрәтүдә иң мөһиме. Тел чараларын (лексика, грамматика һәм фонетика) үзләштерү укучыларның коммуникатив һәм танып-белү ихтыяҗларына җавап бирми. И.А. Зимняя шулай ук чит телнең уку предметы буларак төрлелеге турында да яза.

Шулай итеп, без бу хезмәттә күптелле белем бирүнең юнәлешләренә, туган һәм чит телләрне өйрәнү зарурлыгына, туган һәм чит телләрне өйрәнүдә булган кайбер аермаларга тукталдык. Чыннан да, чит телне өйрәнү һәм өйрәтү процессында туган тел зур роль башкара. Чит телне өйрәнгән вакытта укучы, туган теленә таянып, чит тел белән туган телнең төп сыйфатларын үз эченә алган үзенчәлекле тел системасын булдыра. Туган тел ярдәмендә ул һәр адым саен чит телне яхшырак үзләштерүгә омтыла.

### Әдәбият

1. Каптерев П.Ф. Избранные педагогические сочинения. – М.: Педагогика, 1982. – 703 с.

2. Львов М.Р. Методика преподавания русского языка в начальных классах: учебное пособие для студентов учреждений высшего образования. – М.: Академия, 1979. – 461 с.

3. Рамзаева Т.Г. Русский язык 1 класс: книга для учителя. – М.: Дрофа, 2002. – 249 с.

# КАК ВЫРАСТИТЬ ЧИТАТЕЛЯ?

***Муфазалова З.Г.***
***МБОУ «Лицей №149 с татарским языком обучения»***
***zilushka@mail.ru***

***Аннотация***. В работе рассматривается ответы на вопросы “Как сделать чтение любимым и интересным занятием для ребенка? Какие шаги предпринять, чтобы книги стали помощниками и друзьями?”

***Ключевые слова:*** обучение, принцип опоры на родной язык, читательская грамотность.

Не секрет, что современные дети совсем перестали читать. Если ребёнку скучно, у него есть компьютерные игры или игровые приставки. Дети овладевают компьютером раньше, чем учатся читать, ориентируются в клавиатуре лучше, чем в оглавлении книги. Их литературный опыт ограничивается рассказами из "Азбуки" и хрестоматий, а впоследствии — попытками освоить произведения школьной программы в сокращенном варианте. Всё это ведёт к снижению словарного запаса детей и к снижению грамотности в целом.

Как пробудить интерес к чтению? Этой проблемой занимались и занимаются многие педагоги, но она по-прежнему актуальна.

Чтобы добиться положительного результата в решении данной проблемы, необходима система. А в эту систему должны входить все сферы деятельности учителя:

- учебный процесс на уроке
- внеклассная работа
- работа с родителями.

**Роль семьи** - в решении данной проблемы неоспорима и велика, ведь прививать любовь к книгам нужно начинать ещё в самом раннем детстве. Как только ребёнок научился сидеть, нужно знакомить его с первыми книгами. Это яркие книжки-игрушки, часто со звуковым сопровождением. Такая книжка привлекает внимание ребенка, и уже с младенческого возраста закладывается интерес к настоящей книге. Далее ребёнок взрослеет, вместе с ним взрослеют книги, в них иллюстрации сведены к минимуму, ребёнок видит «только авторское слово».

Давно доказанным фактом является стремление детей наследовать привычки своих родителей, поэтому недостаточно рассказывать своему ребенку о пользе чтения, нужно еще подавать наглядный пример. Увлечение чтением родных спровоцирует ответную реакцию, и ребёнок тоже сможет полюбить читать.

**Занятия литературой** желательно сделать регулярными и систематичными. В доме должна быть детская библиотека, где обязательно будут книги на темы, которые интересуют детей. Желательно, самого ребенка привлекать к выбору книг. Возможность выбора литературы дает неплохой результат. Самое главное, нужно стараться создать такую атмосферу, в которой общение с книгой у ребёнка вызывало бы только положительные эмоции.

Большая роль в пробуждении любви к художественному слову принадлежит **урокам чтения** в школе.

В процессе чтения можно условно выделить две стороны: техническую и смысловую. Недостаточно развитая техническая сторона речи ведёт к снижению осмысленности чтения, а это, в свою очередь, приводит к снижению интереса к чтению. Для развития техники чтения разработано много разных упражнений, которые используют в своей работе многие учителя. Некоторые из них представлены на слайде.

Но как говорил К. Д. Ушинский «Читать — это ещё ничего не значит: что читать и как понимать читаемое - вот в чём главное дело». «ЧТО ЧИТАТЬ» определено образовательными программами, а вот «КАК ПОНИМАТЬ ЧИТАЕМОЕ» - этот вопрос остаётся до сих пор актуальным.

Для того, чтобы дети научились понимать прочитанное, учителю нужно использовать такие приёмы и методы, которые бы разжигали пытливость ума и позволяли детям быть активными слушателями.

Наиболее эффективные приёмы, способствующие формированию у обучающихся интереса к чтению:.

- на уроке литературного чтения использую **приём «Диалог с автором»,** к сожалению, недостаточно освоенный современной школой. Это естественная беседа с автором через текст, в ходе которой дети учатся находить прямые и скрытые авторские вопросы, задавать свои.

- развитие умения анализировать художественные тексты, находить все виды информации: фактуальную, концептуальную и подтекстовую способствует приём «Цветик-семицветик», основанный на таксономии учебных целей американского педагога и психолога Б. Блума. Итак, 7 лепестков - 7 типов вопросов. Дети выбирают лепесток, на котором есть начало вопроса, продолжая его, они формулируют вопрос и задают своим одноклассникам.

*1. Простые вопросы* – отвечая на которые, нужно назвать какие-то факты, вспомнить и воспроизвести определенную информацию.

*2. Уточняющие вопросы:* их целью является предоставление человеку возможностей для обратной связи относительно того, что он только что сказал.

*3. Интерпретационные (объясняющие) вопросы:* обычно начинаются со слова «Почему?».

*4. Творческие вопросы:* если в вопросе есть частица «бы», элементы условности, предположения, прогноза.

*5. Оценочные вопросы* направлены на выяснение критериев оценки тех или иных событий, явлений, фактов.

*6. Практические вопросы* направлены на установление взаимосвязи между теорией и практикой.

7. *Рефлексивные вопросы,* которые помогают выразить детям свои чувства и эмоции.

Таким образом, на уроках создаются такие ситуации, когда ученик должен постоянно думать, чувствовать и делать выводы. Собственная мысль, рождённая в процессе чтения, радует и вдохновляет детей.

Любое действие, которое диктуется сверху, и в котором у человека нет личной заинтересованности, выполняется неохотно и, как правило, даёт мало пользы. Поэтому считаю важным обеспечить ученику право свободного выбора.

Чтение - это нелёгкий и порой мучительный процесс, отнимающий у детей много сил и времени. Задача учителя — найти привлекательные моменты в чтении, преподнести их таким образом, чтобы они выполнялись с интересом и желанием, тогда проблема с нежеланием детей читать исчезнет сама собой. Главное, чтобы такая работа велась целенаправленно и систематически на уроках и во внеурочное время. Я считаю, что у меня это получилось, об этом говорят результаты опроса моих учеников.

Роль учителя на уроках литературного чтения имеет решающее значение, порой определяющее судьбу чтения на протяжении всей жизни человека, ведь влюблённый сам в литературу, учитель влюбляет в неё и своих учеников.

**Литература**

1.Засорина Л.Н. Развивающее чтение: книга для учителя. – СП-б.: Взлет, 1996.

2.Светловская Н.Н. Обучение детей чтению. М.: Русский язык, 2001.

3.Светловская Н.Н. Основы науки о читателе. Теория формирования типа правильной читательской деятельности. - М.: Грамота, 1993.

# ЗАМАНЧА ШАРТЛАРДА ТУГАН ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮ

***Муфахарова Г.Ә.***
***Саба район, Эзмә урта мәктәбе***
**hadieva-gul@mail.ru**

***Аннотация.*** В статье рассматриваются современные педагогические технологии, широко используемые в области языкового образования, в том числе при обучении татарскому языку. Среди них наиболее привлекательными считаются информационно- коммуникационные, дистанционные, игровые технологии. Использование их способствует развитию коммуникативной компетенции учеников, которая понимается как способность порождать высказывание на изучаемом языке.

***Ключевые слова:*** языковое образование, татарский язык, интерактивная доска, современные технологии, инфографика, ZipGrade, LearningApps.org, QR

«...Заман һәм мәдәният алга үскәнчә һәм икенче төрле итеп әйткәндә, ихтыяҗ һәм мәҗбүрилек кебек нәрсәләр мәҗбүр иткәнчә, укыту рәвешләре төрлеләнер, монда исә акыл ияләре берләшәләрдер», – дип бик хаклы язган күренекле мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин. Чыннан да, җәмгыять үсешенә бәйле рәвештә, укыту процессы да һәрвакыт үсеш-үзгәреш кичерә.

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәрешләр сорый. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен , укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Педагогик эшчәнлекнең нигезе тәҗрибә булса, үсеш-үзгәрешне яңалыкка омтылу тәэмин итә.

Мин – укытучы. Ана теле һәм әдәбияты укытучысы. Минем һәр дәресем, һәр сүзем, һәр үткәргән чарам милләтемә, туган халкыма хезмәт итә. Мин укучыларымда халкыбызның данлы үткәненә, гореф-гадәтләренә хөрмәт, бүгенге һәм киләчәк көннәренә ышаныч, туган җиргә, туган телгә мәхәббәт тәрбиялим. Бүген үзгәреш җилләре искәндә, татар телебезгә каршы астыртын көрәш алып барылганда укучыларымда туган телебезгә карата горурлык хисләре уятырга тырышам.

Мәктәптә укучы күп фәннәр укый. Шулар арасында татар теле дә бар.Үз фәнеңне яратырга өйрәтү — иң авыры. Фәнем белән кызысындыру өчен, миңа һәрвакыт үсештә булырга кирәк.

Без XXI гасырда яшибез. Яңача фикерләүләр, яңа ачышлар, яңа стандартлар, яңа таләпләр заманында. Бу исә уку-укытуга куелган таләпләрне дә катлауландыра. Көн саен туып торган яңалыклардан артта калырга ярамый. Укытучы заман белән бергә атларга тиеш. Чөнки җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләр хәзерге заман укытучысына да яңа таләпләр куя.

Танылган педагог К.Д.Ушинскийның: “Укытучы һәрдаим укыганда гына укытучы булып кала”, –дигән сүзләре – минем тормыш фәлсәфәм. Әйе, хезмәт куймый гына укучыларда фәнеңә мәхәббәт уятып булмый.Үз алдыңа максат куеп, шуны тормышка ашыру өстендә эзлекле эш алып барганда гына моңа ирешеп була.

Шуңа күрә, бертуктаусыз эзләнәм, укыйм, яңалыклар белән танышам. Заманадан артта калмас өчен бөтен көчемне бирәм. Үземә һәм укучыларыма туры килгәннәрен, файдалы булганнарын сайлап алып кулланам.

Бүгенге авыл мәктәбе укучыларының да танып-белү дәрәҗәләре югары. Чөнки алар мәгълүмати технологияләр белән кечкенәдән таныш. Аларның кулларында кыйммәтле телефон яки башка төрле гаджет бар. Шулар ярдәмендә үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап таба беләләр. Мин дә дәресләрдә укучыларымның белем алуга кызыксынуларын, активлыкларын арттыру өчен инновацион технологияләрне, алдынгы методикаларны киң файдаланам. Укучы дәрестә алган белемне тормышның төрле очракларында файдалана белерлек булсын дим.

Безнең мәтәптә татар теле һәм әдәбияты кабинеты заманча җиһазландырылган. Мин үз дәресләремдә бик еш интерактив тактага мөрәҗәгать итәм, чөнки интерактив такта ярдәмендә булган материалны күрсәтү генә түгел, ә яңаны да ясарга була. Интерактив такта укучыларның мөстәкыйль эзләнүләрен, эшчәнлекләрен активлаштыруда зур урын алып тора. Һәр дәрестә татар телен өйрәтүнең алдынгы методикаларын куллану, дәреснең нәтиҗәлелеген арттыру мөмкинлеге бар.

Дәресләрдә онлайн инструментлар, чыганаклар ярдәмендә төзелгән биремнәр, алымнар куллану – укучыларны татар теленә өйрәтүдә кызыксындыру чарасы булып тора. Заманча мәгълүмати һәм компьютер технологияләре укучыларның өйрәнә торган предметны актив һәм иҗади үзләштерүен тәэмин итә, материалны сыйфат ягыннан югары дәрәҗәдә бирергә мөмкинлек тудыра. Аларны куллану- укыту процессын оештыруның принципиаль яңа мөмкинлекләрен ача.

Онлайн инструментлар, цифрлы белем бирү чыганаклары дәрескә матур презентация ясарга, инфографика формасындагы материалны креатив уйлап табарга ярдәм итә.

“Сүзләр болыты” тестны визуальләштерүнең бер ысулы. Интернетта сүзләрдән “болыт” генерацияләү буенча сервислар шактый. Андый сервислар танышканнан соң, мин “сүзләр болыты” ның тагын бер, интернет кирәксез нәрсә генә түгел, ә укытучының дәрестә искиткеч ярдәмче икәнен аңладым. Мондый гадәти булмаган формада тәкъдим ителә торган биремнәр балаларны уку эшчәнлегенә бик яхшы этәрә. Бигрәк тә төркемнәрдә, парларда эш уңышы килеп чыга. “Сүзләр болыты”н куллану дәресне продуктив итәргә мөмкинлек бирә, биремнәрне үтәү кызыклырак, ә уртак эш бер мизгелдә үк башкарыла.

Бу стандарт булмаган алымны дәреснең теләсә кайсы этабында кулланырга мөмкин. Уку материалын визуальләштерү өчен “сүзләр болыты” н, мәсәлән, кагыйдәләр итеп тә кулланып була. Мондый кагыйдә балаларның игътибарын дәрестән соң берничә көн рәттән җәлеп итәчәк.

Соңгы вакытта QR – кодлар популярлаша бара. Каралы- аклы шакмакларны бөтен җирдә урнаштыралар: визиткаларда билетларда, журналларда, һәйкәлләрдә, төрле товарларда һ.б. Бүгенге көндә мондый кодларны очрату гадәти хәлгә әверелде. Кыска булган текстларны, Интернет

челтәрендәге сылтамаларны һ.б. мәгълүматны төрле онлайн генераторларда бик тиз һәм җиңел генә кодлаштырып, дәреснең төрле этапларында кулланырга була. Мәгълүматны болай тәкъдим итү- күләмле, катлаулы материалны тиз һәм аңлаешлы итеп кабул итәргә ярдәм итә.

Инфографика - мәгълүматны график рәвештә визуальләштереп күрсәтү. Аның максаты укучыга катлаулы материалны гадиләштереп бирү. Татарча инфографика материалларын "Гыйлем" интернет сайтында (https://giylem.tatar/) табарга, яки Piktochart.com (https://piktochart.com/) , Canva.com (https://www.canva.com/ru_ru/) кебек интернет - сервислар ярдәмендә үзең төзергә дә була. 90% мәгълүматны баш миенең визуаль формасында кабул итүен исәпкә алсак, инфографика, һичшиксез, эффектив ысул булып санала.

ZipGrade –мобиль приложениесе, тиз генә тестларны тикшерү мөмкинлеген бирә, оффлайн эшли. 20, 50, 100 сораулык бланклары бар, шул бланкларны чыгартып, тестларга җавапларны билгелисе, өскә ФИО язасы, приложениегә дөрес җавапларны кертәсе, һәм эшләрне җыеп алгач, скайнировать итәсе. Нәтиҗәләрне % ларда күрсәтә.

Тест сорауларына җавап биреп бетерү белән, һәр укучы үз билгесен белә. Бу системаны ныгыту, кабатлау дәресләрендә куллану өчен отышлы. Чөнки укытучының эшләрне тикшерүгә вакыты сарыф ителмәячәк. Теманы үтүгә, яңа тема өстендә эшкә, үткәнне системалаштырырга вакыт күбрәк калачак. Бу, әлбәттә, укучыларның белем дәрәҗәсен үстерүгә уңай йогынты ясаячак.

Тестлар эшләү өчен бик уңайлы вариантны мин мультиурок сайтыннан таптым.Тестларны төзеп куясың. 1 яки берничә җаваплы итеп төзергә була. Ссылкасын балаларга җибәрәсең. Укучыларның тест нәтиҗәләре укытучының сайттагы шәхси битенә килә.

LearningApps.org программасы Швейцария, Германия университетлары белгечләренең гыйльми – тикшеренү проекты буларак барлыкка килә. Аның ярдәмендә дәрескә төрле күнегүләр эшләргә мөмкин. Мисал итеп түбәндәгеләрне китерергә була : викториналар , "Кем миллионер булырга тели ?" уены, хәрефләрдән сүзләр төзү, пазллар, хронологик линейка һ.б.

Балаларның белемнәрен бәяләүдә Plickers кушымтасының дә ярдәме бик зур. Ул берничә минут эчендә бөтен сыйныфның белемен тикшереп бәяләргә ярдәм итә, укучыларда да өстәмә кызыксыну уята. Ул рекламаларда, кибетләрдә еш очрый торган QR –кодын куллану ярдәмендә эшли. Plickers ноутбук белән бәйләнештә укытучы тарафыннан телефон яисә планшетта кулланыла. Телефон (планшет) камерасы ярдәмендә укытучы укучылар күтәргән QR –кодлы карточкаларны сканер аша үткәрә.

Әлеге карточкада номер һәм 4 инглиз хәрефе язылган. Номер укучының сыйныф журналындагы номерына туры килә. Ә инде җавап биргәндә, укучы бирелгән җавап вариантларының кайсын дөрес дип саный, шуңа туры килгән хәрефне күтәрә. Эшне төгәллэгэч, шунда ук тактада кемнең дөрес, кемнең ялгыш җавап биргәнен күрергә мөмкин .

Әлеге алымнар дәресләрне кызыклырак итә, укучыларны активлаштыра, танып-белү эшчәнлекләрен үстерә. Балаларны ял иттерү өчен дә бик отышлы.

Барлык технологияләрнең нигезен коммуникатив технология тәшкил итә дип саныйм мин. Чөнки кайсы гына технологияне куллансак та, аралашу аша гына без аларны гамәлгә ашыра алабыз.

Әлеге технологияләрне куллану, миңа дәресләремне кызыклы, балалар теләп белем алырлык итеп үткәрергә, югары нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә. Укучыларымның район, респубика күләмендә үткәрелгән иҗади бәйгеләрдә, олимпиадаларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә еш катнашуы һәм җиңүе, газета-журналларда язмалары басылуы – шуны раслый.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә: татар телен өйрәтүнең чиге юк, бары тик эзләнергә, яңалыкка омтылырга, заман сулышын тоеп, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк.

**Әдәбият**

1. Апатова Н.В. Информационные технологии в школьном образовании. - М., 1994.
2. Гайфуллин В. Педагогик технологил̈ер / В.Гайфуллин // Мәгариф, 2000. - № 4. – Б. 7-10
3.Харисов Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр/ Ф.Харисов, Ч.Харисова // Мәгариф. – Казан, 2002. - № 8. – Б.33-36
4. Шайхин А. Татар теле укытучысына Интернет ничек булыша? //Мәгариф. Татар теле, 2016. – № 4. – 40-42 б.

# БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕН ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП УКЫТУ

***Муфахарова Л. В.***
***ТР Мамадыш муниципаль районы «Җөри урта гомуми белем мәктәбе»***
***liliya-muf@mail.ru***

***Аннотация.*** В работе рассматривается вопросы исполҗзования инновационных технологий при обучении младших школьников.

***Ключевые слова:*** родной язык, новые технологии, обучение, начальная школа.

Бүгенгесе көндә татар теле һәм әдәбиятын укыту күпкә катлауланды, чөнки хәтта башлангыч сыйныф укучылары да русча аралашалар, русча фикерлиләр. Шуңа да педагоглар балаларны татар теле фәне белән кызыксындыру, аларның игътибарын җәлеп итү һәм сыйфатлы белем бирү өчен инновацион технологияләр кулланып эшләргә тиеш. Шулай эшләгәндә генә балада укуга кызыксыну туа, уку материалын үзләштерү теләге арта, укучыларның иҗади сәләтен үстерүгә мөмкинлек туа. Бала эшне теләп башкарса гына ул аның исендә кала.

Кайбер укучыларның ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек укучыларда күреп истә калдыруы өстен чыга. Укучыларның яшь үзенчәлеген истә тотып мин фотосурәтләр, видеоматериаллар, тавыш язмалары һәм башка укыту материаллары кулланырга тырышам.

Шулай ук компьютер технологияләре белем бирүнең эчтәлеген, методларын, оештыру формаларын сыйфатлы итеп үзгәртә, укучыларның шәхси сәләтләрен, үзенчәлекләрен, танып белү сәләтен үстерүгә ярдәм итә. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Биремнәр матур, эстетик яктан зәвыклы бирелгәч һәр бала кызыксынып тыңлый, иптәшеннән калышмыйча җавап бирергә тырыша. Бигрәк тә компьютер яңа материалны аңлатканда һәм ныгытканда кулланырга уңай. Дәрес тә җанланып китә. Тикшерү диктантларын яки контроль күчереп язуларны тикшерергә уңайлы. Шулай ук кучыларның теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрен бәяләү, ялгышларын ачыклау, аларны анализлау һәм төзәтү юлларын билгеләү өчен компьютер аша тестлар бик уңайлы.

Башлангыч сыйныф укучылары уеннар аша бирелгән материалны да бик теләп кабул итәләр. Бу очракта үзләштерә торган материал җиңел ныгытыла һәм мавыктыргыч була, балаларның күзәтүчәнлеге арта, әхлак тәрбиясе, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләнә. Күрсәтмәлелек кулланырга да уңай. Сөйләмнәрендә кимчелекләр булган балалар да үзләрен иркен тота.

Проект эшләре дә уңышлы нәтиҗә бирә. “Туган ягым”, “Аквариумда”, “Чәчәкле алан”, “Театр куябыз” һ.б. проект эшләрен балалар бигрәк тә кызыксыну белән башкаралар. Проект эшләре аша курчак театры оештыру, экиятләрне сәхнәләштерү, төбәгебездәге истәлекле урыннарны, вакыйгаларны,

күренекле шәхесләрне яктырту балаларда  иҗади хыялны, уйлау сәләтен үстерә. Алар уку эшен җанландыра, төрләндерә, сөйләм телен үстерүгә уңай йогынты ясый.

Кайбер хикәяләрне рольләргә бүлеп уку  уңай нәтиҗәләр бирә. Балалар үзләрен хикәя геройлары итеп күзаллыйлар, хәтерләре үстерелә.

Проблемалы укыту технологиясен куллану да эзләнергә, төшенчәләрне аңларга, фикер аша үткәрергә, тема белән тирәнтен кызыксынырга этәргеч ясый. Укучылар нәтиҗә ясарга өйрәнә.

Дәресләремдә заманча технологияләрне куллану нәтиҗәсендә укучыларның иҗади эшчәнлеге артты: язган шигырьләребез, хикәяләребез вакытлы матбугатта бастырылып барыла, сөйләм телләре яхшы, сүзлек запаслары бай. Укыткан укучыларым район күләмендә татар теленнән үткәрелгән олимпиадаларда, республика күләмендәге иҗади-эзләнү конкурсларда призлы урыннар яулыйлар.

# СЕМАНТИКА И ФУНКЦИОНИРОВАНИЕ ГЛАГОЛОВ НАСТОЯЩЕГО ВРЕМЕНИ В ПАРЕМИЯХ РАЗНОСТРУКТУРНЫХ ЯЗЫКОВ

***Мухарлямова Л.Р.***
***Казанский федеральный университет***
***mukharlyamova@mail.ru***

***Аннотация.*** Выражение одновременности по отношению к грамматической точке отсчета понимается как значение настоящего времени. Помимо основной функции выражения действия, совпадающего с моментом речи, форма настоящего времени в сопоставляемых языках также способна широко применяться и для выражения прошедшего и будущего времени, т.е. наблюдается относительное или релятивное употребление временных форм.

***Ключевые слова:*** паремия, разноструктурные языки, настоящее время, глагольное время, грамматическое время.

Выражение одновременности по отношению к грамматической точке отсчета понимается как значение настоящего времени.

Форма настоящего времени глагола обладает способностью выражать действия разной временной продолжительности вплоть до процессов, осуществляющихся постоянно.

В татарском и английском языках настоящее время может выражать и будущее действие. Это характерно для описания установленного распорядка или запланированных действий. Такое употребление временных форм называется относительными или релятивными. Данное явление наблюдается в разноструктурных татарском и английском языках: *Ләйсән суын җиде ел сакласаң, энҗегә әверелә, имеш. Җил җилләми, томан* ***ачылмый.*** *After a storm* ***comes*** *the calm.*

В татарском языке настоящее конкретное также обозначает действие, совпадающее с моментом речи: *Күкәй салмас тавык, кон элгәре* ***кытаклый****. Кем* ***эшләми,*** *шул* ***ашамый.*** *Вакыт комны ташка, ташны комга* ***әйләндерә****. Араларыннан җил дә* ***үтми****.*

В английском языке этому значению соответствует настоящее длительное время (Present Continuous): *If you happen to see a spider on Halloween it is the spirit of a dead loved one* ***is watching*** *over you. Do not cut the bough you* ***are standing****. He that has a great nose thinks everybody* ***is speaking*** *of it.*

Настоящее расширенное обозначает действия, представляемые как привычные, повторяющиеся, постоянные. При этом для реализации данного значения необходим контекст, который передавал бы оттенок постоянства, лексические показатели времени. В английском языке это значение передает основное настоящее время (Present Indefinite). Указание на повторяемость действия возникает при наличии лексических показателей времени, придаточных времени: *All things* ***are*** *difficult before they* ***are*** *easy. Mare's tails and mackerel scales* ***make*** *tall ships take in their sails. A clear conscience* ***laughs*** *at false accusations.*

Основным значением перфектного времени является результативность:

*To sell the bear's skin before one* ***has caught*** *the bear. You* ***have made*** *your bed and you must catch none. He knows best what good is that* ***has endured*** *evil. Wine* ***has drowned*** *more men than the sea.*

В татарском языке данной форме времени соответствует прошедшее время.

В то же время к настоящему расширенному времени в татарском и английском языках, как отмечает В.Н. Хисамова, относится настоящее качественное. Качественная характеристика обозначает действие или состояние, приписываемое данному субъекту как его свойство или качество; «в данном случае действие не мыслится как соотнесенное с каким-то определенным моментом речи, а представляется неким постоянным признаком: это профессиональная деятельность, какая-либо черта характера, поведение, умение, свойство» [Хисамова 2004: 23]. Настоящее качественное время может выражать обобщенное действие, близкое к вневременному. Данное значение возникает при формулировании правил, непреложных истин, часто наблюдается в паремиях: *Күз яше җиргә тамса да* ***кипми.*** *Алма агачыннан ерак* ***төшми.*** *Time and tide* ***wait*** *for no man.*

Таким образом, помимо основной функции выражения действия, совпадающего с моментом речи, форма настоящего времени в сопоставляемых языках также способна широко применяться и для выражения прошедшего и будущего времени, т.е. наблюдается относительное или релятивное употребление временных форм.

## Литература

1. Хисамова В. Н. Глагольная система татарского и английского языков: Сопоставительный анализ в аспекте изучения английского языка на базе родного (татарского) языка. – Казань: Изд-во Казан. гос. унив-та, 2004. – 250 с.

# НЕКОТОРЫЕ ВОПРОСЫ ЛИНГВОСТРАНОВЕДЧЕСКОГО АСПЕКТА В ОБУЧЕНИИ АНГЛИЙСКОМУ ЯЗЫКУ

***Насибуллова Г.Р.***
***Казанский федеральный университет***
**Guz1983@mail.ru**
***Шарифуллина Р.Р.***
***"Сатышевская средняя общеобразовательная школа Сабинского муниципального района Республики Татарстан им. Ш.З.Зиннурова"***
**Raniya-sharifullina@mail.ru**

***Аннотация.*** В данной работе исследуются особенности обучения лингвострановедческому аспекту на уроках английского языка. Актуальность работы обусловливается современными реалиями. Сведения о культуре государства необходимы в обучении языку. Лингвострановедческая методика содержит в себе данные факторы – ознакомление с государством с помощью языка и в ходе овладения им. В статье рассматриваются основные методы преподавания лингвострановедческого аспекта на уроках иностранного языка, выявляется роль и место лингвострановедческого материала в учебниках английского языка в средней школе.

***Ключевые слова:*** лингвострановедение, язык, обучение, аспект, метод

Лингвострановедение является одним из важных аспектов при обучении иностранному языку, и его значимость со временем только увеличивается. Обращение преподавателя к элементам лингвострановедения обуславливается рвением присоединить обучающихся к культуре исследуемого языка и сформировать условия для формирования интереса к его исследованию. Обучение иностранному языку требует ознакомление ученика с языковой и культурной сферой, который отсутствует в системе отечественного образования. Значимость лингвострановедения разъясняется еще и практической стороной, а непосредственно, попыткой выработать у обучающихся коммуникативных навыков, что и считается одной из основных целей в обучении иностранному языку.

Данная тема является в центре внимания в работах таких ученых и методистов, как Е.М. Верещагин, В.Г. Костомаров, Н.А. Карманова, Л.А. Садвокасова, Ю.Е. Коростелева, Е.В. Макарова и др.

Лингвострановедение появилось в отечественной методике обучения языкам в 70-х гг. XX века. Его основоположниками являются советские исследователи Е. М. Верещагин и В. Г. Костомаров, которые внедрили в практику преподавания иностранным языкам понятие «лингвострановедение». Они устанавливают его как «раздел культурологии, направленный на цели и проблемы исследования иностранного языка».

Е. Верещагин и В. Костомаров заявляют, что каждый уровень языка несет в себе культурологические сведения, именно поэтому, обладает лингвострановедческим планом. У исследующих иностранный язык с усвоением каждой лексемы создается ее лексическое понятие-ассоциация. В

период учебного процесса следует принимать во внимание то обстоятельство, что термин считается в то же время и символом реалии и единицей языка. Таким образом, фоновый и безэквивалетный лексический состав все время комментируется педагогом во избежание неправильного осмысления лексемы [Борисенко: 83]. Кроме того, нужно выделить, что безэквивалентые фразы непереводимы, но значимость их разъясняется посредством толкования (К примеру, Twelfth Night либо Boxing Day) Р. К. Миньяр-Белоручев и О. Г. Оберемко исследовали соотношение языка и цивилизации, и место языка в цивилизации.

Лингвострановедение, по суждению Г. Томахина, является исключительно лингвистической дисциплиной, так как объектом данной дисциплины считаются языковые единицы и явления, отображающие характерные черты менталитета и национальной культуры, орудием постижения которой, в первую очередь, считается язык [Сомова: 109].

Таким образом, под лингвострановедением мы будем понимать определенный элемент методики обучения иностранного языка, который будет заниматься вопросами ознакомления школьников с новой культурой в ходе обучения.

Имеется большое число точек зрения об участии лингвострановедения в исследовании иностранных языков. В соответствии с Волковой Е.Г.: только целенаправленно выбранный языковой материал, отражающий культуру государства исследуемого языка способен быть объектом лингвострановедения [Волкова: 43]. Картошева В.Н. обращает особое внимание к культурологическому аспекту лингвострановедения. Посредством лингвострановедения обучающиеся знакомятся с культурой страны [Картошева: 52].

Фоновые знания носителей языка, их вербальное поведение в период коммуникативных действий считаются главным объектом лингвострановедения. Цель обучения культуры в рамках обучения иностранному языку – предоставление обучающемуся минимума фоновых познаний, которыми обладает носитель языка. К ним можно отнести: географические знания, также познания, сопряженные с общественной жизнью и бытом государства исследуемого языка.

Таким образом, под лингвострановедением необходимо понимать способ ознакомления обучаемого с современной реальностью страны изучаемого языка.

На базе лингвострановедческой концепции находится направление языкознания – лингвострановедение, один из подходов в преподавании иностранного языка, при исследовании которого совершается ознакомление обучающихся к проявлениям материальной и внутренней культуры народа-носителя языка, знакомство с менталитетом данного народа.

Очевидными плюсами лингвострановедческого аспекта при обучении английскому языку в школе считаются: увеличение культурного кругозора обучающихся; знакомство с традициями и этикетом государства исследуемого

языка; развитие чувства толерантности и уважения к иным нациям; формирование навыков ведения конструктивного разговора среди учеников посредством адекватного понимания лингвострановедческих фактов и применения их в ходе межкультурной коммуникации (то что считается основной целью лингвострановедения в целом); отслеживание взаимосвязи между стилем, характером и культурой его носителя; творческий, познавательный, проблематичный вид занятий [Дроздова: 21].

По суждению некоторых методистов применение на уроке лингвострановедческого аспекта хорошо влияет на обучающихся. С помощью лингвострановедения возможно увеличить познавательную динамичность обучающихся, содействует формированию коммуникативных способностей, приобщает к культуре государства исследуемого языка, дает возможность осуществить поставленные цели преподавателем [Бобкова: 19].

При обучении иностранному языку педагог обязан остановиться на лексике, если конкретнее на безэквивалентной и фоновой ее форме. При введении лексики, касающейся национально-культурной составляющей нужны уместные средства и способы для его освоения. К примеру, с целью приближения обучающихся к иноязычной реальности возможно применять аутентичную литературу.

В особенности значима роль безэквивалентной лексики в исследовании иностранных языков. В безэквивалентной лексике отображается самобытность и реалии государства. В случае если педагог станет знакомить с лингвострановедческим материалом, что основывается на реалиях государства, то повысится результативность самого образовательного хода. Большой уровень сформированности лексических навыков даст возможность стимулировать речевую работу, что обеспечит стимул к последующему исследованию языка. Следовательно, станут выполнены главные цели ФГОС и учебной дисциплины английского языка [Щербакова: 52].

Кроме лексики многочисленные ученые поднимают вопросы, которые касаются структурного содержания самого материала, и то, на сколько он соответствует ФГОС. По мнению Керимовой М.В.: «Лексические единицы и формы речи, не обладающие национальным колоритом, не имеющие самобытности не могут расцениваться как отнесенные к лингвострановедческому материалу» [Керимова: 92]. Примером может быть то, что ученые приводят невербальные формы коммуникации – мимику и жесты.

Выбирая тот либо другой лингвострановедческий материал следует отыскать в них отображение реальности государства и языка носителей. Материалы могут быть презентованы речевыми произведениями либо лексическими единицами, которые порождены в настоящих обстоятельствах и ситуациях коммуникации, то есть материалы обязаны являться аутентичными. При отборе лингвострановедческого материала педагог обязан принимать во внимание и актуальность социально-ролевого взаимодействия среди соучастников коммуникации. Конкретные изменения в общественно-политическом порядке могут оказать влияние на лексические единицы. Еще

одним аспектом при отборе лингвострановедческого материала можно назвать типичность. С целью достижения значительных итогов в образовательном процессе обязаны вводиться унифицированные либо стандартные речевые произведения, постоянно встречающиеся в ситуациях реального общения. Критерии отбора лингвострановедческого материала обязаны опираться в главную очередность на языковедческом подходе, но никак не страноведческом либо культурологическом. Страноведческую информацию обучающиеся обязаны извлекать для расширения уже существующих знаний, однако данное не обязано быть самоцелью при исследовании иностранного языка [Петрова: 112].

Еще одной проблемой при отборе лингвострановедческого материала считается стремление обучающихся к получению и осознанию данных об исследуемом языке. Под готовностью подразумевается желание обучающихся обретать познания не только лишь в период аудиторных, однако внеаудиторных уроков, умение самостоятельно совершенствовать существующие лингвистические навыки. Иными словами, это стремление обучающихся принимать лингвострановедческий материал как познавательную деятельность.

Основным элементом, который показывает уровень подготовленности обучающихся к получению знаний, является конечно же мотивация и языковая готовность. Слово готовность можно сравнить и со словом «коммуникативная компетенция», означающая обладание языковой компетенцией совместно с получением огромным числом внеязыковых данных, что значимо при коммуникации. Но познавательная готовность содействует раскрытию уровня сформированности языковых знаний [Шарафутдинов: 231].

Следовательно, лингвострановедческий аспект образования преобразуется из дополнительного элемента в единственный из базисных и приоритетных. В наше время все большую значимость обретают компоненты лингвострановедения.

Сущность обучения заключается в 3-х компонентах:

1) языкового материала и речевого;

2) основное содержание, включающее лингвострановедческий материал;

3) воздействие по зачислению, переработке и передаче данного содержания, реализуемые посредством упражнений.

Упражнения в данном случае можно назвать средствами, осуществляющими главные функции по передаче содержания [Коростелева, Макарова: 52]. Основными видами материалов можно назвать тексты для чтения и аудирования.

Видно, что эти темы направлены на понимание Родины. Такую ситуацию можно увидеть в материалах, приведенных в учебнике «Музыка» для 3 класса. Например, в учебнике представлены песни «Дияр мадхи» (Похвал Родины. Стихи Х. Рахмата, музыка Н. Норходжаева), «Ватаним завким» (Моя страна моя радость. Стихи П. Мумина, музыка Н. Норходжаева). Тема «Независимая Родина» дана для рисования в 3 классе программы «Изобразительное искусство». Стихотворение «Родина» (Дилшад Раджаб) представлено в теме «Чтение грамоты». По поводу этого стихотворения были заданы следующие вопросы: «Почему поэт говорит, что Узбекистан — самое красивое место в мире?», «Как ты думаешь, что нужно сделать, чтобы быть крылом Родины?»

Также дана сказка на тему «Родина», состоящая из 2-х частей, написанная Худойберди Тохтабоевым в образе птицы. По поводу сказки "Зачем король

выпустил птиц, привезенных из другой страны?" тоже был задан вопрос. Видно, что в тематику учебника входят чувство Родины, любовь к Родине, прославление Родины, пропаганда идеи ее защиты. Анализ учебников стал основой для нашего вывода.

В связи с этим возникает закономерный вопрос: может ли учитель музыки обучать учащихся песне «Дияр мадхи» (Похвал Родины) или «Ватаним завким» (Моя страна моя радость) на основе связи материалов изобразительного искусства, образования, читательской грамотности? Это возможно, конечно. Мы добились положительных результатов, сделав это в ходе нашего исследования. Мы постараемся выразить наши достижения на примере межпредметных методов, используемых при обучении учеников песне «Дияр Мадхи» (Похвал Родины).

Прежде чем приступить к изучению произведения, мы развесили на стенах классной комнаты изображения роскошных зданий, памятников истории, монументов, природных ландшафтов, расположенных в разных регионах Узбекистана. Мы также подготовили их электронные изображения и использовали их на уроке.

Мы разработали собственную методику прохождения уроков на основе межпредметной связи. В процессе обучения учащихся песне «Диёр мадхи» (Похвал Родины) мы сначала показывали портреты авторов, текст стихотворения и ноты на слайде. После этого мы дали краткий обзор творчества авторов и истории создания песни. После этого мы объяснили словарное значение слова «Дияр» - страна, родина и его смысл на примере «Славься Родина». Мы объяснили, что слово «мадх» означает хвалить, чествовать, аплодировать, поднять в небо, описывать. В качестве примера мы использовали стихи: «Все мелодии любимой песни богаты гармонией и музыкой, восхваляют дружбу и красоту». Мы объяснили, что в контексте этих стихов слово мадх (похвал) выполняет задачу соединения музыкальной идеи и художественного смысла песни с определенной целью.

Мы также рассказали о том, как поэт пытался сформировать художественные концепции в тексте песни. В первом абзаце выражено, что «Родина есть плод завтрашнего будущего», «Родина есть фактор, побуждающий к реализации намерений приобретения знаний и умений». На основе этого куплета песни композитор сформировал музыкальный текст. На основе этих нот поются следующие 3 куплета. Во втором абзаце выражено, что «любовь к родине придает силы в осуществлении мечты», «светлые чувства в сердце знакомы со светом и жаждой добрых дел». В третьем абзаце выражается «Мужество и престиж Родины». Выражается также беречь Родину как зеницу ока, оправдывать ее доверие. В четвертом абзаце вспоминается великий полководец своего времени Амир Темур, и уверенно утверждается, что «процветание страны, сияющей и цветущей», «держат знамя свободным и радостно шагают вперед, как храбрые мальчишки».

После понимания художественного текста песни мы вживую исполнили текст песни на кашгарском рубаби, который является одним из любимых

музыкальных инструментов узбекского народа. Хотя ученики внимательно слушали наше выступление, большинство из них не смогли составить четкого представления о мелодии в своих воспоминаниях. Это естественно, конечно. Услышав текст мелодии один раз, невозможно полностью сохранить его в памяти. Эта ситуация проявляется не только у детей раннего возраста, но и у взрослых, даже у людей, обладающих способностью легко вводить в память любой музыкальный текст. Зная это и с целью повышения внимания учащихся, мы повторяли нотный текст произведения на инструменте дутор и наблюдали, как они чувствуют движение и звучание мелодии. В результате мы стали свидетелями того, что у некоторых учеников было особое удовольствие, у некоторых были возбужденные мысли, у других были различные движения в теле, некоторые что-то пели, шевеля губами, а некоторые сидели, не обращая внимания. Отсюда мы узнали, что эффект от исполнения мелодии был неодинаков для всех учащихся. Это связано с тем, что полноценно сформировать образное понятие в памяти детей невозможно, проигрывая 1-2 раза мелодию песни на музыкальном инструменте. Принимая это во внимание, мы использовали акт хлопания ритмической структуры нот при отображении нот песни в электронной версии. Мы попросили играть на хлопушке, считая ноты, не издавая ни звука. Мы ожидали, что этот метод даст результат 3-4 раза. Наша гипотеза подтвердилась. Мы наблюдали положительные результаты учеников после третьего упражнения. Ритмическая устойчивость была практически одинаковой при выполнении упражнения в четвертый раз. После этого мы играли текст мелодии на инструменте кашгар рубоби, а дети играли ноты на хлопушке. Этот прием был интересен детям, но динамическая окраска имела другой оттенок. Этого условия мы планировали добиться на уровне потребности в процессе разучивания песни.

Итак, мы начали обучать этой песне ученикам. Прежде всего выразительно и образно читаем первую строфу стихотворения. Мы показали электронную версию текста, чтобы учащиеся могли читать его, глядя на него. Потому что мы много раз наблюдали на практике, что детям сложно петь, читая текст в учебнике, а легче читать электронную версию и одновременно следить за исполнением учителя.

В процессе обучения словам песни «Родина завтра, плод грядущий, знание, ремесло, хозяин» мы использовали картинки, приведенные в учебнике по грамотности чтения. В частности, мы показывали ученикам фотографии панорамы «Площади Независимости», зданий в районе Регистан г. Самарканда, Ляби-Ховуз, комплекс Арк в Бухаре. Рассказали им, что это красота нашей страны, что их строили образованные, знающие и умелые специалисты.

В процессе обучения словам «Мы обязательно будем, Намерения огромные, большие», а также в процессе обучения словам «Моя страна стабильна, моя страна почетна» мы использовали картинки и видео. В частности, мы показали фотографии зданий Национальной консерватории Узбекистана, Театра оперы и балета имени Алишера Навои, Бухарского государственного университета.

Мы показали видеоролики победителей летних Олимпийских игр в Рио-де-Жанейро по боксу Шахобиддина Зоирова, Хасанбоя Досматова и гордости Узбекистана Бахадыра Джалолова. В процессе разучивания аята «Дед Темур в сердце моем» мы разъяснили смысл поговорки Амира Темура «Сила в справедливости». Мы говорили о флаге Республики Узбекистан, обучая стиху «Держи флаг и будь свободен, мы с радостью пойдем вперед» и о том, что у других стран тоже есть свои флаги.

Таким образом, исполнение песни было обеспечено. Выразительность в пении, динамическое разнообразие, быстрота и исполнение ритмического ансамбля были достигнуты на необходимом уровне. Петь песню с удовольствием стало для учеников привычкой.

В процессе обучения учеников песне «Дияр Мадхи» мы провели первое пробное занятие, чтобы выяснить результаты использованных нами методов в плане м*ежпредметности.* Мы назвали тему урока «Выбери одну из картинок и напиши свое понимание». Мы подобрали картинки по теме. В частности, мы отобрали снимки панорамы «Площади Независимости» в Ташкенте, зданий комплекса Регистана в Самарканде, комплекса Лаби-Ховуза и Арка в Бухаре, Национальной консерватории Узбекистана, Театра оперы и балета имени Алишера Навои, здание Бухарского государственного университета. Мы пронумеровали каждую из них и повесили на стену. Вот несколько примеров отзывов учеников о выбранных ими картинках: «Площадь Независимости – наша родина.

Каждый год на этой площади проходят мероприятия ко Дню Независимости», «Площадь Независимости очень красивая. Когда я был с родителями там, то сказал отцу, что «когда выросту, я пройду этому площадью в военной форме». «Мой брат учится в консерватории. Играют в рубаб. Я намерен учиться в консерватории, как и мой брат», «В городе Самарканде будет музыкальный фестиваль. Он пройдет на площади Регистан. Приезжают музыканты из многих стран». «Мне нравится зона у бассейна Лаби-Хавуз. Я залез на статую осла Насриддина Афанди и сделал снимок. Я буду клоуном, как Эфенди». «Я был в Арк-музее. Я нарисовал трон, на котором сидел царь Бухары». Хотя ответы учеников кажутся простыми, но древние и современные здания, восхваляющие страну как бы побуждают их мечтать и надеяться, что в будущем они станут образованными и знающими людьми.

**Литература**

1. Мавлянова Р., Рахманкулова Н. Педагогика начального образования, инновации и интеграция. Методическое пособие на узбекском языке./. - Министерство Высшего и среднего специального образования Республики Узбекистан. - Ташкент. Издательство «Варис», 2013. – 240 с.

2. Рузиев Д. Основы концертного исполнительства (Учебник на узбекском языке). Бухарское издательство "Дурдона". 2022 год. - 404 страницы.

3. Рузиев Д. Музыкально-исполнительское мастерство Журнал "Педагогическое мастерство" Бухара 2019. Выпуск 6, стр. 260 – 263.

4. Раджабов Т. Воспитательное значение детских народных песен на занятиях музыкальной культуры //Европейский научный журнал. – 2021. – Т. 2. – №. 6. – С. 139-141.

# КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ “СҮНГӘН ЙОЛДЫЗЛАР” ДРАМАСЫНДА МИЛЛИ ЙОЛА, ГОРЕФ-ГАДӘТ, ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ БҮГЕНГЕ КӨНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ

***Сабирҗанова Р.Р.***
***Казан шәһәре Совет районы 72 нче мәктәп***
***ruzila79@yandex.ru***

***Аннотация.*** В этой работе рассматриваются фольклорные элементы и отражение традиций татарского народда в произведении К. Тинчурина “Угасшие звезды”.

***Ключевые слова***: фольклор, традиции, творчество К.Тинчурина, обычаи.

Эшемне Кәрим Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” драммасына багышлыйсым килә. Чөнки бу әсәрнең бүгенге көн белән дә уртак яклары күп.

Минем шушы әсәрдәге милли йола, гореф - гадәт һәм традицияләрне барлыйсым килә.

Максатым: Кәрим Тинчуринның "Сүнгән йолдызлар" драмасындагы татар халкының милли йола, гореф - гадәт, традицияләрен, фольклор элементларын табып, бүгенге көн белән чагыштыру.

Максатка ирешү өчен үз алдыма түбәндәге бурычларны куйдым:

1. әсәрне укып, халкыбызның милли йолаларын, гореф - гадәтләрен, традицияләрен барлау;
2. әбиләрдән сөйләтеп, китаплардан укып, татар халкының милли йолаларына анализ ясау;
3. драмадан татар халык авыз иҗаты элементларын табу;
4. "Сүнгән йолдызлар" әсәрен сәхнәдә карау.

Кәрим Тинчурин иҗатына мин күптән гашыйк. Күбрәк мин аны сәхнәдә күреп беләм. "Сүнгән йолдызлар" драмасын да карадым. Әсәр минем күңелемдә тирән эз калдырды. Андагы милли рух миңа да күчте.

Авторның 1923 елда язылган "Сүнгән йолдызлар" драмасына тукталам.

Беренчедән, ул, чын мәгънәсендә, милли әсәр. Икенчедән, мин аны үзем татар сәхнәсендә карап, бик күп уңай һәм тискәре кичерешләр алдым.

"Сүнгән йолдызлар" әсәре 1913 -1914 елгы тарихи вакыйгаларга нигезләнгән һәм кеше бәхете проблемасын чагылдыра.

Драма Исмәгыйльнең төш күрүе белән башланып китә. Төштә аждаһаның йолдызларны сүндерүе, Исмәгыйльнең, Сәрвәрнең, Надирның һәм башка күп егетләрнең йолдызлары сүнүе, күк йөзен караңгылык каплап алу күңелсез вакыйгаларны кисәтә. Һәм автор башта ук , фольклор үрнәге булган, төш юрауга мөрәҗәгать итә. Төшне Гөлнур әби юрый:

- Төшне һәрвакыт яхшыга юрарга кирәк. Төштә кан күрү, күз яше - кайгы, әгәр

аждаһаны болыт күтәреп алып китсә - хәерлегә, кара аждаһа - кабер, кемне ашый, шул үлә. Кызыл аждаһа - янгын, сары аждаһа - ачлык, яшел аждаһа - үләт, ди...

Төш юраулар бүгенге көндә дә бик актуаль. Мәсәлән, төштә мунча яки чи ит - кайгы, бура - үлем, көзге - ялган, тараканнар - бәйрәм, исерек кеше - яхшы хәбәр, кечкенә балалар - шатлык, сөенеч. Һәрбер кеше төшендә нәрсә генә күрсә дә, аны юрый башлый. Ләкин әби - бабалар сүзе буенча, төшне башта агымсуга сөйлиләр аннары гына кешегә. Гомумән, төшне кешегә сөйләмәскә кушалар. Чөнки кешеләр синең яхшы төшеңне дә начарга юрарга мөмкин. Элек әле махсус төш юраучылар да булган.

Әсәрдә дә бу төш драманың ахырына кадәр юралып барыла. Шулай ук драма халык җырлары, халык көйләре белән үрелгән. Монда да К. Тинчурин отышлы юл таба, ягъни фольклорга мөрәҗәгать итә. "Каз канаты", "Әтнә", "Уел", "Мәдинәкәй", "Әллүки" көйләре уңышлы кулланыла. Халык көйләре - безнең көннәрнең дә милли хәзинәсе. Өченче күренеш Гөлнур әбинең тавыклар кууы белән башланып китә. Бередә дә автор кечкенә генә милли гореф - гадәтне исеннән чыгармый.Тавык астыннан бөтен йомырканы да алып бетерергә ярамый, мая калдырырга кирәк. Ә, күкәй салмыйча,кыткылдап йөргән тавыкларны, салкын су белән коендырып, берәр караңгы җиргә ябып куйганнар. Гөлнур әби оныгы белән сөйләшүгә шуларны уңышлы гына кертеп җибәрә. Шулвакыт Фәхри әби күренә. Ә сәхнәдә ул ыштан балагының берсен керткән, берсен чыгарган. Татар халкының милли гореф - гадәтләре буенча, болай киенгән әбиләр яучы карчыклар булганнар. Фәхри әби Сәрвәрне Надирга яучылап йөри. Яучы әбиләр инде әкренләп онытылып бара. Ләкин К. Тинчурин безгә яучылауны төгәл итеп аңлатып калдыра. Алар кызның ризалыгын гына сорап калырга түгел, ә бирнәлекләр турында да сөйләшергә тиешләр. Һәм автор Фәхри әбинең сүзләре аша, милли йолалар буенча, кызлар егетләрне күреп, сөешеп кияүгә чыкмаганын раслый:

- Никах, балакай, үзе мәхәббәт тудыра. Барыбыз да кыз булдык. барыбыз да кияүгә чыкканда башта сөймәдек. Еладык. Никахтан соң күгәрченнәр шикелле тордык...

Бүген бу гореф - гадәт безгә бик кызык тоела. Хәзерге заман кешесе аны күз алдына да китерә алмый. Шулай да , кыз - егетләрне тормышлы итү максатыннан, шәһәрләрдә "Яучылау бюролары" эшләп килә. Алар инде бөтенләй икенче төрле эш итәләр.

Элек туйлар көз көне булган. Чөнки көзен мул уңыш җыела. Икенче пәрдә дә казлар турында сөйләшеп башлана. Гөлнур әби, салкыннар башланганчы ук, казлар суярга әзерләнә. Димәк, тиздән туй. Автор моны да кисәтергә онытмый. Ләкин әле казлар сую үзе бер милли йола. Өмә рәвешен ала. Кәрим Тинчурин безгә "Каз өмәсе"н, чын мәгънәсендә, нечкәлекләре белән күрсәтә:

Фатыйма. Гөлнур әби, ата - бабадан калган йоланы эшләмичә ярамый, диләр. Кичкә егетләр кертмичә моннан чыгу юк, диләр. Егетләр дә кертмәгәч, каз өмәсе буламыни?..

Кызларның егетләрне өйгә, каз канаты сатып, кара - каршы җырлашып, кертүе үзе бер бәйрәм, аулак өй рәвешен ала. Ә сәхнәдә бу күренеш бигрәк тә матур: кызлар, егетләр милли киемнәрдән, бөтен җирдә каз канатлары һәм барысы да татар халык җырлары җырлыйлар,татар халык биюләре бииләр.

Автор шулар арасына,фольклор үрнәге булган, әйтешүләрне дә уңышлы гына кертеп җибәрә:

- Сиңа, егет, кем кирәк?
- Кара кашлы кыз кирәк.
- Ни эшкә соң ул кирәк?
- Әнигә килен кирәк.
- Егет, сиңа ни кирәк?
- Миңа нечкә бил кирәк.
- Ни эшкә соң ул кирәк?
- Ансыз яна яшь йөрәк.

Бәйрәм милли уеннар, милли җырлар белән үрелеп бара. Парлы уен үрнәкләре, кара - каршы җырлашулар күрсәтелә. Нәкъ шул вакытта начар хәбәр белән Староста

һәм писарь керәләр. Кәрим Тинчурин, вакытын туры китереп, егетләрне армиягә (сугышка ) озату йоласын да күрсәтеп китә.

Хәзер дә егетләрне армиягә җырлашып озаталар. Бер көн алдан, йолага туры китереп, сөрән ( проводы) үткәрәләр. Ләкин чиккән яулыкларны инде күп кеше белми. Чиккән яулык вәгъдә билгесе дә түгел....

Кызлар егетләргә чиккән яулыклар биргәннәр. Бу аларның вәгъдә билгесе булган. Һәм егетләрне армиягә озатканда гына җырлана торган җырлар җырлыйлар:

Без китәбез бу илдән,
Аерылып нечкә билдән.
Безнең хәлне сорашырсыз
Кыйбладан искән җилдән.

Ләкин, шул вакыттан, автор төшкә яңадан мөрәҗәгать итә. Исмәгыйльнең төше юрала. Йолдызлар әкренләп сүнә башлый. Ә йолдыз дигәннәребез - Исмәгыйль, Сәрвәр, Надир һәм башка егетләр. Халкыбызның гореф - гадәте буенча, кеше үлгәч, корьән укыла һәм ясин чыгыла...

Аларның язмышлары да төш кебек начар бетә...

Кәрим Тинчуринның кайсы гына әсәренә карасак та, яңалык һәм миллилек... "Зәңгәр шәл" мелодрамасын алыйк. Бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән "Яулык җыю" күренеше үзенә генә хас җырлары, уеннары белән күрсәтелә. Яулык җыю әле дә онытылмаган. авыл җирләрендә үткәрелә. Элеккеге кебек сабантуйга бер көн кала һәм үзе дә бәйрәм рәвешен ала: егетләр иртә баштан бергә җыелышалар, алар арасында гармунчы да була, авыл буйлап җырлап әйләнәләр. Һәм һәр өйгә керәләр. Хуҗалар исә, я сөлге, я күлмәк, я яулык һәм йомыркалар бирәләр. Аларга рәхмәт әйтеп, "Ура!" кычкыралар. Бер йорт та читләтелеп үтелми.

Әсәрдә шулай ук абыстайларның ашка әзерләнүләре, ашка баруларына автор зур басым ясый. Садакалар алып, ашка йөрүләр хәзер дә күзәтелә.

Милли гореф – гадәтләр бүген дә сакланып калганмы?

Минемчә, Кәрим Тинчурин әсәргә исемне дә Исмәгыйльнең төшеннән алып куша. Һәм драманы, чын мәгънәсендә, милли итеп, бүгенге көнгә кадәр

китереп җиткерә. Биредә кулланылган фольклор элементлары бик уңышлы. Ә татар халкының милли йола, бәйрәмнәре безнең тарихыбызны күрсәтә.

Мәсәлән, егетләр армиягә киткәндә чиккән яулыклар бирү йоласы инде бетеп бара. Ә тавыкларның йомыркасын җыйганда мая калдыру гадәте авылларда әле дә бар. Төш юраулар да бүгенге көнгә килеп җиткән.

Бәйрәмнәрдә халык җырлары сирәк булса да җырлана әле. Яучы карчыклар да инде юк. Ләкин аларны яучы оешмалары алыштыра. Туйлар да икенче төрле үтә. Беренче урында халык җырлары түгел, тамадалар, алар оештырган уеннар... Каз өмәләре әле бетеп бетмәде. Кайбер районнарда, авылларда күзәтелә, ләкин эләккечә шаулап үтми инде...

Менә күпме тарих, милли йола, гореф - гадәт һәм традицияләрне үзенә туплаган бу әсәр. Кәрим Тинчурин "Сүнгән йолдызлар" драмасы белән генә дә үлемсез ул...

Ул - тарихчы.

Ул - фольклорчы.

Ул - язучы, драматург...

**Әдәбият**

1.Батулла Р., Камалиева В.Кәрим Тинчурин: истәлекләр, шигырьләр. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2003. -63 б.

2.Гилязов А., Литвин А. Приговор приведен в исполнение// Идель. – 1997. - №9.

3.Мәхмүтев Һ. Күпкырлы талант// Совет мәктәбе. -1987. - №6.

4.Тинчурин К. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2003.

5.Батулла Р. Хөрмәтле шәхесләр//Азат хатын. -1987. - №3.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ВИЗУАЛИЗАЦИЯ ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНУ

***Сабирова Р. А.***
***МБОУ «Шеморданский лицей «Рост» Сабинского муниципального района РТ"***
***rez-sabirova@yandex.ru***

***Аннотация.*** В материале работы подчеркивается, что представление наглядного материала современному ребенку в образовательном процессе - самый эффективный и удобный способ. Обосновывается целесообразность использования инфографики в образовательной деятельности. Для актуализации и закрепления лексико-грамматических навыков, для достижения предметных и метапредметных результатов предлагаются варианты заданий, инфограммы, мнемотаблицы.

***Ключевые слова*:** визуализация, инфографика, мнемотаблица, функциональные учебные действия, универсальные учебные действия.

XXI гасыр- фән гасыры, икътисадның һәр тармагында югары инновация һәм технологияләр белән эшләү гасыры. Бу уку-укыту, тәрбия процессына да кагыла. Укыту-тәрбия өлкәсендә моңа кадәр билгеле булмаган ысуллар,чаралар гамәлгә керә, таныш булган метод -алымнар үзгәреш кичерә, камилләшә .

Яңа буын федераль белем бирү стандартлары шартларында мәктәп алдында ныклы, тирән белемле, иҗади фикер йөртүче, рухи яктан бай, физик сәламәт, үз позициясендә нык торучы конкурент булырлык шәхес формалаштыру максаты тора. Бүген укытучы белемнәр җиткерүче булып кына кала алмый, киресенчә, ул баланы мөстәкыйль рәвештә белем алырга өйрәтергә тиеш. Әмма бүгенге заман баласына белем бирү процессында визуаль материал тәкъдим итү - иң эффектив һәм уңайлы ысул. Визуаль рәвештә тәкъдим ителгән мәгълүмат балаларга да, өлкәннәргә дә кызыклы. Шуңа күрә мин татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә визуальләштерү технологиясен кулланам.

Визуальләштерү технологиясе, ягъни уку мәгълүматын күз алдына китерү ысулы, белем бирүне активлаштыруның иң эффектив технологияләрнең берсе. Визуальләштерү технологиясе үз эченә берничә юнәлешне ала. Шуларның берсе - инфографика. Нәрсә соң ул инфографика? Инфографика - зур күләмдәге мәгълүматны туплау һәм аны укучы өчен кызыклырак һәм компакт формада тәкъдим итү.Икенче төрле әйтсәк, мәгълүмат һәм белем бирүнең график ысулы. Инфографика төрле формада: таблица, схема, мнемотаблица, график схема һәм башка формаларда бирелергә мөмкин.

Белем бирү мәгълүматны тапшыруга корыла, шуңа да мәгълүматны күрсәтүнең роле аеруча зур. Инфографикада өйрәнеләсе яки өйрәнелгән материалның төп эчтәлеге чагылдырылырга , катлаулы материалны да җиңел кабул итү мөмкинлеге булырга тиеш. Инфографика куллануның уңай яклары бик күп:

1)мәгълүматны тиз һәм җиңел кабул итү мөмкинлеге булу;

2)өйрәнелгән материалны хәтердә калдыру мөмкинлеге булу;

3) белем һәм тикшеренү нәтиҗәләре белән уртаклашу ысулы булуы;

4) текстны укымыйча һәм өстәмә материалларны өйрәнмичә дә теманы аңлау мөмкинлеге ;

5) тәнкыйди фикерләү сәләтен үстерү;

6) функциональ уку күнекмәләрен формалаштыру.

Инфографика белән ике төрле юнәлештә эш алып барыла:

1) укытучы үзе инфографика төзи һәм укучылар шушы инфографиканы укыйлар һәм анализлыйлар;

2)алган белемнәренә, бирелгән мәгълүматларга нигезләнеп, укучылар үзләре инфографика төзиләр.

Татар теле һәм әдәбият дәресләрендә укытучы һәм укучылар зур күләмдә мәгълүмат белән эш итәләр, аларны хәзерге укучыга текст рәвешендә өйрәнү бик авыр. Теоритик материалны җыйнак формада бирү бу проблеманы хәл итә ала. Орфография һәм пунктуация кагыйдәләрен яки язучы иҗатын һәм әдәби әсәрне өйрәнгәндә, инфографика технологиясен куллану укучыларда кызыксыну уятачак һәм иң пассив укучыны да җәлеп итәчәк. Инфографика рәвешендәге катлаулы материал укучы тарафыннан тиз һәм төгәл үзләштерелә, чөнки график мәгълүмат, күп галимнәр фикеренчә, текстка караганда җиңелрәк истә кала.

Инфографика белән эшләү методикасы күрсәтмә әсбап белән эшләү кебек ук. Укытучы тәкъдим иткән инфографиканы анализлаган вакытта, укучыларга төрле юнәлештәге биремнәр тәкъдим ителә. Мәсәлән, укучыларга түбәндәге инфографика тәкъдим ителә.




Әлеге инфографиканы иң беренче чиратта бәйләнешле сөйләм төзү максатыннан файдаланырга мөмкин. Һәм,әлбәттә инде грамматиканы өйрәнгәндә, төрле биремнәр бирелә.

«Бавырсак» рецепты инфографикасы буенча биремнәр:

1) Рецептны билгеле киләчәк заман хикәя фигыльләр кулланып, 3нче зат исеменнән язгыгыз.
2) Рецепттагы фигыльләрне 2нче зат күплек сан боерык фигыльләргә үзгәртеп язгыгыз.
3) Инфографикадан чама саннарын язып алыгыз.
4) Инфографикадан барлык алынма сүзләрне язып алыгыз
5) Микъдар саннары кулланып, текстны тулыландырыгыз, саннарны сүз белән язгыгыз:

Бавырсак пешерү өчен сезгә _____стакан су, ____стакан сөт, ____грамм эремчек, _____грамм он, ___аш кашыгы шикәр комы, ____чәй кашыгы тоз, ___күкәй һәм сыек май кирәк була.

Мондый биремнәр эшләү укучыларда зур кызыксыну уята, укучыларның иҗади фикерләү сәләтен дә үстерә. Мәсәлән, “Тамырдаш сүзләр “ темасын үткәндә түбәндәге инфографика буенча укучылар бәйләнешле сөйләм төзиләр.




Текст үрнәге:

Юлчы төрле илләр, җирләр гизде. Юлда барганда, маҗаралы хәлләргә очрады. Үзенә юлдаш та тапты. Күргәннәрен юллы дәфтәргә язып барды. Бик матур юльязма килеп чыкты. «Илһам» бәйгесенә җибәреп, 1нче урынны алды һәм Төркиягә юллама белән бүләкләнде.

Әдәбият дәресләрендә инфографиканы яңа дәрес материалын өйрәнгәндә дә, укучыларның белемнәрен бәяләү максатыннан да бик еш кулланам. Мәсәлән, Г.Тукай иҗатын өйрәнгәндә, “Кызыклы фактлар”, Дәрдемәнд иҗатын өйрәнгәндә, “Сагышлы, кайгылы, моңсу” инфографикасын укып, укучылар төрле биремнәр үтиләр.







Кызык фактлар” инфографикасы буенча биремнәр:

1) Шагыйрь биографиясендәге 5 кызыклы фактны бәйләнешле текст итеп языгыз.
2) Башка укучыларның аңлавын тикшерү өчен, бирелгән мәгълүмат буенча сораулар яки тест төзеп языгыз.
3) «Бу инфографикада нәрсә аеруча истә калды һәм ни өчен?»соравына җавап языгыз

Әдәбият дәресләрендә мнемотаблицалар куллану да бик отышлы. Алар бәйләнешле сөйләмне камилләштерүдә зур роль уйный. Язучыларның иҗатларын өйрәнгәндә, дәреснең төрле этапларында да бу алымны куллану

отышлы. Актуальләштерү этабында мнемотаблицалар куллану ярдәмендә укучының белемен тиз арада ачыкларга мөмкин. Рәсемнәргә карап, тиешле мәгълуматны уку укучыда үз-үзенә ышаныч тудыра һәм хәтерендә калдырырга да ярдәм итә. Чөнки кайбер бала өчен, бер тапкыр күрү, ун тапкыр ишетүгә караганда отышлырак. Мәсәлән, язучылар иҗатын үткәндә, түбәндәге мнемотаблицалар бирергә мөмкин.







Мнемотаблица төзүне өй эше итеп тә бирергә була. Укучы бу эшне башкарганда теманы гына үзләштереп калмый, ә инде эзләнү эше дә алып бара, шул ук вакытта текст, ягъни бәйләнешле сөйләм төзү күнекмәсен дә ныгыта.

Шулай итеп, визуализация технологиясе түбәндәге педагогик проблемаларны чишәргә мөмкинлек бирә:

- уку һәм танып белү эшчәнлеген активлаштыра;
- тәнкыйди һәм визуаль фикерләү сәләтен үстерә;
- белем һәм уку эшчәнлеген образлы күрсәтүне формалаштыра;
- визуаль грамоталылыкны һәм визуаль культураны арттыра;
-белем һәм күнекмәләрне тикшерерү мөмкинлеге бирә;
- функциональ грамоталыкны үстерә.

Визуализация технологиясе технологиясе шәхеснең ирекле үсеше өчен шартлар тудырып кына калмый, баланы мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә. Укучы дәрестә өйрәнелә торган материалның асылына төшенеп, тулысынча анализлый, нәтиҗәләр чыгара. Бу технологиянең нигезендә стандарт булмаган фикерләү, ирекле күзаллау, һәм иҗади эшләү ята. Бу акыл эшчәнлегенең гадидән катлаулыга таба үсешен тәэмин итәргә ярдәм итә. Г.Ибраһимов сүзләре белән әйтсәк, “Күп белдерүгә караганда, аз белдереп, эзләнү орлыгы салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү- мөгаллим бирә торган хезмәтләрнең иң кадерлесе , иң зурысыдыр”.

**Әдәбият**

1. Бидайбеков, Е.Ы. Уку-укыту процессында инфографика кулланунының мөмкинлекләре./ Е.Ы. Бидайбеков, А.А. Бекежанова // Информатика в школе. - 2019. -№ 6. - С. 62-64.

2. Глизбург, Вита Иммануиловна. Визуализация как средство формирования метапредметных знаний / В.И. Глизбург, И.Ф. Зыкова // Вестник Московского городского педагогического университета. Серия: "Педагогика и психология". - 2016. - № 3 (37) 2016. - С. 65-73.

3. Инфографика. https://artalto.com/articles/infographics_for_business /

4. https://semantica.in/blog/chto-takoe-infografika.html

# КОМПЕТЕНТНОСТНЫЙ ПОДХОД К ЗДОРОВЬЕФОРМИРУЮЩЕЙ ПАРАДИГМЕ НА УРОКАХ РОДНОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ

***Савдаханова Э. Б., Хасанова А. М.***
***ГБОУ «Казанская кадетская школа – интернат им. Героя Советского Союза Б.К.Кузнецова»,***
***emma4011@mail.ru, hasanova.alsina@bk.ru***
***Акчурина Л. Б.***
***МБОУ «Гимназия №3» г. Казани***
***lidiaa0604@mail.ru***

***Аннотация.*** Одной из важнейших задач обучения татарскому языку наряду с формированием черт вторичной языковой личности, делающих учащихся эффективными участниками межкультурной коммуникации и формированием духовно-нравственной личности является здоровье-обеспечение учащихся и педагогического коллектива, формирование основ культуры здоровья.

***Ключевые слова:*** компетентность педагога, здоровьесберегающие технологии, парадигма, энергизаторы, самодисциплина, активизация коммуникативной деятельности, проблемы человечества и судьбы планеты.

Здоровье – великое благо, делающее человека свободным, устремленным в будущее и готовым осуществить самые смелые замыслы. Для того, чтобы творить, созидать, человеку необходимо здоровье.[7]

Человек является главным звеном решения всех проблем человечества и судьбы планеты. Людей необходимо учить здоровью и этике отношений с природой с раннего детства и в течение всей жизни. Рассматривание природы как мира, в котором ребенок рождается, живет и познает окружающую действительность, а так же самого себя, не только облегчает воспитательную работу с детьми, но и делает её богаче, многограннее, содержательнее.

Компетентность педагога в вопросах здоровья – важная составляющая часть его профессиональной культуры, требующая постоянного пополнения психолого- медико-педагогических знаний по вопросам рациональной организации учебно-воспитательного процесса, введения профилактических программ и здоровьесберегающих технологий.[8]

Задача учителя помочь ученику преодолеть усталость, уныние, неудовлетворённость. У учащихся развита способность улавливать эмоциональный настрой учителя, поэтому с первых минут урока, с приветствия нужно создать обстановку доброжелательности, положительный эмоциональный настрой. Для этого на уроках использую простейшие упражнения для глаз, благоприятно влияющие при неврозах, внутричерепном

---

[7] . Добротворская С.Г. Здоровье в системе ценностных ориентаций старшеклассников и студентов. Здоровьесберегающее обучение и воспитание – сборник научных статей. Под. ред. В.И.Андреева – Казань: Центр инновационных технологий, 2000. – 267 с.

[8] Ф.Харисов Здоровье – ресурс развития образования., «Магариф», №10, 2010. стр.5.

давлении; физминутки, упражнения – энергизаторы (это короткие упражнения, либо подготавливающие класс, группу к деятельности в начале урока, либо восстанавливающие энергию класс и каждого ученика в процессе урока), точечный массаж, который активно воздействует на весь организм.

В сложившейся системе образования создаются условия для организации труда и отдыха учащихся, воспитывается у ребят сознательное отношение к охране своего здоровья. Формированию основ здорового образа жизни способствуют уроки литературы, когда речь заходит о творчестве поэтов и писателей, занимающихся активными видами спорта. На их примере доказывается полезность и необходимость ведения активного образа жизни. Поэзия поэта-героя Мусы Джалиля знакома всем, но не каждому известно, что Джалиль был атлетически сложен, хотя и не высок ростом, физически крепок и вынослив, обладал силой, ловкостью и крепким здоровьем. Любил движение, езду верхом, плавание, пешие прогулки и физические упражнения. Находясь в невыносимых условиях, обладая завидной физической силой, Джалиль написал столько, сколько хватило бы на Союз писателей республики. Продолжить ряд писателей и поэтов – физкультурников можно и далее. Это Абдулла Алиш, Фатих Карим, Гадель Кутуй и другие. Не надо думать, что знакомство с биографиями великих писателей сводится только их физкультурно–спортивной жизни. Школьники узнают все, что нужно для понимания изучаемого произведения и личности автора.

Мы, учителя литературы, должны заботиться о том, что наши уроки были интересными, разнообразными по методам и приемам обучения, насыщенными небольшими стихотворениями и загадками. Особую роль при охране здоровья в среднем звене играют физкультминутки. Их цель – поднять работоспособность, настроение, снять утомление. Тексты, звучащие на физкультминутке, должны обязательно сопровождаться движением рук, ног, головы, туловища.[9]
Жизненно важной необходимостью стало проведение зарядки для глаз на уроках. Я предлагаю несколько текстов этой зарядки на татарском языке, в стихотворной форме.

**Керпе бакчага кергән,**
**Керпе алмалар күргән.**
**Сыртында кызыл алма,**
**Керпекәй арма-талма,**
**Ял ит бераз тын гына,**
**Көч өстәлер сыныңа.**

Необходимо знать и особенности внимания, устойчивость которого у школьника невелика и во многом зависит от условий организации обучения. Так как он может заниматься непрерывно одной и той же деятельностью не более 10-12 минут. Если смены деятельности не происходит, работоспособность снижается, что проявляется в рассеянности внимания и

[9] «Наука и школа», №11,2004 стр. 46. И. Сюткина. О спорте на уроках русского языка.

двигательном беспокойстве (ребенок вертится, ложится на парту). Это первые признаки утомления, которые можно устранить за счет нервно- психического, эмоционального и волевого напряжения. Например, изменить характер учебных заданий - ввести игру, которая является наиболее естественным способом воздействия на ребенка. Она обучает, развивает, воспитывает, социализирует, развлекает, является уникальным средством формирования духовных ценностей и раскрытия творческого потенциала личности ребенка.

Игровую технологию использую при освоении понятий, изучении темы, объяснении нового материала и его закреплении, при обучении устным видам речевой деятельности. Задачи игровой технологии: активизация коммуникативной деятельности учащихся; правильное распределение ролей между детьми, поскольку они имеют разный уровень речевой подготовки; создание ситуации взаимопомощи, активного устно-речевого общения, эмоциональное состояние учащихся, что может повлиять на качество усвоения материала и результат игры.

Продолжительность физкультпаузы на уроке составляет 1-3 минуты. Она может быть естественным структурным элементом урока. Рекомендую подбирать физкультминутки с учетом изучаемой темы, под музыку. Учитывая психические особенности школьников, физкультминутка должна быть интересной, «заразительной», чтобы ребенок с удовольствием выполнял его. Предлагаю использовать рифмовки, песни с движениями, коротенькие стишки о животных, природе, о детях, которые легко выучиваются и делают физкультминутки увлекательными и полезными.

Много игровых моментов, связанных физкультурой и спортом, можно ввести в урок, используя иллюстрации к художественным произведениям. Такой вид работы пробуждает к творчеству, а самое главное - создается мотивация для охраны своего здоровья.

Задачи игровой технологии: активизация коммуникативной деятельности учащихся; правильное распределение ролей между детьми, поскольку они имеют разный уровень речевой подготовки; создание ситуации взаимопомощи, активного устно-речевого общения, эмоциональное состояние учащихся, что может повлиять на качество усвоения материала и результат игры.

Учитель не может работать творчески в одиночку. Необходимо содружество, как с учениками, так и с коллегами, преподающими другие предметы. Слово «спорт» в середине века означало приятное времяпровождение, т.е. беседы, шутки, развлечения. И только в начале 19 века оно стало означать соревнование в силе, быстроте, ловкости, выносливости. Иногда работу учеников можно сравнить со спортивными соревнованиями, где ребята показывают свою выносливость. Уроки тематически связанные со спортом, физкультурой, послужат кому-то поводом для выбора профессии телевизионного комментатора или спортивного журналиста. Как знать…( например, Фанис Камал - диктор, ведущий программу «Новости» («Татарстан хәбәрләре» ГТРК «Татарстан»). Я надеюсь, что мои уроки и мероприятия, беседы помогут ребятам сориентироваться в нынешнем сложном и жестоком мире, не попасть в

зависимость от вредных привычек. На уроке татарского языка, посвященном физкультуре и спорту, пишутся словарные диктанты, подбирается тематическая лексика, проводится работа по развитию речи – в целом, идет активная подготовка к созданию сочинения в 5 класса по картине Лотфуллы Фаттахова «Сабантуй»

Как известно, образ жизни формируется в процессе воспитания и образования (самообразования). Важно ребенка приучить к самоконтролю и самодисциплине с раннего детства. Желательно, чтобы была преобретена правильная точка зрения на здоровье.[10]

На любом этапе обучения полезно использовать техники релаксации. Часто дети приходят на урок татарского языка после физкультуры, или контрольной работы по другому предмету в чрезмерно возбужденном состоянии. В таких случаях проводится дыхательная гимнастика с установками на изучаемом языке. Воздух обогащает кровь кислородом, помогает урегулировать процессы возбуждения и торможения в центральной нервной системе. Такие упражнения дают возможность учителю расслабить учеников и в то же время погрузить их в иноязычную среду.

Работоспособность обучающихся на разных этапах урока различна, поэтому при подготовке к урокам необходимо продумывать способы снятия напряжения, виды смены деятельности. Еще Сократ говорил: «Запоминается то, что тренируется». В результате многократного повторения, материал становится более доступным, узнаваемым, и уже не вызывающим чувство страха. Это значит, что на урок обучающийся идет спокойно, даже в том случае, если урок особой радости не вызывает, стрессовая ситуация не возникает.

Стремление подростков к полному выявлению и развитию своих личных возможностей связано с самопознанием, с осознанием своей значимости и индивидуальности. На этой основе я стараюсь воспитывать ответственное отношение к самому себе и окружающему миру. Приобщение школьников к проблеме сохранения своего здоровья это, прежде всего, процесс социализации личности, это создание высокого уровня душевного комфорта, который закладывается с детства и на всю жизнь.

Ребенок должен постоянно ощущать себя счастливым, помогите ему в этом. Каждый урок должен оставлять в душе ребенка только положительные эмоции. Дети должны испытывать ощущение комфорта, защищенности и, безусловно, интерес к вашему уроку. Этому не научит не один учебник. Это осваивается самостоятельно. Это наш самостоятельный путь к мастерству. Он непрост, но наполняет смыслом жизнь педагога.

---

[10] Добротворская С.Г. Здоровье в системе ценностных ориентаций старшеклассников и студентов. Здоровьесберегающее обучение и воспитание – сборник научных статей. Под. ред. В.И.Андреева – Казань: Центр инновационных технологий, 2000. – 267 с.

**Литература**

1. Добротворская С.Г. Здоровье в системе ценностных ориентаций старшеклассников и студентов. Здоровьесберегающее обучение и воспитание . – Казань: Центр инновационных технологий, 2000. – 267 с.

2. Организация здоровьеобеспечивающей среды в обучении татарскому языку // Наука и школа. - 2006.- №1, С.48.

3. Уразаева Л. Здоровьесберегающие технологии в преподавании физики // Магариф. – 2011.- №8. С. 82

4. Сюткина И. О спорте на уроках русского языка//Наука и школа, 2004.- №11, С. 46.

5. Ахметшина Г. Здоровье – категория экологическая //Наука и школа.- 2003.- № 9.- С.65

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКЫТУНЫҢ АКТИВ МЕТОДЛАРЫН КУЛЛАНУ

***Садриева Э. И.***
***МБОУ «Школа №167»***
**Sadrieva.75@mail.ru**

***Аннотация:*** в данной статье рассматриваются вопросы внедрения новых методов обучения в образовательный процесс. Особенно актуален данный вопрос при преподавании языков. В статье показан опыт использования современных методов преподавания на уроках татарского языка и литературы.

***Ключевые слова:*** педагогические технологии, активные формы преподавания, межпредметные связи.

Соңгы елларда ил һәм республика күләмендә инновацион технологияләр, кызыклы проектлар уйлап табыла һәм тормышка ашырыла. Җәмгыятьтә барган зур үзгәрешләр тормышның барлык тармакларына, шул исәптән, мәгариф өлкәсенә дә үтеп кереп, уку-укыту процессында белем һәм тәрбия бирүдә зур мөмкинлекләр ачу белән бергә, яңа максат һәм бурычларны хәл итүне дә таләп итә. Бүгенге көндә белем һәм тәрбия бирү процессының төп бурычы булып, укучыларга әзер белем биреп кенә калмыйча, ә алган белем-күнекмәләрне тормышта гамәли куллана белергә өйрәтү, заман таләпләренә җавап бирә алырлык, конкурентлыкка сәләтле шәхес тәрбияләү тора. Алга куелган бурычларны хәл итүдә татар теле һәм әдәбияты укытучысының, дәресләрне традицион формада оештырып кына калмыйча, укыту процессына яңалыклар кертүе, яңа метод һәм алымнар, яңа технологияләрне, алдынгы эш тәҗрибәсен өйрәнүе һәм белем бирүдә алардан дөрес, урынлы куллануы, дәресләрне кызыклы итеп оештыруы, укытучының үз белемен күтәрү өстендә күп эшләве, бүгенге көн укучысының психологик һәм физиологик үзенчәлекләрен, ихтыяҗларын, күңел дөньясын яхшы аңлап эш итүе актуаль проблемаларның берсе булып кала.

Дәресләрне заманча итеп оештыруда педагогик технологияләрнең, предметара бәйләнешләрне исәпкә алып укытуның, бәйләнешле сөйләм үстерү һәм укытуның башка актив формаларының, метод һәм ысулларның әһәмияте зур.

Эш тәҗрибәсеннән чыгып, әлеге мәсьәләләрнең кайберләренә тукталып китик. Галимнәр фикеренчә, шәхесне төрле яклап үстерү, иҗади фикерле белүне, акыл эшчәнлеге, мөстәкыйль эшчәнлекне үстерүне алга куйган педагогик технологияләр белем бирүдә уңышлы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә [2;5]. Әлбәттә, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дә бу технологияләрне актив кулланырга була. Дәрескә әзерләнгәндә, теге яки бу сыйныфта укучыларның әдәби әсәрне аңлау, тел белү дәрәҗәсе, яшь үзенчәлекләре исәпкә алынып, теманы өйрәнүдә әлеге технологияләрнең иң отышлысы сайлап алына.

Эш тәҗрибәсеннән чыгып, дәресләрдә әлеге технологияләрне куллану укучыларга катлаулы яки күләмле темаларны, теоретик материалны җиңелрәк

үзләштерергә ярдәм итә, дәресләр җанлы, кызыклы үтә дип әйтеп була. Мондый дәресләр үз туган теленә мөнәсәбәте төрле булган укучыларда туган тел һәм әдәби мирасны өйрәнүгә теләк һәм кызыксыну уятуга, халкыбыз җәүһәрләренә сакчыл караш булдыруга да нигез булып тора.

Үстерелешле укыту технологиясенең бер компоненты булган модель төзүне укучылар яратып башкара. Укучылар төрле символлар, билгеләр, график модельләр төзү аша, катлаулы материалны кыска һәм аңлаешлы итеп кабул итә, зур күләмле материалдан иң әһәмиятлесен аерып чыгарырга яки охшаш якларны берләштерергә, чагыштырырга өйрәнә,модельгә таянып билгеләмә чыгара, шулай итеп, яңа белем үзләштерелә.

Мәсәлән, әдәбият тарихына, әдәби чорга караган темаларны үзләштерү укучыларда шактый авырлык тудыра. Шуңа күрә теманы өйрәнү барышында кирәкле мәгълүматны аерып алып, ягъни чор үзенчәлеге, бу чор әдипләре, аларның әсәрләрен,тема, жанр,иҗат юнәлешен ачыклап, модельгә салу отышлы.Лирик әсәрләргә анализ ясаганда төп хиснең сәбәбен, дәрәҗәсен билгеләгәндә модельләштерү эшен кулланып була.

Татар теле дәресләрендә катлаулы тел күренешләрен, закончалыкларны өйрәнгәндә кирәкле булган мәгълүматны терәк- схема, таблица формасында язып барса, укучылар теманы җиңелрәк үзләштерә, тизрәк истә калдыра. Укучылар әзер модельләрдән алдагы дәресләрдә дә белемнәрне искә төшергәндә терәк чара булачак куллана ала.

Тәнкыйди фикерләү технологиясенә караган “Кәрзин”, “Синквейн язу”, кластер ысулларын да татар теле, әдәбияты дәресләрендә актив кулланып була. Бу ысуллар укучыларда иҗади фикер йөртергә, текстны аңлап укырга өйрәтә. Мәсәлән,“Сыйфат”, “Фигыль” темаларын өйрәнгәндә инсерт ысулын кулланып була. Алдагы сыйныфларда өйрәнелгәннәрне искә төшергәннән соң, яңа белем үзләштерү максатыннан, укучыларга дәреслектәге кагыйдә инсерт ысулы белән укытыла, аннары бергәләп бу материал тикшерелә. Укучылар сыйфатларның асыл һәм нисби булуларын, исемләшә алуларын, фигыльнең юнәлешләре булуын һәм башка үзенчәлекләрен ачыклыйлар. Алга таба яңа белемнәрне модельләштереп тә куярга була . Шулай итеп, укучының элек алган белемнәре өр-яңа мәгълүматлар белән тулыландырыла.

Инсерт ысулын әдәбият дәресләрендә, мәсәлән, әдипләрнең тормыш юлларын һәм иҗатларын өйрәнгәндә кулланып була. Кайбер әдипләр укучыларга башлангыч сыйныфлардан ук таныш, шуңа күрә мондый темаларны өйрәнү барышында инсерт ысулы отышлы. Мәсәлән, Г.Тукай турында укучылар инде башлангыч сыйныфлардан ук беләләр. 7 нче сыйныфта Г.Тукай иҗатын өйрәнгәндә дәреслектәге мәгълүматны укучылар тамгалар белән билгеләп баралар, схемага тутыралар һәм нәтиҗә ясыйлар. Шулай итеп, белемнәр системага салына. Алган белемнәрне ныгыту яки үзләштерелү дәрәҗәсен тикшереү өчен Интернет челтәрендәге леарнинг апс орт интерактив биремнәр конструкторы ярдәмгә килә. Әлеге конструктордагы биремнәр кызыклы, мавыктыргыч булуы белән укучыларны җәлеп итә. Пликкерс программасы исә, белемнәрне тиз арада тикшереп алырга мөмкинлек бирсә,

Google форма ярдәмендә белемнәрне тикшерергә һәм үсеш-үзгәрешне күзәтеп барып, нәтиҗәләр ясарга да була.

Дәресләрне кызыклы һәм нәтиҗәле итеп үткәрүнең тагын бер чарасы - предметара бәйләнешләрне исәпкә алып укыту. Әдәбият, тел дәресләрен укытуда предметара бәйләнешләр куллану укучыларда белем алуга кызыксыну уята, өстәмә чыганаклар эзләү, шулар белән белемнәрен киңәйтү, аларны дәрестә гамәли куллануга этәрә,төрле фәннәрдән алган белемнәрне системага салырга ярдәм итә. Интеграль дәресләр ике яки берничә укытучының актив эшчәнлеген тәэмин итә. Дәресне бер генә укытучы яки берничә укытучы да алып барырга мөмкин [1;354]. Татар теле һәм әдәбиятын мәктәп програмасында өйрәнелә торган күп кенә башка фәннәр белән интегральләштерергә мөмкин. Бу өлкәләрнең һәркайсы нинди дә булса күләмдә тел, әдәбият белән кисешә.Мәсәлән, тел, әдәбият, сәнгать, музыка, җәмгыять белеме, тарих фәннәренең бәйләнеше тыгыз.

Татар әдәбияты белән татар телен интегральләштерү бик отышлы. Әдәбият дәресләрендә татар теленнән алган белемнәрне кабатлау, системалаштыру эшен оештырырга мөмкин. Укучыларның сөйләм һәм язма телен камилләштерү, кагыйдәләрне ныгыту татар теле дәресләрендә үзләштергәннәргә нигезләнеп алып барыла. Шулай ук әдәбият дәресләрендә сәнгатьле уку алымнарына өйрәткәндә, татар теле дәресендә өйрәнгән сүз басымын, логик басымны дөрес кую, җөмләне фразаларга бүлү һәм дөрес пауза белән уку,интонацияне дөрес куллану, татар теленең үзенчәлекле авазларын дөрес әйтү күнекмәләре кабат искә төшерелә һәм әлеге юнәлештә белемнәр ныгытыла. Ә инде татар теле дәресләрендә теге яисә бу теманы өйрәнгәндә татар язучыларының әсәрләреннән файдалану, шигырьләрне сәнгатьле уку; грамматик категорияләрне кабатлаганда мәкаль-әйтемнәрне, табышмакларны файдаланырга була.

Әлеге төр дәресләрдә балаларны матур, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәтү, укучыларның телен баету, сөйләм культурасын үстерүгә аерым тукталып китик. Бүгенге көндә бу бигрәк тә актуаль. Китап, газета-журнал укырга, татарча тапшырулар карарга яратмаган, ниндидер символ, билге-тамгалар белән аралашуга өстенлек биргән, үз аралашу стиле булган заман укучысы фикерне телдән дә, язмача да төгәл, тулы, эчтәлекле, бәйләнешле итеп җиткерә белергә тиеш. Сөйләм теле ярлы, үз уй-хисләрен аңлатырга сүз байлыгы җитмәгән укучының язма сөйләме дә камил була алмый. Язма һәм телдән сөйләм үстерү, аларны камилләштерү өстендә эшләү юллары күп төрле. Шуларның берсе – фразеологизмнар өстендә эш – аерым урын алып тора.

Фразеологик әйтелмәләр сөйләмне баетуда, аны үтемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә, сөйләм культурасын үстерүдә зур роль уйный. Менә шуңа күрә дә тел, әдәбият дәресләрендә фразеологизмнарны өйрәнү мөһим. Укучыларга фразеологизмнарны күнегүләрдән, әдәби әсәрләрдән таба һәм аларга салынган мәгънәне аңларга өйрәтеп, нәтиҗәдә үз сөйләмнәрендә куллана алуларына ирешү төп максат булып тора.

Фразеологизмнарны өйрәнү–мәктәп программасында үзләштерүгә бирелгән катлаулы темаларның берсе. Фразеологизмнарны өйрәнгәндә тәнкыйди фикер йөртү, проект технологияләрен; өлешчә эзләнү, әңгәмә методларын; текст өстендә эш, тәрҗемә итү эше, инсерт кебек алымнарны куллану отышлы.

Эш тәҗрибәсеннән күренгәнчә, әлеге теманы үзләштергәндә укучылар фразеологизмнарны тану, мәгънәсен аңлау, аларны ирекле сүзтезмә, тезмә сүзләр белән бутау, фразеологизмның мәгънәсен туры мәгънәдә кабул итү кебек авырлыклар белән очраша.

Тел дәресләрендә фразеологизм төшенчәсенә аңлатма биреп, кагыйдә үзләштерү, тотрыклы сүзтезмәләрне тану һәм мәгънәсен аңлата белү, аларны ирекле сүзтезмәдән аера белүгә, сүзлек белән эшкә, татар һәм рус телләрендәге кайбер фразеологизмнарның мәгънәләре белән бер-берсенә якын тораларына, кайберләренең бер телдән икенче телгә күчәргә яисә калькалаштырылырга мөмкин булуына игътибар ителә, төрле биремнәр үтәлә.

Фразеологизмнарны өйрәнгәндә әдәби әсәрнең әһәмияте зур. Дәреслекләрдә тәкъдим ителгән кайсы гына язучы яки шагыйрь иҗатына күз салсак та, әдипнең халык теленең бөтен мөмкинлекләреннән, бигрәк тә мәкаль һәм әйтемнәрдән, фразеологизмнардан киң һәм оста файдаланганына игътибар итәргә була. Мәсәлән, М.Җәлилнең сугыш чоры иҗатын (“Вәхшәт”,“Бүреләр”, “Имән”, “Чәчәкләр” һ.б.), А. Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” әсәрен, Г.Гыйльмановның “Яшел тутый” новелласын, М.Мәһдиевнең “Без-кырык беренче ел балалары”, “Фронтовиклар” кебек әсәрләрен мисалга китерергә була. Әдәбият дәресләрендә укучылар әдәби әсәрдә авторның фразеологизмнарны куллануның максатын ачыкларга, әсәрнең эчтәлеген фразеологизмнар кулланып сөйләргә, тотрыклы сүзтезмәләрне сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнә. Әдәби әсәрләрне өйрәнү барышында дәфтәргә әсәрдә очраган фразеологизмнарны табып, фразеологизмнар сүзлегеннән карап, мәгънәләрен яза барырга кушыла. Ел ахырында укучыларга проект эше итеп, сүзлек төзергә тәкъдим итәргә була.

Укучылар өлкәннәр, әби-бабайлары сөйләмендә кулланылган фразеологизмнарны туплап бару эшен яратып башкаралар. Эшкә нәтиҗә ясаганда, балалар әдәби әсәрләрдә, халык телендә еш кулланылган ачы–төчене тату, аяклары җиргә тими, әрәм итмәү, бил бөгү, бәгырьне өзү, буш кул белән, җене белән бер күрү, күңел тулу, рәхмәт уку, газап чигү, ис китү, гөнаһ шомлыгы, сүз кату, киртә булу, пыр туздыру, ризык бетү, тап төшерү, пар күгәрчен кебек, таң калу, кояш белән бергә, кирәкне бирү кебек фразеологик әйтелмәләрнең, чыннан да, үз әби-бабайларының, туганнарының сөйләмнәрендә дә еш кулланылуын ачыклыйлар. Нәтиҗәдә, укучыларның сүзлек байлыгы арта, бәйләнешле сөйләм күнекмәләре үсә, сөйләмдә фразеологизмнарны урынлы куллана алуга ирешәләр.

Татар әдәбияты рәсем, музыка, тарих белән тыгыз бәйләнештә тора. Язучы иҗатын өйрәнгәндә портретлар, картина репродукцияләре аеруча еш һәм киң кулланыла. Мәгълүм булганча, бер портретны пассив күзәтү генә

Минемчә, татар теле укытучысының рус теле программасын да яхшы белүе кирәк. Татар һәм рус теле дәресләрендә бик күп уртак темалар үзләштерелә. Ә бу темаларның уртаклыгын белү, исәпкә алу укучыларның теманы тиз һәм нәтиҗәле үзләштерүенә китерә, шул ук вакытта предметара бәйләнеш урташтыру принцибы да тормышка ашырыла.

Шуны да истә тотарга кирәк: һәр дәрестә яки класстан тыш эшләрдә укучының сүзлек составын тулыландыру, баету өстендә эш алып барылырга тиеш. Сөйләм телен үстерү өстендә эшләгәндә әзер жавап, текст, диалогларны баланың ятлап түгел, аңлап үзләштерүенә ирешергә кирәк.

Кече яшьтәге мәктәп баласына белем һәм тәбрия бирүдә уеннар гаять зур әһәмияткә ия. Балалар иң катлаулы теманы да уен формасында аңлатканда җиңел үзләштерәләр. Югарыда әйткәнчә, һәр дәресне мавыктыргыч, эмоциональ, үзенчәлекле итеп оештырырга тырышам.

Ә менә үткәрелгән дәрес - КВНнар, дәрес - кичәләр, дәрес - экскурсияләр, укыганны сәхнәләштереп күрсәтү, экиятләр уку, соңыннан эчтәлекләре буенча әңгәмә үткәрү укучының сөйләм телен үстерүдә, һичшиксез, әһәмияткә ия. Баланың сөйләмен үстерү, халык әйткәнчә, аңа "тел ачкычы" бирү, аның фикер йөртү сәләтен үстерү белән бер диярлек, чөнки тел үсү аң үсү белән табигый бәйле.

Сабый аңына, йөрәгенә нәрсә сеңә, нинди тәрбия ала – болар барысы да аның нинди булып үсүенә зур йогынты ясый. Шуны игътибар үзәгендә тотып, кече яшьтәге мәктәп балаларына белем һәм тәрбия биргәндә, дәреснең темасыннан һәм максатыннан чыгып халык авыз ижатын киң файдаланам.

Халык авыз иҗатында халыкның гасырлар буе тупланган тормыш тәҗрибәсе, иң-иң кыйммәтле халык традицияләре һәм гореф - гадәтләре.

Татар халкының авыз иҗаты өлкәннәрне һәм ата-аналарны хөрмәтләргә, кечкенәләргә һәм көчсезләргә, мохтаҗларга, күршеләргә ярдәмчел булырга, барлык халыкларны дус һәм тату яшәргә өнди, китапка, хезмәткә һәм хезмәт кешесенә мәхәббәт һәм башка бик күп матур сыйфатлар тәрбияли.

Татар халык авыз иҗаты белән беррәттән рус халык авыз иҗатын да укыйбыз, чагыштырабыз. Бу үз чиратында һәр халыкның авыз иҗатында үзләренә генә хас үзенчелекләре булу белән беррәттән, алардагы охшашлыкларны күрергә дә ярдәм итә.

Мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, җырлар, җырлы-биюле уеннар сынамышлар, тизәйткечләр өйрәтәм. Болар барысы да баланың акылын, фикерләү сәләтен үстерә, телгә мәхәббәт тәрбияли, сөйләм телен баета, үстерә.

Укучыларның сөйләм телен үстерүдә класстан тыш эшләрнең әһәмияте гаять зур. Шуңа күрә шигырь бәйрәме, кызыклы грамматика сәгате, күренекле язучыларыбызның (мәсәлән: Г.Тукай, М.Җәлил, А.Алиш, Ш.Галиев,Р. Миңнуллин һ.б.) туган көннәрен билгеләп үткәндә аларның иҗатына багышлап “Шигырь бәйрәме”, шигырь укучылар конкурсы, викториналар кебек кызыклы һәм үтемле чаралардан файдаланам. Бу чаралар бала шәхесен рухи баета , белемен арттыра һәм сөйләм телен, ижади фикер йөртү сәләтләрен үстерә.

Югарыда әйтелгән эшләрне эзлекле рәвештә башкару нәтиҗәсендә сыйныфларда шигырь язучылар да барлыкка килде. Аларның хикәяләре, шигырьләре “Заман сулышы” газетасында да даими басылып килә. Тел яшәсә, милләт яши, милләт яшәсә, милли горурлык яши. Ә милли горурлык –иң көчле тәрбия һәм сәламәтлек чишмәсе. Шуңа күрә һәр милләт вәкиле үз халкының күренекле кешеләре белән горурлана, шатлана, хәтта мактана да. Шул ук вакытта җинаять эшләве аларны хурландыра, борчый.

Ата-аналар балаларының киләчәктә зур фән дөньясында колач салып йөзәрлек булуын теләсәләр, аларны киң таралган 14 телнең (ә татар теле шулар арасында 11 нче урында тора) кимендә 2-3сен бик яхшы белерлек итеп тәрбияләргә тырышырга тиешләр.

Мин үзебезнең шәһәребездә, беренчеләрдән булып, татар сыйныфына балалар туплап, татар сыйныфында эшне башлап җибәрдем. Ул елны бу сыйныфка ана телебездә белем алырга теләге булган унсигез бала кабул ителде. Беренче адымнар бик авыр булды, билгеле. Татар сыйныфына укырга килгәндә бары берничә бала, сүз байлыклары бик-бик ярлы булса да, татар телендә сөйләшә ала; кайберләре бик авырлык белән генә аңлыйлар, ләкин җавап кайтара алмыйлар, ә кайберәүләр хәтта татарча бөтенләй аңламыйлар иде. Беренче елны дәресләрне башта рус телендә алып бардым, аннан соң акрынлап кына татар теленә күчтем. Балаларны дәрестән соң алып калып та, дәрескә кадәр алданрак чакырып та бик күп, бик күп эшләргә туры килде.

Математиканы рус һәм татар телләрендә тигез дәрәҗәдә бик сыйфатлы итеп үзләштерүләренә ирештем. “Әлифба” һәм “Букварь” (соңрак “Татар теле” һәм “Русский язык”ны) параллель өйрәтү программасын төзедем. Бу ике телне дә тирәнтен һәм ныклы үзләштерүгә, вакытны дөрес файдалануга мөмкинлек бирде.

Уку елы ахырына барлык балалар татар һәм рус телләрендә бер үк дәрәҗәдә әдәби телдә сөйләштеләр, аралаштылар, ана телебездә фикерләргә, дөрес язарга өйрәнделәр. Татар халык җырларын, биюләрен башкардылар, шигырьләрне, тыңлаучының күңеленә барып җитәрлек итеп, сәнгатьле сөйләделәр. Алга таба дәресне кайсы гына телдә аңлатсаң да, укучылар белемне тиз үзләштерделәр, сорауларга дөрес, тулы итеп әдәби телдә җаваплар кайтардылар, әсәрләрнең эчтәлеген сөйләделәр, барлык биремнәрне дә төгәл үтәделәр. Теманы тиз үзләштерүләре, игътибарлы булулары белән аерылып тордылар. Аларда милләтебезгә хас булган тыйнаклык, ихтирамлылык, пөхтәлек сыйфатлары әллә кайдан күренеп торды. Үзара дус, ярдәмчел, өлкәннәргә һәм кечкенәләргә карата игътибарлы булдылар. Тәнәфес вакытларында матур итеп халкыбызның уеннарын теләп уйнадылар.

Шуны да әйтәсем килә: минем укучыларым татар телен татар мәктәпләре өчен булган программа, рус телен  рус мәктәпләре өчен булган программа нигезендә, ягъни ике телне дә тирәнтен үзләштерделәр.

Безнең шәһәр зур түгел. Барысы да күз алдында. Миңа балаларны йорттан-йортка йөреп, әти-әниләр белән  үз ана телебездә белем алуның, телләр белүнең әһәмияте турында сөйләшеп, аңлатып тупларга туры килсә, инде алдагы елда шәһәребезнең ата-аналары укучыларымның белем һәм тәрбия алуда уңышлары турында хәбәрдар булганлыктан, үз балаларын үз теләкләре белән татар сыйныфларына укырга алып килделәр.

Ата-аналар белән туктаусыз эшләүнең дә нәтиҗәсе булды: укучыларымның әти-әниләре район башлыгы Садриев И.Ә. 11 нче мәктәпнең киләсе уку елында татар гимназиясе булып ачылуын сорап, гариза язып, мөрәҗәгать иттеләр. Шулай итеп,  биш сыйныф ачарлык  балалар тупланганлыктан, мәктәбебез татар мәктәп-гимназиясе статусын алды. Шәһәребездә бу мәктәп-гимназия хәзер дә эшләп килә.

Минем эшемне ата-аналар югары бәяләделәр, бик күп тапкырлар үзләренең рәхмәтләрен белдереп, “Заман сулышы”, “Заветы Ильича” газеталары битләрендә мәкаләләр бастырып чыгардылар.   Мин үзем дә газета битләрендә ана телебездә белем алуның әһәмияте, укучыларымның уңышлары турында мәкаләләр яздым. Телевидениедән укучыларымның чыгышларын күрсәттеләр, үзем дә чыгышлар ясадым.

Йомгаклап, шуны әйтәсем килә: укытучы балаларга татар телен өйрәтүдә иҗади эшләсә, эзләнсә, уйлап тапса гына эшнең нәтиҗәсе була.

# ПРИМЕНЕНИЕ ИНТЕРАКТИВНЫХ ТЕХНОЛОГИЙ В ПОЛИКУЛЬТУРНОМ ОБРАЗОВАНИИ МЛАДШИХ ШКОЛЬНИКОВ

***Сахабиева С.Р., Юсупов А.Ф.***
***Казанский федеральный университет***
***sakhabieva.98@mail.ru, faikovich@mail.ru***

***Аннотация.*** Статья посвящена изучению современных информационных технологий в образовательном процессе, в частности использованию интерактивных технологий в поликультурном образовании младших школьников. Как известно, концепция модернизации российского образования ставит новые цели и задачи перед общим образованием на современном этапе. В современной системе образования стремительно набирает скорость процесс внедрения информационно-коммуникационных и интерактивных технологий, которые должны быть направлены на развитие познавательной самостоятельности и творческих способностей учащихся.

***Ключевые слова:*** поликультурное образование, интерактивные технологии, младшие школьники, образование

В настоящее время в современном мире учащиеся начальной школы в образовательном учреждении проводят очень большое количество своей времени. В учебном заведении они не только получают знания, но и формируются как отдельные личности. Именно поэтому главные образовательные результаты каждого ребенка смещаются с показателей учебной успеваемости на личные и социальные успехи [3: 156]. Данный феномен отражен в содержании Федерального государственного образовательного стандарта начального образования второго поколения. Следует отметить, что ФГОС второго поколения внедряются в образовательные учреждения с сентября 2011 года. И в государственной политике образования данный вопрос является обязательным и закреплено в необходимых документах.

Для начала хотелось бы дать определение понятию «социальное развитие». Так как оно напрямую связана с понятием «Поликультурное образование». Социальное развитие человека – это процесс усвоения и интенсивного воспроизведения индивидуумом общественного опыта, системы общественных взаимосвязей и взаимоотношений.

Социализация человека происходит не только в процессе образования, но и в процессе воспитания и самовоспитания человека. Когда человек ставит перед собой цели и добивается их несмотря ни на что, воспитывает в себе чувство собственного достоинства, четко видит свое место в обществе.

В социальном развитии человека большую роль играет общение. Следует отметить, что ребенка младшего школьного возраста проблема личного общения беспокоит чаще больше, чем проблемы успеваемости по учебным предметам и качества их образования. Это можно доказать тем, что для каждого возрастного периода развития ребенка характерна своя особенность,

свое развитие и своя ведущая деятельность. Если мы обратимся к периодизации Д.Б. Эльконина, то увидим, что младший школьный возраст является временем, когда познавательная активность ребенка направляется на явления в социальных отношений.

В младшем школьном периоде ребенок овладевает ключевыми теоретическими и практическими знаниями. И роль педагога в данной ситуации заключается в том, чтобы грамотно и осторожно направлять эти полученные знания. На данном этапе своего развития дети очень эмоциональны. Для них характерна высокая чувствительность, отзывчивость, человечность, открытость ко всему. У детей доминирует эмоциональная составляющая, это является основой заложения в них таких качеств, как гуманность, сострадание, терпимость.

Но в то же время младший школьный возраст это такой период, когда у детей очень мало собственного опыта и их поведение, в основном, имеет подражательный характер. В этом возрасте у детей выстраиваются отношения со своими сверстниками, взрослыми и с самим собой. Таким образом, формируются и закрепляются базовые индивидуально-психологические особенности ребенка, которые будут определять его будущее.

В различных документах прописано, что начальная школа является очень важным элементом социального развития младшего школьника. Так как достижения ребенка в это период определяют успешность и качество образования человека в дальнейшей жизни [5: 6]. В настоящее время в образовательных учреждениях учатся и развиваются различные дети с различным уровнем образовательного и социального развития.

Для достижения необходимых целей образования и воспитания современная школа использует ряд технологий. Одними из самый современных технологий являются интерактивные технологии.

Интерактивные технологии являются одним из видов инновационных технологий. Не для кого не секрет, что современными компьютеры, сетевые коммуникации с большими и уверенными шагами вошли в нашу современную жизнь. Благодаря им у нас появляется масса возможностей: это коммуникация между людьми, независимо от их местоположения; накопление и передача знаний; дистанционное обучение, которое бешенным темпом развивался именно во время Пандемии 2020 года и другие.

В современном мире знакомство ребенка с инновационными технологиями начинается с раннего детства. С младенчества ребенок видит, что люди, которые его окружают, постоянно носят с собой элементарные мобильные телефоны, дома смотрят телевизор, работают в ноутбуке и так далее. И таким образом, ребенок привыкает их постоянному присутствию. Уже в детстве он так же становится как бы «потребителем» этих технологий, смотри «Машу и медведь», «Фиксики» и так далее. Таким образом, и сам становится частью современного информационного общества.

К вопросам интерактивного образования известные ученые обращались не раз. В своих работах такие ученые, как В.В. Гузеев, М.В. Кларин, Г.М.

Коджаспирова, А.Ю. Коджаспиров, О.П. Осипова, Н.В. Суворова отмечали, что интерактивное обучение является одним из актуальных направлений современного образовательного процесса. Большинство из них отмечают, что занятия в интерактивном режиме имеют этапы организации. В частности, они (этапы) следующие: вычленение проблемы, организация поиска решения поставленной проблемы в группах, обсуждение решений, выбор из числа выдвинутых решений наиболее оптимальное, рефлексия, которая также является обязательной.

Как отмечалось ранее, наиболее часто термин «интерактивные технологии» используется в связи информационными технологиями, дистанционным образованием, с ресурсами Интернет. Еще чаще упоминаются такие источники как электронные учебники, справочники, электронные материалы, работа в режиме онлайн и т.д. Безусловно, это намного облегчает работу, так как предполагается разработка преподавателем заданий с использованием Интернет-источников. Далее задания могут направляться на поисковую деятельность учащихся, тем самым расширяется и масштаб заданий [1: 5].

Использование интерактивных технологий педагогами, в частности учителями начальных классов, способствуют созданию благоприятных условий обучения и воспитания. При этом учащиеся с ранних лет учатся активно взаимодействовать друг с другом, налаживают общение между сверстниками и учителем, тем самым у них формируются коммуникативные УУД. Безусловно, это говорит о том, что учитель в своей педагогической деятельности использует инновационные технологии обучения. Их реализация именно в начальных классах способствует формированию и развитию сознания ребенка. Это может быть достигнуто при помощи создания модели жизненных ситуаций, ролевых игр, коллективных творческих дел на основе анализа ситуаций и т.д. [2: 16].

Организация урока с использованием интерактивных технологий помогает всесторонне развивать учащихся. В процессе такого обучения учащиеся с младшего школьного возраста учатся критически мыслить, на основе анализа информации решать сложные проблемы,взвешивать различные мнения, дискутировать и, конечно же вступать в коммуникацию с другими людьми, что позволяет им адаптироваться, а далее социализироваться в обществе.

Рассматривая сущность, особенности интерактивных технологий следует отметить, что многие ученые, исследователи в состав функций интерактивных технологий обучения включают формирование предметных знаний, умений, навыков, развитие творческих способностей учащихся, создание психологического климата и его улучшение, развитие дружеских отношений и организация взаимопомощи в коллективе и др. В связи с этим не стоит забывать и социализирующей составляющей интерактивных технологий, под которой понимается формирование у обучающихся умений, качеств и способностей, которые способствуют самореализации человека в том обществе, в котором о развивается. Здесь стоит рассматривать всестороннее развитие личности на

протяжении всей жизненной пути во взаимодействии с окружающей средой в процессе усвоения и воспроизводства социальных норм и культурных ценностей, а также саморазвития и самореализации в том числе, к которому он принадлежит [4: 23].

Развитие личности не самостоятельный процесс, оно не происходит без каких-либо воздействий. Мы знаем, что учащиеся в большей степени социализируются в рамках образовательных учреждений, так как именно они играют ведущую роль в этой области. Поэтому педагогам очень важно целесообразно подойти к выбору интерактивных технологий обучения, необходимо учитывать их социализирующий аспект. Здесь под этим понимается те стороны технологий, которые способствуют социализации личности и его развитии.

**Литература**

1. Бордовская Н.В. Современные образовательные технологии [Текст]: учеб. пособие / Н.В. Бордовская, Н.В. Бродская, И.М. Дандарова. – М.: Кно Рус, 2011. – 432 с.

2. Виситова. Л.С. Инновационные методы преподавания в начальной школе // Образование и воспитание. – 2016. – С. 16-19.

3. Григорьева В.Е. Стандарты второго поколения в начальной школе // Герценовские чтения. Начальное образование. – 2010. – Т. 1. – С. 152-156.

4. Переломова Н.А. Интерактивные технологии и проблемы социализации личности. – Иркутск: ИПКРО, 2008. – 67 с.

5. Шкуричева Н.А. Дружеские взаимоотношения младших школьников // Начальная школа. – 2010. - № 11. – С. 6-8.

# ТУГАН ТЕЛҺӘМ ТУГАН ТЕЛ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

***Сәгыйтова Г.Г.***
***МБОУ «Арская средняя общеобразовательная школа №1 им. В. Ф. Ежкова с углубленнымизучением отдельных предметов»***
***gulsina.sagitova@yandex.ru***

***Аннотация.*** В статье рассматриваются вопросы использования новых методов обучения при преподовании предметов родной язык и родная литература.

***Ключевые слова:*** родной язык, родная литература, инновации, методы.

Мәктәптә эшләү дәверендә, шундый проблемалар белән очрашабыз: укучылар дәреслектәге кагыйдәләрне, мәгълүматларны ятлап сөйләргә тырыша, ләкин шул кагыйдә буенча сорауга җавап бирә, мисал китерә алмый; үзләштергәнен башка мәгълүматлар белән чагыштырып, булган белемен яңасы белән бәйли, белемнәрен гамәлдә куллана белми. Педагогик һәм психологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, бала пассив булып калган очракта, укуга карата кызыксынуы булмаганда, бернинди укыту ысулы да нәтиҗә бирми. Балада үзенә билгеле булмаганны ачканда гына кызыксыну уяна.

Күргәнебезчә, укытучы каршында торган төп бурыч өйрәтү түгел, өйрәнергә өйрәтү. Укучы аңында үзе уйлап тапкан, үзе очына чыккан белем генә ныклы уелып кала. Укучы алган белеме алдагы тормышта кирәк булуын тойса, танып белү процессында үз ролен аңласа гына теләп укый. Яңартылган ФДББС да безнең каршыбызга яңа максатлар куя: укучыларда универсаль уку гамәлләре формалаштыру. Димәк, иң кирәклесе белемнәр белән генә коралландыру түгел, ә шул белемне алганда формалашкан гамәл һәм күнекмәләр.

Белем алу – бик авыр акыл хезмәте: аңларга, истә калдырырга, эшләргә өйрәнергә, үзләштерергә, чагыштырырга, нәтиҗә ясарга. Бу хезмәт шатлык китерергә тиеш. Ләкин бу һәр дәрес күңелле, мавыктыргыч булырга тиеш дигән сүз түгел. Иң мөһиме: укучы үзенең үсешен, хәрәкәтен күрергә тиеш. Кичә булдыра алмаган идем, бүген – булдырдым! Укучының уен уятырга, үзе белән горурлана алырлык мөмкинлек тудырырга, аның фикере белән дә исәпләшергә, ләкин, хаксыз булса, шунда ук аңлатырга кирәк.

Заман таләпләре бүгенге көндә татар теле һәм әдәбияты укыту процессында зур үзгәреш сорый. Бу үзгәрешләр, әлбәттә, дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә яңа – инновацион технологияләр куллануны таләп итә.

Инновацион технологияләр дип түбәндәгеләрне әйтергә була:

- Үстерелешле укыту технологиясе
- Проблемалы укыту технологиясе
- Мәгълүмати – коммуникацион технология
- Эзләнү- тикшеренүләр технологиясе
- Хезмәттәшлек технологиясе
- Интерактив технологияләр

- Кейс технологиясе
- Тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясе
- ТРИЗ технологиясе һ.б.

Чыгышымда шулардан үз тәҗрибәмдә куллана торган мәгълүмати-коммуникацион технологияләргә тукталып үтәсем килә. Аны татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларны кызыксындыру, дәресне мавыктыргыч итеп үткәрү, белемнәр һәм күнекмәләрне ныгыту һәм тикшерү өчен отышлы дип саныйм. Әлеге технологияне укыту-тәрбия эшендә гамәлгә ашыру, укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән, укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белүне дә таләп итә. Бу — яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты.

МКТ үз эченә ике төшенчәне сыйдыра. **Мәгълүмати технология** - мәгълүматны саклау, эшкәртү, чагылдыруны тәэмин итүче методлар, ысуллар һәм чаралар җыелмасы. **Коммуникацион технология** – кешенең әйләнә – тирә белән мөнәсәбәтен билгеләүче метод, ысул һәм чаралар җыелмасы.

МКТ белем алу процессында күп төрле мөмкинлекләр ача: интерактив классларда уку, онлайн тестлар эшләү, интерактив дәреслекләрдән, цифрлы белем бирү ресурсларында китерелгән күнегүләрдән файдалану; презентацияләрне укучыларның үзләреннән төзетү, роликлар ясау, аларны бизәкләү, сайт ясау һ.б.

Үз дәресләремдә шулардан түбәндәгеләрне кулланам:

1. LearningApps сайтында ясалган интерактив күнегүләр. Алар бик күп төрле: классификация ясау, ярышу, кроссворд төзү, исем һәм портретларны туры китерү, тыныш билгеләре һәм төшеп калган сүзләрне сайлап кую һәм башка бик күп төрлеләр. Аларны, интерактив такта белән эшләү өчен, дәреснең төрле этапларында кулланып була. Әлеге сайтка кереп, үзеңә ошаган күнегүне сайлап алырга һәм шул күнегү астына урнаштырган “Создать подобное приложение” төймәсенә басып, җайлы гына үзеңә яраклаштырып була. (https://learningapps.org/)

2. “Kahoot!” викторинасы. Укучылар, компьютер/смартфон аша шул сайтка кереп, экрандагы сорауларга җавап бирә. Җавапны дөрес итеп кенә түгел, тиз дә бирергә кирәк. Һәр сорау саен рейтинг күренә, уен беткәч, җиңүчеләр билгеләнә. Ярыш формасында үткәч, укучылар теманы тирәнтен өйрәнергә, төгәл җавап бирергә тырыша. (https://kahoot.com/)

3. QR- кодлар бүгенге көндә тормышның төрле өлкәләрендә кулланыла. Әлеге алым укучыларның социальләшүенә дә ярдәм итә. Интернетта әлеге кодларны ясаучы сайтлар шактый. Кирәкле биремне QR-кодка әйләндереп, өй эше биреп тә, әлеге кодларны биремнең бер өлешен яшерү өчен дә, төрле ярышларның биремнәрен язу өчен дә кулланырга була.

(qrcoder.ru)

4. Кроссворд төзү һәм ясау алымы күптән кулланыла. Ләкин аны хәзер кулдан төзеп торуның кирәге юк. Кроссвордта булырга тиешле сүзләрне язсаң, махсус кушымталараны бик тиз арада төзеп бирә. Аны кәгазьгә чыгарып та,

презентациягә куеп та була. Материалны гомумиләштерүнең бик кулай алымы дип саныйм мин аны. (https://crosswordlabs.com/)

5. Төрле мәкальләрне, шигырь юлларын яшерергә кирәк булганда , “сүзләр болыты”н кулланырга була. Укучыларның җөмлә төзү күнекмәсен, хәтерен үстерүнең әйбәт чарасы бу. (https://wordscloud.pythonanywhere.com/)

Менә шундый чаралар безнең дәресләребезне заманча, эффектив, нәтиҗәле һәм кызыклы итә. Димәк, укучылар да аны үзләштерүдән баш тартмас, дип уйлыйм мин. Татар теле `һәм әдәбияты дәресләре - телебезне саклап калуда мөһим чара.

Минем уемча, татар теле һәм әдәбияты укытучысының бурычы – туган телгә, милли йолаларга хөрмәт уятуда, саклап калуда, ә иң әһәмиятлесе, татарча фикер йөртергә, уйларга һәм дөрес, төгәл, саф татарча сөйләргә өйрәтүдә. Бүгенге көндә, татарча сөйләмне генә түгел, милли үзаңны торгызу проблемасы килеп туганда, укытучының җәмгыяттәге роле тагын да үсә. Бу проблеманы хәл итү – укытучыларның төп бурычы. Балаларыбызның киләчәге бүген хәл ителә. Иртәге көнне алар төзи бит. Димәк, минем алдагы көнем дә алар кулында.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ХРОНОНИМНАРДАН ЯСАЛГАН СҮЗЛӘРНЕҢ СТРУКТУР-СЕМАНТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Сәлахова Р.Р.***
***Казан федераль университеты***
**ruzilya5@mail.ru**

***Аннотация***. В данной статье рассматриваются структурно-словообразовательные особенности хронимов современного татарского литературного языка. Хрононимы функционируют в качестве единиц сложных номинаций лексической системы, содержащих семы «определенный промежуток времени», «культурно-исторические события», что предопределяет значимость их изучения не только с чисто лингвистического, но и лингвокультурологического, этнолингвистического аспекта.

***Ключевые слова:*** татарский язык, хрононимия, хрононим, этнолингвистика, словообразование, лингвокультурология.

Вакыт төшенчәсе төрле мәдәниятләрдә һәм җәмгыятьнең төрле үсеш стадияләренә бәйле рәвештә төрле халыкларда аерым бер дәвердә бер-берсенә охшаш булмаган күзаллаулар формалашуы белән бәйле. Бу күренеш бер төркем факторлар белән билгеләнә. Бүгенге көн, күп кенә галимнәрнең фикеренчә, үткән белән киләчәк турындагы күзаллаулар, мәгълүмат тапшыру юнәлешендә бара, ягъни кешелек җәмгыятенең тәҗрибәсен үткәннән киләчәккә тапшыру процессы. Шулай итеп, фәнни яссылыкта вакыт төшенчәсе үткәннән киләчәккә юнәлдерелгән процессны белдерә.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә вакыт төшенчәсе түбәндәгечә шәрехләнә: "Вакыт – яшәешнең гасыр, ел, тәүлне, сәгать, минут һ.б. белән исәпләнгән дәвамлылы аралык кисеме, мизгеле һәм аларның бер-бер артлы алмашыну процессы [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 662]. Гомуми тел белемендә вакыт төшенчәсенә турыдан-туры бәйле булган хрононим термины да кулланыла: Хрононим – (грек теленнән «chronos» – «вакыт», «чор», onoma, onyma – «исем», «атама») билгеле бер вакыт аралыгыгын белдерә торган исем яки кешелек җәмгыятендә мөһим булган (тарихи, мәдәни) вакыйга атамасы [Розенталь: 489].

Һәр телдә вакыт төшенчәсе үзгә бер формаларда чагылыш таба. Татар телендә ул бер төрле булса, мәсәлән, инглиз телендә ул бөтенләй башка булырга мөмкин. Әлеге атамаларда халыкның күзаллаулары, тарихы, менталь үзенчәлекләре чагылыш тапкан. Шуңа күрә вакыт төшенчәсен белдергән лексик берәмлекләрнең семантик һәм ясалыш-төзелеш үзенчәлекләрен өйрәнү кызыклы һәм актуаль мәсьәләләрдән санала.

Татар телен фәнни яктан тикшеренүләр XVIII гасырның II яртысында башлана. Бу чорда Сәгыйть Хәлфиннең беренче "Татар әлифбасы" (1778) басыла. XIX гасырда этимология, сүзьясалышы, сүзнең атау функциясен, вакыт, табигать күренешләре, ландшафт, үсемлекләр һәм җәнлекләр дөньясына караган сүзләрне, ягъни бүгенге көндә экология белән бәйләп каралган төшенчәләрне тикшерүгә багышланган хезмәтләр дөнья күрә

башлый. Нәкъ әлеге беренче өйрәнүләрдә вакытка бәйле лексиканың формалашу үзенчәлекләре билгеләнә. Вакытны белдергән төшенчәләрне өйрәнүләр шул көннән башлап үзенә күп кенә лингвистларның игътибарын җәлеп итә. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында төрки халыкларның лексикасын өйрәнүдә төрле милләт вәкилләре – аерым бер галимнәр катнаша башлый: К. Насыйри, Ч.Ч. Вәлиханов, М.Ф. Ахундов, И. Алтынсарин, Н.Ф. Катанов һ.б. Бу галимнәрнең фәнни эзләнүләре теге яки бу дәрәҗәдә вакытка бәйле лексиканы өйрәнүне үз эченә ала. Алга таба Н.И. Исанбаев, Л.С. Левитская һәм К.М. Мусаевларның фәнни хезмәтләрендә төрки телләрдәге метеорологик күренешләрнең этимологиясе һәм терминологиясе буенча бай мәгълүмат тупланган. Әлеге метеорологик күренешләр вакыт төшенчәсенә бәйле рәвештә өйрәнелә.

Билгеле булганча, вакыт – абстракт төшенчә, димәк, вакытны белдерә торган сүзләр конкрет мәгънәле сүзләрдән күпкә соңрак, кешелек цивилизациясенең предметлы фикерләүдән абстракт фикерләүгә күчү дәверендә генә барлыкка килгәннәр, шуңа күрә күпчелек халыкларда вакытны кисәкләргә бүлгәләү, вакытны санау астрономик җисемнәр – кояш һәм ай белән бәйле. Элек-электән вакытны билгеләү өчен халыклар физиологик халәткә, хезмәт итү, көнкүреш, дини ориентирларга таянганнар, телдә әлеге ориентирларга бәйле сүзләр, сүзтезмәләр барлыкка килгән, мәсәлән, *ахшам вакыты, сабан, урак өсте* һ.б. Татар телендә вакыт төшенчәсен белдергән сүзләрнең структуралары төрле, алар арасында синтетик сүзләр дә, мәсәлән, *мизгел, секунд, минут, сәгать, таң, иртә, кич, көндез, өйлә, кич, төн, көн, , атна, тәүлек, кичә, атна, ай, яз, җәй, көз, кыш, ел, йөз, чор, гасыр, заман, дәвер, вакыт, мәңгелек,* шулай ук *бүген, төштән соң, өченчекөн, берсекөнгә, быел, бишьеллык, унъеллык, йөзьеллык, меңьеллык* кебек аналитик сүзләр дә байтак. Алар арасында төрле лексик-семантик төркемчәләрне, мәсәлән, кеше гомере белән бәйле сүзләрне аерып чыгарырга була: *сабыйчак, балачак, бала-чага, үсмерчак, яшьлек (яшь чак), яшь-җилкенчәк, егет чак, кыз чак, ир уртасы, картлык* һ.б.ш.

*Атна* – бер дүшәмбедән икенче дүшәмбегә кадәр булган җиде көнлек вакыт үлчәү берәмлеге, шулай ук нинди дә булса бер көннән алып исәпләнгән җиде көнлек вакыт арасы. Атна җиде көннән тора, һәр көннең үз атамасы бар – *дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе*. Әлеге көн исемнәре татарларга XVIII һәм XIX йөзләрдә Урта Азия аша Ираннан кергән һәм халкыбыз телендә кулланылышта булган *баш көн* (дүшәмбе), *буш көн, яман көн* (сишәмбе), *кан көн* (чәршәмбе), *кече атна* яки *атна кич(пәнҗешәмбе), атна көн* (җомга), *атна арасы көн* (шимбә), *урыс атнасы көне*, *базар көн*(якшәмбе) кебек хрононимнарны кысрыклап чыгарган. Бу берәмлекләр безнең көннәргә кадәр төрле язма истәлекләр (кулъязмалар, календарьлар, сүзлекләр) аша үтеп кергәннәр [Беркутов: 20]. Ясалышларына игътибар итсәк, ясагыч нигезләрендәге төп компонент булып *көн* һәм *атна* берәмлекләре торуын күрәбез. Бу төр хрононимнар исем + исем һәм сыйфат + исем тибы ярдәмендә, атрибутив бәйләнеш нигезендә, сүзтезмәнең кушма сүзгә

күчү ысулы белән ясалганнар. Кайберләренең компонентлары арасында метофорик мәгънә сизелә. Мәсәлән, буш (яман) көн – (сыйфат+исем тибы нигезләр кушылу ысулы, сүз ясалыш мәгънәсе – җаваплы, мөһим эшләргә тотынырга ярамый торган көн. Исем+исем тибы ярдәмендә ясалган *кан көн* хрононимының семантикасында халкыбызның гореф-гадәтләре яктыртылган, чөнки борынгы мәҗүсиләрдә атнаның өченче көнендә корбан чалу йоласы булган һәм шул сәбәпле бу көнгә шундый исем бирелгән.

Югарыда телгә алынган ясалма хрононимнарның структур үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, аларның язылышында төрлелекләр күзәтелә: мәсәлән, *баш көн* яки *башкөн*, *атна көн* яки *атнакөн*. Бу урында ачыклык кертеп китү урынлы булыр, чөнки телдә бер үк берәмлекнең, бу очракта хрононимның, ике төрле язылышы булырга тиеш түгел. Югарыда искәртелгәнчә, халык телендә кулланылган көн исемнәренең тарихы борынгы чорларга барып тоташа, алар шул чорда сүзтезмә рәвешендә кулланылганнар һәм язма истәлекләрдә шул рәвешле теркәлеп калганнар. Хәзерге татар әдәби телендә аларны вакыт төшенчәсен белдерә торган кушма сүзләр буларак тикшерәбез икән, беренче чиратта, без аларның ясалыш үзенчәлекләренә игътибарлы булырга тиеш. Ф.А. Ганиев хезмәтләрендә атрибутив бәйләнеш нигезендә сүзтезмәдән кушма сүзгә күчү ысулы ярдәмендә ясалган бу төр берәмлекләрнең кушылып язылырга тиешлеге искәртелә: *атнакич, атнакөн* [Ганиев: 94].

Хәзерге татар әдәби телендә көн исемнәренең фарсы яки гарәп (җомга) теленнән алынган варианты кулланылса да, кайбер диалектларда, аерым алганда мишәр диалектында, *атна арасы көн* (*атнараскөн*), *базар көн*, *урыс атнасы көне* кебек хрононимнар бүгенге көндә дә актив кулланылышта. Күргәнебезчә, хрононимнар составында өчәр компонент булырга мөмкин, аларның төзелешендә изафә (II төр) бәйләнешендәге сүзтезмәләр күзәтелә (*атна арасы, урыс атнасы*), бу төр хрононимнар структурасы буенча кушма сүзнең тезмә төренә мисал булып тора.

Ислам динендә 7 көнлек атна җомгадан җомгага кадәр хисапланган. Атна ахырындагы *җомга* көн ял көне исәпләнгән. Бу көнне ислам дине бәйрәм итәргә кушкан. Ул турыда борынгыдан калган татар халык бәйрәмнәрен уздыру гадәте дә сөйли. Яз бәйрәме «Сабан туен» элек бер җомгадан икенче җомга көненә кадәр бәйрәм иткәннәр. «Җыен» бәйрәме дә «Сабан туеннан» соң җиде җомга дәвамында төрле исемнәрдә узган (тенбер, качалҗар, биектак һ.б.). Фарсы исемнәре белән бергә XVI гасыр гарәп-төрки сүзлегендә якшәмбенең һәм дүшәмбенең махсус исемнәре дә очрый: «*ка (и) рки кун*» *(якшәмбе) һәм* «*ка (и) рки артасы (дүшәмбе)*. Бу сүзләр «*кер*» фигыль формасыннан ясалганнар (*кер* + *че* – аффикс). Моның мәгънәсе “керүче, беренче, башлангыч көн”. Әлбәттә, моның фарсы «*йек-шәмбе*» үрнәгендәге калька икәнлеге аңлашыла. Әлеге нигездә «*ка (и) рки артасы*»*ның* якшәмбедән соң иң беренче көн икәнлеге (дүшәмбе) ачык аңлашыла [Катанов: 77-78].

Шул рәвешле, татар телендә сәгать вакытын һәм атна көннәрен белдергән сүзләр озак еллар дәвамында төрле тарихи факторлар нәтиҗәсендә

формалашкан. Бүгенге көндәге сәгать һәм атна көннәренең белдерелүе борынгы заманнардагы атамалардан шактый аерыла. Бу аңлашыла да, чөнки элек татар халкына гарәп һәм фарсы халыкларының йогынтысы зур булса, бүгенге көндә инде рус һәм европа халыкларының тәэсире көчле.

Кояш-Ай календаре дүрт периодка, ягъни ел фасылына бүленә. Аларның һәрберсенә өчәр ай кергән. Бу – тирә-якта табигать күренешләренең сезонга карата үзгәрешенә һәм Кояшның күзкүрем хәрәкәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән яз, җәй, көз, кыш вакытлары [Исәнбәт: 56].

Тел галимнәренең фикеренчә, *җәй* сүзе «җәелү, җәю»дән килеп чыккан булырга тиеш, чөнки бу вакытта табигать җанлана, анда тормыш күкрәп тора: *Җәй көне җәел* [Исәнбәт: 201].

*Көз* сүзе «көзән»нән (җыелу, кысылу) килеп чыккан. Моның башка мәгънәләре дә бар (көзән – кечкенә бер ерткыч җәнлек; ул оясына кергәч түгәрәкләнеп җыерыла). Димәк, *көз* – табигатьнең кышка җыйналуы, һавалар салкынаеп, җанлы табигатьнең физик яктан да кысылу процессы: *Көзге көн – арткы акыл, язгы көн – ярты акыл; Көзгә – хәл үзгә; Көз бай булмаса, яз бай була; Көз килеше җәеннән билгеле* [Исәнбәт 2010].

*Кыш* сүзе «кыс – кысу» фигыленнән килеп чыккан. «ш» белән «с» авазларының алмашынуы да закончалыклы. Мәсәлән, казах телендә бу соңгы көннәргәчә сакланган. Икенче төрле әйткәндә, кыш – каты кысылу, табигатьнең бик кискен шартлар тудыру вакыты була: *Кыш бавыры бик озын; Кыш – кыямәт, яз – җәннәт; Кышның гамен җәй уйла; Кышны кышсынмаган язны язсынмас; Кыш – үги ана, яз – үз ана* [Исәнбәт 2010].

*Яз* сүзе «язылу – язу» сүзләренә якын. Һәркемнең аңлавынча, бу табигатьнең җанлана башлау чорына туры килә (үзбәкләрдә һәм төрекмәннәрдә аны «баха» диләр). Этимологик анализдан күренгәнчә, тикшерелгән сүзләр үзара логик яктан нык бәйле булган бер бөтен тәшкил итәләр: *Яз җиткәнне җилкәсе җылынгач белгән; Яз җитсә кызам, кыш җитсә сызам; Язган булса язга килер, язмаган булса көзгә килер* [Исәнбәт 2010].

Татар телендә вакытны белдергән рәвешләр дә шактый күп, аларның ясагыч нигезен дә хрононимнар тәшкил итә: *кышын (эшләү), җәен (ял итү), көнозын (йөрү), һәрчак (истә тоту), быел (эшли башлау), бүген (очрату), иртәгә (кайту): Кышын кысыл, җәен җәел, көзен үзең белерсең (мәкаль). Мин бүген йә кайтырмын, йә юк,- диде ул Сәрби апага. (И. Гази). Күр, ничек эшли кояш: Иртә тора таң аттыра, Көнозын күктә йөзә, Һәм көн буена яктыра (Г. Тукай).*

Әлеге рәвешләрнең күпчелеге исемгә *-ын/-ен/-н* кушымчалары ялгану нәтиҗәсендә барлыкка килгән: *кышын, җәен, көзен, язын, иртән.*

Кушма вакыт рәвешләре озак еллар дәвамында формалашкан һәм аларның этимологиясен бары тик тарихка мөрәҗәгать итү аша гына ачыкларга мөмкин: *бүген – бу* (күрсәтү алмашлыгы) + *көн* (исем)*; быел – бу* (күрсәтү алмашлыгы) + *ел* (исем) *һ.б.*

Шулай ук исемнең вакыт ягыннан билгесен ачыклап килгән ясалма сыйфатлар да еш күзәтелә, алар исемгә *-гы/-ге, -кы/-ке* кушымчалары ялганып

ясалган: *Кышкы көн – бер карыш; Кышкы көннең җылынуына ышанма; Көзге көннең көлүе, көлүе дә җылавы һ.б.ш.*

Шул рәвешле, татар телендә вакыт төшенчәсен белдергән лексик фонд бик бай. Әлеге берәмлекләр гасырлар дәвамында формалашып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Хәзерге көндә кулланылыштан төшеп калганнары да байтак, әмма, мисаллардан күренгәнчә, ясалма (кушма) хрононимнар хәзерге татар әдәби теленең актив кулланыштагы сүзләр рәтендә саналалар, аларның ясагыч нигезен тамыр хрононимнар, мәсәлән, *ел, көн, чак* сүзләре тәшкил итә. Әмма бу әле алардан һәрвакыт хрононимнар гына ясала дигән сүз түгел. Телебездә *елъязма, көньязма, көнүзәк, көнитеш, көнкүреш кебек сүзләр дә шактый күп.* Әлеге мәкаләдә без халкыбызның тарихы, яшәеше, тирә-якка карата булган күзаллаулары белән тыгыз рәвештә бәйле булган хрононимнарның бер төрен тикшерү белән генә чикләндек. Халкыбыз телендә билгеле бер чорларда кулланылган тарихи, сәяси, дини, мәдәни вакыйгаларына бәйле хрононимнар да җентекле фәнни тикшеренү сорый. Мәсәлән, ел хрононимыннан ясалган «Урыс елы», «Мәсихи елы», «Милади елы», «Христиан елы» һ.б.ш. Халкыбызның рухи хәзинәсе булган хрононимнарның ясалыш һәм төзелеш үзенчәлекләрен тикшерү, аларның семантик төркемчәләрен, этимологиясен ачыклау тарихи мирасыбызны тулырак яктыртырга мөмкинлек бирер, дип саныйбыз.

**Әдәбият**


1. Беркутов В.М. Бизмәннәрдә вакыт. – Казан: Татар китап.нәшр.,1992. – 80 б.
2. Ганиев Ф.А. Образование сложных слов в татарском языке. – Казань: Печатный двор, 2002. – 192 с.
3. Исәнбәт Н. Татар халык иҗаты. Татар халык мәкальләре җыелмасы: 3 томда: Т. 2. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2010. – 750 б.
4. Катанов Н.Ф. Восточная хронология. – Казан, 1920. – 78 с.
5. Розенталь Д. Э., Теленкова М. А..Словарь-справочник лингвистических терминов. – Москва: Просвещение, 1976. – 543 с.
6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А-В. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 712 б.

# ИСПОЛЬЗОВАНИЕ РОДНОГО ЯЗЫКА ПРИ ФОРМИРОВАНИИ ИНОЯЗЫЧНЫХ НАВЫКОВ

***Свирина Л.О.***
***Казанский федеральный университет***
***l.o.svirina@yandex.ru***

***Аннотация***. Статья рассматривает возможность использования родного языка на разных этапах формирования языковых и речевых навыков. Определяются положительные и отрицательные стороны обращения к родному языку в практике обучения иностранному языку. Делается вывод о вспомогательной роли родного языка как инструмента формирования иноязычной коммуникативной компетенции на этапе формирования первичных языковых и речевых навыков.

***Ключевые слова***: родной язык, иностранный язык, сознательность, сопоставление, языковая среда

Вопрос о возможности или необходимости использования родного языка в практике преподавания иностранного языка – один из наиболее дискутируемых на протяжении всей истории методики. Начиная с грамматико-переводного метода, когда перевод был основным приемом обучения, продолжая прямым методом, когда родной язык полностью «изгонялся» из учебного процесса, и завершая современным этапом, когда коммуникативный подход в качестве одного из принципов обучения оставляет родной язык, методисты пытаются определить его роль и место в обучении иностранному. Остается окончательно решить вопрос: если родной язык имеет право принимать участие в формировании иноязычных навыков, то в какой степени и на каких этапах урока.

В педагогической литературе существуют различные рекомендации по данному поводу. Психологи отмечают, что «родной язык неизбежно будет опосредствующим звеном в изучении иностранного языка и в порождении речи на нем. Чтобы понять закономерности иностранного языка, обучающийся должен объяснить их себе на родном языке… Перед обучающимся стоит задача упорядочить взаимоотношения между двумя языковыми системами в своем сознании таким образом, чтобы родной язык стал помощником в изучении иностранного языка» [Цветкова, с. 202-207].

Обычно, методисты указывают на необходимость сопоставления языковых единиц родного и изучаемого языка для ускорения процесса их усвоения. Так, родной язык получил определенное методическим принципом сознательности право участвовать в формировании грамматических навыков на этапе знакомства с новым грамматическим явлением, где он используется как для раскрытия значения, так и для сопоставления с аналогичными языковыми явлениями родного языка. При формировании лексического навыка перевод на родной язык применяется как средство семантизации абстрактных понятий и «для экономии времени» в старших классах. При постановке произношения учителя, используя транспозицию как положительный перенос навыка,

привлекают родной язык для обучения артикуляции сходных звуков иностранного языка. Таким образом, в формировании языковых навыков родной язык участвует на «законном основании» и в небольших, обусловленных необходимостью, объемах.

При формировании речевых навыков роль родного языка не так методически регламентирована. Безусловно, аудирование, направленное на формирование навыков восприятия иноязычной речи на слух, исключает вмешательство родного языка. Некоторые методисты-исследователи и учителя-практики допускают проверку общего понимания устного иноязычного высказывания после первого прослушивания в виде краткого изложения на родном языке. Затем следует второе прослушивание и выполнение тестов на детальное понимание услышанного.

Однако наибольшие претензии предъявляются к речи учителя, которая является одним из важнейших факторов, влияющих на формирование аудитивных навыков, в силу того, что она обусловлена реальной ситуацией общения. Обычно на вопрос «какой должна быть речь учителя на иностранном языке, сложной или простой», студенты отвечают: «Конечно, простой. Иначе ученики не поймут». Рассуждаем о том, должны ли дети, начинающие изучать иностранный язык, говорить так, как говорит их учитель, и что плохого в том, если они будут понимать обращенную к ним иноязычную речь, имеющую практическую значимость в момент говорения. И не так ли все мы начинали изучать свой родной язык, погружаясь в языковую среду и постепенно усваивая значение слов из ситуации, из контекста, благодаря наглядности, интонации, жестам. Таким же образом работают на курсах обучения иностранному языку носители языка. Они не владеют языками своих учеников, но используют весь арсенал вербальных и невербальных средств, чтобы донести до них смысл высказывания, приучают их слушать и понимать акустические особенности звучащей иноязычной речи. Однако, в неязыковой среде, где все учащиеся владеют одним родным языком, у учителя есть ещё одна возможность семантизировать фразу, «привязав» её к определенной ситуации классного общения - перевести. Опыт подобного раскрытия значения широко используется в рамках интенсивной методики: фраза громко и четко произносится на иностранном языке, а затем на полтона тише («голубым фоном») дается перевод на родной язык. Данным способом можно семантизировать любую нужную нам в классном обиходе фразу. Постепенно мы убираем перевод, а «привязанное» к ситуации иноязычное высказывание остается, выполняя свою коммуникативную функцию. По мере совершенствования коммуникативных навыков родной язык постепенно уходит из речи учителя, и весь урок идет на изучаемом языке, приучая учащихся переключать языковой код как только они переступают порог кабинета иностранного языка.

Формируя навыки иноязычного говорения, мы максимально избегаем обращения к родному языку, стараясь не разрушать «ауру» иноязычной среды. Тем не менее, на подготовительном этапе, отрабатывая лексические блоки

(lexical chunks) необходимые для решения коммуникативной задачи, учителя и некоторые учебные пособия [Калимуллина] используют прием «задрилливания» (drilling) для ускорения автоматизации навыка употребления устойчивых словосочетаний в речи учащихся. Учитель произносит фразу на родном языке, а учащиеся дают перевод на иностранном (на младшем этапе обучения учащиеся перекидывают мяч друг другу и учителю). Проверяется адекватность понимания значения, корректность произношения и отсутствие грамматических погрешностей, затем речевое клише включается в условно-речевую ситуацию как компонент, обеспечивающий решение коммуникативной задачи.

Одним из самых часто встречающихся замечаний при обучении чтению является перевод как единственный видимый учителем прием проверки понимания прочитанного текста. Практика показывает, что несмотря на годы обучения иностранному языку по коммуникативной методике, первым этапом текстовой деятельности зачастую является чтение и перевод. Чем выше уровень коммуникативной компетенции, тем сложнее и длиннее становятся тексты и тем больше времени отнимают чтение и перевод, снижая и без того невысокий интерес к изучению языка. Со временем данный неэффективный прием работы с текстом уходит из практики. Родной язык, тем не менее, остается эффективным средством усвоения иноязычных коллокаций и фразеологических единиц, когда учащиеся устанавливают эквиваленты в способах выражения образных или привычных словосочетаний, так как лингвисты отмечают необходимость подбора точного способа выражения мысли посредством нового языкового кода [Ярмакеев и др., с.104 -113]. Так как, «индивид, чья картина мира сформирована одним языком и одной культурой, сталкивается при изучении иностранного языка с двойной трудностью. С одной стороны, его языковое сознание "не хочет" принимать чуждую ему языковую систему и постоянно навязывает построения на иностранном языке, которые являются кальками с родного и часто абсурдны с точки зрения изучаемого языка» [Колкер, Устинова, с. 20-28]. Родной язык помогает лучше понять смысл и в случае удачного перевода определить регистр словоупотребления.

В письменной речи мы используем родной язык в основном как средство контроля, включая отдельные слова, словосочетания и предложения в контрольные и тестовые задания для проверки уровня сформированности языковых навыков. Последние годы, следуя образцу международных тестов, задания на перевод не применяются в промежуточных тестах, нет их и в формате ОГЭ и ЕГЭ. Однако учителя продолжают активно использовать задания на перевод при текущем контроле в практике диктантов-летучек и для получения обратной связи при проверке знания грамматических структур.

Сопоставления с родным языком также помогают создать проблемную ситуацию при обучении новым грамматическим явлениям. Так, например, приступая к изучению страдательного залога, затруднение вызывает вопрос «как сказать по-английски *мне дали книгу*». The Passive Voice вводится в речь на том этапе, когда порядок слов английского предложения уже усвоен, и

учащиеся знают, что с косвенного местоимения в качестве подлежащего фраза начинаться не может. Поиск правильного варианта приводит к формулировке правила и построению аналогичных образцу предложений в ситуации, когда подлежащее не является исполнителем действия.

Делая заключение о роли и месте родного языка в изучении иностранного, мы определяем ему функцию эффективного вспомогательного инструмента в формировании как языковых, так и речевых иноязычных навыков. Постепенное вытеснение родного языка из практики обучения учащихся происходит по мере совершенствования их иноязычной коммуникативной компетенции, осознания и принятия способов оформления речевой интенции новым языковым кодом в соответствии с конкретной ситуацией общения. Наблюдение и сопоставление аналогичных языковых явлений, как на интуитивном уровне на основе накопленного лингвистического опыта, так и в ходе организуемой учителем целенаправленной работы, способствует формированию вторичной языковой личности в новой лингвокультурной среде.

**Литература**


1. Калимуллина Л.И. Игры на уроках английского языка. URL: https://urok.1sept.ru/articles (дата обращения: 06.02.2023)
2. Колкер Я.М., Устинова Е.С. Роль родного языка в обучении иностранному// Иностранные языки в школе. 2004. №2. С. 20-28.
3. Цветкова Т.К. Усвоение иностранного языка и роль родного языка. Материалы Международной научно-практической конференции «Языковой дискурс в социальной практике». Тверь.- 2021.- С. 202-207.
4. Ярмакеев И.Э., Пименова Т.С., Абдрафикова А.Р. Роль родного языка в изучении иностранных языков: новый ракурс// Общество. Коммуникация. Образование Т. 12, № 1, 2021. С.104 -113.

# ОБУЧЕНИЕ ТАТАРСКОЙ РЕЧИ НА СЛУХ

***Сибгатуллина М.Г.***
***МБОУ "ООШ №6" г. Чистополь***
***milyausha.sibgatullina@yandex.ru***

***Аннотация.***Как особый и самостоятельный вид речевой деятельности, слуховое восприятие имеет свои особенности, и оно имеет сложное отношение к другим видам речевой деятельности. Понимание, по мнению Б. В. Беляева, возникает в результате множества мыслительных операций, которые вместе образуют процесс мышления. Мыслительный процесс является сознательным процессом, так как ориентирован на осмысление содержания сообщения [3,42].

***Ключевые слова:*** татарский язык, речь, обучение.

При прослушивании речи звуковые волны, состоящие из последовательных звуков, образующих слова, словосочетания и предложения, передаются через ухо в слуховой центр головного мозга.

Речь со слуховым пониманием рассматривается с точки зрения "уровня" усвоения учащимся языка, то есть двух явлений: ребенок может не знать того или иного слова, словосочетания, предложения или текста, использовать его в своей речи. По этой причине, с одной стороны, на начальном этапе обучения татарскому языку в русской школе особенно важно выстроить на его основе методику обучения навыкам понимания на слух и восприятия слов и предложений, а с другой-умению использовать слова, словоформы в словосочетаниях и предложениях (эти навыки даются в программе).

В устной (разговорной) речи есть два равноправных аспекта – способность высказывать свои мысли и понимать чужую речь. В начальных классах русской школы второму уделяется меньше внимания.

Учитель должен учитывать языковые трудности и психологические трудности обучения пониманию на слух и речи. Таким образом, русский читатель должен распознавать звуки речи, чтобы понимать татарскую речь. Для этого, в свою очередь, ему необходимо знать состояние органов речи при произнесении звуков и уметь произносить звуки, поскольку понимание основано на внутреннем повторении услышанного. Только после этого можно понять смысл сообщения [1, 18].

Исходя из вышесказанного следует сделать вывод, что учителю необходимо систематически уделять 1\3 урока аудированию и речевым упражнениям. Только следуя этому принципу можно достичь поставленной цели.

Важнейшим условием общения является понимание собеседником друг друга. Известный психолог Л. С. Выготский считал понимание особой формой мышления, происходящей во внутренней речи [5] психологические исследования А. Н.Соколова, Н. И. Жинкина и других ученых показывают, что человек, слушая чужую речь, одновременно изнутри говорит то, что слышит, так как слуховое восприятие вызывает слухомоторную реакцию [6, 25].

**Аннотация.** На протяжении тысячелетий наши предки родной язык сохраняли и передавали из поколения в поколение. Язык-это богатство разума, которое нашлось и поклонялось нации на протяжении всего ее существования. Сохранение этого богатства зеницей ока – священный долг каждого человека.

**Ключевые слова:** родной язык, национальный язык

*“Милли тел язмышы ул - милләт язмышы, аның яшәеш, үсеш формасы, милләтнең сакчысы да, аның киләчәгенең гарантиясе дә. Кешелек әле милләтнең төп таянычы булган, йөрәк пәрәседәй нечкә, кадерле башка төр могҗизаны уйлап тапмаган, таба да алмас, бу бөек көчне бернәрсә дә алыштыра алмый. Безнең бүгенге яшәешебез, уебыз, теләкләребез, гамәлләребез хәзер бары тик бер максатка – милли телебезне саклау, торгызу, үстерүгә юнәлтелергә тиеш” (Әбрар Кәримуллин).*

Татар халкын милләт буларак саклап калу, үстерү, үткәннәр турында түкми-чәчми балаларыбызга тапшыру – хәзерге буынның төп вазифасы. Күңелендә аз гына милли хисе булган кеше дә моңа битараф кала алмый торгандыр. Ана теле сабыйларга аң-белем һәм тәрбия бирү өчен иң шифалы чишмә.

Татар теле – татар халкы өчен уртак милли тел ул. Бу телдә миллионлаган татар халкы үзара аңлаша, аралаша ала, төрле фәннәрне үзләштерә, мәдәни байлыгы белән таныша, үз эшендә алардан иҗади файдалана. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телеңне кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү һәр кешенең изге бурычы.

Татар халкының үткән бөек тарихы, бүгенгесе, киләчәге, матур сөйләме һәм эчке дөньясы аның телендә саклана, тел аша зиһенгә үтеп керә. Ана телен кем саклый соң бездә?

Туган телне өйрәнү гаиләдән башлана, чын татар булу өчен баланы татар мохитендә тәрбияләргә кирәк. Әгәр дә бала туган көненнән башлап ана теле дөньясында яшәмәсә, бу әһәмиятле милли сыйфатның уңай йогынтысыннан мәхрүм калачак. Туган телен яратсын өчен, ана телендә аралашсын өчен, татар баласы, һичшиксез, аны камил белергә тиеш, үз ана телен хөрмәт итәргә тиеш. Үзенең татар булуы белән горурланырга, кимсенү дигән нәрсә булырга тиеш түгел. Әгәр иркле сөйләшсә, оялмаса (ә бу беренче урында тора) теләге чынга ашачак.

Күп кенә ата-аналар, хәтта әби-бабайлар да балаларны ике тел өйрәтеп җафаланмыйк дип, ватып-җимереп булса да бишектән үк урысчага гына өйрәтә башладылар. Мин бүген безнең кадерле ата-аналарга һәм дәү әти-дәү әниләргә әйтәсем килә, балаларны милли телдән мәхрүм итеп бәхетсез ясамагыз. Телләр белүдән бала җафаланмый, армый да, киресенчә, белемгә омтылышы гына арта.

Татар теле – безнең тел. Аны бабаларыбыз меңләгән еллар буе саклап, буыннан-буынга тапшырып килгән. Шуңа күрә, тел күрке – сүз дигәндә, милләт күрке – тел дияргә була. Тел милләтнең бөтен яшәү гомерендә тапкан һәм табынган зиһен байлыгы. Бу байлыкны күз карасыдай саклау – һәрбер ата-ана һәм әби-бабайларның изге бурычы.

Гаять катлаулы һәм мөһим бу мәсьәләне, гаилә, балалар бакчасы, мәктәп бердәм булып, кулга-кул тотынып эшләгәндә генә яхшы нәтиҗәләргә ирешеп була.

Мәктәптә ана теле дәресләрнең дә йогынтысы бик зур. Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Укытучылар алдында бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, телебезне саклау бурычы булса, икенчедән, укучыларда телне өйрәнүдә мотивация булдыру, аны үстерү бурычы. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, ягъни профессионализм сорый.

Рус мәктәпләрендә ана теле буларак татар теле укытуның төп бурычларыннан берсе булып, татар телен өйрәнүгә кызыксынуны көчәйтү, үз теленә, милләтенә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт тәрбияләү тора. Ә бала күңеленә боларны ничек салырга соң? Хәзерге информацион чорда укучыларны ничек итеп үз фәнеңә тартырга? Әгәр дәресләрең кызыксыз, бертөрле генә бара икән, бу балаларда битарафлык тудырачак. Беркемгә дә сер түгел: күп кенә ата-аналар иң мөһиме рус телен яхшы белү дип саныйлар. Димәк, татар теле һәм әдәбияты укытучыларына балалар белән генә түгел, ата-аналар белән дә эшләргә туры килә. Әлбәттә, хәзерге чорда чишеләсе проблемалар күп, һәм алар үзара тыгыз бәйләнгән. Әгәр без әти-әниләр белән эшләүнең нәтиҗәле юлларын тапсак, ул чакта балалар күңеленә дә юл ачылачак.

Менә шуларны күзалдында тотып, мин укыту процессын дәрестән тыш эш белән берлектә алып барырга тырышам. Мин дәресләрне сәнгать белән бәйләргә яратам, чөнки туган тел буенча оештырыла торган түгәрәкләр – бөтен укыту-тәрбия процессының аерылгысыз өлеше. Мондый эшчәнлек укучыларга сөйләм культурасын, иҗади мөмкинлекләрен үстерергә, татар теле предметына кызыксыну уятырга ярдәм итә. Татар теле буенча аларның төрләре гаҗәеп күп: телдән журнал, бәйгеләр, викториналар, диспутлар, иҗат түгәрәкләре, очрашулар, экскурсияләр, конференцияләр. Укытучы 45 минут эчендә ничек кенә тырышмасын, укучыны татар телендә аралашырга, милли кыйммәтләргә өйрәтә алмый. Чөнки балалар дәрестән чыгуга рус телендә сөйләшә башлыйлар. Өйдә дә әти-әниләре белән күбрәк рус телендә аралашалар. Дәресләр дәрестән тыш эшчәнлек белән үрелеп барганда гына максатка ирешеп була. Шушы максатка ирешү өчен, укучылар белән төрле бәйгеләрдә, конференцияләрдә катнашам. Бик теләп татар теле түгәрәкләренә йөриләр. Бергә сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерәбез, бәйрәмнәргә әзерләнәбез, татар телендә басылып килүче газета-журналлар белән танышабыз, фикерләр алышабыз.

Менә инде берничә ел дәвамында укучылар белән берлектә Татарстаныбыздагы язуларны, алтакталарны тикшереп йөрибез. Татарча

язуларда хаталарның күп булуы бердә сөендерми. Язмаларның хаталы булуы тел үсешенә дә йогынты ясый. Ничек кенә булса да, Татарстанда хаталар күп булуга карамастан, язуларның ике телдә дә язылуы куанычлы. Бу хаталар кимер дигән өметтә калам, чөнки “эшләмәгән кеше генә хаталанмый” дигән әйтем бар. Телебезнең алга китүе, аның үсүе өчен һәр татар кешесе җаваплы. Чөнки безнең телебез – безнең байлыгыбыз. Үз телен яраткан кеше генә камиллеккә, матурлыкка омтылып яши.

Мин ышанам: бай тарихлы, зур үсешкә ирешкән туган телебез бүгенге көндә җәмгыятьтә килеп туган сынаулардан исән-сау калып, киләчәктә тагын да зуррак унышларга ирешер, республикабызда, Россия җөмһүриятендә һәм дөнья күләмендә хөрмәткә ия тел булып сакланыр! Һичшиксез,киләчәктә телебез өр-яңадан дөнья күләмендәге зур телгә әверелер, Татарстанда яшәүче һәр кеше татар телендә сөйләшер.

**Әдәбият**

1.Ахунзянов Э.М. Двуязычие и лексико-семантическая интерференция. – Казань, 1968. – 112 б.

2. Вәлиев Р. Белемебез ачкычы//Мәгариф, 2003. –№2, 8-10 б.

3.Вәлиева З. Теле барның – иле бар//Мәгариф, 2003. –№2, 5-6 б.

4.Миңнуллин Р. Телебез булса, киләчәгебездә булыр//Мәгариф, 2006. №2, 7-8 б.

5.Таһиров И. Чигенүләр булмасын//Мәгариф, 2004.- №3, 10 б.

# РУС БАЛАЛАРЫНА ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

**Хәсәнова А.М.**
**ДБГББУ «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадет интернат мәктәбе»**
**hasanova.alsina@bk.ru**

***Аннотация.*** Издавна развивалась система образования, опираясь на традицинную методику. Но пишло время принимать новые методы внедрения образования. Информационные технологии стали основной частью реализации этих планов. Использование новых технологий в обучении татарскому языку занимает одно из основных мест.

***Ключевые слова:*** инновационные технологии, увлекательные и проблемные ситуации, возрастные особенности, принцип индивидуализации, активизация мышления, грамматические и ролевые игры.

Мәгариф системасы гомер-гомергә традицион укыту методикасына нигезләнеп үсте. Шулай да, тормыш бер урында гына тормый, заманалар үзгәрә бара. Димәк, яңалыкларны исәпкә алмыйча эш итәргә ярамый. Бүген без техника зур тизлек белән алга киткән заманда яшибез. Мәгълүмати технологияләр тормышның барлык өлкәләренә үтеп керде. Белем бирү өлкәсе дә моннан читтә калмады – заманча техника белән җиһазландырылган мәктәпләр барлыкка килде, укытуда яңа методик алымнар, технологияләр кулланыла.

Шул рәвешле бүгенге көндә укытучыдан бик күп нәрсә таләп ителә: үз фәнеңне бик яхшы белү, балаларны яратудан тыш, аларның фикерләү сәләтен үстерү, уку-танып белү эшчәнлеген оештыру, рухи һәм физик үсешен тәэмин итү. Ә моның өчен мөгалимнән үз шәхесенә тәнкыйть күзлегеннән карау, яңалыкка омтылу, заман сулышын тоеп, белемне өзлексез камилләштерү, укыту-тәрбия процессына иҗади якын килеп эшләү сорала.

Татар телен чит тел буларак укытуда яңа технологияләрне куллану гамәли эштә төп урынны алып торырга тиеш. Телне өйрәтүнең төп чараларын билгеләү, укыту –тәрбия эшчәнлеген оештыру һәм үткәрүгә булышучы барлык уку материалы белем бирү чарасы булып санала.

Бүгенге көндә «Үзенең дәресләрен ничек кызыклы, мавыктыргыч итеп, ничек укучыларны үз дәресең белән кзыксындырырга, ничек итеп һәр укучыга уңыш ситуациясе булдыру» турында уйланмаган бер генә укытучы да юктыр. Һәм бу очраклы гына уйланулар түгел. Чөнки бүгенге укытуның төп максаты булып – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт телендә һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү. Бу максатларга коммуникатив технологияләр аша гына ирешеп була. Коммуникатив технология нигезендә оештырылган укыту принциплары:

1. Телне аралашу аша өйрәнү принцибы – башта укучыларның яшь үзенчәлекләренә карап, аларның аралашу сферасы, аралашу ситуацияләре

ачыклана, аннан соң шул сферада аралаша алырлык материал сайлана. Бу материал мәктәптә телгә өйрәтү шартларын телне тормышта куллану шартларына якынлаштыру мөмкинлеген бирә.

2. Уку процессын индивидуальләштерү принцибы – хәзерге заман белем бирү системасы үсешенең төп юнәлеше – укыту процессын укучыларның теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру.

3. Телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү принцибы – белем алу процессын укучыларның актив фикерләвенә нигезләнеп оештыру – педагогика фәнненең алдынгы вәкилләре куйган төп таләпләрнең берсе. Уку материалын кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына туры килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль сөйләшүе, тел өйрәтү өчен нәтиҗәле алым булып тора.Аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр булырга тиеш.

4. Телне функциональ төстә өйрәнү принцибы – материал аралашу ихтыяҗыннан һәм кулланыш ешлыгыннан чыгып билгеләнә; материалның күләме,катлаулыгы укучыларның үзләштерү мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнә; [4, 300 ]

Рус телле балаларның татар телен үзләштергәндә, беренче планга сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен дә бер-бер артлы формалаштыру һәм үстерү чыга. Димәк, рус телле балаларны, беренчедән, татар телен аңларга өйрәтергә, икенчедән, үзләренең фикерләрен татар теле чаралары белән әйтеп бирә белергә, өченчедән, башкаларның фикерләрен аңлап, язма һәм сөйләм формасында күрсәтә белергә тиешләр. Әйтеп киткән бурычларны укытуда коммуникатив принциплар кулланып кына максатка ирешеп була. Коммуникатив принцип телдән (тыңлап аңлау, сөйләү), язма (уку,язу), сөйләү формаларын бер-берсе белән тыгыз бәйли.

Икетеллелек шартларында шулай ук информацион компьютер технологияләрен куллану татар телен, аның культурасын, татар халкының тарихын өйрәнүдә зур мөмкинлекләр ача,читтән торып экскурсияләрдә булу шартлары тудыра. Бу технологияне куллану укучыларда фән белән чынлап торып кызыксыну уята.

Телебезне өйрәнә башлауның мөһим баскычы - фонетика (авазлар системасын) үзләштерү. Һәр дәреснең оештыру өлешеннән соң фонетик күнегү үткәрелә. Дәүләт стандартының укучыларга татар теленең фонетик, лексик, грамматик нигезләре буенча гамәли белем бирү нәкъ менә шул эш үтабында ачык күренә.

Татар телен чит тел буларак өйрәтү проөессында уеннардан файдалану укучыны белем алырга , укуга дәртләндерә, аларда фән белән кызыксынуны уята. Бу очракта коммуникатив уеннар алыштыргысыз күнегүәр булып тора, чөнки алар лексик – грамматик материальның үзләштерүенә китерә. Уен барышында ни кадәр сөйләм күнекмәләре күбрәк булса, нәтиҗә шулкадәр яхшырак була. Телне белү өчен тенең үзен түгел, ә тел ярдәмендә әйләнә - тирәне өйрәнергә кирәк. Уенның башка төр укыту методларыннан өстенлеге

шунда ки, аны бер укучы белән генә түгел, ә парлап та, төркемләп тә уйнарга була. [3, 78]

Аеруча грамматик уеннар баланы уйларга, эзләнергә өйрәтә, телләр белүнең тормышта кирәк булуын төшендерә. Өйрәнелгн темадан соң үткәрелгән уеннар аеруча нәтиҗәле була. Ул укучыларның сүз байлыгын арттыра.Дәрестә уйнала торган уеннарны берничә төркемгә бүлеп өйрәтәләр:

1)әле өйрәнелмәгән татар лекисикасын үзләштерергә ярдәм итүче уеннар.

2)өйрәнелгән лексиканы ныгытырга ярдәм итүче уеннар.

3) грамматик кагыйдәләрне кызыклы формада бирүче уеннар.

4)грамматик формаларны , җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгытырга ярдәм итүче уеннар.

Дәресләрдә еш кулланыла торган уеннарның берничәсенә тукталып китәсем килә:

1. «Сүз уйла» уен татар теленә генә хас авазларны өйрәнгәндә уйналына. Мәсәләнә авазына башланган яки шушы аваз булган сүзләрне кем күбрәк әйтә.

2. «Әйтеп бетер» Бу уен аерым теманы өйрәнгәч уйнала.Укытучы сүзнең беренче иҗеген әйтә, ә укучы сүзне әйтеп бетерергә тиеш. Мәсәлән, «Безнең мәктәп» темасы буенча кит ...., дәф ..., ак... һ.б.

3. «Дәвам ит» Теманы яки авазны өйрәнгәч уйнала. Балалр түгәрәккә басалар. Мәсәлән, беренче бала , «укучы » дип , тупны күршесенә бирә, ә ул, караган башка сүз әйтә, тупны чираттагы иптәшенә бирергә тиеш.Сүз әйтә алмаган бала түгәрәк уртасына чыгарга тиеш була.Уен шулай дәвам итә туп кемдә кала шул җиңүче була.

4. «Капчыкта ниләр бар» Өстәлдә төрле әйберләр салынган кечкенә капчык ята . Укучылар чиратлап киләләр дә, капчыктан берәр әйбер алып, аның исемен , билгеләрен , кемнеке икәнлеген әйтәләр. Барысын да дөрес әйткән бала җиңүче була. Мәсәслән: Бу китап, яңа китап, матур китап,китап өстәлдә, китап укытучыныкы.

5. «Бу кем?» Укучылар дәрескә фоторәсемнәр алып киләләр. Һәр укучы үзенең иптәше белән «Гаилә» темасынаөйрәнгән сөйләшүне кабатларга тиеш. Мәсәлән: Бу кем? Бу әти. Ул кем? Ул укытучы. Аның исеме ничек? Аның исеме Виктор Петрович. Һ.б.

6. «Танышу» Укучылар дәрескә төрле хайван, кош битлекләре алып киләләр һәм үзара түбәндәгечә сөйләшәләр.

-Исәнме. Син кем?

-Исәнме. Мин куян. Ә син кем?

-Мин сыер.

7.«Күз, колак, борын» Уен кешенең тән төзелешенә караган сүзләрне кабатлау, ныгыту максатын күз алдында тота. Мәсәлән: укытучы «күз»диюгә, укучылар,басып , күзләрен күрсәтәләр.

8. «Шәвәли» Шәвәли ролен укытучы үзе башкара. Өйрәнелгән тема буенча укучылар аңа сораулар бирәләр. Шәвәли аларга ялгыш җавп бирә. Укучылар аны төзәтергә тиеш булалар. Мәсәлән: син кем?- Шәвәли. Мин кыз .( дөрес җавап мин малай) һәм башка төрле уеннар.[ 1, 27]

Уеннар укыту процессына, укытучыга уңай мөнәсәбәт тудыра, аралашып тел өйрәнүгә ярдәм итә.

Шулай ук рольле уеннар, татар теле өйрәнүгә уңай тәэсир итә. Тәкъдим ителгән ситуацияне күзаллап, укучылар рольле уеннарда да теләп катнашалар. Аларны парларда һәм төркемнәрдә үткәрергә мөмкин. Рольле уен катнашучылар һәм тыңлаучылар өчен дә бер үк дәрәҗәдә файдалы. Балаларда сөйләшүдә катнашу, нидер сорау яки әңгәмәдәшенә җавап бирү ихтыяҗы туа. Уенны оештырганда берничә шарт истә тотып эшләнә: укучыларның сөйләм эшчәнлеге төрле дәрәҗәдә булуын истә тотып, рольләрне дөрес бүлеп бирү; укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрне генә файдалану; телдән актив аралашу мохите булдыру бик зарур.

Белем бирү эшчәнлегемдә проблемалы укыту технологиясен кулланырга була. Укучылар белән берлектә проблемалы ситуациянең хәл итү юлларын эзләү процессы, укучыларның иҗади эшчәнлеген арттыра. Проблема тудыруның түбәндәге алымнарын бар:

- текст яки диалог төзегәндә, ситуацияне конкретлаштыру;
- дөресләү, нигезләү максатыннан чыгып, сораулар кую;
- проблемалы максат, бурычлар кую, тел күренешләрен чагыштыру, проблемалы биремнәр билгеләү.[4, 207]

Педагогика фәнендә укыту- тәрбиянең сыйфатын үстерүгә булышлык итүче технологияләр шактый. Без яңалыклар агымында югалып калмыйча , дөрес юнәлеш ала белергә, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын таба белергә тиешбез.

**Әдәбият**

1. Әхмәтҗанова С. Яңа программа , яңа дәреслек // Мәгариф . – 2004 . № 9. – Б. 96

2. Вагыйзов С.Г. Вәлитова Р.Г. Башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы.- Казан: Мәгариф, 2001. – 344 б.

3.Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. - Казан: Мәгариф, 2004. – 483 б.

4. Харисов Ф.Ф. Основы методики обучения татарскому языку как неродному. Санкт-Петербург: Просвещение, 2001.– 430 с.

5. Харисова Ч.М. Теория и Практика обучения татарс кому произношению в русскоязычных школах. - Санкт-Петурбург: Просвещение, 2001 .- 166 с.

# *QƏRBI AZƏRBAYCAN PALEOTOPONIMLƏRI AZƏRBAYCAN TÜRKÜNÜN ETNOYADDAŞININ ƏN MÖHTƏŞƏM ABIDƏSI KIMI*

***Hüseynova Mahirə***
***Filologiya elmləri doktoru, professor***
***huseynova.mahira@yandex.ru***

***Аннотация.*** Видные тюркологи и топонимисты мира однозначно подтверждают, что Кавказ - это не только древнейшая культура и расселение, но и край древних топонимов - географических названий. С этой точки зрения Азербайджан, обладающий древнейшей материальной культурой, очень хорошо известен в этой стране и регионе как страна палеотопонимов. Древние тюрко-азербайджанские палеотопонимы занимают основное и ведущее место в топонимической системе народов, проживающих на Кавказе, как в древности, так и в современную эпоху, причем эти древние географические названия охватывают как дописьменный, так и дописьменный периоды и являются тысячи лет. Возраст большинства палеотопонимов тюркского происхождения, существующих в настоящее время на территории Западного Азербайджана (современная Армения), составляет не менее 4-5 тысяч лет, и содержит и отражает древнейшие языковые элементы. Хотя эти топонимы были подвергнуты искусственным изменениям и репрессиям армянскими фальсификаторами и вандалами в течение менее 200 лет, им удалось сохранить свои древние формы, образы и значения. Палеотопонимы, существующие на территории Западного Азербайджана, самого величественного памятника тюркско-азербайджанской этнопамяти, учитывали, что архаический этнолингвистический ландшафт до конца еще недостаточно изучен. Поставив перед собой цель обнаружить субстратные признаки азербайджано-тюркских географических названий, мы попытались определить, все ли они принадлежат азербайджанским тюркам.

***Ключевые слова*:** палеотопонимы, древние географические названия, знаки-субстраты, армянские подделки, политика арменизации топонимов, древняя летопись тюрко-азербайджанской этнопамяти

Azərbaycanın görkəmli toponimistlərindən H.Mirzəyev, Q.Qeybullayev, B.Budaqov, Ə.Ələkbərli, İ.Bayramov, S.Sadıqova, C.Cəfərov və digərləri məqalə və kitablarında dönə-dönə qeyd etmişlər ki, Qərbi Azərbaycan ərazisində (indiki – Ermənistan) mövcud olan toponimlərin 99 %-i türk mənşəlidir və 200 il bundan əvvəl bu regionda bir dənə də olsun erməni coğrafi adına təsadüf edilmir. Türkoloq və tarixçilər də doğru olaraq vurğulayırlar ki, türkdilli etnoslar bu ərazidə nəinki bizim eranın əvvəllərindən, hətta bizim eradan çox-çox əvvəllərdə bu torpaqlarda məskunlaşmış ən qədim aborigen sakinlərindəndir. Bu baxımdan Z.İ.Yampolski və N.Z.Hacıyevanın tarixi və arxeoloji qazıntılara istinadən dedikləri – "azərbaycanlılar eradan 2 min il əvvəl bu yerlərin aborigen sakinləri idilər" – fikri tam və real şəkildə özünü doğruldur (1, 226). T.Hacıyev və K.Vəliyev də linqvistik və ekstralinqvistik faktlara istinad edərək yazırlar ki, "tarixi həqiqəti bir qədər dərinlikdə axtarmaq lazımdır. Görünür, qədim Midiya və Albaniya ərazisində ən qədim dövrlərdə gələn,

bir növ köçəri əhvali-ruhiyyəsi ilə davranan-ya yerli qohum etnoslara qarışıb, ya da çıxıb gedən türklər olmuşdur.” (2.15) Bəzi tədqiqatçılar doğru olaraq göstərirlər ki, “elmi ədəbiyyatlarda həmişə söhbət ikinci qrup türk etnoslarından getmişdir.” (2.15) Yayı yaylaqda, qışı qışlaqda keçirmək qədim türkün antik xarakterini işarələyən spesifik əlamətlərdəndir. Məhz bunları nəzərə alaraq, Qərbi Azərbaycanın paleotoponimlərinin hərtərəfli və sistemli öyrənilməsinin əhəmiyyəti olduqca böyükdür, elmi-siyasi əhəmiyyətinin möhtəşəmliyi onunla fərqlənir ki, hibrid, soyu-kökü məlum olmayan, tarixinin qədimliyi, dilinin geologiyası aydın olmayan erməni vandallarının, saxtakarlarının iç üzü açılır, onların saxta dil və tarix yaratma kimi cəfəngiyyat fikir və rəzil müddəalarını ifşa etmək işi mümkünləşir. Azı 5-6 mil eradan əvvəlki dövrləri götürsək, dünyanın dil xəritəsində heç bir dilin yazı mədəniyyətinin formalaşmadığı qənaətinə gələ bilərik. Lakin dünya şumeroloqlarının əksəriyyətinin fikrincə, şumer dili qədim türk dilinin damğa və işarələr sistemi əsasında yaranmış, türk etnoslarının qədim yazı mədəniyyətinin dünyada ilk nümunələridir. Qərbi Azərbaycan ərazisində elə paleotoponimlərə rast gəlirik ki, onların tərkibində türk-Azərbaycan dilinin həm yazıyaqədərki, həm yazıdansonrakı elementləri daha yaxşı mühafizı olunmuşdur. Məsələn, Dərələyəz mahalına məxsus Ardaraz toponiminin fonetik və morfoloji tərkibi əsasında, qədim və müasir mənbələrin verdiyi məlumatlar üzrə fikrimizi şərh etməyə çalışacağıq. Ardaraz oykonimi mürəkkəb quruluşa malik olub, coğrafi relyef bildirən “ard//art” və hidronimik nomen ifadə edən, işarələyən “Araz” sözü əsasında formalaşmışdır. Dərələyəz toponimlərinin mahir tədqiqatçısı professor Həsən Mirzəyev Ardanuş paleoykonimi haqqında doğru olaraq belə bir etimoloji təhlil vermişdir: “Ardaeaz Dərələyəzdə ən qədim azərbaycanlılar yaşayan kəndlərdən biridir. Bu Yelpin kəndi ilə Qozluca kəndinin arasında yerləşir və hazırda isə həmin kəndlərin qışlağına çevrilmişdir. Bu toponim iki sözün “ard və Araz” sözlərinin birləşməsindən əmələ gəlmişdir. “Art//ard” sözü qədim türk dllərində “dağlar”, “daq keçisi”, “aşırım”mənalarını bildirmişdir.” (3.76) Mahmud Kaşğarinin “Divan”ında “ard” sözü “art” fonetik tərkibində (d-t samit əvəzlənməsi – M.H.) qeydə alınmış, “dağ beli”, “sıldırım”, “yoxuş”, “təpə” anlamlarında etimolojiləşdirilmişdir. (4.44) Saxtakar erməni toponimistləri antik dövrün türk dillərinin yadigarı olan Ardaraz paleoykonimini həyasızcasına öz dillərinə transkripsiya edərək Ardaraz şəklinə salmış və bunu 1988-91-ci illər arasında etmişlər. Paleotoponimin birinci komponentindəki “ard” sözü fikrimizcə, türk dillərinin yazı dövrünün yadigarıdır, ikinci komponentdə gələn söz (Araz sözü) antik dövrün leksik vahidlərindən olub, özündə yazıdan əvvəlki dövrlərdə mövcud olan “ar” və “as” sözlərini əks etdirir, yəni pallohidronimlik xarakterini nəzərə alsaq, müasir dövrümüzdəki Araz çay adı qədim “ar, er, ər və as” komponentləri əsasında formalaşmışdır. Yazı mədəniyyəti yaranandan sonra “er” və “as” sözlərinə qədim mənbələrdə təsadüf edirik. Tarixin şumerdən başlandığını nəzərə alsaq, şumercədə “ər//er” sözünün işləndiyini görərik. Antik tariçilərdən Strabonun, Hekateyin (e.ə. VI-V əsrlər), Heradotun (e.ə. 484-425-ci illər) və başqalarının əsərlərində Araz toponimi çay, şəhər, düzənlik adları kimi “Araks” formasında yazıya alınmışdır. Türk dillərinin tarixi inkişafı ilə bağlı olaraq Araks arxaik toponimində “k” samiti düşmüş, söz sadəcə “Araz” forması almışdır,

sözün sonunda s-z samit əvəzlənməsi də Azərbaycan türkcəsində qanunauyğun fonetik hadisələrdən hesab olunur, Araz fonetik tərkibi alması bununla bağlı bir məsələdir. Qeyd etdiyimiz kimi, sözün birinci komponentində gələn “ar” sözünün yaşı 5-6 minillərlə ölçülən şumercədə forması “er” sözüdür və o, gil tabletləri üzərinə “eren” şəklində həkk olumuş və mənası çağdaş türk dillərində “döyüşçü” anlamını verir. Həmin söz qədim türk lüğətlərində “ərən // eren” fonetik tərkiblərində götürülərək “qəhrəman, igid döyüşçü” anlamında mənalandırılır. Çağdaş dilimizdəki Araz toponimi bəzi qədim mənbələrdə Araz, Ərəs fonetik tərkiblərində yazıya alınmış, xalq, tayfa, etnos adı kimi etimolojdirilmişdir. Həqiqətən də, Araz sözünün ikinci komponentində işlənən “as” sözü xalq adı olub, türkdilli xalqların, o cümlədən Azərbaycan xalqının etnogenezisində mühüm rol oynamışdır. Mifoloq M.Seyidovun qeyd etdiyi kimi, aslar eranın IV yüzilliklərindən deyil, eradan əvvəlki minilliklərdən də Altayda, Orta Asiyada, Qarabağda bütövlükdə Azərbaycanda yerli sakinlər olmuşlar. Erməni tarixçilərinin qədim aslarının kökünün ismaililərdən, tarixlərdən, farslardan, ərəblərdən ibarət olması – fikirləri cəfəngiyyatdan başqa bir şey deyil və bu saxtakarlar bununla Qafqazın qədim saklardan olan köklü sakinlərinin izini itirmək istəmişlər (5, 240). Orta əsr tarixçisi Rəşidəddin “Aslar ölkəsi” dedikdə şübhə etmirik ki, Azərbaycanı nəzərdə tutmuşdur, çünki “as” sözü Azərbaycan ölkəsi adında “as” fonetik tərkibində daşlaşmışdır. As // az xalq adı barədə Orxon-Yenisey abidələrində də müəyyən məlumatlara rast gəlirik. Qurani-Kərimdə də “as” xalqının adı çəkilir. C.İ.Cəfərov yazır ki, təkcə Asiya, Qafqaz, Azov kimi qitə, ölkə, dəniz adlarındakı as//az sözü sübut edir ki, aslar vaxtilə dünyanın qüdrətli xalqlarından olmuşdur. Qədim və müasir “as” ünvanlı çay, dəniz, dağ adı Həştərxan (Astarxan), Astarxan bazarı (Cəlilabad rayonu), Astara (rayon, kənd, çay adı), Ashı dağı (Şərur rayonu), os//oş (Qırğızıstan, Fransa, Macarıstan və s.) kimi toponimlər asların çoxünvanlı və çoxölkəki bir xalq olduğuna dair tutarlı sübutdur” (6,113). Hətta xalq yazıçısı İsa hüseynov “İdeal” romanından “Qapalı dünya” hissəsində Ersarlardan danışarkən igid, döyüşkən, qəhrəman, cəngavər asları nəzərdə tutmuşdur. XIX əsr qafqaşünası İvan Şopen də Ermənistanda – Qərbi Azərbaycanda “as” adını daşıyan toponimlərdən danışarkən onların xalis türk mənşəli olduğunu, asların-azərbaycanlıların bu torpağın əsl sahibləri kimi səciyyələndirir.

Beləliklə, Qərbi Azərbaycanın Dərələyəz ərazisində mövcud olan Ardaraz paleotoponiminin qədim və müasir mənbələr əsasında izahı göstərir ki, həmin paleotoponim xalis türk mənşəli xüsusi ad olub, həmin dilə məxsus arxaik “ard”, “ar//az” sözlərini əks etdirir, erməni saxtakarlarının bu söz üzərində apardıqları əməliyyatların və etimolojiləşdirmələrin cəfəngliyini, birmənalı şəkildə kökündən çürük olduğunu təsdiqləyir. Təhlillərimiz onu da göstərir ki, Ardaraz paleoykonimini “as//az xalqının çökəklikdə, sıldırım qayalar arasında axan çayı, suyu” anlamında etimolojiləşdirmək daha ağlabatan hesab olunmalıdır, çünki kəndin yerləşdiyi coğrafi relyef də söylədiyimizi təsdiq edən ekstralinqvistik amillərdəndir.

Qərbi Azərbaycanın yazıdan əvvəlki paleotoponimik sistemində “arpa” derivatlı yer yurd adası mühüm yer tutur və bu qəbildən olan coğrafi adlar əksər mənbələrdə bizim eradan əvvəlki dövrlərə aid edilir. Son iki əsrlik zaman kəsiyinin müxtəlif dönəmlərində erməni vandalları “arpa” derivatlı Qərbi Azərbaycan ərazisindəki

türkmənşəli coğrafi adları dəyişdirməyə etsələr də buna gücləri çatmamışdır. H.Mirzəyev yazır ki, ermənilər 1986-cı ildə çapdan çıxan toponimlər lüğətinin bir neçə yerində Arpa sözünü erməniləşdirməyə çalışsalar da buna nail ola bilməmiş və Arpa toponimi ilə bağlı digər adları lüğətdə olduğu kimi verməyə çalışmış və onları gizlədə bilməmişlər. Lüğətdə verilmiş Arpayədik, Arpaçadıq, Arpagöl, Arpadağ, Arpadərəsi, Arpaenməz, Arpatəpə, Arparalı, Arpalıq, Arpalıçay, Arpalıqaya, Arpayol, Arpaçay, Arpaçuxurlu, Arpavut, Arpatala və s. kimi xüsusi adları buna canlı misaldır (3,81; 7,510-514). Türk tarixçisi Fəxrəddin Kiziroğluna istinadən Həsən Mirzəyev Arpa komponentli coğrafi adların etimologiyasına diqqət yetirərək onu da göstərir ki, "Xan Teqri dağından öz mənbəyini alan və İssık gölünə tökülən Arpa suyu hövzəsindən çox - çox qədimlərdə bir türk eli, türk oylağı gəlib Dərələyəzdə, Ağbaba və Sörayeldə məskunlaşmış və öz adlarını çox qala, kənd, göl adlarında əbədiləşdirmişlər" (3,81; 8,462). Q.Qeybullayevə, B.Budaqova, A.Bayramov və digər toponimistlərə əsaslanaraq H.Mirzəyev qeyd edir ki, "Arpa etnoniminin mənşəyinə gəldikdə demək lazımdır ki, burada məsələ bir qədər mürəkkəbdir. Belə ki, tarixi mənbələrdə Arpa toponiminin çox-çox qədim dövrlərdə mövcud olduğu göstərilir. Hətta bəzi mənbələrdə bu toponim bizim eradan əvvəlki dövrlərə aid edilir. Arpa sözünün etimologiyasını araşdırarkən birinci növbədə söz kökünün tarixən yüksəklik, ucalıq, dağlıq mənasını bildirən Alp-Arp olub-olmadığını, "*l*" "*r*" sonorlarının bir-birini əvəz edib-etmədiyini (*zərər-zərəl*), Arpa və Alban toponimlərinin bir yuvadan təşəkkül tapıb-tapmadığını, Arpa sözünün tarixən "Arpan" formasında işlənib-işlənmədiyini, Arpa toponiminin qatında tarixən cəmlik bildirən "*-pi*" şəkilçisinin olub-olmadığını (kas-pi) müəyyənləşdirmək zəruridir" (3, 81-82). Bütün bu şərhlərimiz deməyə əsas verir ki, qədim "arpa" sözündə müəyyən dil prosesini baş vermiş, yazıyaqədərki dövrü ilə ondan sonrakı dövrlərə çox güclü struktur-semantik fərqlər əmələ gəlmişdir. Lakin bu fərqləri müəyyən qrammatik ünsürlərin köməyi ilə bərpa etmək mümkündür. Yazıdan əvvəlki dövrlərin dil göstəricilərindən biri olan "ayı, azı, arax, azıq, azıx" fonetik tərkibli sözlərin yaşı bəlkə də milyon illərə söykənir və bu baxımdan Dərələyəz mahalında mövcud olan "Ayısəsi" paletoponiminin birinci komponentində çıxış edən "ayı" sözü pitikantrop dövrünün dil yadigarıdır. Ayısəsi toponimini etimoloji qayı // kayı türk etnosları ilə əlaqədar olaraq yaranması fikri bizcə, özünü doğrultmur. Fikrimizcə, istər Qərbi Azərbaycanda, istərsə də türk xalqları yaşayan digər bölgə və coğrafiyalarda "ayı" komponentli toponimlərin əksəriyyətinin yaşı 600 min ildən çoxdur, Mahmud Kaşğarinin 24 oğuz tayfasından biri kimi qeydə aldığı qayı // kayı etnoslarının yaranış tarixi 2000 il əvvəldən uzağa getmir. Aşağı paleolit dövrünün dil yadığarı olan "ayı" sözündə türk dillərinin tarixi inkişafı ilə bağlı olaraq, y-z əvəzlənməsi və q, x samit əlavələri baş vermiş, nəticədə, ayı sözü azıx, azux, azıq, ayık, ayı fonetik tərkiblərində türk dilləri və dialektlərində sabitləşmişdir. T.Əhmədov çoxlu sayda qədim və müasir elmi mənbələrə istinad edərkən yazır ki, "pitikantropun (qədim insanın) çənəsi tapılan çox qədim mağara adı olan Azıx mənbələrdə Azax // Azıx // Azuq variantlarında da qeydə alınmışdır. İstər müasir, istərsə də əvvəllər qeydə alınmış variantlarında toponimik ad qədim türk dillərinin "z" səciyyəli dil ittifaqının (birləşmələrinin) – qıpşaq qrupu dillərinin ilkin fonetik variantını mühafizə etmişdir.

Bu söz türk dilləri və abidələrində *adıq, azuğ, azıq, ayıq, azu, ayu, ayik, ayı* və s. formalarda "ayı" mənasında işləndiyi isə çoxdan məlumdur. Kənd isə öz adını yaxınlığındakı Aşağı Paleolit dövrünə aid nadir mağaralarından birinin adı olan "Azıx"dan almışdır. Nəzərə alsaq ki, Dərələyəz mahalına məxsus Ayisəsi yaşayış məntəqəsi də bu mağaradan çox da uzaqda yerləşmişdir, onda belə bir fikrə gələ bilərik ki, toponim öz adını bu mağaranın adından götürmüşdür (9, 242-243).

Qərbi Azərbaycan ərazisində paleotoponimik vahidlərdən biri də "Çul" coğrafi adıdır və bu türk toponimləri haqqında Ptolomeyin əsərlərində müəyyən məlumatlara rast gəlinir. Bu məlumatlara əsaslanaraq, Q.Qeybullayev yazır ki, "Çul tayfası Xəzər və Aral sahilində IV əsrin 50-ci illərində yaşamışdır. Çöl // çul türk tayfası Albaniyada çox qədimlərdə mövcud olmuş və öz adlarını Qafqazda olan 5 kənd adında əbədiləşdirmişdir" (10, 57). Həsən Mirzəyev qeyd edir ki, "Çul Dərələyəzdə (Paşalı, Əzizbəyov rayonları) kənd adıdır, türk tayfasının adını daşıyan bu kənddə yaxın zaman kəsiyində ermənilər yaşamışdır" (3, 94). Son yüzilliklərin türkoloq araşdırmalarının əsərlərindən belə aydın olur ki, "Çul tayfası Cənubi Azərbaycanda da eranın ilk əsrlərində məskən salmış və onlar Qafqaza, o cümlədən Azərbaycanın müxtəlif bölgələrinəHunlar, Suvarlar, Xəzərlərlə eyni dövrdə gəlib məskunlaşmışlar" (10, 45). Paleoetnonimik səciyyəli bu coğrafi adın paralellərinə hazırda türkdilli xalqlar yaşayan əksər ərazilərdə müəyyən fonetik fərqlərlə - çul, çor, çur, çöl, şul və s. şəkilçilərdə rast gəlmək mümkündür və bunlar haqqında məlumatlar çoxlu tədqiqat əsərlərində öz elmi əksini tapmışdır. Fikrimizcə, "çul" sözü ilkin, qədim yaranış dövründə opelyativ, coğrafi termin kimi fəaliyyət göstərmiş, uzun tarixi inkişf prosesində coğrafi termin semantikasını özündə mühafizə edərək etnos, tayfa adına transfer olunmuşdur. Bu xüsusda H.Mirzəyev göstərir ki, "ümumi sözlərin xüsusi adlara çevrilməsini başa düşmək asandır. İbtidai cəmiyyət müasir bəşəriyyətə nisbətən, təbii hadisələrin təsirinə artıq dərəcədə məruz qalmış, bütövlükdə isə təbiətdən xeyli asılı olmuşdur. Coğrafi adlar insanın ətraf mühitlə birbaşa ünsiyyətinin nəticəsi olan terminlərdən əmələ gəlmişdir, hələ onu demirik ki, ilkin başlanğıc adlar xüsusi adlar kateqoriyasına daxil ola bilməzdi. Yalnız cəmiyyətin inkişafı ilə yanaşı, coğrafi adlar sistemi də, dilin leksik kateqoriyalarından biri kimi, tədricən meydana gəlmişdir" (11, 98). Deməli, "çul" coğrafi adı da ekstralinqvistik baxımından termin səciyyəli sözdən törəmiş, dilin ən qədim arxaik qatının paleotoponimik səciyyəsini özündə ehtiva etdirir.

Paleotoponimlərin tərkibində mühafizə olunmuş qədim türk (paleoazərbaycan) leksik vahidlərinə Dərələyəz ərazisində mövcud olan Erpərin və Ertiş coğrafi adlarında da rast gəlinir. Hər iki paleoykonimin tərkibindəki – birinci komponent yerində işlənən ər // er sözləri şumer dilində və Orxon – Yenisey abidələrində "yer" mənasında əksini tapmışdır. Fikrimizcə, Ertiş toponimi "kotanla şumlanmış yer" anlamında ola bilər, çünki Mahmud Kaşğarinin "Divan"ında "tış" sözü qeydə alınmışdır və həmin söz "kotan dəmiri" mənasında etimolojiləşdirilmişdir (4, 542). Orxon yazılarında əksini tapmış və hazırda Sibir ərazisində axan İrtış çay adını da "suyun kotan kimi açdığı yer" anlamında da etimolojiləşdirmək mümkündür. Ərdəpin toponiminə gəldikdə isə deyə bilərik ki, bu coğrafi ad arxaikləşmiş, lakin Azərbaycan dilinin dialekt arealında öz izini mühafizə edib saxlamış "ərdəm" sözünün fonetik

tərkibcə güclü dəyişikliyə məruz qalmış forması ola bilər və Kaşğarinin qeyd etdiyi kimi, bu söz "tərbiyə, fəzilət, hünər" mənasında türk ləhcələrində işlənmişdir (4, 181). Deməli, Ərdəpin poleotoponimini "tərbiyə, fəzilət, hünər öyrənildiyi yer" mənasında izah etmək bir qədər ağlabatan görünür.

Qərbi Azərbaycanın Dərələyəz mahalında kənd adı kimi işlənən Əkərək toponimi, fikrimizcə, paleotürk mənşəli "aqaraq" sözü əsasında formalaşmış, ümumi leksik vahiddən törəmişdir. Belə ki, şumeroloqların əksəriyyəti "aqar // akar" sözünün şumercədə işləndiyini göstərmiş və həmin sözün uzun illər ümumtürk dillərində "əkin yeri" mənasını ifadə etdiyini göstərmişlər. 1935-ci ildə ermənilər "Əkərək" adlı yer-yurd adlarını öz dillərinə transkripsiya edərək "Akaradza" qoymuşlar. Biz şübhə etmirik ki, aqr // əkər // akar fonetik tərkibli coğrafi termin səciyyəli leksik vahid türk dilindən (5-6 min il bundan əvvəl – M.H.) şumercəyə keçmişdir. Aqaraq // Əkərək coğrafi termini əsasında formalaşan paleotoponimlərə türk dillərinə aid mənbələrdə I əsrdən təsadüf edirik. I əsrə qədər aqar//əkər sözü coğrafi termin kimi əksər türkcələrdə işlənmiş, sonrakı dövrlərdə toponimlərin yaranmasında fəal iştirak etmişdir. Həsən Mirzəyev müxtəlif mənbələrə istinad edərək göstərir ki, "Əstərək, Qafan, Meğri, Cəlaloğlu, Talin rayonlarında və Eçmədzində də Əkərək//Aqarak adında kəndlər vardır və bunlardan başqa Türkiyədə, Borçalıda, Dağıstanda Əkərək yaşayış məntəqəsi adlarına rast gəlirik" (3, 111). Anonim və saxtakar erməni toponimistlərinə uyaraq E.Murzayev belə iddia edir ki, "Çuya, aqar" sözü şumerlərdən yunan, roma, gürcü, erməni dillərinə keçibdir" (11, 108). Bir daha da qeyd edirik ki, ağar//əkər sözləri türk dillərindən şumercəyə keçmiş, ola bilsin ki, Murzayevin göstərdiyi dillər həmin sözü mənimsəmişlər. Belə mənimsəmənin tarixin hansı dövründə baş verməsini konkret şəkildə dəqiqləşdirmək çətin olsa da, hər halda ermənilərin bu ərazilərdə yaşamaları barədə mənbələrdə heç bir real-obyektiv məlumatlara rast gəlmirik. Beləliklə, aqar//əkər sözü türk dillərinin yazıyaqədərki dövrlərində relyef bildirən coğrafi termin kimi işlənmiş, ondan sonrakı dövrlərdə onomastik vahidə, daha dəqiqi, etnotoponimə transformasiya edilmişdir və hazırda bu söz Azərbaycan dilinin dialekt arealında "əkin yeri" mənasında və yaxud "becərilən torpaq" anlamında işlənmişdir.

Erməni saxtakarlığı Dərələyəzin Keşkənd rayonunda vaxtilə mövcud olan azərbaycanlılar yaşayan Ərgəz paleotoponimində də iz qoymuş və bu qədim yer adını dəyişərək "Arqazan" qoymuşlar. 1918-ci ildə bu yaşayış məntəqəsini dağıdıb xaraba qoyan ermənilər toponimin "ər" və "kas//qus//qaz" komponentlərini düzgün anladıqlarından onun adını hiyləgərcəsinə erməniləşdirmiş və bu paleotoponimin dürüst anlamını müəyyənləşdirə bilməmişlər. Xatırladaq ki, hər iki tərkib (ər+kas) dünyanın, o cümlədən türkdilli xalqlar yaşayan ərazilərində yer-yurd adlarının əvvəlində və arasında, bəzən də sərbəst halda çox yayılmışdır. Dünya xəritəsindəki "ər" və "kas//gəz//kus//qaz" komponentli qədim coğrafi adların demək olar ki, əksəriyyəti eradan əvvəlki minilliklərdə formalaşmış türkmənşəli toponimlər sırasına aid edilməlidir və bu barədə ümumtürk toponimik sistemində görüləcək tədqiqat işlərinin diapazonu genişləndirilməlidir. Mürəkkəb inkişaf yolu keçərək çoxlu sayda minillikləri arxada qoyan bu tip paleotoponimlər ciddi forma dəyişikliklərinə məruz qaldığından hiyləgər erməni tarixçiləri bu paleotürk mənşəli yer-yurd adlarını öz

dillərinə asanlıqla çevirə bilirlər, nəticədə, müasir qafqazşünasları, türkoloqları çaşbaş sala bilirlər. Ölkəmiz müstəqillik qazandıqdan sonrakı dövrlərdə yazılan tədqiqat əsərlərində Ərgəz toponimini "ər kuşların, ər quşların, quşların torpağı, yeri-yurdu" anlamında izah edənləri biz də haqlı sayırıq (3, 118; 2, 26).

**Nəticə.** Qədim türk (paleoazərbaycan) antik toponimləri Azərbaycanın qərb bölgəsi (indiki Ermənistan -M.H.) üçün də olduqca səciyyəvi olub, leksik-semantik elementləri ilə də olduqca zəngindir. Belə arxaik-leksik vahidlərin paleotoponim yaradıcılığındakı rolunun tədqiq edilib aşkara çıxarılması hiyləgər erməni cızma-qaraçılarına tutarlı cavab ola bilər. Qərbi Azərbaycan paleotoponimlərinintərkibində mühafizə etdikləri arxaik məna çalarlarını isə həm qədim türk abidələri və qohum türkcələrin materialları əsasında, həm də coğrafi obyektin özünün bolavasitə müəyyən səciyyəvi cəhətlərini nəzərə almaqla müəyyənləşdirmək, bərpa etmək mümkündür ki, bütün bunlar erməni saxtakarlığını açmaqla bərabər, həmin yer-yurd adlarının Azərbaycan türkcəsinə mənsubluğunu sübuta yetirmiş olur.

## Ədəbiyyat

1. Гаджиева Н.З. Тюркоязычные ареалы Кафказа. Москва, «Наука», 1979.
2. Hacıyev T., Vəliyev N. Azərbaycan dili tarixi. Bakı, "Maarif"", 1983.
3. Mirzəyev H. Azərbaycan toponimləri və şivə sözləri. Bakı, "Elm", 2006.
4. Kaşğari M. "Divani lüğət-it-türk" dörd cilddə. II cild. Bakı, "Ozan" 2006.
5. Seyidov M. Qarabağ-Arsak (Arçak) toponiminin etimologiyası haqqında qeydlər. Azərbaycan filologiyası məsələləri jurnalı, №4, 1988.
6. Cəfərov C.İ. Milli etnik yaddaşın izi ilə. Bakı, "Səda", 2005.
7. Апорян Т.Х., Бахшян Т., Барсегян О. Словарь топонимов Армении. Том 1, Ереван, 1986.
8. Kiziroğlu F. Türk tarihi. İstanbul, 1953.
9. Əhmədov T. Azərbaycan toponimikasının əsasları. Bakı, 1991.
10. Гейбуллаев Г.А. К этногенезу азербайджанцев. Баку, 1991.
11. Мурзаев Э.М. Очерки топонимики. Москва, 1974.

# ЗАМАНЧА ШАРТЛАРДА ТУГАН ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮ

**Һадиева Г.Ә.**
**Саба районы, Эзмә урта мәктәбе**
***hadieva-gul@mail.ru***

***Аннотация.*** В статье рассматриваются современные педагогические технологии, широко используемые в области языкового образования, в том числе при обучении татарскому языку. Среди них наиболее привлекательными считаются информационно- коммуникационные, дистанционные, игровые технологии. Использование их способствует развитию коммуникативной компетенции учеников, которая понимается как способность порождать высказывание на изучаемом языке.

***Ключевые слова:*** языковое образование, татарский язык, интерактивная доска, современные технологии, инфографика, ZipGrade, LearningApps.org, QR

«...Заман һәм мәдәният алга үскәнчә һәм икенче төрле итеп әйткәндә, ихтыяҗ һәм мәҗбүрилек кебек нәрсәләр мәҗбүр иткәнчә, укыту рәвешләре төрлеләнер, монда исә акыл ияләре берләшәләрдер», – дип бик хаклы язган күренекле мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин. Чыннан да, җәмгыять үсешенә бәйле рәвештә, укыту процессы да һәрвакыт үсеш-үзгәреш кичерә.

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәрешләр сорый. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен , укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Педагогик эшчәнлекнең нигезе тәҗрибә булса, үсеш-үзгәрешне яңалыкка омтылу тәэмин итә.

Мин – укытучы. Ана теле һәм әдәбияты укытучысы. Минем һәр дәресем, һәр сүзем, һәр үткәргән чарам милләтемә, туган халкыма хезмәт итә. Мин укучыларымда халкыбызның данлы үткәненә, гореф-гадәтләренә хөрмәт, бүгенге һәм киләчәк көннәренә ышаныч, туган җиргә, туган телгә мәхәббәт тәрбиялим. Бүген үзгәреш җилләре искәндә, татар телебезгә каршы астыртын көрәш алып барылганда укучыларымда туган телебезгә карата горурлык хисләре уятырга тырышам.

Мәктәптә укучы күп фәннәр укый. Шулар арасында татар теле дә бар.Үз фәнеңне яратырга өйрәтү — иң авыры. Фәнем белән кызысындыру өчен, миңа һәрвакыт үсештә булырга кирәк.

Без XXI гасырда яшибез. Яңача фикерләүләр, яңа ачышлар, яңа стандартлар, яңа таләпләр заманында. Бу исә уку-укытуга куелган таләпләрне дә катлауландыра. Көн саен туып торган яңалыклардан артта калырга ярамый. Укытучы заман белән бергә атларга тиеш. Чөнки җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләр хәзерге заман укытучысына да яңа таләпләр куя.

Танылган педагог К.Д.Ушинскийның: “Укытучы һәрдаим укыганда гына укытучы булып кала”, –дигән сүзләре – минем тормыш фәлсәфәм. Әйе, хезмәт куймый гына укучыларда фәнеңә мәхәббәт уятып булмый.Үз алдыңа максат куеп, шуны тормышка ашыру өстендә эзлекле эш алып барганда гына моңа ирешеп була.

Шуңа күрә, бертуктаусыз эзләнәм, укыйм, яңалыклар белән танышам. Заманадан артта калмас өчен бөтен көчемне бирәм. Үземә һәм укучыларыма туры килгәннәрен, файдалы булганнарын сайлап алып кулланам.

Бүгенге авыл мәктәбе укучыларының да танып-белү дәрәҗәләре югары. Чөнки алар мәгълүмати технологияләр белән кечкенәдән таныш. Аларның кулларында кыйммәтле телефон яки башка төрле гаджет бар. Шулар ярдәмендә үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап таба беләләр. Мин дә дәресләрдә укучыларымның белем алуга кызыксынуларын, активлыкларын арттыру өчен инновацион технологияләрне, алдынгы методикаларны киң файдаланам. Укучы дәрестә алган белемне тормышның төрле очракларында файдалана белерлек булсын дим.

Безнең мәтәптә татар теле һәм әдәбияты кабинеты заманча җиһазландырылган. Мин үз дәресләремдә бик еш интерактив тактага мөрәҗәгать итәм, чөнки интерактив такта ярдәмендә булган материалны күрсәтү генә түгел, ә яңаны да ясарга була. Интерактив такта укучыларның мөстәкыйль эзләнүләрен, эшчәнлекләрен активлаштыруда зур урын алып тора. Һәр дәрестә татар телен өйрәтүнең алдынгы методикаларын куллану, дәреснең нәтиҗәлелеген арттыру мөмкинлеге бар.

Дәресләрдә онлайн инструментлар, чыганаклар ярдәмендә төзелгән биремнәр, алымнар куллану – укучыларны татар теленә өйрәтүдә кызыксындыру чарасы булып тора. Заманча мәгълүмати һәм компьютер технологияләре укучыларның өйрәнә торган предметны актив һәм иҗади үзләштерүен тәэмин итә, материалны сыйфат ягыннан югары дәрәҗәдә бирергә мөмкинлек тудыра. Аларны куллану- укыту процессын оештыруның принципиаль яңа мөмкинлекләрен ача.

Онлайн инструментлар, цифрлы белем бирү чыганаклары дәрескә матур презентация ясарга, инфографика формасындагы материалны креатив уйлап табарга ярдәм итә.

“Сүзләр болыты” тестны визуальләштерүнең бер ысулы. Интернетта сүзләрдән “болыт” генерацияләү буенча сервислар шактый. Андый сервислар танышканнан соң, мин “сүзләр болыты” ның тагын бер, интернет кирәксез нәрсә генә түгел, ә укытучының дәрестә искиткеч ярдәмче икәнен аңладым. Мондый гадәти булмаган формада тәкъдим ителә торган биремнәр балаларны уку эшчәнлегенә бик яхшы этәрә. Бигрәк тә төркемнәрдә, парларда эш уңышы килеп чыга. “Сүзләр болыты”н куллану дәресне продуктив итәргә мөмкинлек бирә, биремнәрне үтәү кызыклырак, ә уртак эш бер мизгелдә үк башкарыла.

Бу стандарт булмаган алымны дәреснең теләсә кайсы этабында кулланырга мөмкин. Уку материалын визуальләштерү өчен “сүзләр болыты” н, мәсәлән, кагыйдәләр итеп тә кулланып була. Мондый кагыйдә балаларның игътибарын дәрестән соң берничә көн рәттән җәлеп итәчәк.

Соңгы вакытта QR – кодлар популярлаша бара. Каралы- аклы шакмакларны бөтен җирдә урнаштыралар: визиткаларда билетларда, журналларда, һәйкәлләрдә, төрле товарларда һ.б. Бүгенге көндә мондый кодларны очрату гадәти хәлгә әверелде. Кыска булган текстларны, Интернет

челтәрендәге сылтамаларны һ.б. мәгълүматны төрле онлайн генераторларда бик тиз һәм җиңел генә кодлаштырып, дәреснең төрле этапларында кулланырга була. Мәгълүматны болай тәкъдим итү- күләмле, катлаулы материалны тиз һәм аңлаешлы итеп кабул итәргә ярдәм итә.

Инфографика - мәгълүматны график рәвештә визуальләштереп күрсәтү. Аның максаты укучыга катлаулы материалны гадиләштереп бирү. Татарча инфографика материалларын "Гыйлем" интернет сайтында (https://giylem.tatar/) табарга, яки Piktochart.com (https://piktochart.com/) , Canva.com (https://www.canva.com/ru_ru/) кебек интернет - сервислар ярдәмендә үзең төзергә дә була. 90% мәгълүматны баш миенең визуаль формасында кабул итүен исәпкә алсак, инфографика, һичшиксез, эффектив ысул булып санала.

ZipGrade –мобиль приложениесе, тиз генә тестларны тикшерү мөмкинлеген бирә, оффлайн эшли. 20, 50, 100 сораулык бланклары бар, шул бланкларны чыгартып, тестларга җавапларны билгелисе, өскә ФИО язасы, приложениегә дөрес җавапларны кертәсе, һәм эшләрне җыеп алгач, скайнировать итәсе. Нәтиҗәләрне % ларда күрсәтә.

Тест сорауларына җавап биреп бетерү белән, һәр укучы үз билгесен белә. Бу системаны ныгыту, кабатлау дәресләрендә куллану өчен отышлы. Чөнки укытучының эшләрне тикшерүгә вакыты сарыф ителмәячәк. Теманы үтүгә, яңа тема өстендә эшкә, үткәнне системалаштырырга вакыт күбрәк калачак. Бу, әлбәттә, укучыларның белем дәрәҗәсен үстерүгә уңай йогынты ясаячак.

Тестлар эшләү өчен бик уңайлы вариантны мин мультиурок сайтыннан таптым.Тестларны төзеп куясың. 1 яки берничә җаваплы итеп төзергә була. Ссылкасын балаларга җибәрәсең. Укучыларның тест нәтиҗәләре укытучының сайттагы шәхси битенә килә.

LearningApps.org программасы Швейцария, Германия университетлары белгечләренең гыйльми – тикшеренү проекты буларак барлыкка килә. Аның ярдәмендә дәрескә төрле күнегүләр эшләргә мөмкин. Мисал итеп түбәндәгеләрне китерергә була : викториналар , "Кем миллионер булырга тели ?" уены, хәрефләрдән сүзләр төзү, пазллар, хронологик линейка һ.б.

Балаларның белемнәрен бәяләүдә Plickers кушымтасының дә ярдәме бик зур. Ул берничә минут эчендә бөтен сыйныфның белемен тикшереп бәяләргә ярдәм итә, укучыларда да өстәмә кызыксыну уята. Ул рекламаларда, кибетләрдә еш очрый торган QR –кодын куллану ярдәмендә эшли. Plickers ноутбук белән бәйләнештә укытучы тарафыннан телефон яисә планшетта кулланыла. Телефон (планшет) камерасы ярдәмендә укытучы укучылар күтәргән QR –кодлы карточкаларны сканер аша үткәрә.

Әлеге карточкада номер һәм 4 инглиз хәрефе язылган. Номер укучының сыйныф журналындагы номерына туры килә. Ә инде җавап биргәндә, укучы бирелгән җавап вариантларының кайсын дөрес дип саный, шуңа туры килгән хәрефне күтәрә. Эшне төгәллəгәч, шунда ук тактада кемнең дөрес, кемнең ялгыш җавап биргәнен күрергә мөмкин .

Әлеге алымнар дәресләрне кызыклырак итә, укучыларны активлаштыра, танып-белү эшчәнлекләрен үстерә. Балаларны ял иттерү өчен дә бик отышлы.

Барлык технологияләрнең нигезен коммуникатив технология тәшкил итә дип саныйм мин. Чөнки кайсы гына технологияне куллансак та, аралашу аша гына без аларны гамәлгә ашыра алабыз.

Әлеге технологияләрне куллану, миңа дәресләремне кызыклы, балалар теләп белем алырлык итеп үткәрергә, югары нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә. Укучыларымның район, респубика күләмендә үткәрелгән иҗади бәйгеләрдә, олимпиадаларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә еш катнашуы һәм җиңүе, газета-журналларда язмалары басылуы – шуны раслый.

Кто разберет — черт ногу сломит в смешной поэтовой душе.

Тут притаилась дичь, Ведь счастье бьем мы пулею хорошей, Умеем метким выстрелом настичь.

В стихотворении «Прощание с Мариенгофом» [Стихотворения 1916-1925, не включенные С.А.Есениным в основное собрание]. Есенин почти срывается на истерику. Были у них ссоры, было непонимание и разрыв на годы. Но на самом деле дружба с А.Б.Мариенгофом не знала ни времени, ни расстояния, ни смерти – поэты пронесли её через всю жизнь. Эта дружба стала для них и огромным даром, и тяжким крестом. Но только положительные эмоции не в силах дать человеку полное, цельное восприятие жизни. Есенин умел видеть счастье во всём, умело показывать ее другим, и он смог.

Есть в дружбе счастье оголтелое

И судорога буйных чувств —

Огонь растапливает тело,

Как стеариновую свечу. Возлюбленный мой! дай мне руки —

Таким образом, анализ концепта «счастье» в творчестве имажинистов показывает, что почти нет поэтов, не затрагивающих этого образа. Получается, термин «счастье» в стихотворениях поэтов - имажинистов имеет разные определения: удача, рок, судьба, благополучие, любовь, дружба и революция.

Мариенгоф писал: «Имажинизм связывает себя с символизмом и ренессансом в духе революционного времени». Понятие Ренессанса было возобновлено имажинистами с новой силой, и при этом не только воскрешалась

почти угасшая, с гибелью культурного слоя, знаковая семантика «старого» модернизма, но она и насыщалась новыми идеями, и при этом они воздвигали концепт «счастья» «образно» в революционной эпохи. Для Шершеневича романтическая величественность определялась «великими темами» или репрезентация образа «счастья» с учетом ее составляющих – системы когнитивных компонентов литературы.

В январе 1919 года в воронежском журнале « Сирена» появилась декларация представителей имажинизма. И в этой декларации они показали себя как « распространители счастья»:

*« Мы последние в нашей касте, и жить нам недолгий срок. Мы – коробейники счастья, кустари задушевных строк!.. Скоро вытекут на смену оравы не знающих сгустков в крови - машинисты железной славы и ремесленники любви... И в жизни оставят место свободным от машин и основ: семь минут для ласки невесты, три секунды в день для стихов ... Со стальными, как рельсы нервами (не в хулу говорю, а в лесть!) от двенадцати до полчаса первого будут молиться и есть !.. Торопитесь же, девушки, женщины, влюбляйтесь в певцов чудес. Мы пока последние в нашей династии, любите же в оставшийся срок нас, коробейников счастья, кустарей задушевных строк!».*

И мастерство Есенина завершило создания сложной, внутренне единой и вместе с тем бесконечно разнообразной картины мировосприятия героя при помощи различных языковых средств и законов поэтической речи.

**Литература**

1. Воркачёв С.Г. Концепт счастья в русском языковом сознании: опыт лингвокультурологического анализа Краснодар, 2002. – 142 с.

2. Серебряный век. Поэзия. – М.: Олимп; ООО «Фирма Издательство АСТ»,1999. – 672 с.

3. Шершеневич В. Листы имажиниста. Ярославль, 1997. С. 39.

4. Мариенгоф А. Стихотворения и поэмы. — Спб. : Академический проект, 2001. — 350 с. (Новая библиотека поэта. Малая сери ). ISBN 5-7331-0138-5.

5. Хуттунен Т. Монтажный принцип в романе А.Б. Мариенгофа « Циники». – Рус. Филология. 8. Тарту,1997.

6. Источник - http://katlyric.narod.ru/article9.htm).

7. Поэты-имажинисты. СПб., 1997.- 9 с. (Б-ка поэта, БС).

8. Источник: https://kulturologia.ru/blogs/100319/42475/.

9. ЕСЕНИН 1995-2002а: http://feb-web.ru/feb/esenin/texts/es6/es6-1222.htm 26.2.2016 .

10. ЕСЕНИН 1995-2002б: http://feb-web.ru/feb/esenin/texts/e72/e72-2342.htm?cmd=2.

# ИНГЛИЗ ТЕЛЕ СҮЗЛЕКЛӘРЕНДӘ ТӨРКИ ЛЕКСИКА

***Шәйхулов Ю.Д.***
***Казан федерал университеты***
***yunus19981812@mail.ru***

***Аннотация.*** В работе представляется информация о тюркских словах в английских словарях.

***Ключевые слова:*** тюркизмы, этимология, источники, словари, английский язык.

Илләр арасында сәяси һәм икътисади мөнәсәбәтләр үсү белән бәйле рәвештә, инглиз теленә Азия, Африка, Көньяк һәм Төньяк Америка һәм Австралия территориясендә яшәүче күп кенә халыклар телендә булган сүзләр үтеп керә. Галимнәр хәзерге инглиз телендә якынча 50 телдән кергән алынма яши дигән фикердә тора. Шәрыкъ илләре белән сәяси, икътисади һәм мәдәни мөнәсәбәтләрнең тыгыз булуы инглиз теленең сүзлек байлыгында тирән эз калдырган. Ягъни инглиз теленә әлеге илләрдәге халыкларның сөйләме, көнкүреше, тормышында булган шактый гына сүзләр үтеп кергән. Нигездә, инглиз телендә күпләгән гарәп һәм төрки алынмаларны очратырга мөмкин.

Галимнәр исәпләвенчә, инглиз телендә 400 гә якын төрки алынма бар. Шуларның 55 % - этнографик реалийлар, 26 % - иҗтимагый-сәяси юнәлештәге сүзләр, 19 % - табигый реалийлар тәшкил итә.

Шунысын да әйтергә кирәк: төрки алынмаларның инглиз теленә уңышлы гына үтеп кереп “яшәп” киткәннәре аз түгел. Аларны стилистик яктан нейтраль алынмалар дип атарга була. Чөнки әлеге сүзләр әдәбиятта да, сөйләм телендә дә шактый иркен файдаланыла. Төрки алынмаларның инглиз телендәге фразеологизмнар составында очравы моның ачык мисалы булып тора. Төрки алынмаларны инглизләр еш куллана. Кайчандыр инглиз теленә үтеп кергән алынмаларны инглиз халкы үз сүзләре кебек файдалана һәм шуңа күрә дә алар инглизләр сөйләмендә еш күзәтелә. Шулай ук төрки алынмалар аша инглиз телендә сөйләшүчеләрнең дөнья картинасына булган карашлары да шактый киңәя төшә.

Төрки телләрнең башка телләр белән мөнәсәбәткә керү күренешен өйрәнү хәзерге лингвистиканың үзәк мәсьәләләреннән санала. Төрки алынмаларның бүтән телләргә, шул исәптән, инглиз теленә дә үтеп керү сәбәпләрен, вакытын һәм юлларын тикшерү һәм өйрәнү, аларның башка телдә яраклашып китү үзенчәлекләре тарихи лексикологиядә дә актуаль булып кала. Моннан тыш, инглиз теле һәм төрки телләр кебек төрле төзелешкә ия булган телләрнең үзара мөнәсәбәткә керү күренеше дә бик кызыклы. Хезмәтнең актуальлеге шуның белән дә бәйләп аңлатыла.

Төрки халыкларның телләре төрле телләрдә, шул исәптән, инглиз телендә дә шактый эз калдырган. Галимнәрнең мәгълүматлары буенча, инглиз телендә дүрт йөзләп төрки алынма бар, аларның 55% этнографик реалийлар, 26% иҗтимагый-сәяси лексика, 19% табигать реалийлары белән бәйле. Төрки

лексикага караган үзенчәлекләрне инглиз телендәге сүзлекләр нигезендә тикшереп карыйк.

Табигать реалийлары исәбенә badian, beech, irbis, jougara, mammoth, sable, taiga, turkey һ.б. сүзләрне кертеп карарга мөмкин. Бу төркемгә 18 минерал атамасы да керә, мәсәлән, dashkesanite, turanite һәм башкалар да шулар исәбенә кертелә.

Инглиз телендә мамонт (филләр семьялыгыннан плейстоцен чорында Евразия һәм Төньяк Америкада яшәгән, климат үзгәрү һәм ау нәтиҗәсендә юкка чыккан, йонлы эре гәүдәле, озын казык тешле хайван [ТТАС 2018: 487]) сүзе – mammoth [ˈmæməθ] буларак укыла [https://www.oxfordlearnersdictionaries.com/]. “Oxford Learner’s Dictionaries” сүзлегендә әлеге сүзгә түбәндәге билгеләмә бирелә: филгә охшаган, йон белән капланган, моннан мең еллар элек яшәгән һәм хәзерге вакытта юкка чыккан хайван [https://www.oxfordlearnersdictionaries.com/]. Төрек телендә мамонт сүзе mamut формасында бирелә. Күреп торуыбызча, әйтелеше һәм язылышы белән чагыштырганда, әлеге сүзләр күпмедер күләмдә аерыла: mamut (төрек) – mammoth (инглиз).

Игътибарга лаек иҗтимагый-сәяси реалийлар: bashi-bazouk, begum, effendi, chiaus, cossack, ganch, horde, janissary, khan, lackey, mameluke, pasha, saber, uhlan.

“Oxford Learner’s Dictionaries” сүзлегендә saber – кәкре пычаклы авыр кылыч [https://www.oxfordlearnersdictionaries.com/definition/english/saber?q=saber] буларак аңлатыла.

Этнографик реалийлар арасында шулай ук инглиз лексикасының аерылгысыз өлешенә әверелгән төрки алынмалар да бар: caviar, coach, kiosk, kumiss, macrame, shabrack, shagreen, vampire h. б.

Кайбер тикшеренүчеләр һун чорындагы төрки алынмаларга түбәндәге сүзләрне дә кертеп карый: beech, body, girl, beer, book, king. Инглиз теленең үсеш процессында борынгы инглиз сүзләренең күпчелеге, шул исәптән, һун чорында төрки телләрдән үтеп кергән алынмаларның күбесе, алман телләре сүзләре белән алышынган, яки иске француз телендәге сүзләр йогынтысында кысрыклап чыгарылган. Мәсәлән, төрки телдән үтеп кергән tapor борынгы инглиз сүзе axe алман сүзе тарафыннан кысрыклап чыгарыла.

Шунысы кызык, “тапа” – “кисү” тамырыннан ясалган бу сүз гарәп, фарсы һәм рус телләренә дә үтеп керә һәм бүгенге көнгә кадәр аларда, шулай ук Көнчыгыш төрки телләрдә сакланып кала. Көнбатыш төрки телләрдә, мәсәлән, төрек һәм татар телләрендә бу сүзне шул ук мәгънәдәге балта сүзе этеп чыгара, мәсәлән, татар телендәге тапагыч дигән сүз шуның ачык мисалы булып тора.

Төрле һинд телләреннән инглиз теленә 900ләп сүз үтеп керә, аларның кырыгының килеп чыгышы, үз чиратында, төрки телләргә карый: beebee, begum, burka, cotwal, kajawah, khanum, soorme, topchee, Urdu.

Рус һәм инглиз телләре аша 60 тан артык төрки алынма уртаклаштерелә: astrakhan, ataman, hurrah, kefir, koumiss, mammoth, irbis, shashlik һәм башкалар.

Поляк теле аша инглиз теленә hetman, horde, uhlan сүзләре үтеп керә.

Алман һәм француз телләре йогынтысында венгр теленнән инглиз теленә түбәндәге төрки алынмалар үтеп керә: oach, haiduk, kivasz, vampire.

Coach сүзе инглиз телендә иң еш кулланыла торган төрки алынмаларның берсе булып тора, ул “зур ябык арба” мәгънәсен аңлата. Күпчелек этимологик сүзлекләр coach сүзенең килеп чыгышын Венгриядәге авыл исеме белән бәйләп карый. Ул авыл Kocs дип аталган, анда, янәсе, беренче зур ябык арба ясалган. Тик борынгы рус телендә “кочь” төрки алынмасының булуы да мәгълүм, ул “күченү өчен кулланыла торган зур ябык арба” дигәнне аңлаткан, соңрак аны “кибитка” (көймәле арба) дип атый башлыйлар.

“Куч” тамыры төрки телләргә барып тоташа, “күчеп йөрү, күченү” мәгънәсен аңлата, ул күп кенә телләргә үтеп керә. Шул исәптән, рус телендәге “кочевать, кочевник, кочевье, кош, кошевой, кощей, куча” сүзләре дә искәрмә булып тормый.

Венгр телендә хәзер 800 дән артык төрки алынма бар дип исәпләнә. Борынгы рус телендә “кочь” сүзенең шул ук “зур ябулы арба” мәгънәсен аңлатуын истә тотып, венгрлар Паннониядәге авар җирләренә килеп урнашкан гына чорларда, венгр теленең дә, рус теленең дә, алман теленең дә әлеге сүзне төрки телләрдән үзенә алуын аңлау кыен түгел. Әлеге халыкларның теленә төрки-аварларның йогынтысы зур булган. Алар Венгрия территориясендә яшәгән һәм 800 елда Бөек Карл тарафыннан тар-мар ителгән. Бу сүзне шулай ук авар-һуннарның борынгы теленнән үтеп кергән дип тә әйтергә була. Испан телендә шулай ук coche – “автомобиль, вагон” дигән төрки алынма бар.

Төрки алынмалар инглиз теленә төрле телләр аша үтеп керә. Мәсәлән, аларның күбесе немец теле аша үзләштерелә: shabrack, trabant; шулай ук испан теле аша үтеп кергәннәре дә бар: bocasin, lackey; латин теле аша түбәндәге сүзләр кергән: janissary, sable; итальян теле аша да төрки алынмалар үзләштерелгән: bergamot, kiosk. Төрки алынмаларның иң күп өлеше инглиз теленә француз теле аша үтеп керә, мәсәлән: badian, caique, caviar, odalisque, sabot, turkuose сүзләре шуның ачык мисалы булып тора. Алынмалар инглиз теленә берничә тел аша үтеп кергән очракларда, әлеге телләрнең соңгысы, нигездә, француз теле була.

Дөрес булмаган этимологиянең тагын бер мисалы – sabot – тәре походы вакытындагы алынма. Sabot һәм тамырдаш сүзләр булган saboteur, sabotage сүзләренең килеп чыгышы француз теленә барып тоташа, sabot сүзе төрек теле һәм гарәп теле йогынтысында үтеп керә. Sabot сүзе гарәп теленнән килеп чыккан диелә, sabbat “сандалия” дигәнне аңлата. Чынлыкта исә, әлеге сүз гарәп теленә дә, иске француз телләренә дә Якын Көнчыгышта яшәүче төркиләр теле аша үтеп керә.

Төрки телләрдәге чабат (чабат, чабат, сабат, шабат) сүзе “кисү, чабу” мәгънәсен белдергән фигыльдән килеп чыккан һәм башта агач кисәгеннән киселгән аяк киемен аңлаткан. Аннары ул агач аяк киеменең төрләрен, шул исәптән, үреп эшләнгән аяк киемен дә белдерә башлый. Агач аяк киемнәренең күпчелек төрләре кулланылыштан төшеп калу сәбәпле, әлеге сүз төрле төрки

телләрдә төрле аяк киемнәренең төрләрен белдерү өчен кулланыла. Хәзерге татар телендә дә “чабата” сүзе бар, ул борынгы вакытта кулланылышта булган үреп ясалган аяк киемен белдерә. Иске француз теленә әлеге сүз иске мәгънәсе белән үтеп керә, ягъни sabot - агач кисәгеннән ясалган аяк киемен аңлата [Биккинин, 1998: 25].

Рус телендә “чебота” буларак кулланылучы сүз шулай ук төрки телләрдәге чабат сүзенә барып тоташа. Испан теленә бу сүз гарәп хәлифәтләре вакытында Испаниядә төпләнеп калган төрки кабиләләр теленнән кергән һәм аның zapata дигән формасы да бар.

Инглиз телендә, sabot, saboteur, sabotage сүзләреннән кала, чабу фигыленнән ясалган тагын берничә төрки алынма бар. Моңа түбәндәге сүзләрне кертеп карарга мөмкин: chabouk (chabuk, chawbuk) – “камчы, озын сыек чыбык”; chibouk – “чыбык, трубка”; saber (sabre) – “кылыч”; sjambok – “чыбыркы, мөгезборын тиресеннән эшләгән камчы” [Биккинин, 1998: 26].

“Чабу” фигыленнән ясалган алынмалар инглиз теленә француз, алман, африкаанс, малайя һәм һинд телләре аша үтеп кергән. Әлеге барлык төрки алынмаларда да “чабу” фигыленең “кисү, турау” кебек мәгънә төсмере сакланып калган.Күп кенә төрки алынмалар инглиз теленә гарәп, фарсы һәм һинд телләре аша кергән.

Шулай итеп, без төрки алынмаларның инглиз теленең сүзлек составындагы урынын һәм сүзлекләрдәге чагылышын карап киттек. Төрки алынмаларның инглиз теле сүзлекләрендә шактый урын биләп торуын күрдек. Алар күпмедер күләмдә лингво-фонетик яктан үзгәреш кичереп, лексик мәгънә үзгәрешләренә дучар булып, хәзерге инглиз теле нормаларына яраклаштырылып, инглиз телендә яши.

**Әдәбият**


1. Биккинин И.Д., Тюркизмы в английском языке / И.Д. Биккинин // Татарская газета. – 1998. - № 13. – 18-34 с.
2. Галиуллина Г.Р., Юсупова А.Ш., Хадиева Г.К., Денмухаметова Э.Н. Тюрко-татарская лексика как проекция национального менталитета. – Казань, 2011. – 120 с.
3. Денмухаметова Э.Н., Юсупова А.Ш., Онэр М. Словари как источники информации о татарах // Turkic Studies Journal. – 2022. – Т. 4. - № 2. – С. 48-55.
4. Локетт Брайан. Английский язык: вчера, сегодня и завтра. – М.: Рус. яз. – Медиа, 2003. – 608 с.
5. Сафиуллина Г.Р. Сравнительная лексикография: система помет / учебно-методическое пособие по лексикографии / Автор-составитель Сафиуллина Г.Р. – Казань: ООО ПК «Астор и Я», 2016. – 40 с.
6. Җамалетдинов Р.Р., Нурмөхәммәтова Р.С. Тел белеме нигезләре. – Казан: Ихлас, 2014. – 240 б.

# ЛИНГВИСТИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ АНЕКДОТОВ О НАСРЕДДИНЕ АФАНДИ НА МАТЕРИАЛЕ УЗБЕКСКИХ ГАЗЕТ

***Шермухамедова Н. А.***
***Бухарский государственный университет***
***shermuxamedova.n.74@gmail.com***

***Аннотация.*** в данной статье рассматриваются некоторые особенности современных анекдотов об Насреддине Афанди – восточного хитреца и шутника, его национально-культурная специфика. Освещены вопросы использования прецедентных текстов на страницах узбекских газет.

***Ключевые слова:*** лингвокультурология, публицистика, сатира, анекдот, национальная специфика, прецедентность.

Язык средств массовой информации обогащает и насыщает речь оценочными оборотами. Сила и преимущество языка публицистики, занимающей в языке средств массовой информации заключаются в прямом воздействии на адресата, аудиторию. Развивая литературный язык, СМИ способствуют и развитию культуры. Язык СМИ своими усредненными, стандартными значениями объединяет нацию. Язык народа в известной степени стал производным от языка газеты.

Из многочисленных языковых средств, оказывающих влияние на структуру мышления и тем самым на процесс восприятия, наибольшее внимание привлекают прецедентные тексты – это пародируемые и высмеиваемые тексты. Основные прецедентные тексты данного общества непременно отражаются в популярных в этом обществе смеховых произведениях [Нигматова: 93]. Следует отметить, что в качестве текста – источника прецедентных элементов могут выступать анекдоты (как наиболее распространенный тип юмористического жанра), так как некоторые их ключевые фразы являются частью языкового сознания носителя языка и считаются такими фразами, которые широко понимаются членами общества данной культуры. Следовательно, они являются в определенной мере отражением мировоззрения и обычаев данной общности.

Именно анекдоты наделены огромным этнокультурным зарядом и, аккумулируя лингвокультурологическую информацию, обладают большой когнитивной ценностью.

Анекдот характеризуется устойчивой формой, принадлежит к числу устных видов словесности и строится по законам жанра фольклорных текстов. Анекдот создается народом, автор его анонимен. Поэтому его можно считать объективным показателем происходящих в социуме когнитивных и нравственных процессов и господствующих в обществе ценностных ориентиров [Sobirovich: 86].

Исходя из данного тезиса, можно утверждать, что в узбекском национальном герое Ходже Насреддине (Афанди), можно увидеть мудрую, всезнающую и в то же время хитрую личность, которая постоянно выражает интересы простого народа. Афанди, не уставая, высмеивает жадных и скупых

богачей, которые в результате его хитрых проделок всегда оказываются в неловком положении. Основная черта Насреддина – выходить из любой ситуации победителем с помощью слова. Насреддин-эфенди виртуозно владея словом, нейтрализует любое своё поражение. Частые приёмы Ходжи — притворное невежество и логика абсурда.

Неотъемлемой частью образа Насреддина стал ослик, который появляется во многих притчах либо как главный герой, либо как спутник Ходжи.Как триста лет назад, так и в наши дни анекдоты о Насреддине пользуются очень большой популярностью среди детей и взрослых во многих азиатских странах.

Отличительной особенностью современных узбекских анекдотов об Ходже Насреддине является их социальная направленность. В них во многом находят отражение социальные отношения. Вот, к примеру, один анекдот о нем: «Будучи в начальных классах школы, Насреддин постоянно докучал своему учителю, домулло, всевозможными вопросами, на многие из которых учитель просто не находился, что отвечать. В результате домулло, вышел из себя и сказал своему ученику – Не стоит хвалиться своими знаниями. Дети, которые в детстве хотят казаться очень умными, часто вырастают просто дураками. – На что Насреддин ответил – Вероятно, Вы, многоуважаемый учитель, в детстве были очень умны!».

Насреддин Афанди – восточный шутник и хитрец, не зря был выбран героем всевозможных рассказов и анекдотов. Несмотря на всю глупость и неловкость его поведения, а также немыслимость его приключений, каждая история или анекдот о нем – это шкатулка, наполненная драгоценными жизненными мудростями, знанием о том, кто есть человек и какой у каждого путь и предназначение, а также о том, что человек должен обрести самопознание и духовную наполненность своего бытия.

Вышеприведенный пример из узбекских анекдотов, фиксируя мировоззрение социума, отражают повседневный жизненный быт узбекского народа [Шарипов: 8].

Но среди веселья нет-нет да и зазвучит щемящая нотка, и тогда смешное вдруг перестает быть таковым, и мы начинаем смотреть на жизнь другими глазами. «Насреддин говорит знакомому: – Слышал? Наш приятель скончался. –Нет, – ответил тот. – От чего же? – Бедняга не знал, ради чего живет, так что о причине смерти и говорить нечего» [TEMIROVA: 146].

Таким образом, некоторые жизненные ситуации – хорошая тема для анекдотов. С национальной и культурной точек зрения анекдоты отражают мировоззрение, обычаи и традиции той или иной общности.

Духовно-нравственное воспитание – это становление значимого отношения к жизни, которое способствует устойчивому и слаженному развитию личности, содержащее в себя формирование справедливости, ответственности и чувства долга. Для развития любому обществу нужно передавать свой накопленный опыт. От идеи развития и обучения, которая вырабатывается на базе особенностей взглядов данного общества на жизнь, зависит сохранение опыта. Решение проблем нравственного и творческого

развития требует нахождения более действенных путей или пересмотр уже известных.

Эффективным методом в развитии духовно-нравственного и творческого потенциала человека является фольклор, устное народное творчество (сказы, пословицы, присказки, прибаутки, поговорки и т.д.). С помощью них молодёжь знакомиться с миром не только умом, но и душой. Устное народное творчество незаменимо, так как оно развивает любовь к Родине.

Яркие впечатление оставляет и книга Леонида Соловьёва «Повесть о Ходже Насреддине». В шестой главе первой книги «Возмутитель спокойствия», рассказывается о том, как Ходжа Насреддин раздал должникам Джафара все выигранные деньги, чтобы они смогли отдать свои долги, купить лекарства и начать жить спокойно. Раздав деньги, Ходжа Насреддин ни капельки не жалеет о своем поступке, приведи улыбок людей, которым он помог, он забывает о своих желаниях и мечтах: как он хотел купить четыре мастерские, иметь трех жен и стать богатым человеком. Он уезжает, не прося благодарности и даже не представившись. После того как он уехал, люди начинают понимать, что такой поступок мог совершить только Ходжа Насреддин и никто другой, но так как его разыскивают в городе, они решают молчать о его благородстве, дабы не выдать его эмирским шпионам. Желание наказать ростовщика, эмира, всех богатых, которые являются источником всех несчастий всех бедных людей, красной нитью проходит через все произведение.

Ходжа не вытерпев, слез с седла и направился к ростовщику, идя рядом с ишаком. В глазах Ходжи Насреддина вспыхивал чудовищный огонь, когда он просил ростовщика подождать его. Ходжа обещал ростовщику, что его доля будет мучительой, а также предупреждал эмира, чтобы тот, трепещал, так как он Ходжа Насреддин, в Бухаре. Ходжа Насреддин сравнивает власть с жадными гиенами, ему больно смотреть на то, как мучается его народ. Ходжа дает обещание ростовщику, что если не расквитается с ним за все страдания, которые он причиняет беднякам, то пусть его славное имя на веки веков покроется позором.

Восточный народ славится своим гостеприимством, отзывчивостью, состраданием, пониманием и оптимизмом. В давние времена, у простых рабочих людей особых поводов для радости не было, так как люди были погружены в нескончаемые проблемы и заботы, появился национальный герой Ходжа Насреддин, который внешне ни чем не отличался от обычного бродяги, но его ум, проницательность и юмор прославили его не только на востоке, но и на весь мир и не на одну эпоху.

Анализируя жизнь Ходжи Насреддина, мы видим, что это человек - слова, он является примером для подражания, его умение разрешать конфликты, уважение к людям, постоянная борьба за справедливость, желание помочь всем чем только можно и не когда не жалеть о том, что для того, чтобы оказать помощь другим, ни раз приходится забывать о своих желаниях и потребностях.

Принципы жизни Ходжи Насреддина – это наследие для всего человечества, прежде всего для молодежи. Ведь молодежь – это смена старшего

поколения и именно от уровня развития духовно- нравственного и творческого потенциала зависит будущее нашей страны.

Жизнь этого великого человека описана не только в повестях, сказках и рассказах, но и в анекдотах. Вот, к примеру, один анекдот о нём: «Однажды Ходжа и его жена услышали, как в их дом забрался вор. – Ходжа, у нас вор, – взволновано сказала жена. –Тихо, женщина, не спугни его, – отвечал шепотом Ходжа.– Может быть, он найдет что-нибудь стоящее, а уж отнять у него будет легко!».

Анекдоты – это самая распространённая форма речевого творчества среди молодежи. Анекдоты, как и все литературное наследие о Ходже Насреддине способствуют развитию духовно-нравственного и творческого потенциала читателя, так как в них сокрыт глубокий смысл, который понимается со временем, а на поверхности, казалось бы, обычной шутки, мы видим острый ум Ходжи Насреддина и его умение выходить из любой ситуации победителем при этом дав урок своему оппоненту.

Чье-то детство украшали сказки Пушкина, а в чьем-то сердце оставили след незабываемые Сказы Бажова, а для кого-то литературным кумиром остался Ходжа Насреддин, выходец из простого народа, воплотивший в себе все мечты, чаяния простого человека олицетворяющий собой доброту, человечность, желание сделать жизнь бедного человека лучше. В памяти читателя остается его острый ум, добрый и искромётный юмор.

**Литература**

1. Нигматова Л. Х. ЛЕКСИКОГРАФИЯ ТАРИХИДАН ИЗ ИСТОРИИ ЛЕКСИКОГРАФИИ FROM THE HISTORY OF LEXICOGRAPHY //ANIQ VA TABIIY FANLAR. – Т. 93.

2. Шарипов С. С. ОСНОВНЫЕ ПРОБЛЕМЫ ПЕРЕВОДА //Электронный инновационный вестник. – 2020. – №. 3. – С. 7-9.

3. Sobirovich A. S. Lecturer at the Department of Russian Language and Literature Bukhara State University //Scientific reports of bukhara state university. – С. 86.

4. TEMIROVA D. THE PROBLEM OF CLASSIFICATION OF CHILDREN'S GAME FOLKLORE IN THE SPHERE OF COMPARATIVE ANALYSIS //E-Conference Globe. – 2021. – С. 145-149.

## ТУГАН ТЕЛЛӘРГӘ ӨЙРӘТҮДӘ ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ АЛАРНЫ ЧИШҮ ЮЛЛАРЫ

***Шиһапова Г. М., Мөбәракова М. Ф.***
***Казан шәһәр Совет районынын 149нчы лицее***
***mila_mub@mail.ru, gulchachak.shigapova@mail.ru***

***Аннотация.*** В этом докладе мы поделились с опытом работы над проблемами обучения татарскому языку в качестве родного языка. Показали, как мы, используя множество методов и технологий, стараемся решать проблемы в изучении татарскому языку. Лишь некоторые из них мы упомянули в этом выступлении. Ни для кого не секрет, что современные дети и родители не владеют своим родным татарским языком и нет желания изучать. Поэтому наша цель-пробудить у учащихся интерес к родному языку.

***Ключевые слова:*** проблемы обучения, татарский язык, инновационные технологии.

Әгәр башка телне өйрәнергә уйласаң,
туган телнең кагыйдәләрен белү мәҗбүри.
Каюм Насыйри.

Һәр милләт кешесе өчен:
Иң матур көй-милли көй,
Иң матур тел-милли тел.

Бу юлларны тоеп, ләззәтләнеп яшәгән кеше, һичшиксез, бәхетле кешедер. Андый кеше эшләргә дә, укырга да сәләтле була. Ана теле яңгырашы белән колакны назласа, ягымлылыгы белән ул күңелне юата, тәэсирлеге белән изгелек хисләре уята, тәрбияли. Туган тел-ул коммуникация чарасы гына түгел, ә аралашырга, берәрсе белән элемтәләр һәм мөнәсәбәтләр урнаштырырга мөмкинлек тә. Тел ул халык җаны, ата-бабалар белән бәйләнеш, үз-үзеңне аңлау һәм үз-үзеңне билгеләү. Һәр халык үз телен балаларына җиткерү максатыннан кадерли һәм саклый. Тумыштан ук бала туган телнең матурлыгын ишетергә һәм үсә төшкәч тирәнтенрәк өйрәнергә кызыксыну уяныргa тиеш. Шуңа күрә безнең укытучыларның максаты - туган телне , туган әдәбиятны өйрәнүгә балаларыбызны үз халкыбызның иң яхшы традицияләрендә һәм гореф-гадәтләрендә тәрбияләүгә карата кызыксынуны арттыру. Безнең бурыч - балаларны үз илен яратучы, халкын ихтирам итүче, башка милләт вәкилләре белән дустанә мөнәсәбәттә яши ала торган шәхес итеп тәрбияләү. Укучыларны тел мөхитенә чумдырып, без укучының фикерләү, чагыштыру, иҗади анализлау, алган белемнәрне гомумиләштерү сәләтен үстерәбез.

Безнең лицейда төрле милләт балалары укый. Шуңа да карамастан, укучылар туган тел буларак татар телен өйрәнәләр. Балаларны татар теленә өйрәтү-иң катлаулы методик бурычларның берсе. Укучыларны татар теленә өйрәтү мөһим. Беренчедән, укучыларда туган якка, табигатькә мәхәббәт һәм аңа сакчыл караш тәрбияләү, икенчедән, шәһәрнең, республиканың, илнең

тарихи үткәне белән танышу. Шулай ук патриотик хисләр, кече Ватаныбызның үткәненә һәм хәзергесенә хөрмәт һәм горурлык тәрбияләү, кызыклы тарихи вакыйгалар, хезмәт эшчәнлеге, мәдәният, татар халкының көнкүреше һәм бәйрәмнәре белән таныштыру-барысы да татар теле яки татар әдәбияте дәресләрендә үзләштерелә.

Кызганыч, бүгенге көндә татар телен туган тел буларак өйрәнгәндә төрле кыенлыклар белән очрашырга туры килә. Яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартлары белән бергә татар телен укытуга да үзгәрешләр килеп керде. Элек башлангыч сыйныфларда атнасына 6 сәгать бирелсә, хәзерге көндә 3 сәгатькә калды. Бу вакыт эчендә генә баланы татар теленә өйрәтү мөмкин түгел. Ләкин без дәресләр белән генә чикләнеп калмыйбыз. Лицеебыз тулы көн тәртибендә эшли һәм без көннең икенче яртысында балалар белән төрле чаралар үткәрәбез.

Әлбәттә, балага туган тел иң беренче чиратта гаиләдә сеңдерелә. Ләкин, ни кызганыч, әти-әниләрнең күпчелеге татар телендә аралашмый, татар теле кирәк дип санамый. Ата-аналарның рус теленә өстенлек биреп, үзләренең туган телләренә илтифатсыз каравы бик борчый. Шуңа күрә, аларның балаларына татар телен өйрәтү бик кыен. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм башлангыч мәктәптә белем һәм тәрбия бирү буенча ФГОСка таянып, без мәктәптә ата-аналар белән актив эш формаларын кулланабыз. Аларны инновацион эшчәнлек белән таныштыру максатыннан, лекторияләр, консультацияләр, мастер-класслар, презентацияләр конкурслары, дискуссияләр үткәрәбез. Ата-аналарга балаларына ярдәм итү мөмкинчелекләрен тудырабыз. Бүгенге көндә җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләр уку – укыту системасының барлык өлкәләренә дә яңача якын килүне таләп итә. Һәр укучыга шәхси якын килү татар телен өйрәнүгә уңай омтылыш тудыра. Без баланың укуга булган табигый мөмкинлекләрен, кызыксыну даирәсен истә тотып эш итәргә тырышабыз. Укыту – тәрбия системасын яңарту ул – үрнәк белем бирү һәм үрнәк эш программаларына нигезләнеп яңа технологияләр, ысуллар, алымнар, чаралар эзләү. Шуңа күрә без дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда заманча технологияләр кулланып эш алып барырга тырышабыз.

Компьютер – соңгы елларда уку процессына актив кертелгән яңа һәм иң мөһим чараларның берсе. Өйрәнелә торган материалны матур төсләр белән бизәлгән, гади генә, әмма аңлаешлы итеп ясалган күрсәтмәлелектән файдаланып укытырга мөмкинлек бирә. Хәзер балалар китапка азрак мөрәҗәгать итә, аларга компьютер белән эшләү кызыклырак. Укуга кызыксыну азрак булганда, укучыны мультимедиа чаралары белән активлаштырырга, укуга теләк һәм омтылышны үстерергә мөмкин.

Интернет аша татар сайтларына чыгып, андагы мөмкинлекләрдән файдалану өчен мәктәбебездә шартлар тудырылган. Татар телендә презентацияләр, аудио һәм видео күрсәтмәлелектән файдалану мөмкинлеге бар. Татар телен укыту сыйфатын күтәрү өчен укучыларыбыз белән фильмнар, мультфильмнар, интернет-тапшырулар, спектакльләр карыйбыз. “ Сәлам”

сайтындагы материаллар дәресләрне тагын да җанландырып җибәрә. Ләкин бу эштә санитария һәм гигиена таләпләрен истә тоту да кирәк.

Башлангыч сыйныфларда уен технологиясен кулланып эшләү уңай нәтиҗәләргә китерә, чөнки дәрестә өйрәнеләсе материал җиңелрәк үзләштерелә. Уеннар барышында сөйләм телен үстерү белән бергә, балаларның мөстәкыйль фикер йөртү сәләте дә үсә, бала туган теленең матурлыгын тоярга, аның яңгырашын аңларга, яратырга өйрәнә. Уенда бала шәхес буларак формалаша. Уеннар дәресне күңелле итеп үткәрергә, балада кызыксыну уятырга, иң авыр бирелә торган сүзләрне җиңел итеп аңлатырга ярдәм итә. Шуның белән бергә, уеннар балада иң кирәкле әхлакый сыйфатлар: гаделлек, күмәклек, логик фикерләү, мөстәкыйльлек, җитезлек тәрбияли.

Рольле уеннар да тел өйрәнүдә мөһим урын алып тора. Рольләргә бүлеп уйнау балаларга бик ошый һәм нәтиҗәле. Дәресләр җанлы, кызыклы үтә. Балалар, үзләре дә сизмәстән, татар сүзләрен, фразаларын, җөмләләрен күпкә яхшырак үзләштерәләр. Төрле әкиятләрне сәхнәләштерүдә укучылар бик теләп катнашалар. Әле декабрь аенда гына лицеебызда әкиятләрне сәхнәләштерү буенча 1 – 11 сыйныфлар арасында конкурс булып узды. Шагыйрьләр иҗатына багышланган шигырь сөйләү бәйгеләре, төрле тематик бәйрәмнәрне сәхнәләштерү дә телебезне өйрәнүдә ярдәм итә. Бу чаралар балаларны татар телендә аралашырга, сөйләшергә мәҗбүр итә. Сөйләшү – ул аерым сүзлек запасына ия булу, аларны актив куллана белү, үз фикереңне аңлаешлы итеп әйтеп бирү, тирә-яктагы кешеләрнең сөйләмен аңлау һ.б. Боларның барысын да бала мәктәпкәчә чорда олылар ярдәме белән үзләштерә.

*«Балага теләсә нинди 5 яңа сүз өйрәтегез, ул алар белән шактый озак җәфаланачак; әмма шундый ук 20 сүзне рәсемнәре белән бәйләп өйрәтергә уйласагыз, аларны шундук «эләктереп» алачак. Баланы мөгаллимгә якынайтуның иң яхшы чарасы – рәсемнәр күрсәтеп сөйләү»,* - дип яза бөек педагог К.Д.Ушинский. Төрле хәрәкәтләр, рәсемнәр, предметлар күрсәтү, әлбәттә, балаларга материалны үзләштерүдә терәк булып тора. Башлангыч сыйныфларда татарча сөйләм теленә өйрәтүне күрсәтмәлелек кулланмыйча башкаруны күз алдына китерү мөмкин түгел. *«Сөйләсәң онытырмын, күрсәтсәң истә калдырырмын, кызыксындырсаң өйрәнермен»,* - дип юкка гына әйтмиләр.

Халык авыз иҗаты әсәрләрен киң куллану, музыка, җыр сәнгатенә мөмкин кадәр мөрәҗәгать итү бик әһәмиятле. Әкиятләр, мәзәкләрне укып яхшыны яманнан аерырга өйрәнсәләр, җырларыннан илһам алалар. Укучылар белән әкият, табышмак, мәкаль, әйтемнәрне өйрәнәбез. Халык йолалары, традицияләре, фольклор аша бала шәхесендә олыларга карата хөрмәт, табигатькә сакчыл караш, үзара хөрмәт, ярдәмләшү тәрбияләнә. Дәресләрдә балалар өчен язылган вакытлы матбугаттан да файдаланабыз. Класс белән

«Сабантуй», «Салават күпере» журналларына язылабыз.

Мәктәбебез тулы көн режимында эшләү сәбәпле, татар телен туган тел буларак укытуда килеп чыккан проблемалардан чыгу юлын без җиңел хәл итәбез. Беренчедән, без, татар мәктәбе буларак, барлык тәрбия чаралары,

сыйныф сәгатьләре, ата-аналар җыелышлары татар телендә алып барыла, тәнәфесләрдә татар телендә аралашабыз. Икенчедән, укучылар һәм эти-әниләр белән бергә Г.Камал, К.Тинчурин, Г.Кариев, «Әкият» курчак театрларында татарча спектакльләр карыйбыз. Шаян ТВ тапшыруларын даими рәвештә карап барабыз. Лицеебыз укучылары үзләре дә бу тапшыруларда бик теләп катнашалар.

Асылда без, укытучылар, барыбыз да иҗат итәбез. Баланың ак кәгазьдәй саф күңеленә ак нур белән эзләр салабыз. Шул эзләрнең якты, мәгънәле булуы өчен гомеребез буена тырышырга,эзләнергә тиешбез.

**Литература**

1.Харисов Ф.Ф. Татар теле: укыту теориясе һәм практикасы.- Казан: Ак бүре, 2018.- 448 б.

2.Мияссарова И.Х. Отдохнем чуть-чуть: Физкультминутки и сюжетные игры (на татарском языке). – Казань, 1998. – 60 с.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КУЛЛАНУ

***Юнысова С.Г.***
***Казан шәһәренең 4 нче гимназия-интернаты***
***yunusova.sania@yandex.ru***

***Аннотация.*** В данной работе рассмотрена коммуникативная технология, составляющая основу принципов изучения татарского языка и литературы.

***Ключевые слова:*** коммуникативная технология, учебно-методический комплект, цикличность, виды работы.

Мәктәптә татар теле укытучысының эше җаваплы һәм шактый ук катлаулы. Туган тел дәресләре һәм чаралары белән укучыларга мөмкин кадәр тулы йогынты ясарга омтылу укытучыдан киеренке рухи эшчәнлек, тирән белемнәр һәм педагогик осталык таләп итә. Укучыларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, аның аша үсеп килүче яшь буынга патриотик омтылышлар булдыру, сүз ярдәмендә безне чолгап алган табигать һәм иҗтимагый тормышта тулып яткан матурлыкны тою кебек олы хисләр тәрбияләү зарурлыгын да исәпкә алсак, укытучы өстенә нинди җаваплы эшләр йөкләнүен сиземләве кыен түгел. Шуңа күрә дә укытучы гел эзләнә, яңа алымнар, яңа технологияләр өйрәнә. Дәресләрне һәм дәрестән тыш эшләрне кызыклы, җанлы, нәтиҗәле итеп үткәрергә тырыша.

Максатым – укучыларда туган телгә мәхәббәт, аны өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү һәм тирәннән белергә омтылыш тудыру; иҗадилыкны үстерү; сөйләшкән һәм язган чакта һәр әйтелгән һәм язылган сүзең өчен җаваплылык хисе тоярга күнектерү; татар теле туртаында күп белү, аны олылауның, фикерне аңлаешлы, күңелдәге хисләрне матур һәм үтемле итеп әйтеп бирә белүнең һәрбер кеше өчен зарури икәнлеген төшендерү.

Рус телле балаларга татар телен өйрәтү чит телне өйрәтү кебек үк. Ә чит телгә өйрәтү тарихы 100 еллар белән исәпләнә. Шул исәптән укыту методикасы да күп тапкырлар алышынды: басым әле укуга, әле тәрҗемә итүгә, әле аудированиегә, әле бөтенесен бергә кушуга ясалды. Бөтен методлар арасында үзенең гадилеге һәм эффектив булуы белән игътибарны җәлеп итеп торганы “гувернантка методы”, ягъни шул телдә шәхсән аралашу методы. Фәнни телдә әйтсәк, коммуникатив укыту технологиясе.

Коммуникатив укыту технологиясенең нигезен аралашу тәшкил итә. (Е.И.Пассов). Аралашу - чит телгә өйрәтүче бөтен интенсив курсларның асылында ята. Интенсив технологияне болгар галиме Г. Лозанов эшли. Шуның нигезендә күп кенә гамәли вариантлар барлыкка килә.

Ә коммуникатив укытуның теориясен һәм практикасын Г.А.Китайгородская эшли.

Укыту – методик комплекты түбәндәге компонентлардан тора:

1.Дәреслек

2. Укытучы өчен методик ярдәмлек

3.Укучы өчен эш дәфтәре

4. Ишетеп аңлау күнегүләре һәм биремнәр язылган диск

5.Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар,

6.Ата – аналар өчен кулланма.

Укыту – методик комплектның үзенчәлеге шунда: сөйләм эшчәнлеге төрләренә бер – бер артлы түгел, ә параллель рәвештә өйрәтү бурычы куела. Ягъни һәр дәрестә сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре дә катнаша. Аралашу процессы сөйләшү, ишетеп аңлау, уку һәм язу аша оештырыла. Алар арасында төп урынны сөйләшү алып тора. 1 нче сыйныфта дәрес вакытының 70-80% ын сөйләшергә өйрәтү ала.

Рус телле балаларны татар сөйләменә өйрәтү процессында коммуникатив технология циклылыкка корылган. Цикл – уку материалын диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр. Дәрес тибы буенча бу дәресләр ЛКФ, ГКФ, ЛГКК, д\м сөйләм дип атала. Бу дәресләрдә өйрәнелергә тиешле лексик – грамматик материал сөйләмдә мөстәкыйль куллану дәрәҗәсенә җиткерелә, укучылар материал эчтәлеге буенча автомат рәвештә сөйләм этабына чыгалар. Шушы нигездә программада билгеләнгән коммуникатив компетенциягә ирешү күздә тотыла.

Дәреслекләрдә укучыларны җәлеп итәрдәй кызыклы, матур текстлар бар. Аларны сөйләмгә өйрәтү чарасы буларак та, уку техникасын үстерү чарасы буларак та файдаланырга була. Күп вакыттта дәресләр уку, тәрҗемә итү, сорауларга җавап бирү кебек күнегү төрләреннән генә тора. Нигездә текст сөйләшергә өйрәтү чарасы булып торсын учен, укытучы бу текстлар белән ничек эш итәргә тиеш соң? Әгәр дәреслекләрнең эчтәлегенә күз салсак, сөйләшү өчен мәктәп, спорт, кибет, ашханә, һөнәрләр, табигать һәм башка темалар бирелә.Эш төрләре: артык сүзне табу, дөрес сүзләр кулланып, җөмләләрне тулыландыру, рус теленә тәрҗемә итү, тестлар, бирелгән терәк сүзләр белән текст төзү, диалог һәм монолог төзү.

Бүген рус телле балаларга татар телен үзләштерүдә тиешенчә ярдәм итү, аларның тел өйрәнүгә теләген сүндермәү өчен нәтиҗәле чаралар шактый күрелә. Шул максаттан дәрес материалын да, класстан тыш чаралар эчтәлеген дә мөмкин кадәр кызыклырак, мавыктыргычрак итү балаларның белемен, татар телен өйрәнүгә омтылышын арттыра, диалогик һәм монологик сөйләм телләрен үстерә. Укучыларга дәрес – сәяхәт, дәрес – уен, кроссвордлар, ребуслар чишү дә бик ошый. Хәзер без шушыларны карап китәрбез.

Тестлар белән эшләгәндә, һәр укучының да аз вакыт эчендә белемен тикшерергә һәм бәяләргә мөмкин. 8-9 нчы сыйныфларны дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерләгәндә, тестлар белән эшләүгә аеруча игътибар бирәм. Монда укучы тәкъдим ителгән 4 яки 2 җавапның берсен сайлап алырга тиеш.

Сүзләрнең логик парларын табу хәтерне, игътибарны үстерә. Шулай ук сүзнең синонимын да табарга мөмкин.

Артык сүзне табу – укучыларның иң яраткан эш төренең берсе дисәм, хата булмас, чөнки 1 нче сыйныф укучыларыннан башлап, бу эш төрен яраталар. Бу исә үз чиратында хәтерне ныгытуга ярдәм итә.

Дөрес тәрҗемәне табу өчен укучыларның сүзлекләр белән эшләү күнекмәләрен камилләштерү максатын куям. Бу исә үз чиратында күрү хәтерен үстерә.

Сүзләрнең антонимнарны тапканда да хәтер һәм игътибарны үстерү максатын куябыз. Хикәядәге тискәре геройларны уңай геройга үзгәртеп язганда, нәкъ менә антонимнар кирәк.

Төшеп калган сүзләрне куеп язу – иң отышлы алымнарның берсе.Ул укучының игътибарын нәтиҗәле эшчәнлеккә юнәлтә, укучыны активлаштыра. Тулыландыру яки тәрҗемә итү өчен текстлар татар телендә җөмлә калыпларын үзләштерү һәм сөйләм формалаштыруны күздә тота.

Билгеле бер текстны укыганнан соң, гадәттә, укытуны эзлекле итеп оештыру максатыннан, кечкенә текстларны хикәя эчтәлеге эзлеклелегендә язу – телгә өйрәтүдә нәтиҗәле алым.

Телне ятлап түгел, ә актив фикерләп өйрәнү принцибы – чит тел өйрәнүдәге төп принципларның берсе. Укучыларның телне актив фикерләп өйрәнүләрен, беренче чиратта, аралашуны хәтерләтүче ситуатив күнегүләр аша тәэмин итеп була. Мондый күнегүләр яңа лексик, грамматик материал белән таныштырганда да, камилләштерү һәм мөстәкыйль сөйләм этабында да кулланыла ала. Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат – кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе, - тел өйрәнү өчен, күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүри. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шунда ук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа, һәм тел өйрәнү процесының мотивлашкан булуы тәэмин ителә. Ситуатив биремнәр сөйләм (текст) төзергә өйрәтүгә хезмәт итә.

Алдагы эш төре – чуалчыкны чишү (путаница) – игътибарны, үзконтрольне үстерә һәм координацияли.

Хронологик тәртиптә язу өчен укучы өйрәнгәннәрне хәтерендә сакларга яки үзлегеннән күп укыга тиеш дип исәплим.

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтүдә дә аудирование (тыңлап, ишетеп аңлау) нәтиҗәле кулланыла. Гомумән алганда, коммуникатив технологиягә корылган Р.З. Хәйдәрова дәреслекләре белән эшләгәндә, укучыларның диалогик һәм монологик сөйләмнәрен үстерү, татарча текстларны аңлап укырга өйрәнү, әңгәмә корырга, фикер йөртергә өйрәтү кебек максатлар укучыны сөйләмгә алып чыгарга тиеш.

«Укытучының тере сүзен бернинди компьютер да алыштыра алмый» дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Бу сүзләр белән килешәм. Туган тел дәресләрен укучыларны мониторга каратып кына үткәреп булмый. Чөнки дәреснең төрле этапларында урынлы, уйланылып кулланылган компьютер белән эш укучының укытучы һәм сыйныфташлары белән аралашуы һәм башка күп төрле эшләр белән үрелеп барырга тиеш.

**Әдәбият**

1. Пассов Е. И. Основы коммуникативной методики обучения иноязычному общению.- Москва , 1989.

2. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре.- Казан, 2001.

3. Томахин Г. Д. Лингвострановедение. Что это такое?// Ин.языки в школе.-1996.-№6.

4. Харисов Ф.Ф. Научные основы начального обучения татарскому языку как неродному/ Под ред. Л.З.Шакировой.- Казань, 2000.

# МАТЕРИАЛЫ ПО ФОНЕТИКЕ В САМОУЧИТЕЛЯХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА XVШ - НАЧАЛА XX ВВ.

***Юсупова А.Ш.***
***Казанский федеральный университет***
***alyusupova@yandex.ru***

***Аннотация.*** Как известно, необходимым условием развития коммуникативных навыков и умений является овладение навыками правильного произношения. Общение не представляется возможным без овладения произносительными навыками, так как нарушение произносительных норм существенно затрудняет процесс коммуникации. Фонетический уровень языка тесно связан с другими языковыми уровнями, а фонетические единицы детерминируют лексические и синтаксические единицы. Учет этого факта определяет коммуникативный подход к обучению произношению, в котором учитываются как формальный, так и функциональный аспект овладения фонетическими навыками. В этой связи перед авторами самоучителей татарского языка XVШ-начала XX вв ставились две основных задачи: с одной стороны, необходимо дать учащимся представление об артикуляционных и произносительных характеристиках татарских фонетических единиц, а с другой стороны, важно было обеспечить усвоение учащимися смысловой наполненности тех или иных фонетических явлений, а также речевых функций фонетических единиц

***Ключевые слова***: фонетический уровень, звуковой состав, алфавит, татарский язык, XVШ-начала XX вв

При обучении языку необходимо заложить правильные основы знаний об устройстве и закономерностях звуковой стороны языка. Закономерности устной формы языка и речи открываются в связи с изучением фонетического и орфоэпического материала, письменной речи в связи с графикой и орфографией. Изучение звуковой и буквенной формы слова происходит в начальном этапе изучения языка. С изучением звуков тесно связано изучение и таких явлений звуковой стороны языка, как ударение, слог и интонация. Фонетические знания и умения необходимы не только для понимания речи, но и для обучения говорению. Это касается, в частности, произносительных норм, соблюдение которых необходимо для того, чтобы коммуникативная деятельность происходила без помех.

Перед самоучителями татарского языка конца XVШ-начала XX вв стояла задача помочь изучающим язык овладеть первоначальными фонетическими и фонологическими знаниями татарского языка и умениями, чтобы дальнейшее обучение не доставляло трудностей. Без фонетики невозможно научить лексике, грамматике. Фонетическая подготовка - основа преемственности в обучении языку.

Фонетические навыки включают себя такие операции как: дифференциация фонем, их вариантов и инвариантов в речевом потоке; выделение словесного, фразового и логического ударения, интонации в

предложении. К фонетическим навыкам относят еще расчленение речевого потока на синтагмы в опоре на ритмико-мелодическую организацию предложения, вычленение главного и второстепенного в сообщении в опоре на логическое ударение и паузацию, а также распознавание коммуникативного типа предложения по его ритмико-мелодической организации

Овладение навыками правильного произношения является необходимым условием развития навыков и умений во всех входах речевой деятельности. Без произносительных навыков невозможно никакие коммуникативные умения, т.е. невозможно общение на изучаемом языке.

Для начинающих изучать татарский язык сложность при изучении татарского алфавита основанного на арабской графике и татарской фонетики заключалось в том, что почти все буквы татарского алфавита обозначают несколько разных звуков

